ISSN 0206–4189
Индекс 73210
12+

# КАЗАН УТЛАРЫ

4.2013



# ТАТАРСТАН ГИМНЫ

*Рамазан БАЙТИМЕРОВ сүзләре,*
*Филипп ПИРАЕВ тәрҗемәсе*

**Мәңге яшә, газиз Ватаныбыз,**
**Халкым теле изге теләкләр!**
**Гомерлеккә якын туган булып**
**Яши бездә төрле милләтләр.**
**Күп гасырлар кичкән чал тарихлы**
**Данлы илем, үзең бер дастан!**
**Синдә генә безнең язмышыбыз,**
**Республикам минем, Татарстан!** } *Ике тапкыр*

**Цвети, священная земля моя,**
**Да будет мирным твой небосвод!**
**Единый дом у нас, одна семья,**
**Живет в согласии наш народ.**
**Богатый мудростью седых веков,**
**Надеждой, верою ты нам стал,**
**И пусть хранит тебя моя любовь,**
**Моя Республика, мой Татарстан!** } *Два раза*

Моннан егерме ел элек Татарстан Республикасының Дәүләт гимны кабул ителгән иде. Әлегәчә гимн Рөстәм Яхин музыкасына сүзләрсез генә башкарылып килende. Быелның 21 февралендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы IV чакырылышның 38 утырышында ТР Дәүләт гимны текст белән кабул ителде. Гимнның расланган тексты – шагыйрь Рамазан Байтимеров шигыре, аның нигезен 1970 елларда композитор Рөстәм Яхин язган «Туган илем» җыры тәшкил итә. Шигырьнең төп җыр тексты, конкурс комиссиясе теләкләрен искә алып, беркадәр үзгәртелә. Шигырьне Гәрәй Рәхим гимн таләпләренә туры килерлек итеп эшкәртә, ә Филипп Пираев русчага тәрҗемә итә. Шулай итеп, ТР Дәүләт гимны тексты татарча һәм русча 8әр юл булып чыга һәм ул рәсми чараларда, тантаналы утырышларда һәр ике телдә башкарыла.

Казан утлары
Qazan utlari

2013

4
(1086)

*ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:*
*«ТАТМЕДИА»*
*ачык акционерлык җәмгыяте*

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Рәдиф Гаташ**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Айрат Сибагатуллин**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Марат Закир, Әлфәт Закирҗанов, Камил Кәримов.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир — 562-10-62.*
*Баш мөхәррир урынбасары — 562-10-38.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге — 562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге — 562-11-53.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге — 562-11-53.*
*Гамәли хезмәткәрләр — 562-11-28.*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80.*
**Факс** — (843) 562-11-28.
**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда


**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА. Үзем генә беләм... *Бәян.* ....5
Халисә МӨДӘРРИСОВА. Безгә инде язлар кагылмаслар... *Шигырьләр.* ....67
Рифат СӘЛАХ. Җиһанның бар яктылыгы үзгә... *Шигырьләр.* ....85
Рашат НИЗАМИ. Сүзгә – мәрхәбә! *Эссе.* ....89

**ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ**

Марат ЗАКИР. Иңнәреңдә канат барда... ....72
Илүзә ГАЙНЕТДИНОВА. Өмә. *Хикәяләр.* ....73
Алмаз МАНСУРОВ. Дога. *Хикәя.* ....78

**ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ ВАФАТЫНА 100 ЕЛ**

Мәҗит ГАФУРИ. Г.Тукай вафатыннан соң. *Шигырь.* ....117
Индус ТАҺИРОВ. Тукай – мәңгегә халык күңелендә. ....118
Идрис ГАЗИЕВ. Тукай әсәрләре – граммофонда. ....126

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Наил ШӘРИФУЛЛИН. Без бетәбез инде, сез каласыз. ....134

**ФӘН**

Раиф МӘРДАНОВ. «Кыз хикәяте» кыйссасы. ....140
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ....155
«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ....158

**СӘНГАТЬ**

Алмаз ХӘМЗИН. Шәрәфине сөйләштерү. ....161

**ХӘТЕР**

Таһир ГЫЙЛАҖЕВ. Фидакарь затлар онытылмый *(Ибраһим Нуруллинның туууына 90 ел).* ....165

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Фәрит СОЛТАНОВ. Фән һәм дин берлеге. ....170

**ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР**

Флёра ТАРХАНОВА. Укол. ....172

**ШӘХЕСЛӘР ҺӘМ ШӘРЕХЛӘР**

Госман ГОМӘР. Өч борынга – бер һәйкәл. ....184

«Казан утлары» архивыннан. ....188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: повесть Н.ГИМАТДИНОВОЙ «Знаю я один»;
эссе Р.НИЗАМИ «Хвала слову»; стихи Х.МУДАРИСОВОЙ, Р.САЛАХА.
«Творчество молодых»: рассказы И.ГАЙНУТДИНОВОЙ «Субботник»,
А.МАНСУРОВА «Молитва».
«100 лет без ТУКАЯ»: стихотворение М.ГАФУРИ; статьи И.ТАГИРОВА
«Тукай бессмертен для народа», И.ГАЗИЕВА «Произведения Тукая в граммофонах».
«Публицистика»: статья Н.ШАРИФУЛЛИНА «Как мы живем?»
«Наука»: Р.МАРДАНОВ. «Кисса «Девичий рассказ»;
Ф.ГАРИПОВА. «История наших деревень».
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Искусство»: беседа А.ХАМЗИНА с актером Р.ШАРАФИЕВЫМ.
«Память»: статья Т.ГИЛЯЗОВА, посвященная 90-летию со дня рождения
И.НУРУЛЛИНА.
«Книжное обозрение»: Ф.СУЛТАНОВ. «Содружество науки и религии».
«Рассказы из жизни»: Ф.ТАРХАНОВА. «Укол».
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Апрель»; поэт Фарит ГАБДРАХИМ.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: story by N.GUIMATDINOVA «Just I Know it»;
essay by R.NIZAMI «Praise the word»; verses by H.MUDARISOVA, R.SALAH.
«Creativity of youth»: story by I.GAYNUTDINOVA «Community work day»,
A.MANSUROV «Prayer».
«100 years without TUKAI»: poem by M. GAFURI; article by I.TAGUIROV
«Tukai is immortal for people», I.GAZIEV «Works of Tukai in gramophones».
«Journalism»: article by N.SHARIFULLIN «How do we live?»
«Science»: R.MARDANOV. «Kissa «Girl's story»;
F.GARIPOVA. «History of our villages».
Pages of «Tatar encyclopedia».
«Art»: interview of A.HAMZIN with actor R.SHARAFIEV.
«Memory»: article by T.GUILYAZOV dedicated to 90th anniversary of I.NURULLIN.
«Book review»: F.SULTANOV «Concord of science and religion».
«Stories from life»: F.TARKHANOVA. «Sting».
From photo archives of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: April; the poet Farit GABDRAKHIM.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән китКән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмахананең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 02.04.2013, график буенча 02.04.2013.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С-734. Тираж 4017.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААЖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2013 ел.



Нәбирә Гыйматдинова

# ҮЗЕМ ГЕНӘ БЕЛӘМ...

БӘЯН

## I

«Быел көз озын килә, туфракта җәй җылысы кала, язны көт, чәчмә, дигән идем, тыңламадың, улым... Әнә, ужымнарың урыс сакалы кебек нинди килбәтсез. Кар астында кышламый алар, тунып үлә. Басуны әрәм иттең, улым...»

Ник бу ата сагышы бәгырьгә үтеп, яндыра-көйдерә икән? Төшләренә кереп, аның һәр ялгышына төртеп күрсәтмәсә, бүтән кайгысы юк микәнни?! Рас, җәннәттәдер агроном Сөләйман. Җаныннан да артыграк күреп җир яраткан кешегә Ходай оҗмах капкаларын киереп ачып куйдыр һәм анда хәсрәт дигәнең борын очын да тыгалмыйдыр. Фанилыкта ул — хәсрәт дәрьясы. Аның тобасы монда.

Быел Гафур беренче тапкыр көзге бодай чәчте. Бик кыйбат сортын юнәтеп, орлыкны туфракка күмгәндә аның баш миендә берсеннән-берсе шәбрәк фикерләр туган иде. Җире күпереп пешкән мич ипие кебек йомшак, кулыңны тыксаң — терсәктән үк бата. Әтисе шикелле үк, ир учында иләгән туфракны ялады. Тәмле иде җир! Кыскасы, затлыдан затлы яралган төсле, «зыялы» орлыктан мул уңыш чыгачак һәм Гафур, бодайны суктырып-җилләтеп, амбарга тутырачак иде. Икенче язда кыр-басуларны тагын да күбрәк колачлар ул, боерса. Ирнең куены зур, анда Чыпчык, Тургай, Сандугач басулары — һәммәсе-һәммәсе дә сыяр. Аннан, тау-тау алтын бөртекләренең ярты өлеше матур гына төзелеп яткан тегермәнгә китәр. Он тарттырыр Гафур. Хатын-кызлар соңгы чорларда уңдырып-уңдырып ипи салуның ни икәнен дә хәтерләми. Алар өчен күмәч кибет киштәсендә пешә. Менә Гафур урмандагы чикләвек куакларына уралган колмакны җыйдыртып, шунардан чүпрә кайнатып, тегермән онынннан ипи салдырыр. Әй, таралыр авыл урамнарына хуш исле икмәк исе!

Их-ма, ялгышты ир. Тәҗрибәсез яшь бүре сыман эзне дөрес алмады. Бодай орлыклары да ялгышты, җәй бу дип алданды. Әнә, мәрхүм атасының рухы шуңа борчыла. И әйтәләр, андагылар белән җирдәгеләрнең арасы өзек, диләр. Алайса, агроном Сөләйман нишләп төшләр аша шелтәли икән, ә?

---

Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА – *язучы, «Бер тамчы ярату», «Ут күбәләге», «Мәхәббәттә гөнаһ бар» һ.б. китаплар авторы. М.Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты. Казанда яши.*

...Таң әтәчләре уяна башлады. Туган апасы Мингайшә былтыр аңа кикриге бүрек хәтле әтәч китергән иде. «Энем, монын тавыкларга мәхәббәте көчле, усал дип әгәренки суйма!» — диде карчык. Мал хуҗасына охшый ди, әтәч тач Мингайшә кортка иде. «Бүрек кикрик» авыл агайлары сыман берике көн башын кыңгыр салып, мыштым гына биләмәсен өйрәнде-күзәтте дә, тәртип урнаштырырга тотынды. Хуҗалыкта туксан тавыкка ун әтәч иде, «бүрек кикрик» башта көндәшләре белән мөнәсәбәтләрне ачыклады: һәркайсын тибеп егып, корсакларын чукыды. Янәсе, җиңелегез дә, миңа буйсыныгыз! Янәсе, биредә хәзер мин баш, мин түш! Җим тагарагына «ир кавемнәре» соңыннан, «тавыкбикәләр» туенгач кына якыная, чөнки туендыручы «халык» әүвәл гаиләсен кайгыртырга тиеш. Иртән «кикрикүк!» дип дөньяга яңа көн тууы турында апасының әтәче генә шар яра, кем дә кем шул законны боза, «бүрек кикрик» аны кетәклек тактасыннан канаты белән сугып төшерә иде. Әнә, тамак төбен гырылдатып ничек кычкыра! Ә бүтәннәре нәзек тавыш белән кыяр-кыймас кына аңа кушыла.

Яктыргач, Гафур, киенеп, ишегалдына чыкты. Әйтерсең җәй уртасы, чирәмдә чык тамчылары җемелди. Их-ма, ялгышты шул! Оялчан киленнәр кебек чаршау артына поскан җәй каенатасыннан тел яшерәмени! Үз хокукынны даула инде, җебегән. Дауласа ни хәзер. Терлек ашатыр идең, ун баш тана белән ун сыерга бигрәк зур мәйдан. Авыл көтүе өчен үтергән дә бит, бүген Җиде Чишмәдә мал сирәк кеше асрый.

— Кәк-күк, кәк-күк...

Ир муенын каерып нарат агачына карады. Монысы нинди хикмәт тагы? Нинди җүләр кәккүк таң белән моңлана?

— Кәк-күк, кәк-күк...

— Көш! — диде ул, усал гына. — Көш, сантый! Санама монда юклыбарлы гомерләрне. Әти дә шулай кайтты берсендә. Урманда кәккүктән юраттым, ике генә ел яшисе икән, диде. Яшәде нәкъ синеңчә. Көш!

— Кәк-күк, кәк-күк...

Нарат җәй белән көзне бутамаган бердәнбер зирәк агач иде. Ул ылысларын сәлә генә сары төскә мандырып койган һәм аның шәрәләнгән ботакларын әкрен генә җил кага иде. Кош кайдадыр бүтән куакта.

— Кәк-күк, кәк-күк...

Мунча ишегендә күрше хатыны Сәлимә күренде.

— Кәк-күк, кәк-күк! Кичә юынганда телефонымны оныттым, хәтерсез!

— Син икән. — Гафур ялангач күкрәген томалап күлмәк сәдәфләрен каптырды. — Артистның кызык инде аның, каркылдаса — карга, күкелдәсә — күке.

— Әй, нинди артист ди мин! Гомерем театрның тегү цехында узды. Шәрәфиләргә, Таҗетдиннарга сәхнә киемнәре тектем. Бер генә спектакльдә уйнатты мине Марсель ага. Анда шундый күренеш бар иде. Егет белән кыз парлашып урманда йөри. Егет сөйгәненә мәхәббәтен аңлатам дигәндә генә күке аваз сала! Кәк-күк, кәк-күк... Исәнмесез, бу мин инде. Чын күкеме, ялганмы, билләһи дим, тамашачы аермый иде. — Сәлимә иңбашларын сикертеп көлде. — Халык артисты исемен генә бирмәделәр, шайтан алгыры, күке роле өчен! Сиңа да костюм әтмәллим, Гафур. Америка фермерлары киеме сиңа килешер иде, ә? Кин кырлы эшләпә белән, ә?

— Түбәтәйле татар агае гына булып торыйм, кем... Апа! Сәлимә апа! Мин синнән сигез яшькә олырак, күршекәем.

Сәлимә атна-ун көн инде авылда кунаклый иде. Гаҗәп, Җиде Чишмәгә ничә дистә еллар аяк басмаган иде ул. Хуҗасыз гына муртайган өйләре үзеннән-үзе шыкаеп-бөкрәеп җиргә табан авышты, каралты-куралары

череде, кара мунчалары ишелеп, үлән-куак басты. Йорт аягүрә килеш үлепбетеп ята иде. Хатын мона илтифат итмәде бугай, зарланмады. Мунчага ул Гафурларга ияләште. Көн дә яксын, җәлмени! Тик бер генә нәрсә эчне пошыра иде. Кайчан Казанга кыяклый икән ул? Батырып кына сорарга кыен. Сорамыйча да ярамый.

— Озаккамы? — диде ир, галушы белән чирәмне ышкып. Җир дымсу иде.

— Ай, сөйләндереп эшеннән бүлдерәм икән, Гафур! Терлекләренне кара син.

— Туктале, Сәлимә апа, авылда озак торасыңмы?

— Минме? Озак, күршекәем, озак. Үлгәнче нигеземдә яшим дип кайтуым бит. Улым өйләнде, ике бүлмәле тыгыз фатирда бишәү идек без! Таш ызбаның ни сулар һавасы, ни иркенлеге. Яшьләр үзләренчә кыландырсыннар, дидем. Иң курыкканым — күршеләр исән микән иде. Аллага шөкер, саулар! Күрше бит ул туганыңнан да якынрак. Менә сикерәм дә керәм бит әле сезгә ауган койма өстеннән генә. Синең өчен мин бик шат, Гафур!

— Мин дә, — диде Гафур, тыенкы гына.

— Без үскәндә син ут борчасы идең. Бөтен шөгылең — әтиеңнең мылтыгын чәлдереп, шарт та шорт тилгән ату иде. Сине күрсә, урмандагы куяннарны бизгәк тоткандыр, әйеме? Бәракалла, син бүген — фермер икән. Хуҗалыгың колхоздан әз генә кайтыш, күршекәем.

— Сәлимә апа, болай иде, — ир су буе сүз дилбегәсен кыскартасы итте. — Уң яктагы Нургали бабайларның йорты ябулы, аның кызы Хәнифә апа аргы ярда кияүдә. Мин анарга, бәрәңге бакчагызны вакытлыча кулланыйм әле, налогын үзем түләрмен, дидем. Биш куллап риза, диде Хәнифә апа. Мин ул якта койма белән әйләндереп таналар яптым, ә синекендә — сыер утары иде. Гафу ит, шәһәрдән эзләмәдем сине. Юкса театрда эшләгәнеңне дә ишеткән идем. Җиде Чишмәгә бүтән кайтмассың кебек иде. Язга бакчаңны әрчим, Сәлимә апа. Бәрәңге чәчәрлек итеп сөреп тә бирәм.

— Кәк-күк, кәк-күк, Гафур! Ялгыз башкайларыма утыз сутый җир ниемә миңа! — диде хатын. — Авылы белән буш бакчалар, теләсә кайсына ике чиләк бәрәңге утырт! Рәхәтен генә күр, зинһар! Бай күршеләрдән акмаса да тама әле ул.

— Алланың рәхмәте яусын, Сәлимә апа.

— Кая, телдән килешү төзелде дип кулга-кул сугышыйк, — диган генә иде хатын, капка шыгырдады.

— Оятсыз! — Чиләкләр аскан Мингайшә апасы Сәлимәгә акайды. Ул аны өнәми иде. — Монда кайтып ирләр аула тагы!

Хатын очып килеп аның чиләкләренә ябышты.

— Сөт аерттың мәллә, Мингайшә апа? Каймагы куемы?

— Сиңа дигән каймак сыер койрыгы астына каткан, оятсыз! Менә, энем, яхшы чиләкләр, сөтне әчеттерми алар.

— Эмальме, апа? — диде Гафур.

— Имилированный, — диде апасы, «дөреслэп». — Сыерларны саварга вакыт!

— Апа, мин Сөнчәледә ике хатын белән сөйләштем, хәзер...

— Аптөшмә! Үзем гөбердәтеп савам! Ун сыер малмыни миңа! Әй, син, Хәмит кызы, сезнең кушаматыгыз күке идеме әле?

Елан карчык! Берәрсенә чакмаса, үз агуыннан үзе агулана! Ләкин Сәлимә аңа ачуланмады.

— Әйе, күке! — диде һәм, «кәк-күк» дип үртәп, өйләренә китте.

— Их, апа, апа, — диде Гафур, шелтәләп.

— Һаман апа да апа! — Мингайшә кортканың зәһәре кузгалганда ике каш арасындагы сызыгы тирәнәя иде. — Күкеләр нәселендәге кыз-катыннарның барчасы да ихахай-михахай иде. Төлке күк хәйләкәр үзләре. Бусы бай дип синнән акча суырмасын. Йортыңнан биздер, ату җилкәңә атланыр. Давай сөт, дияр, давай ит, дияр, син фирмыр дияр. Әнә бит, каймак дип авызын чәпелдәтә.

— Тар күңелле син, апа. Шәһәрнекеләр сөт-каймак ашамый, зарарлы холестерин күбәя, диләр.

— Иртән һәйбәтләп арыш ипиенә каймак ягып чәй эчтем әле менә. Халыстирин дигән җанварыгызга төкердем! Яклама күке кызын! Әллә... — Карчык күзләрен чекерәйтте. — ... бергә йоклыйсызмы?

— Апа, әкрен, Гүзәлия ишетер!

— Ишетмәс. Катының төн ката шигер-мигер язып, иртән үлек йокысы белән йоклый ул! И Алланың берлеге, анысы да бетәшкән җан, — дип уфырды кортка. — Хуҗалыкта салам бөртеге дә селкетми. Тәрәзә төбендәге чүлмәк гөле! Су сипмәсәң — яфраклары шәлперәя. Кемгә өйләндең соң син, ахмак энем?! Шушы ике метр буең, куна тактасы шае җилкәң, көрәк кадәр кулларың белән чебеш хәтле генә катын алдың, адәм ыстырамы! Битеңә чәпәп әйткәч, ошатмадың. Мин аны ат төсле арбага җигеп, йөк ташытырга җыенмыйм, дидең. Чын катын, беләсеңме, нинди? Менә безнең сымак ул. — Мингайшә апасы күркәдәй кабарынды. — Без яшь чакта кибеттә ипигә чират иде. Халык дингезен күкрәгем белән ерып, юл ача идем үземә. Беренче буханка минеке булмаса — тамагымнан үтми иде. Гайрәтле идем мин! Сука белән җир сөрә идем. Җен куәте бар иде миндә!

Гафур очындык апасына төрттереп:

— Җизни нинди иде соң безнең? — диде.

— Нинди иде? Шундый иде. Настояшни ир иде.

— Апа, ул кәтәнә иде бит, синең кендегеңнән генә иде. Кунакта-мазарда исерсә — син аны капчык кебек култыгыңа кыстыра идең бугай.

— Ыржайма! Бидоннарыңны әзерлә, — дип, апасы дак-док басып абзарга юнәлде.

Ничек кенә орышса да әтисенең сеңлесен ярата иде Гафур. Җан тартмаса — кан тарта ди. Әнә бит, һәр иртә килеп, хуҗалыкта кайнаша. Чынлап та, җен куәте бар үзендә, дистә сыерны ялт кына савып, сөзеп, савытларга тутырып, машина әрҗәсенә төяшә. Ул гынамы, кош-кортларга бодай бөртерә, бозауларга апара җылыта, оядагы йомыркаларны барлый. Аның хәтта ки исәп-хисап дәфтәре дә халат кесәсендә иде. Көненә ничә литр сөт савылган, күпме йомырка җыелган — барысы да саннарга күчерелеп куела иде. Атасының кавеме шулай эшкә батыр иде шул. Ләкин ир затларының гомере генә ташка үлчим иде. Гаҗәп, авырмыйча-нитмичә җир җимертеп эшләп йөргәндә генә алар кинәт кенә, киселгән агач төсле, гөрселдәп ава иде.

...Бидоннарны әрҗәгә тезгәч, кузгалам дигәндә генә Сәлимә йөгереп килде. Хатын чәчләрен күпертеп ясаган, зәңгәрсу плащ кигән иде.

— Син үзәккәме, күршекәем? Заводка сөт илтәсеңме? Шәрбәнбану чатына кадәр юлдашың итсәнә!

Олы юл басу кырыеннан үтә иде. Ужымга төренгән кырлар тагын йөрәккә пычак кадады. Их-ма, ялгышты Гафур!

— Искиткеч, — диде Сәлимә, басуга ымлап. — Яшел — җәй күрке.

— Кызганыч, — диде ир, рулен чытырдатып кысып. Театр сәхнәсендәге ясалма тормышны күреп чынбарлыктан ераклашкан хатын бу матурлыкның зур фаҗига икәнлеген аңламый иде, билгеле.

— Әле дә атасыңмы, Гафур?

— Әз-мәз, урманда, чикләвек коелсын өчен генә.
— Тилгән дә юк, ахры, хәзер.
— Сирәк.
— Мылтыгынны гел янында йөрт, Гафур.
— Нигә, Сәлимә апа?
— Казандагы бизнесменнарны бик еш үтерәләр. Саклан, Гафур.
— Мин бизнесмен түгел, Сәлимә апа. Гап-гади жир малае кемгә кирәк?
— Алай димә. Син кулак. Батрагың берәү генә — Мингайшә апа гына анысы.
— Жиде Чишмәдә эшсез хатын-кызлар байтак, Сәлимә апа. Тагын унбиш сыер кайтартам, миниферма ясыйм, әйдәгез, сыер савыгыз, хезмәт хакы түлим дим, ә алар киреләнәләр.
Сәлимә алгы көзгегә муенын сузып чәчен рәтләде.
— Онытма, мине Шәрбәнбану чатында төшер. Киреләнәләр дисеңме? Үзләре акча юк дип балавыз сыга. Хурланмыйча Сөләйман малаена ялланаммы соң диләр алар, күршекәем. Авылда халык әллә ялкауланган, әллә эреләнгән. Хатының хужалыкта бер дә булышмый, ахрысы.
— Аңа авыр эш ярамый, Сәлимә апа.
— Йа Аллам, чирле мәллә?
— Юк, сәламәт.
— Әтү?
— Тәрәзә төбендәге чүлмәк гөле ул.
— И бигрәк матур чагыштыру! Гөленә сокланып карап кына торасын икән, алайса. Шәһәр кызлары иркә шул. Авылныкылар төсле каешланмаган. Туктат, яме, күршекәем.
Хатынның аягында табаны яссы туфли иде. Гафур утыргыч астыннан резин итекләр алып, аңа сузды.
— Мә, Сәлимә апа. Шәрбәнбануга асфальт түшәлмәгән, янгырдан сон юл пычрак. Жинел машина бата хәтта. Сигез чакрымны жәяү генә тәпилисе әле сиңа. Бу авылда ни йомышың бар?
— Шунда... берәүләр кил дигән иде, — диде Сәлимә, жәелмичә генә.

## II

Жәелмәде шул. Чөнки жәелерлеге юк иде. Бүген анын тормышы тоташ ялганнан гына гыйбарәт. Сукбай Сәлимә. Урамга аны маржа килен сөрде. Киемнәрен бүктәре белән подъездга чыгарып бәрде. Ә монда хатын күршеләренә матур ялганнан челтәр үрә: имеш, таш ызбаның ни сулар һавасы, ни иркенлеге юк. Яшәсеннәр яшьләр үзләренчә, имеш.
Килен белән каенана башта ук ярашмадылар. Ерак юлларда йөк ташыган улы аны машинасына утыртып кайтты. Мотельдә танышканнар, янәсе. Рязань кызы, беренче онык тугач та, аны Бауман урамындагы чиркәүдә чукындырып, поптан Анастасия исеме куштырды һәм баласының муенына алтын тәре асты. Улы Фәрит командировкада иде, ана зар елагач, әти кеше «хата»ны «төзәтте»: «Синенчә дә булсын», — дип, өйгә мулла чакыртып, колагына «Әнисә» дип кычкыртты.
— Әни, тынычландыңмы? — диде аннары. — Онығың мөселманга әйләнде.
— Юк, улым, сабый ни насара, ни мөселман түгел, анын дине күк белән жир арасында эленеп калды, — диде Сәлимә һәм шуның белән улының ачуын гына кузгатты.
— Сиңа алай да кыек, болай да кыек, әни! Син юри Варварага каныгасың!

Икенче онык — малай мәсьәләсендә дә Сәлимә килен белән тартышты. «Монысының исеме митрикәсендә үк татарча язылсын», дип җан талаша торгач, яшьләр Сәфәр дип атадылар. Берничә айдан хатын сабыйның туу турындагы таныклыгына юлыкты. Нигәдер Варвара аны матрас эченә яшергән иде. Укыса... күз аллары караңгыланды. Оныгы Сергей Фәритович Минханов иде.

— Ник син безне алдадың?! — диде Сәлимә, марҗа киленен буар дәрәҗәгә җитеп. — Ник син татар балаларын мыскыл итәсен?!

— Кем татар?! — диде килен, ирен чите белән генә көлемсерәп. — Минем кызым белән улымның милләте — урыс.

— Фәриткә әйтеп, Фәриткә... — Сәлимәнең тыны капты. — Кудыртам Рязанена!

— Посмотрим, — диде килен. — Кем-кемне куар.

Улы хәсрәт хатынының кубызына бии иде. Анасын якламады Фәрит, үзең гаепле, телләшмәскә иде дип, ишекнең йозакларын алыштырып ук куйды. Келдер-келдер кием теккәндә, мөгаен, Сәлимә җепкә кушып бәхетен дә теккәндер инде, һай! Уналты яшендә якташы, артист Хөснулла Минханов белән кавышкан иде ул. Ир кисәге гастрольләрдә дә уйнады, берьюлы хатыннар белән дә шаярды. Фәриткә өч ай иде, хыянәт әчесеннән үте сытылган Сәлимә хәләле белән хушлашты. Икенче ире белән дачада танышты. Бәлки, ертыкка ямаулык булып, матур гына яшәп тә китәрләр иде, үсмер Фәрит үги атасы Фиргатьне яратмады. Бала хакы дип анардан да өзелде ул. Хөснулланың дүртенче яры — азау ярган тәҗрибәле хатын иде, ирен бала белән күмеп, койрыгын бозга катырды. «Өйдә алты тамашачы, безгә генә кәмит күрсәтерсен», — дип, театрдан да куптарып алды. Хөснулла Минханов талантлы артист иде, әллә сәхнәдән аерылуны авыр кичерде, әллә йөрәк тамырлары нечкәргән иде, ике тапкыр инфаркт булган ди үзенә әнә. Фатирыннан куылып, театр белән дә саубуллашкач, Сәлимә: «Бәлки соңгы тапкыр күрешәбездер», — дип аларга сугылды.

— Кер, — диде коры гына хуҗабикә. Көндәше кия-кия төсе уңган күлмәк төсле таушалган иде. – Ару гынамы?

— Аллага шөкер, Бәрия. Сез ничек?

— Абзаң залда, яме.

Җилләтелмәгән бүлмәдә тынчу иде. Авыр истән тыгызланган һава күзне әчеттерде.

— Исәнме, Хөснул? — Сәлимә диванга ярым янтайган шәүләгә якынайды. — Ни хәлләрдә син?

Ир элек дастан иде, ә хәзер аны, әйтерсең, учка кысып кечерәйткәннәр, ул илаһым бәләкәй, илаһым ябык иде. Агач төсле адәм баласы да кибә-корый икән. Хөснул аны таныды. Өч бөртек сирәк керфекләре яшьләнде.

— Абзаң телсез, — диде хуҗабикә-көндәш. — Үзең генә сөйлә.

— Балаларыгыз кайда соң?

— Үстеләр дә, таралыштылар, — диде хуҗабикә-көндәш һәм аш бүлмәсенә кереп югалды.

— Синең белән минем малай — Фәрит өйләнде, — диде Сәлимә. — Ике оныгың бар синең. И шаяннар, и наяннар. Сергей, әйем лә, Сәфәр нәкъ син Хөснул. Синеке сыман кашлары калын.

Ир, сөенеченнән, балалар кебек гүелдәде. Әй Аллам бер генәм! Шушы гарип бәндәнне ничекләр яман хәбәр белән яңаклыйсың ди! Әйдә, матур ялганынны сиптер дә сиптер инде.

Хатын йөзендәге елмаюын сүндермәскә тырышты:

— Фәрит хәлемне белми дип ачуланма, юлда ул, гел юлда. Себердән әйбер ташый супермаркетларга. Хәзер бит яшьләргә эш дигәннәре катлаулырак,

хуҗалары һәр минутын тикшерә, джи пи эс навигатор беркетәләр машиналарына. Синекеләр бишесе дә кыз бит әле, Хөснул? Кызлы кеше — бәхетле кеше инде. Биш киявен биш яктан «бабай» дисә, күнелледер ул. Ә Фәритең — нәсел дәвамчысы инде, Хөснул.

Ирнен тоныксу күзләре җанланды. Ул кинәнә иде.

— Ни диим тагын? Терел син. Менә мин... — Хыянәтче тавыш, ник калтырыйсың, йә? — Мин авылга китәм, Хөснул. Бөтенләйгә. Балачак нигеземә. Шулай, әйе. — Хатын ирнен күкрәгенә бакты. Башын төртеп әрни-әрни елар иде дә, тарайган шул монын күкрәге, тарайган... — Әтиләр йорты аякта, Хөснул. Шәрбәнбануда әниең исәнме соң әле?

Ир телен әвәләп, нидер әйтмәкче иде дә, сүзләре ирен кырыена аккан селәгәе белән буталды.

— И-и-ис-и-и...

— Исәнмени? Олыгайгандыр, әйеме?

Хөснулла «а-а» дигән авазлар чыгарып, күзе белән диван япмасына ишарәләде.

— Нәрсә, Хөснул? Дарумы? Хәзер, — диде хатын һәм япма кырыен күтәрде. Анда бөгәрләнгән мең тәнкәлек акча ята иде. Ир мөгрәде:

— М-ә, ә-ә...

— Бу акча әниенә дисенмени?

— Ы-ы-ы, — дип җөпләде Хөснулла.

— Бүген үк, шушы сәгатьтә үк почтадан срочно итеп салам, Хөснул! — диде Сәлимә.

Авылга кайчан кайта да кайчан Шәрбәнбануга юл саба: хатын үзеннән өч мең тәнкә өстәп, Хөснулла әнисенен адресына акча җибәрде. Әмма әманәтен үтәсә дә, җаны тынычланмады. Гафурга «берәүләр инде» дигәнен чынлыкта исә Мөршидә карчык иде! Чакырмадылар, кил димәделәр аңа, бара әле менә. Таш асфальтка өйрәнгән нәзберек җанга пычракта тәпиләве бер газап, итекләрне балчык суыра иде.

... Килен булып төшмәде ул Шәрбәнбануга. Нигәдер Хөснулла туй ясамады. Үзеннән егерме яшькә олырак ир, хәер, аңа хәтле ике хатынның «башын ашаган», аның өчен туй, үзе әйтмешли, «искелек калдыгы» иде.

Сәлимә гөрелте ишетеп артына борылды. Бер трактор пычрак дингезеннән «йөзә» иде. Хатын турысында ул туктады.

— Шәрбәнбанугамы, апа? — диде яшь егет. — Утыр!

Биек кабинага җитез генә үрмәләде Сәлимә.

— Бу юллардан шайтан арбасы гына тәгәрәрлек икән.

— Без авыллар күнектек: батабыз да калкабыз, апа. Син шәһәрнеке ахрысы, — диде егет. — Кыяфәтең кәттә.

— Мин дә сезнең камырдан, энем.

— Кем апасы соң син?

— Җиде Чишмәдән мин, энем.

— Ә-ә, Гафур абыйлар авылыннан икән! Быел мин аның басуын сөргән идем. Классный мужик! Ыжмут түгел.

Алда сыннарын куырган кукуруз басуы сузылган иде.

— Һай, нишләп әлегә чаклы боларны силоска урмадылар?

— Ягулык кытлыгы, апа. Колхозлар җан тәслим кылды ич.

— Хуш, икенче елга чәчеп нужаланмассыз, коелган орлыктан үзе тишелер, энем.

— Тишелми, апа. Адәм атабыз, апа, авыл кешесе булган ди. Үзе колхоз рәисе, үзе агроном, үзе игенче, үзе көлтә бәйләүче, үзе суктыручы — барысын да ялгызы гына эшләгән беренче пәйгамбәребез. Аллаһы Тәгалә аңа күктән бодай, арыш, арпа, солы ише орлыклар индергән. Шуңа безнең ата-бабалар

икмәкне илаһи изге ризык дигәннәр. Икенче могҗизасы шунда аның, апа. Мин санаган орлыклар көз туфракка коелса, җәренгә үзлегеннән шыта, ә кукуруз чери, апа. Чөнки аны Аллаһ безгә төшермәгән, аны кешеләр уйлап тапкан.

— Һай-һай, син фәйләсуф икән, энем.

— Һи, безгә ди акыл! Моны миңа Гафур абый сөйләде.

— Ә кукурузлар барыбер кызганыч.

— Авылда бүген бөтен нәрсә кызганыч, апа. Авыру карт-корылары, җил сызгырган фермалары, хуҗасыз этләре, ташландык алма бакчалары дигәндәй. — Юлдашы телгә оста иде. — Эш юк, шунлыктан авыллар үлә диләр. Нишләп таза-сау ир-атка эш бетсен ди икән, апа? Әнә, Гафур абый тере үрнәк: оештыр үз хуҗалыгыңда кечкенә генә колхоз! Мәктәпкә дә ачуым бар минем, апа. Укытучылар башка төя-төя укыта. Ничек тә «дүрт»ле ал син! «Аңгыра, надан» дип тиргиләр өстәвенә. Куй симез-симез «икеле»ләр! Аның шул «икеле капчыклары» авылда төпләнеп калачак. Хәтта син аларны түбән билгеләр өчен бүләклә! Мин тапкырлау таблицасын буташтырам, апа. Әмма тракторым ватылса — күземне бәйләп сүтеп, кире җыям. Мин сөргән җир мамыктан да йомшаграк! Мактанчык жегет икән димә, апа. Ә аттестатымда шыр «өчле»ләр. Директор: «Төзәттерәм, кайда укырга хыяллана?» — дигәч, эти: «Тормыш институтына барыр инде, минем иске тракторны иярләп», — дигән. Безнең сыйныфта ун малай, биш кыз иде, шуларның ундүрте вузларда укый. Кимсенмим мин, апа. Әзрәк тернәкләнүем генә, Гафур абый кебек ферма ачам!

— Афәрин, энем, афәрин! Авылыгызда тагын синдәй уңган егетләр бармы соң?

— Олыраклар бар, кырык яшьлекләр. Кәҗә Гыйлфаны, Чыпчык Идрисе, Бозау Хәбрие, Шөпшә Гамиры. Дүртәүме? — Егет рулен кулыннан ычкындырып, берәм-берәм бармакларын бөкте. — Кабак Фәниле, Дөя Барласы. Алтаумы? Суррогат эчәләр шул апа бу абзыйлар. Быел безнең басуларда билдән печән иде. Хет үзең сыердан көнләшеп чәйнә! Гафур абый әйтә, Хаммат, симертергә унлап бозау бирәм, ди. Чабыгыз ирләр белән печәнне җыйнаулашып, ди. Әтисе Сөләйман абзый — Шәрбәнбану кияве иде, шунар якын итә иде ул безнең авылны.

— Чаптыгызмы? — диде Сәлимә.

— Кая, апа? Кәҗәсе дә, Чыпчыгы да, Шөпшәсе дә, Кабагы да — берсе дә чыкмады. Чалгы белән чаба белмибез, аякны кисәбез, диләр. Син, диләр, печәнне тракторың белән капка төбенә китереп аудар, бозауны коймага бәйлә, икесен бергә сатып эчәрбез, диләр.

— Һай, һай, бик күңелсез хәлләр икән, энем.

— Шулайрак, апа. Әби безнең авылны Ходай каргаган, ди. Күрше Ибрайларның да эшләре хөрти әнә. Урам тулы исерек.

— Мин, энем, шәһәрдә яшәгәч, туган җирдән аерылган идем, — диде Сәлимә. — Баксаң, татар авыллары тоташ каргышта икән, һай-һай! Мөршидә әбиегез исәнме?

— Артист әнкәсеме? Картлар йортына озаталар дигән иде әти. Аның йорты — урта урамда өченче, апа.

Беренче иренең туган йорты да хәрабә өеме: капка баганасы череп ауган, койма рәшәткәләре эт кимергән сөяк төсле кителгән иде. Әй, уңмаса да уңмас җете җәй төсе! Ишегалдын ямь-яшел чирәм каплаган иде. Гүя хуҗасы кибәргә дип идән җәймәсен сузып салган!

Бер хатын туңкаеп баскыч идәннәренең балчыгын кыра иде.

— Әпәт үзәктәнме? Әбиең киреләнә, бармыйм ди сезгә. Хөснулласын көтә. Анысы да җәйләрен кайтып, утынын ваклый, абзар-курасының тишек-

тошыгын ямаштыра иде, инде ике елдан артык, анасын гүпчим ташлады, — дип, ул зарланырга тотынган иде, Сәлимә:

— Мин картлар йортыннан түгел, — диде.

— Чуртымнан булсаң бул, матурым, Мөршидәттәйне генә кымтырыкла. Тамагы тук, күте җылыда дип без дә куанышырбыз. Аның ызбасына газ кертелмәгән, утын яга иде, быел анысы да хәстәрләнмәгән. Кыш туңып үлә, бичара. Без, күрше-күлән, чиратлашып ашатабыз үзе. Мунчада юындырабыз. Карау да житешми инде. Үземдә дә каенана белән каената. Икесе дә туксанда. Яшь чакта безнең сымак корсаклары күбенгәнче тәмледән тәмле тыгынсалар, күптән Газраил тырнагына эләгерләр иде, әстәгъфирулла! Ачлы-туклы яшәп, кычыткан, алабута гына ашагач, күр, гомерләре нинди озын! Ә үзләре сабый балалардан да хужы, бик көйсезләр.

«Мин Хөснулланың әнисенә ничек дип эндәшим икән?» — дип уйлады Сәлимә. Кем ул? Әбиме, апамы, әниме? Әни дип авыз тутырып әйтерлеге бар: Фәрит — баласының баласы. Гомердә бер очрашмаган килен белән оныкl Һай, дөньясы!

Дисбе тартып утырган карчык саңгырау иде, күрше хатыны:

— Мөршидәттәй, сиңа кунак килде, — дип, колагына кат-кат кычкыргач кына очлы ияген селкетеп:

— Хуп, хуп, — диде.

— Кучтәнәчләр белән, Мөршидәттәй!

— Әрбир белән җумаламагыз да, хөкүмәт ызбасына бармыйм тек бармыйм!

— Холыксызланма, Мөршидәттәй! Сине картлар йортына кауламый бу кыз-катын.

— Сән кем? Кайсы җирдән? — диде карчык.

Сәлимә: «Әни, мин өченче киленен», — димәкче иде, нигәдер теле көрмәкләнде. Карчык яулыгын шудырып, аңа сул колагын әзерләгән иде, ул шунда иелеп:

— Мин театрдан, — диде.

— Бәрәкалла, тиәтердәнмени, олан? Хөснуллам элгәре заманда әртистлектә жөрде. Аулга кайтса, әни дир, ике кунам да таям дир, безнең кәстрүлләр, дир. Хәбәрсез нишләптер Хөснуллам, хәбәрсез.

Карчык карашын ярым сыгылган матчага төбәде. Ә анда — ярыкларга саргайган кәгазь кисәкләре кыстырылган иде. Телефонсыз елларда язган хатлардыр, күрәсең. Элек авылның берләнбер хәбәр чыганагы шул хатлар иде лә. И шуңа сөенгәннәр, сөенгәннәр! «Улың (яки кызың) язамы? — элек авылда баш сорау шушы иде.

Шәрбәнбануның билгесез килене ым-шымсыз гына кайтып китте. Күңелгә коточкыч авыр иде. Коточкыч авыр! Хөснулла начарайса (улының атасы бит!) Фәриткә дә әйтермен дип ул сырхауның хатынынннан телефонын алган иде. Кырда — иркендә Сәлимә көндәшенә шылтыратты. Чыбык очында бичә кыска гына:

— Бер имгәге белән чиләнгәнем дә җиткән, әнкәсен дә миңа такмагыз, — диде.

## III

...Ашъяулык хәтле генә уентыктагы шәмәхә чәчәкләрне ул кичә үк шәйләгән иде. Табигать кызганыч итеп тә, матур итеп тә шаяра. Тамырларын имгәтмичә генә өзеп, букет ясап Гүзәлиясенә бирергә кирәк. Шатлансын! «Син тупасландың», — ди ул. Ходай дөнья тоткасы дип яралткан ир-ат сүзләр чәчә-чәчә төчеләнеп кыланамени?! Аның мәхәббәте тирәндә — йөрәктә була. Үзгәргәндер, анысы да хак. Булдырам дип сыртына галәмәт зур

йөк төяде дә, менә хәзер вакыт-вакыт, йөгеннән сыгылып, чүгеп-чүгеп ала. Көч-гайрәт кимемәде, әлеге дә баягы шик-шөбһәдән кыйнала иде ир. Быел ул кредит акчасын җилгә сипте. Хәзер инде сакал-уҗымнар аңарда кызгану хисе уята иде. Киләсе елда да алданмас микән? Йә корылык, йә туктаусыз яуган яңгыр кәкре каенга терәтмәсме? Әтисе ныграк җил исеп арышларны аударса да, атналар буе хәсрәтеннән йомылып, ләм-мим сөйләшми иде. Ә инде алдан ук фаразланган уңыш җыелмаса — агроном Сөләйман озын, караңгы көзгә төннәрдә йокламыйча ыңгырашып таң аттыра иде. Мөгаен, иренең пырдымсыз холкы әнисен дә бик иртә гүргә индергәндер.

Чыпчык, Тургай, Сандугач басуларын чәчәм дип үрсәләнә, билгеле. Ә менә җир сорап язган гаризасына тугыз ай кул куелмаган. Авыл җирлеге башлыгы Туктар Ильясов «Җыелышта карар кабул итәбез», — дип вәгъдә шулпасы белән сыйлый, ләкин кулдагы кашык һаман коры иде. Тик Гүзәлиягә «Хәлләрем хәл», — дип мескенләнмәс Гафур. Әтисе кебек йөз җимереп, дәшмичә дә йөрмәс. Тәкъдир аларны ызгыш-талаш өчен очраштырмады. Авыл хуҗалыгы академиясенең дүртенче курсында укыганда егетләр «культурныйлар» (мәдәният институты шәкертләрен шулай диләр иде) тулай торагына бәйрәмгә барды. Талантларның нәкъ оясы: студентлар җырлады-биеде. Кичәдә Гүзәлия исемле ябык кына кыз номер аралаш шигырь укыды да шигырь укыды. Алып баручы аны шагыйрә, бер җыентык авторы дип игълан итте. Кыз очына-талпына нәкъ менә Гафурга гына мәхәббәтен аңлата сыман иде. «Сельхоз» егетләре дә осталыгын күрсәтергә тиеш иде. Хәзер инде баянда сыздырган Гафур күзе белән залдан — беренче рәтләрдәге утыргычлардан Гүзәлияне эзләп тапты... Кичәдән соң ул шагыйрәне озатырга да базды. Гүзәлия Казан кызы икән, Бауман урамындагы фатирда яши икән. Әмма бу очрашуның әүвәлгесе — актыккысы иде. Ут үрләгән йөрәгеп су сибеп суытты егет: «Авыл гыйбады дип мыскыллардар. Туктат, җилбәзәк шәһәр туташлары белән мавыкма!»

Ел да узмагандыр, «культурныйлар» җавап рәвешендә аларның институтына килде. «Гыйбадлар» сынатамени! Үзләрендә театр, үзләрендә артистлар. «Аулак өй» күренешен сәхнәләштереп, боларның өскә чөелгән борыннарына чирттеләр. Гафурга гына әлләни булды. Бармаклары төймәләргә ялгыш баскалап, баянны тыкрыкта адашкан кәҗә бәтиедәй мөкрәтте. Залдан коңгырт күз аңа төбәлгән иде. Аннары сәхнә түренә «культурныйлар» менде. Шагыйрьләр өчәү иде. Башта ышкылган такта кебек юка гәүдәле, колга буйлы егет калкына-калкына бөек җисемнәр турында поэмадан өзек сөйләде. «Җирдә — баш, болытларда — аяк, чәч — тамыр, үкчә — ми» дигән тезмәләрнең мәгънәсенә төшенмәде Гафур. «Надан мин», — дип уе белән генә үзен баштүбән әйләндерде. Егылдыра, шайтан алгыры!

Фикерләрен дәвам иткәндәй «Колга буй»га икенчесе кушылды.

Чиратта Гүзәлия иде. Кыз томырылып егеткә карады.

Әйтәсе сүз әйтеп бетте инде,  
Очрашулар язмас безгә бүтән.  
Аланнарда юкә чәчәк койган,  
Хушлашырга дисең вакыт күптән.

Җанымны әй, минем әрнетмәче,  
Үз хәлемне бары үзем аңлыйм.  
Сихерләнгән төсле басып торам,  
Ни китәлмыйм синнән, ни калалмыйм.

Гафурның йөрәген, әйтерсең, черт иттереп ачкыч белән борып ачтылар.

Ачтылар да хәнҗәр белән: «Мин!» — дип сыздылар. Менә ул күкрәгеннән уып ыңгыраша. Тик ярасы әрнетми, ярасы рәхәт сулкылдый гына... «Без синең белән хушлашмадык, коңгырт күз», — диде егет һәм өчәүнең артыннан урамга чыкты. Үгезне мөгезеннән эләктерергә кирәк иде.

— Гүзәлия, мин сине өеңә үзем илтәм. — Егет студентлар отряды белән төзелештә эшләп, акчасына иске «Нива» юнәткән иде. — Әйдә!

Колга буй, ата каз кебек ысылдап:

— Иптәш! Аң бул: туташ минеке! — диде.

Гүзәлия, аның кулына суккалап:

— Зәбир, шапырынма, — диде. — Гафур, исәнме? Безнекеләр белән танышасыңмы? Бусы — Зәбир Кәбиров, ә монысы — Галинур Маразов. Казан шагыйрьләре.

— Тату төркем. — Гафурга мәзәк иде. — Мин — Жиде Чишмә малае. Бәлки, үзегезнең партиягезгә әгъза итеп теркәрсез, ә?

— Син безнең сәфәрдәш түгел, жиреңдә генә казын, — дип, Колга буй кызны култыкламакчы иде, Гафур каршы төште:

— Гүзәлия минеке!

Бер читтә мыштым гына тәмәке пыскыткан өченче төркемдәш төпчеген ташлады да, егетнең жилкәсеннән умырып:

— Таһир белән Зөһрәгә тимә! Аларның мәхәббәт! — диде.

Зәбир дә, батыраеп, Гафурның күлмәк изүенә ябышмакчы иде, егет аларның икесен бергә тарттырып, мангайга мангай чәкештерде. Кул кычытса да, сукмады. Ә аның беләкләре тимер иде. Бервакыт урманда, кинәт өстенә ыргылган кабанның ике каш арасына йодрыгы белән тондырып, ерткычны дүңкәйткән иде ул. Ә болар — Гүзәлиянең ижатташ дуслары. Болар — бер гөнаһсыз жаннар.

Кызны ул жилтерәтеп кенә машинасына утыртты. Тыпырчынмады Гүзәлия, әз генә үпкәләп:

— Сугыш чукмары икән син, — диде.

— Теге Зәбир иптәш сөекләнмени?

— Әйе.

— Өйләнешәсезме?

— Бәлки.

— Шулай икәү башыгыз аста, аякларыгыз өстә килеш жир белән күк арасында асылынып яшәрсез микәнни?

— Көлмә, Зәбир талант иясе.

— Еларга икән, алайса.

— Зәбир минем ижатымны бәяли. Без аның белән пар.

— Яз син, яз! Син язганда мин комачауламам.

— Тилерден мәллә?! Мин — Зәбирнең кәләше!

— ... идең. Ә бүгеннән минем парым. Сине ятларга бирсәм, Сөләйман малае исеме хәрам миңа! Соңгы шигыреңне миңа багышладыңмы, коңгырт күз? Димәк, син дә миңа битараф түгел.

Ахырдан ул Зәбир белән дә, Галинур белән дә дуслашты. Аны шигырь кичәләрендә баян уйнарга чакыра башладылар. Гафурның жырга да сәләте ачылды. Хәер, жыр-көй һәм шигырь белән үрелгән бәйрәм мәжлесләре озакка бармады. Шагыйрь егетләр: «Синең белән сүз тәме югала, халык концерт ягына авыша», — дип төркемнән киттеләр. Калды икәү: Гүзәлия һәм Гафур. Алар өр-яңадан репертуар әзерләделәр. Ульяновск өлкәсендә туганнарыбыз күп, шундагы татар авылларын урап кайтыйк, анда халык моңга сусаган дигәч, егет ничектер бик жиңел ризалашты. Ә Жиде Чишмәдә аны дүрткүз белән кем көтсен! Мингайшә апасы гына: «Энем, энем», — дип өтәләнәдер.

Академияне тәмамлагач, кесәсенә агроном дипломы салгач, ул, бөтенләй авыл хуҗалыгыннан бизмим инде дип, аспирантурага документларын тапшырды. Читтән торып уку иде исәбе. Мөгаен, Гафур, зарыгып көтмәсәләр дә, туган авылына кайтыр иде. Нигезләре нык. Нарат бүрәнәләр тагын йөз елга түзә. Әмма мәхәббәтеннән исергән егет Гүзәлиядән җанын каерып алалмады...

Остарып-шомарып, җырчы данына тәмам күмелгәч кенә Гафур Җиде Чишмәсенә афиша элде. Якташларын да бер шаккатырсын әле! Клубка эресе-вагы, яше-карты тулган иде. Соңыннан мәрхүм атасының яшьтәше Гыйрфан бабай:

— Һәй, Сөләйман малае да җырларга калгач, безнең авыл гына түгел, дөнҗасы да йөзтүбән каплана икән, — дигән.

Шагыйрә белән «артист» Мингайшә апаларда төн куна иде. Апасы үзенә пырлады:

— Адәм ыстырамы! Такмак такмаклар өчен сигез ел укыдыңмы?! Хөкүмәт акчасын туздырып теге! Атаң хурлыгыннан каберендә биш әйләнгәндер!

Гүзәлия уңайсызланып кына:

— Апа, тамашачы Гафурга мөкиббән. Аны бүген сандугачка тиңлиләр, — дигән иде, апасы отыры ярсыды.

— Сандугач бала чыгарганда гына, анда да үз кадерен белеп кенә сайрый, гөлкәем! Ә бу көн-төн чыркылдаган саескан! Ниткән эш ул, иртә җырла, кич җырла! Җиде Чишмә өчен бер генә дә көймисеңмени, малдумыт энем? Кеше авылларында, әнәгенәк, калхузлар урынына фирмырлар пәйда булган. Тилбизердан күрсәтләләр. Ә бездә артист тә, исерек!

Гафур ерак гастрольләргә китәргә ашыкмады. Авылның тып-тын кичләре, су буйлары, түбәсе болытларга орынган Кинә таулары, аннан да битәр урманнары сагындырган иде. Әтисенең чормадагы мылтыгы да, мөгаен, ир-ат кулын тансыклагандыр. Авыл табигате кунакка да ошады. Кыр чәчәгеме, күбәләкме, кырмыскамы — барысы да аның өчен «романтика» иде. Төнлә кыз: «Нинди матур!» дия-дия, йолдызлар белән чуарланган күк гөмбәзе астында бөтерелде, чирәмдә тәгәрәде. Кинә тавының биеклегеннән әсәренде, «ай-яй, сездә ай зур!» дип, коты очып егеткә сыенды... Матурлык янәшәсендә ямьсезлек тә бар иде. Анысын инде менә Гафур гына күрә иде.

Элек «Син минем җиремә өч сүәм кергәнсен», — дип бәрәңге бакчалары өчен тәпәләшкән әби-апалар кабереннән кубарылса ни дияр икән? — ул бакчаларда алабута үсә. Чәчәргә кешесе юк. Элек колхоз көтүенең башы — авылда, койрыгы — болында иде, ә бүген фермаларда тояк эзен кырып-кырып эзләсәң дә табалмыйсың икән. Ә сөрелмәгән кыр-басулар кысыр хатыннар кебек ята иде!

— Мин авылда калам, — диде Гафур, өздереп.

— Кайтканнан бирле бер җүнле сүз! — Апасының күзе яшьләнде. — И рәхмәт яугыры, энем! Ә кунагыңны кайчан озатасың?

— Гүзәлия кала, апа. Мин аңа өйләнәм!

— Бәй, шәһәр иркәсе нишләр икән монда?

— Иҗат белән шөгыльләнер. Ул — шагыйрә, аның коралы — каләм.

— Ә кем ишегалды себерер?

— Мин, апа.

— Кем су ташып, мунча ягар?

— Мин, апа.

— Керен дә син юарсыңмы? Ашарга да син пешерерсеңме, ә, энем, алтыным?

Казанда исә кызның туганнары авылны хурлады. Һәркем үзен хаклы

саный иде. Гафур, нәрсәдер исбатлап, нәрсәдер раслап вакланмады. Су болгана-болгана да, юшкыны төпкә утыра. Тора-бара каланыкылар да, саланыкылар да язмыш белән килешер. Аларга шул мәгълүм микән: яшьләрдә ярату бар! Илаһи ярату! Бөтенесе дә мәхәббәт иләгеннән иләнә! Алай да шәһәрдәге туган-тумача сыкранып кына Жиде Чишмәне күрәсе итте. Ул көнне болытлар, үчеккән төсле, нәкъ авыл өстендә укмашты да ишеп-ишеп яңгыр яуды. Урамнардан шаулап ерганаклар акты... «Табигать» дип әсәренгән Гүзәлия табынны бакчада әзерләткән иде, өстәл лычма су булды... Бердәнбер кеше — Гүзәлиянең туганнан туган депутат абзасы мунчада чабынып, кысла кебек кызарган Гаяз Идрисович:

— Все-таки авылда шәп! — диде.— Экзотика! Син, кияү, кара мунча эшләттер. Хәзер аның шундый төре модада. Миченә чуер таш өйдер. Чыжлатып үлән суы сибәсең дә, парына уралып, тирлисең!

Әмма аның да, чалбар балагына балчык буялгач, чырае сытылды:

— Ну шушы авыл пычрагы! — диде депутат, сүгенеп.

Яшьләр, кунаклардан котылгач, яшәү планы төзелде. Гафур концертларда йөргән микроавтобусны сатып, шуның акчасына УАЗик машинасы ала, сыер-тана, сарык кайтарта. Беренче бурыч — әкрен генә яңа хуҗалыкның нигезен кору иде. Ә Гүзәлия — яза! Ана инде илһам тынгылык бирми: алан-болыннар, Кинә таулары, йолдызлы төннәр чиратка тезелгән. «Мине шигырь теленә күчер, мине...» Тик бер елдан хатыны «романтика» сүзен сирәгрәк әйтә башлады, ә ике елдан — ул аны бөтенләй онытты. Быел Жиде Чишмәдә төпләнүләренә өч ел... Гүзәлия тиктомалдан боега башлады. Өзәргә кирәк ул кыр чәчәкләрен, өзәргә кирәк... Хатын-кыз — нечкә халык, әз генә кырыслансаң да, үпкәсен белдерә. Әнә бит, кулларың тупасланды, ди.

...Сөт заводы директоры Әнәс Хөсәенов аны ерактан ук сәламләде.

— Үзе суктыра, үзе җилгәрә, үзе төяп җибәрә. Менә сиңа табышмак. Кем ул, Гафур? Син, туган, син. Үзе терлек асраучы, үзе сыер савучы, үзе сөт ташучы. Кем ул, Гафур?

— Мин, Әнәс абый, мин. Саулармы?

— Саулар. Җырламыйсынмы инде хәзер?

— Туктадым, Әнәс абый.

— Җырлатмый дөньясы, әйеме? Мин дә сельхозда укыдым. Роберт абыйның театр түгәрәгендә шомаргач, җинел генә акча күрәмәкче идем. Концерт бригадасы оештырдым. Йөрибез район авыллары буйлап. Әлфия апа әйтмешли «бушка кошлар да сайрамый, иркәм». Кич — клубта җыр, иртән кәнсәләрдә — мин. Колхоз рәисенә «Тиярен бир» дип киләм. Ул иртәгә, ди. Тагын киләм. «Бир инде, агай-эне», — дип ялынам. Акча юк, фермадан үгезләтә ал, ди. Соң, дим, миндә ун артист, нишлим үгез белән, дим. Бүл, ди. Кайсына койрыгы, кайсына боты, кайсына муены, ди. Берсендә хакимият башлыгы кабинетына чакыртты.

— Хөсәенов, электр баганасы хәтле буең белән ничек теләнеп йөрисең? — ди.

— Ялгышасыз, Гамил Әфләтунович, мин җырлыйм, дим.

— Җырлау эшкә исәпләнми, Хөсәенов, — ди башлык. — Синдә агроном дипломы, бүген үк «Сөнчәле» колхозына рәис итеп билгелим, миннән рөхсәт, буш вакытында бугазыңны киереп җырларсың, ди. Җырларсың, пычагым. Кыз-катын кебек чәчеңне йолкырсың ул колхоз белән. Эт булып арыта иде, туган. Шушы элеккеге глава, Гамил Әфләтунович, каты бәгырь, мине гел артта сөйрәлгән хуҗалыкларга тыкты. Син бу заводың кара, ярты ел ремонт ясаттым. Сәхнә белән саубуллаштым дип үкенмә, туган. Авыл баласының һәрберсе моңлы, һәрберсе сагышлы аның. Син әнә, канауда

аунаган сәрхуш Хисмине айнытып, юып-чистартып, киптереп, киендереп сәхнәгә бастыр, ул үзәкләрне өзеп җырлый. Ә Ходай җир-туфрак ярату таланты белән сирәк кешеләрне бүләкли. Шул бүләккә куан, туган.

— Бүләкме, сынаумы, кем белгән, Әнәс абый, — диде Гафур. «Сакаллы басу» һаман бораулап-бораулап бәгырьне тишкәли иде.

— Ә син төртсәләр дә егылма, туган. Без түзмәсә, кем түзәр дөньяларында. — Директор ашыга иде. — Шәрбәнбануга барышым әле.

— Бүген ул авылда бәйрәм мәллә, Әнәс абый?

— Бәйрәм сиңа! Алар басуында кәкрәешкән кукурузлар безнең оешманыкы иде. Уралмадык, шуның өчен киңәшмәләрдә хаким чукып-чукып талый. Чыгышын минем белән башлый, минем белән тәмамлый. «Син атказанмаган булдыксыз җырчы, фәлән-фәсмәт...» Аның, туган, шунысы — артист дип сүгүе үтерә. Макталганда мин — Хөсәенов кына, ә тиргәлгәндә — «атказанмаган булдыксыз җырчы». Шул тирәләрне карап әйләнim, эч поша, туган.

## IV

...Шәрбәнбану аның йөрәк сыкрануларын гына кузгатты. Ата-баба гореф-гадәте буенча әүвәл, килен сыйфатында шушы авылга — Хөснуллалар йортына төшәргә тиеш иде Сәлимә. Каенана кеше бусагадагы йомшак мендәргә бастырып аңа май белән бал каптырырга тиеш иде. Тәрәзәләргә ап-ак челтәрләр эләргә тиеш иде яшь бичә. Иңнәренә пар чиләкләр асып, чайпалдырмыйча гына чишмәдән су китерергә тиеш иде Сәлимә. «Тиеш»ләр күп иде шул, күп иде. Йоласы үтәлмәде, һәй! Шуңа күрәдер, хатын-кыз бәхете дә тәтемәде.

Дымсу кыр җиле аның эчен актарган моң-зарын таратмый, әйләндереп-тулгандырып яңадан йөрәгенә сылый иде. Хатын юл кырыена бер чүгәләп, бер утырып тамагына бөялгән утлы күмерне көч-хәл белән генә йотты. Кукуруз басуыннан лас-лас атлап таза гына ир бәндәсе килә иде. Җитәкче-фәлән, ахрысы: ак күлмәктән, кызыл галстуктан. Эсселәгәндер, мөгаен, пиджак төймәләрен ычкындырган. Авыл пычрагы һәркемне тигезли: түрәсен дә, Сәлимәсен дә җәяүлегә калдыра.

— Исәнләшер идем, шикләнәм. Әллә пәри, әллә кыз-катын, — диде ир, үз мәзәгеннән шаркылдап.

— Күзлегең парланган бугай, Әнәс.

Хатын, әлбәттә, аны таныды. Кариле егете Әнәс Хөсәенов аның сабакташы, алар Җиде Чишмә мәктәбендә бергә укыганнар иде.

— Тукта, сулама! — диде ир. — Биш былтыр күрешмәдек бит без! Син кайларда бүген, күке Сәлимәсе?!

— Күкесе — урманда, Сәлимәсе — каршында, Әнәс.

— Без, сыйныфташлар еш җыелабыз, син генә эреләнден, безне санга сукмыйсың, Сәлимә. Баюың җиттеме соң?

— Җитте генәме, ташып акты.

Гадәттә күптән очрашмаган танышлар (ә болар сабакташлар!) төпченергә тотына. Кайберәүләре күнеленә үк чокына. Әнәс минем шәхси тормышым турында сорашмасын дип хатын кукуруз басуына төртте:

— Әнә-ә, теге кырны бер булдыксызы урмаган, әйеме?

— Әйе, әйе, Сәлимә. Ул булдыксыз — атказанмаган җырчы. Сәхнәдән куганнар да, кукуруз чәчкән, имеш.

Мендәр кадәр корсагын дерелдәтеп көлгән Әнәс ачуны чыгара иде.

— Сәнгать кешеләрен мыскыллама, сабакташ. Син түрә бугай, ник аңа булышмыйсың?

— Их, Сәлимәкәй, Сәлимәкәй. — Ир дә басуга карашын төбәде. — Әй, ярар ла, — диде. — Син кай тарафларга чаптырасың?

— Жиде Чишмәгә.

— Машина олы юлда, әгәр авылыгыз күперенә кадәр илтсәм, ачуланмассыңмы?

— Ачуланмам.

Ә тукталышта Әнәс ишекне ачарга жыенмады.

— Үзәктә шәп кунакханә төзеделәр. Номерлары искитмәле, шунда берике сәгать серләшик, ә, сабакташ? — дип ул аның ботын угаламакчы иде. Сәлимә жене кузгалып:

— Менә хәзер ачуланам! — диде.

Болай да Шәрбәнбану хатирәләреннән йомшарган хатын сыгылып-сыгылып еларга уйлады. Ичмасам, әзрәк бушаныр... Ялгыз дип мангаена уйганнар мәллә? Кунакханәдә серләшәләр, янәсе. Серләшмичә генә тор, яме!

Чибәр шул, кызыгырлык шул Сәлимә. Үз рәхәтенә шәһәрдә яшәде ул. Өстендә фуфайка, аягында сәләмә галуш түгел иде. Тик парсыз күке иде Сәлимә. Шәрбәнбану егете аның бәхетен урлады. Бүген хатын Хөснулланың туган авылына барып, яраларын тирәнәйтеп кенә кайта. Синең өчен еламый ла ул, симез Әнәс!

— Кәк-күк, кәк-күк!

Кем үрти аны, кем? Кайсысы күке теле белән моңлана?

— Кәк-күк, кәк-күк!

Сәлимә җавап итеп:

— Кәк-күк, кәк-күк, — диде.

«Кем» дә уенга кушылды:

— Кәк-күк, кәк-күк...

— Һәй, син чын күке ләса! — диде хатын. — Адәм жанында синеке кебек моң булмый. Алайса нигә үзеннән күзең сагышлы, дисеңме? Сорама, кошкаем, сорама! Әчем четер-четер янса да, мин сиздермим, көләм-шаярам. Театр уйнама, дисеңме? Бәй, мин бит үз тормышымны гына уйныйм, бүтәннәрнең роленә ымсынмыйм. Хәзер минем сәхнәм — Жиде Чишмә, кошкаем. Чү-чү, улым белән киленемә тел-теш тидермә! Үз көйләренә яшәсеннәр, яме? Минем бит, Аллага шөкер, нигезем бар. Иске, билгеле, алай да шөкерана кылам мин. Театр житәкчеләре тулай торактан бүлмә хутлый иде анысы. Мин бит, кошкаем, синең даныңны арттырдым. «Кәк-күк» дияр өчен мине Төркия, Финляндия мәмләкәтләренә алып бардылар, ышанасыңмы?

— Кәк-күк, кәк-күк, — диде кош һәм әрәмәлек талларын тибрәндереп очып китте.

Мингайшә апа колгалы кое янында бидоннар чайката иде.

— Вәт-вәт! Гафурның сөт машинасы таксый түгел сиңа. Ана тагылдың инде нәрсәгәдер өметләнеп тә, хәзер арыган бүре сыман аякларыңны сөйрәп кайтасыңмы? — диде карчык, теленнән агу тамызып.

Сәлимәнең сүздән ызгыш арканы ишәргә бер генә теләге дә юк иде, ул кое каршындагы бүкәнгә утырды.

— Кәк-күк, кәк-күк...

— Күкелдәмә, — диде кортка.

— Кәк-күк, кәк-күк...

— Сиңа әйтәләр! — Мингайшә апаның төймә хәтле генә күзләре зурайды. — Канатларыңны сындырам, күке кызы. Энем йортында күкелдәмә, күкелдәмә, күкелдәмә!

Хатын тынды. Карчыкның кулы каты иде. Бервакыт авыл хатыннары кырда чалгы белән печән чаба, ә мәктәп балалары кояш кызуында кипкән покосларны әйләндерә иде. Кич белән бригадир чабылган мәйданны күзләп:

— Кырык биш сутый, апалар, — диде.

— Тучнысы алтмыш, — диде Мингайшә апа.

— Минем анлык кына баш эшли, кырык биш, апалар, — диде бригадир.

— Синең үлчәвең башсыз башында, ә минеке — аякта, — дип, Мингайшә апа адымлап җирне үлчәде.

— Алтмыш!

Бригадир:

— Ыспурлашмагыз, апалар, кырык биш, — дигән иде, Мингайшә апа егетне сугып екты:

— Алтмыш!

...Карчык, әһә, шүрләденмени, дигәндәй, канәгать елмаеп, кое авызына иелде. Чыкырт-чыкырт...Чыкырт-чыкырт... Әле театр юксындырыр. Әнә, сиртмә нәкъ сәхнәдәге декорация алмашынгандагы төсле чыкырдый...

— Су болгана. Чиләгеңне апкил, чәйлек ал, — диде кортка.

— Рәхмәт, Мингайшә апа. Суым ярты бак.

— Шәһәр кешесе кашыклап кына эчә шул. Мин сиңа йорт белештем, күке кызы. Вәлетдиннәр сата.

— Нинди йорт?

— Пәтистинни. Сарае, мунчасы өр-яңа. Җитмеш мең тәңкә, ди.

— Минем оҗмах кебек йортым бар бит, Мингайшә апа!

Карчык салкын судан күшеккән кулларын сулышы белән җылыта-җылыта:

— Тәмугтан хужы нигезегез! Кыш син анда суыктан кәңкәясең әле, күке кызы! Таракан күк катасың әле, бел!

— Кайгыртуың өчен рәхмәт, Мингайшә апа. Мичен төзәттердем, яктым, төтенләмәде. Һич булмаса, урманга очармын, мин бит күке!

— Әй, ни исемең, ни кушаматың! — Карчыкка бу шаяру ярамады. — Сәлимә ни, сәләмә ни. Менә син шуны аңлат, күке кызы: нишләп ташкаладагы фатирыңны бәреп, Җиде Чишмәгә индең, йа?

— Сер, Мингайшә апа.

— Монда безнең чүлмәк гөле дә җитеп ашкан иде, — диде кортка һәм сызгыртып алъяпкыч итәгенә борынын сеңгерде. — Томау, заразы.

— Сарымсак суы файдалы, Мингайшә апа.

— Матри, сереңне белермен мин, күке кызы!

— Нинди сер ул? — Капкадан Гафур чыкты.

— Кыз-катын сүзен тыңлама, колагың сасыр, энем, — диде карчык. — Көзге көн кыска, сыерларыңа печән сал. Тиздән караңгылата.

— Юлың ундымы, Сәлимә апа?

Күршесенең бу соравы нибарысы әдәплелек билгесе, хатынның юлы унса да, унмаса да аңа барыбер кебек иде. Иртән генә шат-көләч Гафурның күз нуры тоныкланган иде.

## V

...Шәмәхә чәчәкләр иясе өйдә юк иде. Өстәлдә тузгыган кәгазьләр, компьютер кабызган килеш. Язган да сызган, язган да сызган. «Иҗат газабы кичерә...» Үз халәтен шулайрак аңлата Гүзәлия. Иркенләп-тынычлап эшләсен дип Гафур алгы бүлмә диварына ишек уеп, бераздан җыйнак кына өстәмә кабинет ясаткан иде. Анда илһамнан гайре бүтәннәргә керү тыела иде. Керде әле. Ихлас күңелдән сөйләшергә кирәк. Араларыннан боз шуышкан төсле, хатын аңа салкынайды.

Гүзәлиянең кулында исә әрем бәйләме иде. Ул дивандагы чәчәкләргә аһ димәде, сүзсез генә тәрәзә төбендәге сулы пыяла савытка куйды.

— Аппагым, күзгә чәчәкләр матурмы? Синең өчен үскән алар. — Гафур хатынын биленнән кочаклады.. — Әрем әче инде ул.

— Минем тормышым төсле...

— Ничек?

— Мина күнелсез.

— Ә син иҗат ит, аппагым, — диде беркатлы ир. — Хәтерлисеңме, без өйләнешкәндә син көненә икешәр-өчәр шигырь яза идең? Илһам синең түреңә үк кунаклаган, безгә сүз алышырга ирек бирми иде.

— Алдама, синең үз эшең куәтлерәк иде ул чакта. Сыер, үгез, тана иде синең бөтен хәсрәтең.

— Шатлыгың, диген, аппагым. Мин бит хуҗалыгыбызны тернәкләндердем. Боерса, терлек санын арттырабыз әле. Әкрен генә кинәя-зурая мегаферма төзербез, шәт.

— Без димә, мин дип күкрәк как. Хуҗалык — ул синеке.

— Юк, безнеке!

— Юк, синеке!

Кырлы-мырлы сөйләшкән Гүзәлия, аның кулыннан ычкынды да, киштәрдәге ике китабын учлап шап-шоп өстәл кыйнарга керешге.

— Менә болар минеке! Мин язган! Мин! Яшьтәшләрем дүртәр-бишәр җыентык бастырды. Аларның исемен халык белә! Алар танылды инде! Без, синең белән икебез ике дөнья кешеләре, икебездә ике төрле шөгыль!

Гафур өчен көтелмәгән ачыш иде бу. Ир белән хатын бербөтен җан түгел икән лә. Күр, аның яратып туймаслык ягымлы һәм мөлаем Гүзәлиясе аждаһа кебек авызыннан ут чәчә!

— Букка чумган сыер-таналар, печән чүмәләләре, тирес өемнәре, бәрәңге бакчалары — синеке! Аягыңдагы кирза итекләр, өстеңдәге сырган фуфайка — синеке! Синең бөтен уең — ферма! Ярася, тизәктән дә акча сугар идең.

— Акчага табынмыйм мин, аппагым. Авылны яшәтәсе килә, шул гына.

— Яшиме соң Җиде Чишмәгез?! Мәдәният йорты белән мәктәп ишегендә йозак! Ирләрегез эчә, әбиләрегез көмешкә коя.

— Яшәр, — диде ир. — Нишләп яшәмәсен ди. Әнә, Мөбәрәкша бабай оныгы Илдус, Гафур абый, синнән күрмәк мин дә фермер булып теркәләм, токымлы кәҗәләр үрчетәм, ди.

Моннан өч ай элек хатыны бер кәефсезләнеп алган иде инде.

— Язылмый, — дигән иде ул.

— Нишләп? — дигән иде ир.

— Кризис...

— Илдәме?

— Минем күнелемдә, — дигән иде хатын. Гафур моңа илтифат итмәгән иде. Шул вакытта ук шеш тулган булган икән, инде менә тишелде.

— Ике генә җыентык белән чикләнмә, өченчесен, дүртенчесен туплап чыгар, аппагым.

Хатын аның һәр сүзенә бәйләнә иде.

— Бетем беләнме? Мин каладагы язучылар шикелле көн саен нәшрият-редакция тирәсендә чуалмыйм. Мөхәррирләр белән дә дуслыгым чамалы. Алар минем дөньяда барлыгымны да оныттылар, — дип үксергә үк тотынды Гүзәлия.

— Түләп бастырыйк, аппагым!

— Нинди акчага?

— Безнекенә! — диде Гафур да, кызып.

— Бүтән безнеке димә!

— Хуш, минекенә! Ник син китап турында моңарчы әйтмәдең, аппагым?

— Шуннан ни файда? Синең хуҗалыгың капкорсак төсле: йота да йота! Башта сиңа биш кенә сыер кирәк иде, аннан аппетитың үсте, тагын биш өстәлде. Аннан йөк машинасы, аннан тегермән, аннан орлык! Муеннан кредитың. Тагын нишләрсең икән?!

— Җирләр алам, иген игәм. Авыл тегермәнендә тарттырган оннан пешергән ипи бик тәмле ул, аппагым.

— Минем китабым чиратның койрыгында икән, — диде Гүзәлия, кызганыч тавыш белән. — Синең акчаңа брошюра да чыгармыйм әле мин!

— Чү, аппагым, алай усалланма. Йә, нишлим, боер. Үзеңне Кинә тавына күтәреп менимме? Сине ул тау ничә шигырьлек хисләндерде әле? «Аның түбәсендә учларыма йолдыз чәчелә», — дия идең.

— Менмә!

— Бу шәмәхә чәчәкләрнең кайсы уентыкта үскәнен күрсәтимме?

— Күрсәтмә!

— Урман һавасы сулатыйммы? Поши малайлары белән таныштырыйммы?

— Сулатма! Таныштырма!

Хатын керпе сыман инәләрен тырпайтты.

— Ниш-лим? — диде Гафур, гаҗиз булып.

Гүзәлия йөзен аның күкрәгенә терәде. Бармаклары белән ирнең колак яфрагын кытыклап:

— Мине әле дә яратасыңмы? — диде.

Ике дә уйлап тормыйча «әйе» дип җавап бирердәй иң җиңел җавап иде бу.

— Җаным-тәнем белән яратам, аппагым!

— Мәхәббәтебез хакына минем бөтен теләкләремне дә үтисеңме?

— Боер дидем бит, аппагым.

— Казанга китик!

— Ә?

— ...туйдым мин ябылып ятудан! Туйдым авылдан! Яңгырыннан, карыннан, иләмсез көзге кичләреннән! Минем иҗатташларым белән кичәләрдә катнашасым, әдәби салоннарда шигырь ярышлары оештырасым килә-ә! Анда сиңа да эш бар. Абый депутат, министрлыкта урын җайлыйм, ди. Әниләрнең фатиры иркен, биш бүлмә. Китик, Гафурым! Синең авыл дип йөзгә ярылуың кемгә хаҗәт? Җиде Чишмәгезнең гомердә дә тереләсе юк.

Ир юмаланып муенына уралган хатынны диванга селтәп атты:

— Китмим мин авылдан!

Хатын-кыз куенында бөгәрләнеп елан ята һәм ул бер чага икән. Әнә, яратыр өчен яратылган нәфис күбәләге өр-яңа яктан ачылды. Кара син, мыштым гына усаллык исәпләп йөри икән! Ир-ат куенында исә балта ята, ул да бер чаба икән. Селтәп кенә атты аппагын Гафур. Менә бу — тупаслык инде. Беренче тапкыр ир аранны җимергән айгыр кебек дулады. Ачу яман кимчелек икән.

Гүзәлия елап калды, ул аш бүлмәсендә табак-савыт юган Мингайшә апасының күзенә чалынмаска тырышып, ишегалдына сызды. Бәлки, тәртәгә тибеп алуы ярап куяр. Моннан соң, бәлки, хатыны «синеке», «минеке» дип, гаиләне урталай ярмас. «Казанга китик», — дигән коточкыч тәкъдиме белән дә ярсытмас. Кыр-басуларны рәсмиләштергәч, җәренгә, боерса, бодай белән арыш чәчәр. Икмәкнең әзрәген сатса — кулга акча керер һәм Гафур иң мактаулы нәшриятта хатынының шигырьләрен бастыртыр. Ник юк-бар өчен үпкәләшергә, аппагым. Букка чумган сыер-таналар дигән

ямьсез сүзләрне син ничек оялмыйча әйттең соң әле? Син бит сүзләрдән үтә күренмәле челтәр үрәм дисең, аппагым. Ташла, ир-ат башың белән үртәлмә, Гафур! Хатын-кыз белән чәкәләшәсең икән, «авырта» дип тиресе суелганчы мангаеннь ышкыма!

Алмагач куаклары уртасында ул нарат бүрәнәдән «Сыерчык оясы» төзеттергән иде. Кунак өе дип аталган әлеге куыш махсус депутат абый өчен эшләнгән, сайлаучыларыннан гарык булган яисә сессияләрдә законнар төзәтеп арган Гаяз Идрисович монда өч-дүрт тәүлек ял итә иде. Аның портфелендә биш йолдызлы коньяк жемелдәр, һәм жиннәрен сызганып тутырган тавык боты кимергән депутат агай һаман да хужаның бер «кимчелеге»н тәнкыйтьләр иде.

— Син йөз грамм кәкмисең, кияү. Пример, сез — фермерлар жыелышып мәжлес укмаштырасыз ди. Барлык иптәшләрең дә кабып куя ди. Капкан ир-ат обязательно жә начальствоны сүгә, жә гүләйт иткән хатыннары белән мактаныша. Айнык кеше исә дәшми. Вот шунда коллегаларың синнән бизә дә инде. Жә бу безне Фәлән Фәләновичка әләкли, диләр, жә бу слабак ир, диләр.

— Мин өйләнгән, Гаяз Идрисович, — ди Гафур. — Минем хатыным — сезнең сеңелегез ягъни.

— Да, син өйләнгән, — ди депутат абзый. Ләкин баш миен хәмер тамчылары кыздырган кунакның үз мантыйгы мантыйк иде. — Эчмәгән кеше беркая да сыймый, кияү. Тамак төбемне юешләтмим дисәң, иреннәнне генә чылат! Эчкән кыяфәт яса! Партизан булма! Пример, сезнең район главасы кыстый ди. Давай, Гафур Сөләйманович, минем исәнлеккә берне тот, ди. Нишлисең, кияү? Тәгәрәп үлсәгез үлегез, Фәлән Фәләнович, ну мин сезнең исәнлеккә эчмим, дисеңме?

— Безнең хаким ашказаны жәрәхәтеннән жәфалана, Гаяз Идрисович. Аракы белән дус түгел.

— Алай икән. — Хатынының абыйсы бүтән бәхәсләшми, әмма икенче тапкыр килгәч, коньяк шешәсе бушагач, тагын куерган ботканы болгата иде.

Гафур «Сыерчык оясы»на керде, курткасын салып ташлады да, шырпы сызып мичкә тутырылган утынга ут төртте һәм бар буе белән караватка сузылды. Киштәдә гармун, ә дивардагы чөйдә иске мылтык эленгән иде. Бервакыт өч угры аның хужалыгына һөжүм итте. Тыкрык башындагы үзбушаткыч машинага болар, мөгаен, терлекләр төямәкче иде. Аллаһы Тәгалә алдан ук хәбәр салгандыр, Гафур кичтән чормадагы мылтыгын чистарткан гына иде. Ул эт өргән тавышка тышка чыкты. Бакчада ат пошкыра, сарыклар мәэлдәшә иде. Ир ишегалдында мылтыгыннан бер гөрселдәтте, аннан абзар почмагында икенче тапкыр һавага төзәп атты. Шәүләләр машинага табан чапканда уч төбе кызып, сөрлегеп егылган өченче каракның арт чүмеченә «истәлеккә» утлы ядрә утыртмакчы иде, акыл тыйды: «узынма, егет!» Шуннан бирле озын саплы «тугры дус» сакта тора. Ә ул бит угрыларны төсмерләде. Үзәк базарында Чабак Садри малае ит сата, ә үзе йортында аксак кәжә дә асрамый иде.

— Сугымлык терлек кайдан аласың? — диде Гафур.

— Самарадан, — диде Садри малае.

Ул тезен чалбар өстеннән генә пычрак сөлге белән бәйләгән иде.

— Каймыктырдыңмы?

— Ахрысы, малай. Каты гырдага бәрдем.

— Сәүдән гөрләсен, — диде Гафур һәм киная белән: — Самара минем бакчада түгел, юлларны буташтыра күрмә, — диде.

Ул «сөйләшә-сөйләшә» янган учакны ярата иде. Каен утыны сүзгә

саран, шылдырт иттереп күмерен төшерә дә, «авызын» яба. Юкә черт-черт төкеренеп, чаткысын чәчкән кылана. Анын бытбылдык хатыннар кебек «сүзе» күп. Усак (бигрәк тә чи усак) башта пышылдый, аннан табада коймак пешергәндәй чыжылдый, ә инде тәмам җылынгач, кайнар яшен агызып җәлләтә... Һәр агачның үз холкы! Элек Гүзәлиясе мичтә кабыклы бәрәңге тәгәрәттерә иде. Анын өчен ул иң тәмле авыл сые иде. Соңгы вакытта хатынының бәрәңге дигәне юк. Мич тә яккан юк. Туктале, бәхетле мизгелләрне кабатларга кирәк. Ир сарай нуешендәге лардан эре-эре бәрәңгеләрне чүпләде. Мичнең күмерен соскыч белән тимер савытка көрәгәч, кызган ташка «җир алмалары»н ыргытты.

— ...кабыгы каралып көйгән, әти.

— Аша, аның күмере эчәкләрне чистарта, улым.

— Кырда пешергән бәрәңге ярмалы, иеме, әти?

— Сорты шундый, улым. Икенчедән, ул колхоз кырыныкы. Уртак табакның ашы тәмле була, улым.

— Ипи башмы, бәрәңгеме, әти?

— Ипекәй йөрәкне ныгыта, бәрәңге ашказанын юата, улым. Алып барам, кире алып кайтмыйм дигән ди бит ул. Дөньяда өч нәрсә махмырлатмый, улым. Берсе — ипекәй, икенчесе — бәрәңге, өченчесе — су.

— Син нигә ашамыйсың, әти?

— Әрвахлар ашамый шул, улым. Безнең ризык — сез кылган дога...

— Син үлдеңмени, әти?

...Гафур сискәнеп уянды. Көпә-көндез йоклап кителгән. Ару галәмәтеме? Нервылар тынычланганмы? Хәер, тынычланырга иртәрәк әле. Гүзәлиясен тәмле сые белән сыйларга иде. Әтисе... Борчылса, шулай төшләр аша йөрәккә шакый, мәрхүм.

Хатыны бүлмәсенең ишеген ачмады.

— Аппагым, кап-кайнар бәрәңгеләрдән авыз ит, — дип ни ялынса да, эчтә өн-тын ишетелмәде. Хатын-кыз үпкәләсә күкләрне болыт сара шул! Ир, кулындагы коштабагын тавыклар тагарагына илтеп бушатты. Ялгыз башка барыбер тамактан үтмәс иде.

Кое янында апасы Сәлимәнең бәгырендә казына иде.

— Серенне белермен мин, күке кызы!

Хатын-кыз аны җиде йозакка бикли. Җинел генә белә алмассың шул, апа. Гафур, әнә, без Гүзәлия белән бер тән, бер җан дип яши иде, баксаң, аппагының күңелендә әллә ниләр бар икән.

...Сәлимә, итекләрне юып, чирәмгә куйды.

— Рәхмәт, Гафур.

Кәс-кәс басып, койма буеннан гына өенә табан атлаган хатынга Мингайшә апасы, бүре күзләре белән акаеп:

— И-и, ничек артын уйната. Сине кызыктырмакта монын бөтен уе, энем, — диде. — Әртислегенә чыдаш түгел, бер Ходаем! Күке тек күке!

— Апа, бәйләнмә, — димәкче иде ир, капкадан юл сумкасын җилкәсенә аскан Гүзәлия чыкты.

— Гафур, мин өч-дүрт көнгә Казанга китәм, — диде ул, аска гына карап. — Нәшриятка кульъязмаларымны тапшырам.

— Әбәү! Ниткән Казан? — диде апасы.

— Кысылма, апа! — Гафур хатынына гаҗәпләнеп карады. Монарчы алар шәһәргә гел икәү бара иде. Сирәк баралар иде, билгеле. Чөнки каланыкылар кияүне өнәп бетерми иде.

— Мин синең колын түгел, Гафур! Мин — ирекле кеше.

— Сине беркем бәйләп тотмый, аппагым. Җыентыгына акча мәсьәләсе...

— ...бушлай бастырсыннар! Мин — талантлы шагыйрә!

— Үзең күрәсең, тездән пычрак! Җиңел машина бата. Сөтнеке белән илтәм мин сине. Хәзер, киенәм дә, — дип ашкынган иргә хатыны, тупас кына:

— Илтмә! — диде. — Мине олы юлда көтәләр инде!

— Кемнәр?

— Дусларым. Сорау алма миннән, яме? Көнләшмә дә! Мин сиңа хыянәт итмим. Син кемнәр белән генә аралашмыйсың, нинди генә хатыннарны машинаңда ташымыйсың!

— Әбәү, катыннар диме? — Апасы киленен җайларга маташты. — Күке генә бит ул!

Гафур:

— Сумкаң шактый авыр, юлга хәтле озатам, — дигән иде, хатын кулларын аркылы куйды:

— Мәшәкатьләнмә!

Апалы-энеле капка төбендә сураеп калдылар.

— Ник җибәрдең, җебегән!

— Нәрсә, апа?

— Ирме син, йа? — Апасы кайнап ташыды. — Шушы чебеш хәтле генә катыныңнан җиндерәсең. Өч ел иркәләп боздың да, хәзер үзеңнән чиркана, чүлмәк гөле! Берсендә утырмага җыенган идем, җизнәң чәчемнән караватаягына бәйләде. Буе тәбәнәк иде дә, вәләкин настояшни ир иде, мәрхүм. Тормышың ватыла, энем, төзәтү ягын кара!

Ир-атның да сере була. Бәлки, ул аны җиде генә түгел, кырык тугыз йозак артына яшерәдер. Бу серне ачып бетерер өчен фанилык гомере генә аздыр. Бәгырен ялкын чолмаган ир кырык тугыз йозакка берьюлы селтәнде:

— Бала юк безнең, апа! Бала юк!

Апасы шалдор-шылдыр тактага бидоннар тезде.

— Ишетәсеңме, апа?! Бала юк безнең! — дип сыкранган иргә:

— Ишетәм, — диде. — Өзгәләнмә! Кыз туса — ялкау әнкәсенә охшар иде. Ә малай... сиңа малай таптырырга ярамый, энем! Безнең нәсел ирләре каргалган! Шушы күке Сәлимәсен җир читенә кудыртыр идем, әй. Шул катын күренгәннән бирле намазларымны саташтырам. Синең башыңа кайтты ул, эне-ем!

## VI

...Урталай сыгылган черек матча бүрәнәсе бер сынар микән? Ничек тә бу кышны хәвеф-хәтәрсез генә уздырасы иде. Җәй җәй инде, кояш үзе зур мич төсле сөякләреңә кадәр җылыта.

Салкыннар башланды исә Сәлимә шәһәр урамнарында каңгыраган хуҗасыз этләрне җәлли иде. Койрыкларын бот арасына кыстырып, туныпөшеп чабалар. Ә җәйләрен алар өчен сөенә иде. Туңмыйлар ичмасам. Менә үзенә дә эт тормышы килде. Мүге сирәкләнгән бүрәнә ярыкларыннан җил ыжгыра, шиферы чатнаган түбә тишегеннән яңгыр ява... Ул монарчы гел өметләнде: улы Фәрит юл унае һичшиксез сугылыр, әни, ни хәлләрдә яшисең, дияр. Казанга кайт, оныкларыңны сагынгансыңдыр димәсә дә, әни, мин акча эшлим, мә, унбиш-егерме мең, йортыңны төзекләндер, дияр. Сугылмады Фәрит. Варвара килен аны кай төше беләндер сихерләгән иде.

Сәлимә иртән, тәвәккәлләп, авыл җирлеге башлыгы янына барды. Ачык йөз белән каршылады аны Туктар.

— Син, Матур апа, безгә карендәш, — диде башлык. — Үзем дә хәлеңне белмәк идем шушы көннәрдә. Җиде Чишмәдә озаккамы?

— Үлгәнгә кадәр, карендәш.

— Китче! Сезнең йортыгыз җимерек бит!

— Әзрәк сипләсәң, терәү терәтсәң — җан асрарлык, карендәш.

— Син яшь, чибәр, Матур апа. Казанны караңгы авылга алыштыруың гаҗәп. Без мондагы баткаклыктан ничек качыйк икән дип уфырабыз.

— Һай, качулары җиңел ул, аның өчен әлләни батырлык кирәкми, карендәш. — Хатын егетнең мескенләнүен өнәмәде. Хакимият, янәсе! — Элеккеге заманнарда авылда меңнән артык йорт иде, ә бүген синең карамакта ничә җан?

— Җиде йөз җитмеш, Матур апа. Карты-яше, үләсе-туасы белән. Аның Гафур кебекләре үзләре йөз кешегә торырлык! Өч ел инде бимазалый Сөләйман калдыгы, хәзер инде җир дип җелегемне суыра, дошман!

— Ай-һай, бигрәк кискен түрә икән син, карендәш! Кайчан аның белән дошманлашып өлгердең әле?

— Хәтерең тутыккан ахры, Матур апа, — диде җирлек башлыгы, урыныннан калкынып. — Сөләйманнар борын-борыннан безнең нәсел дошманы!

Хатын карендәшен куәтләмәде.

— Туктар, әтиләрнең нигезе, чынлап та, искергән, — дип, үз йомышына күчте. — Минем сездән берни таләп итәрлегем юк. Үсмер чагымда әни өчен каникулларда колхозда яшь бозаулар тәрбияләштем. Шуннан гайре Җиде Чишмәгә чәнти бармагым хәтле дә ярдәмем тимәде. Әти тракторчы иде, аяклары шешеп үлде. Ул чакта фермаларда тизәк боламыгы иде, резин итекләр, салкын тартып, әнинең исәнлеген бетерде. Аларның хезмәте хакына өемне әз-мәз ремонтларга булышмас микән җирлек, карендәш?

Туктар, бетләгән сыман, озак кына баш түбәсен кашыды.

— Хм... Театрда уйнадыңмы әле син, Матур апа?

— Юк, сәхнә киемнәре тектем.

— Хм... Театрда бөтерелгән кеше почти артист инде, Матур апа. Тел чарланган синең, дөресме? Абруй зур, дөресме? Как-никак, сәнгать әһеле! Әле син берәр фирка әгъзасыдыр? «Бердәм Россия»некеме? Миңа халыкны кузгатырга иде. Җыелышта Гафурга каршы башлап син чыгыш ясыйсың, Сәлимә апа! Сытабыз дошманны! Басу-кырларга борынын сузмасын Сөләйман малае. Аларга хуҗа бар, бай инвесторга тәгаенләдем мин җирләрне, вот!

Сәлимә иелә-бөгелә көлде. Күзеннән яшь атылды хәтта.

— Һай-һай, кем диим икән мин сине, карендәш? Бөтен сыйфатларыңны берләштерерлек исем кирәк иде дә сиңа... Тел байлыгым ярлырак ахры. — Хатын ишекне этте дә, баш аркылы гына: — Таптым, таптым, — диде. — Кабахәт син, кабахәт!

Ул юл буе хәтерен актарды. Туктар әтисе ягыннан ботак очы иде. Әниләре күрше-күлән белән әрләшмәде, йомшак күңелле, күндәм хатын иде мәрхүмә. Сыерларны да ул назлап-иркәләп кенә сава иде. Әтисе исә кырку иде. Явызлыгы да чиктән ашкан иде. Сөләйман абзыйларның әтәчтавыклары бакчаларында тибенсә, таш белән бәреп имгәтте. Күршеләрнең сарыклары да әтисеннән җик күрде: бәрәңге сабагын таптаганнар дип, ул хайваннарның колагын кисте. Күршеләрнең гауга куптарганын хәтерләми менә. Бик сабыр иде Гафурның атасы. Берсендә генә агроном Сөләйман шартлады. Ике ирнең тавышы урамны яңгырата иде.

— Ник басуны сай сөрдең, Хәмит? — диде агроном Сөләйман. — Туфракка бармакны кадасаң — кап-каты.

— Бик мачтыр икән, үзең сөр, — диде Хәмит.

— Сөрермен дә! Тракторны турга китереп бастырган бул!

— Акылың алтын икән, Сөләй балыгы!

— Минеке алтын, синеке — күгәргән калай, Хәмит.

— Бугаз киермә, Сөләй балыгы! Мина прсидәтел хужа, бу факыт!

— Хет ун председательгә буйсын, анда минем эшем юк, бу да факт! Кырларны жиренә житкереп кенә сөр! Нишләп син жиркәйнен битен генә тырнап җылатасың? Һава житми аның үпкәләренә, сулый алмый жиркәй! Басу бит тилмереп безгә карый, жанлы бит ул! Шул жиргә кереп ятасыларың бар, имансыз күке!

Өченче-дүртенче буыннарда туганлык җепләре нечкәргәч, кемнең кем икәнен аеруы да кыен шул. Сәлимә уналты яшендә авылдан киткәндә ике-өч яшьлек Туктар әнисенең итәгенә маңкасын гына сөрткәндер әле. Фәләк оныгы бит ул, бабасы кебек усаллык кына исәпләп йөри әнә. Фәләк карт әтисе Хәмитне гел Сөләйманга каршы өстерә иде.

— Без, күкеләр, шыпырт кына Айсиннарның миен чукыйк, Хәмит энем, — дия иде ул. — Авылга баш итмик без аларны! Ату Сөләйман мин агранум дип кәперәя. Бүген кыр-басуларга хужа булыр, иртәгә прсидәтеллеккә сайлаттырыр. Райунына жалу яздым, исемсез жалу, энем. Синең белән төнлә печән кибәнен яндырган идекме, Хәмит? — яндырган идек. Кем кулы дип тикшерәләр анау. Кибәнгә сөялеп агранум Сөләйман тәмәке пыскытты да төпчеген сүндермәде, дидем. Ыштыраф чәпәсеннәр шуңа, әйеме, Хәмит энем.

— Без, бабай, икенчерәк нәрсә укмаштырыйк. Сөләй балыгы тәмәке тартмый, бу факыт, — диде әтисе, тешләрен шыкылдатып. — Төрмәгә олактырасы иде аны, төрмәгә!

Фәләк карт белән әтисе, күрәсең, мәкер ятьмәсен үргәндер, әмма «Сөләй балыгы» аңа эләкмәгәндер. Аннан ул якты дөнья белән дә иртәрәк хушлашкан икән. Менә хәзер шул чакларны уйлый-уйлый да, тәмам аңгырая Сәлимә. Авылдашлар ни-нәрсә бүлеште икән? Жиде Чишмә ин зур аймактыр, мөгаен. Урамнар тар иде микән аларга? Кара-каршы очрашканда терсәкләре бәрелеште микән?

Сәлимә чишенгән генә иде, дак-док ишеккә суктылар. Туктар икән, егет борыны тыгылгандай, авызы белән генә сулый иде:

— Эсселәдем, уф! Ну элдертәсең, Матур апа, үзеннән жил көнләшә, валлаһи, дим. — Авыл жирлеге башлыгы буявы кыршылган урындыкка артын төртте. — Без синең белән тәки туганнарча аңлашмадык, ә! Болай әллә ничек кенә.

— Син, кем... — Хатынның карендәш диясе килми иде. — Бабаң Фәләк исемле идеме әле?

— Фәләк! Мировой карт иде бабай!

— Әтиең Фәйзетдин, әйеме?

— Миңа ике яшьтә әти үлгән. Бабай үстерде мине, Матур апа.

— Сизелә-ә, — диде хатын. — Болай әллә ничек кенә дисенме, Туктар Фәйзетдинович?

— Безнең кушаматыбыз уртак, без — Күкеләр, Сәлимә апа. Туганнар, кыскасы. Бер-беребезгә ярдәмләшик, дим. Уһу, синең матчаң кәнтәя икән! Безнең жирлекнең бюджеты өч тәңкә, матур апа. Спонсор табам мин сиңа, ә син...

— ...минем себеркем бул, яла-гайбәт чүпләрен себер, Матур апа.

— Ну тәл-тәл дә син, Матур апа! Йортыңда куанып-шатланып яшә димәкче идем. Жирең зур. Кстати, Сөләйман малаен кисәт: язга бакчаңны чистартсын. Ату жалу язам дип, астына ут үрләт!

— Кинәшләренә рәхмәт, кем, Туктар Фәйзетдинович! Спонсор эзләмә, яме?

— Матчаң ишелсә — нишләрсең икән, Матур апа?

— Жилкәм белән терәтермен, яме?

— Курчак өе ясаттырам үзенә, идәннәрен җәйдерәм, тыштан ярты кирпеч белән тышлаттырам. Берләшеп, Сөләйман малаен гына сытыйк, Матур апа, дим! Без — көчле нәсел, без — күкеләр. Гафур минем урынга ыргылачак киләчәктә, безне изәчәк ул. Миңа Фәләк бабай васыять калдырды, бөркетләрнең канатын сындыр, диде.

Егеттә иман әсәре юк иде. Шәһәрдә генә көнче түрәләр кәнәфи өчен бер-берсенең бугазын чәйни дисә, авылларда да беттән азган вак хәшәрәтләр тешләшергә өйрәнгән икән.

— Энем, минем башым авырта, зинһар, кит, — диде Сәлимә. Ул инде «карендәш»еннән ярдәм сораганы өчен мең кәррә үкенә иде. Театрда, декорацияләр корганда, егетләргә анысын-монысын тотышып булыша иде. Терәү куешканы да булды. Сарайда тузанлы жирдалар бар иде, ул шуның икесен сөртеп, матчаның кыл уртасына «кадады». Сөбеханалла, колонналар залына охшады әле өе!

Урамда машина кычкыртты. Йа Аллам, хәерсез Туктарның хәерсез спонсоры мәллә?

Хатын жилкәсенә шәлен генә ябып, ишегалдына чыкты. Жир туңдырган иде, аягы таеп, әз генә егылмады. Авып жиргә сыланган капка хәрабәләре өстендә мендәр корсагын тибрәндереп Әнәс басып тора иде. Сәлимә салкын гына күреште.

— Өенә — жылыга чакыр. У-у, суык бабай биттән чеметә, — дип, ир такта сыныкларын атлап үтмәкче иде, хатын:

— Ирем юк бит минем, ялгыз хатын кунак чакырмый, — диде.

— Беләбез! — Әнәс алтын тешләрен жемелдәтеп «хих-мих» диде. Янәсе, казыдык, сереңнең тамыры тирәндә түгел икән. — Өч атна элек Шәрбәнбану юлында бигрәк төксе сөйләштең син, сыйныфташ! Бу дим, бигрәк житди, укытучыдыр инде, дим. Хих-мих, син театр мәчесе икән, күке! Таныш безгә артистлар дөньясы, шәп таныш! Үзебез дә жырлаштырдык заманында. Гастрольләрдә ире-хатыны коммунизм юрганына төренеп йоклыйсың. Иртән кем кемне кочкан, кем кемне үпкән, берсе дә хәтерләми. Закон шундый: хәтерләмәскә! Артистларга гына хас тәртип димәс идем мин моны. Безнең районда элегрәк хакимнең урынбасары Фәридә Барласовна чеп-чи сүгә иде колхоз рәисләрен. Миңа шактый эләкте аңардан. Шулай агроном белән УАЗикта чәчүне тикшерәбез. Фәридә Барласовна очрый. «Ник икәүләшеп тотынышып йөрисез, әллә сез зәңгәрләрме?» — ди һәм йомры-йомры сүзләрне очырта гына авызыннан! Сүгенү ярышларында берсе дә урынбасарны жиңәлмас иде. Бүген апабыз — абыстай. Ак яулыклы Ак апа. Мәжлесләрдә Коръән укый. «Ну сәнгать дәрәжәсенә житкереп, матур да сүгенә идегез!» — дигән идем, Ак апабыз хәтерләми. «Ник мине каралтасың, тәмуг кисәве», — ди.

— Карале, Әнәс! — Сәлимә шәлен муенына урады.— Сигезенче сыйныфта, математика дәресендә Илсөяр апа бер егетебезгә тактада мәсьәлә чишәргә кушты. Чишәлми генә егет! Югыйсә жип-жинел. Бичара, тугызга тугызны тапкырлый белми икән. Без аңа пышылдыйбыз, сиксән бер дибез, ишетми. Илсөяр апа: «Дәрес азагына хәтле чиш, утырма», — диде. Ә үзе безгә өй эшен яздыртты. Бервакыт такта янында күлдәвек жыелды. Егетебез астына пес иткән, һай-һай! Син хәтерләмисеңме, кем иде әле ул чалбар төбен юешләткән сабакташыбыз?

— Бәс, жыелышка соңарам икән, — диде Әнәс беләгендәге сәгатен селеккәләп һәм машинасына чумды.

«Син идең ул, Әнәс, син идең! Хәтерләмисеңмени? Кешедән көлүе рәхәт, әлбәттә».

## VII

...Ул аны койма буенда сагалады. Бәргәләп, тузаннарын каксаң — комачауламас иде. Кабинетында диктофон кабыза, янәсе, янасаң, яздырып, полициягә хәбәр итә.

Туктар Ильясов Сәлимәләрдән чыкканда кызарган-бүртенгән иде, кинәт кенә каршында калыккан Гафурдан өркеп, артка чигенде.

— Сук кына! Хакимият вәкилен кыйнаган өчен статья каралган!

— Сукмыйм, кабинет күсесе! Сине үтерсәм, кем безнең башларны кимерер, — диде Гафур, алай да, башлыкның беләгеннән боргычлады. — Кайчан минем гаризама култамганны саласың?

— Пай җирләре халыкныкы, халык ни дияр!

— Буш җирләр ничаклы бездә, аларга син ни диярсен, ә?

— Син, Гафур абый, авыл кешеләре белән дуслаш.

— Мин һәркем белән дус. Җыелыш көнен билгелә, кабинет күсесе!

— Билгелим, Гафур абый. Җибәр, кулымны сындырасың!

Ирләрчә сөйләшү булмады, тузаннар кагылмады. Бүген иртән үк кәеф әйбәт иде. Казаннан Гүзәлия шылтыратты, иртәгә мине көт, диде. Күкрәгендә үрле-кырлы шатлык сикерә, шуңа күрә Туктар Ильясов алар урамыннан исән-имин кыяклады.

Мингайшә апа гына ухылдады:

— Күкеләр берләшә, энем, — диде. — Сәлимә белән Фәйзетдин малае — туганнар.

— Ярты авыл бер-берсенә туган, апа.

— Күкеләр асубый туган, энем. Болар үчтән әвәләнгән бисмилласыз халык. Башыңны юк белән катырмыйм дигән идем дә, күке кызы кайтып шикләремне ишәйтте әле менә.

Әбиең бәянын гына сөйлим, аңа әбисе сөйләгән, ди. Үземнән мыскал да ят әйбер өстәмим. Тарих диләрме әле үткәннәрне китап язучылар? Бу тарихның очы ерак-еракта, энем. Безнең Мөхәммәтъяр исемле бабабызга синнән чутласаң, мең дә җидейөзенче елларда Аллаһ җан иңдергән.

— Апа, әгәр син безнең нәсел шәҗәрәсенә экскурсия ясыйсың икән, вакытымны урлама, мин Казанда укыганда ук архивлардан документлар укып, аны үзем төзегән идем, — диде Гафур.

Ләкин апасы:

— Тыңла! — дип боерды. — Исемнәре белән ел саннарын куйган да, шәҗәрә ясаган ди берәүсе! Төбен актар син әүвәл, укымышлы карга! Мин җиде кылас грамытым белән дә синнән башлырак, энем. Әбинең бәяны кызганыч, энем. Ерак Мөхәммәтъяр бабай Җиде Чишмәнең мулласы була. Ә күкеләрнең шундый ук ерак бабасы аңарда батраклыкта эшли. Кыш аенда кое казыта Мөхәммәтъяр батрактан. Кое ишелә дә күкеләрнең ерак бабасын кызыл балчык баса. Үле гәүдәсен дә табалмыйлар, чишмә юлына эләгеп, су агызган, имеш.

— Әкияттер бу, апа.

— Әкиятләрнең ахыры күңелле тәмамлана, энем. Күкеләрнең ерак бабасының ун баласы ятим кала. Катыны, Мөхәммәтъяр бабаларның турларында ауный-ауный җылый, аның аунаган җирендә бозлы кар эри, энем. Шунда күке катыны безнең нәселне каргый. Туган һәр ир балаларыгыз, җиде буынга тиклем яшьләй тәгәрәпләр үлсен, ди. Әстәгъфирулла, аның каргышы төшеп бара кана! Моратхуҗа, Сәлимгәрәй, Кыяметдиннәрне кырык яшьтән соң Газраил берәм-берәм чүпләде. Чирләсәләр бер хәер иде. Тап-таза ирләр кана! Аларның каргышы күке тавышында, имеш. Кәк-күк диләр дә, гумерне кисәләр. Сөләйманга да шулар кычкырдылар!

— Әйе, әти берсендә урманда кәккүктән юраттым, ике генә ел яшисе

икән, диде. Аның да, синең кебек акылы таралган иде, ахрысы, апа. Хорафат бу, апа, хорафат. Мин дә еш ишетәм кәккүк моңланганын, мин дә шаяртып кына, әйдә, сана минем гомеремне, дим.

— Ишетәсеңдер, рас. Күке Сәлимәсе синең башыңа күкелди кана. Ниндән куркам, син — жиденче буын ир бала, энем! — дип чын-чынлап хафага төшкән туганын Гафур оялтырга маташты.

— Үзең намаз карчыгы, үзеңнең авызыңда гел килделе-киттеле сүз, апа!

— Сезнең шул инде, хәзерге яшьләрнең! Ни бәддогаларга, ни каргышларга ышану юк! — Апасы сузып-сузып сукранды да, усал гына: — Күке кызын Вәлетдиннәр йортын алырга күндер! — диде. — Аркага арка терәшеп яшәрдәй күрше түгел Сәлимә. Аның нияте ачык миңа: ташкаласыннан сине бетерергә кайткан! Алдан хихый-михый уйнап, сине гыйшык иттерер. Әртис бит. Сез ир-ат халкы тиз йомшыйсыз, ә син чүлмәк гөләнә өф-өф, дип, жил дә тидертмисең. Шуннан соң күке нәсел каргышын яудырыр.

— Юкка йөрәк бозма, апа. Каргышы-бәддогасы бардыр, бәхәсләшмим. Ә күкесе — уйдырма. Сәлимә эченне көйдерә синең. Нишләп син шул хәтле хатын-кызларны күралмыйсың, апа? Сиңа Гүзәлия дә начар. Әллә жизни мут идеме? Кыз-кыркын белән шаярдымы?

— Мин моны инкяр итмим дә, энем. Толбикәләргә юаткыч иде шул жизнәң. Амбар мөдире, ашлы хужа. Тавыгыма ике-өч уч бодай бирче дип йөрештерде шул кыз-катын. Бөртеккә оялаган күгәрченнәрне куарга да чакыра иде. Яле, энем, сүзне икенчегә борма!

Мыек астыннан гына апасыннан көлгән Гафур соңыннан «Ә ник алай икән?» дип уйлады. Ике нәсел — күкеләр белән бөркетләр (монысы аларның кушаматы иде) гомер бакый бер-берсе белән тынышмаган. Сугыш мыштым гына — эчтән генә барган. Бусы жиңгән, тегесе жиңгән диярлек түгел. Бабайлар ничегрәк яңаклашкандыр, Гафурга анысы караңгы, ә менә күрше Хәмит абзый кош-корт жәллады иде. Күп аксатты ул чебеш-тавыкны. Ул гынамы, койма аша яшелчә түтәлләренә күсе, тычкан үләксәләре ташлый иде. Берсендә Гафур (аңа унике яшь иде) урманнан кайтканда, аны трактор куып житте. Малай читкә тайпылып, аңа юл бирмәкче иде, тимер ат аның өстенә ыргылды. Кабина тәрәзәсеннән Хәмит абзый ыржая иде. Эчсә — юлында ни очраса, шуны изә-сыта ул диләр иде. Юк, шар ачык иде абзыйның күзләре! «Таптата!» — диде Гафур, һәм дуфкымга йөгерә башлады. Ләкин трактор, бөтен көченә үкереп, аның артыннан «чапты». Куыша-куыша кырдан болынга чыктылар. Текә яр гына коткарды малайны, югыйсә исерек Хәмит гәүдәсен жир белән тигезли иде. Аякларын камыл кискән, йөрәге дөп-дөп типкән малай, елгада бит-кулларын юып, хәлләнгәч, майкасына эре-эре чуерташлар жыйды. «Тагын куып кына карасын! Чуерташ белән тәрәзәсен ватып, чын мәгәр, бәбәген агызам», — диде Гафур, гайрәтләнеп. Хәмитнең малайда нинди үче бар иде икән? Әгәр апасының уйдырмасы хак булса? Гасырлардан гасырларга кан белән күчсә дошманлык? Тинтәк син, Гафур! Шәжәрәннең беренче ботагында утырган Мөхәммәтъяр унжиденче гасырда туган. Шуннан бирле ничәмә-ничә буын алмашынган. Нинди үч, нинди каргыш ди бүген?! Хуп, монысы ышандырмый, ди. Ә нишләп бөркетләрнең ир-атлары гөрләтеп яшәгәндә генә, Газраил тырнагына каба? Бәлки, бу да ахмак сораудыр. Гомернең озынлыгын Аллаһ кына үлчи. Бүген Гафур исән, шуңа шөкерана кылырга кирәк. Иртәгә Гүзәлиясе кайта! Дүрт-биш көнгә дигән хатын Казанда өч атна кунак булды. Инде күңелдә соры дулкыннар чайкала иде: әллә шәһәрдә калыргамы исәбе? Нәрсә жиңәр: кала тормышымы, Гафурмы? Ир жиңде, шөкер.

— Апа, иртәгә төшкә бәлеш пешерерсең әле, — диде ул. Бәлеш — кунак ашы иде. Аппагы бит дөньяда иң зур кунакның да кунагы иде.

— Кемнәрне сыйлыйсың?

— Гүзәлия шылтыратты.

— Табылмаса дугасы — тагын бер кич кунасы. — Апасы бу хәбәргә сөенмәде. — Элгәре күрше авылдагы туганнарга ат белән куналата баралар иде. Безнең бабай бик шаян кеше иде. Әби белән моны әйбәт иттереп ашаталар-эчертәләр, мунча ягалар. Бабай кунакта рәхәт чигә, икенче көнне ул атның дугасын печәнлеккә яшереп куя. И эзлиләр, и эзлиләр ди дуганы. Шуннан бабай: «Табылмаса дугасы, тагын бер кич кунасы» дигән ди. Синең чүлмәк гөлең дә мондагы рәхәтне татып алды, ә! Китми, ә! Йөрәгенә үк яшерде дугасын, ә малай!

— Син ник тузынасың, апа? Гүзәлия минем хатыным! — диде Гафур.

— Хатын түгел, җәфа ул! Чүлмәк гөлем дип хисләнмә монда! Төнгегә терлекләрне лутчы абзарга яп. Буыннар сызлый, суытыр, Гафур. Иртүк киләм!

Апасы әмерләрен уңга-сулга сипте дә, тагын бер тапкыр Гүзәлияне «юып-чайкап» «кер бавына элде».

... — Улым, туңган уҗымнарыңны кар каплады. Хурлыгыңны ак юрган белән томалады Ходай.

— Ярар инде, әти! Ник һаман шул басу белән тәпәлисен?! Әллә син ялгышмадыңмы?

— Ялгыштым, улым. Ул ялгышымны төзәтерлек түгел, улым.

— Дүрт аяклы ат та абына, әти.

— Алар икесе ике нәрсә, ат торып да тагын юыртыр, бәндә абынса, харап, улым. Безнең нәсел тамыры өзелде, синең балаң юк. Мин генә гаепле, улым.

— Җә инде, әти. Өстеңә гөнаһ өймә.

— Өям, улым. Исән чакта сөйләмәдем, хәзер мин ерак-еракта, сөйлим, улым. Син кечкенә идең, әнкәң белән Шәрбәнбануга кунакка бардык. Төнлә ай яктысында кире кайтканда алдыбызга ана пошн сөйрәлеп чыкты. Аның арт саны яраланган иде. Атны туктаттым да, әз генә урман эченә кердем. Икәү иде хайванны җәберләгән кабахәтләр, берсе качты, икенчесен куа-куа тотып, дөмбәсләдем, улым. Озаграк кайнашылган, атымның корсагы да, сине кочаклаган әниең дә бәсләнгән иде. Бүлнистә айдан артык яттыгыз сез анаң белән. Врач әйтте, хатының башка сабыйлар белән куандырмас, Сөләйман, диде. Врач тагын шунысын да әйтте, улың савыгыр, түлке үскәч өйләнсә, ата бәхете насыйп булыр микән, билен туңдыргансыз, диде. Кичер, улым...

— Поши соң, яралы поши үлдеме?

— Үлмәде, улым. Мин аны чанага салдым. Атаңны беләсең, трактор аударырлык көчле идем мин. Терелттек без аны, улым. Хайван буаз иде. Ике кечкентәй бәбиләде. Әзрәк буй калкыткач, урманга җибәрдем үзләрен, улым.

— Рәхмәт, әти.

— Ни өчен, улым?

— Изгелеген өчен, әти. Бәлки син пошиларның нәселен саклагансыңдыр, әти! Безнең урманда алар сирәгәйде, әти.

— Син дә тармакмөгезләргә тидермә, мылтыгыңны корулы тот, улым. Шык-шык... Шык-шык...

— Нигә тәрәзә шакыйсың, әти?

...Тирләп пешкән Гафур юрганын аяк очына шудырды. Уф, төш икән! Шык-шык... Шык-шык...

Өендә дә төшенең дәвамын күрә микәнни? Юк, кемдер урамнан шакый! Ир торып өйалдындагы уткабызгычка басты. Ишегалды яктырды.

— Сәлимә апа?!

Баскычта дер-дер калтыранып күрше хатыны таптана, ул яланөс иде.

## VIII

...Матча шартлап сынды. Бүлмәне тузан болыты күмде. Хатын караватыннан ничек торганын һәм ничек ян тәрәзәнең рамын сындырып тышка сикергәнен искәрмәде. Артыннан тагын нәрсәдер дөбердәде. Ул яланаяк кына күршеләренә чапты. Ходайның рәхмәте, Гафур йокыга сизгер иде, тиз уянды.

— Сәлимә апа?!

— Әз генә үлмәдем, Гафур!

— Туңасың, тизрәк кер, Сәлимә апа! — Ир хатынны бусагадан тартып алды. — Ни булды?

— Матча... — Сәлимә сулкылдап, күршесенең күкрәгенә капланды. — ... ишелде. Терәү чыдамады...

— Елама, Сәлимә апа. Үзең исән, шөкер!

— Нишлим? Кая барыйм? Яна өй салырлык рәтем юк.

— Берәр нәрсә уйларбыз, Сәлимә апа. Минем урында йокла, бар. Йорт тирәләренне караштырыйм әле.

— Документлар шкафта, Гафур. Әйберләр сытылгандыр инде. Түшәме белән убылды бугай.

Сездә кунсам, килешмәс, дип оялыр чак идемени! Өе белән бергә аның соңгы тамчы бәхете дә җимерелде ләбаса! Ташландык хатын, ташландык ана иде бит ул! Менә хәзер йорт-җирсез сукбай да. Түшәк җылы иде. Мендәрләр гүя Гафурның кайнар сулышы белән кабартылган иде. Сәлимә чатнап-чатнап авырткан башын шунда төртү белән күз яшьләре дә кипте. Кеше мендәрен чылатмыйлар...

Гафур озак тормады.

— Фонарь белән генә караштырдым, караңгы, көн күзендә тикшерермен, Сәлимә апа, — диде. — Синең терәүләрең черек жирда гына, Сәлимә апа. Аны башта ук проблемаларынны яшермәскә иде. Күршеләр бит инде без. Мин диванда ятам, тыныч йокы сиңа!

Хатын «рәхмәт» дияр иде, тамагына очлы таш кадалгандай, әрнетә иде. Һай, таш эрер иде әле. Ә менә йөрәккә укмашкан хәсрәт төенен ничек чишәргә?! Чәбәләнгән-чәбәләнгән дә ул! Эре генә күз яше яңагын юешләтте. Сәлимә кул арты белән аны тиз генә сөртте. Чит-ятлар мендәрен чылатмыйлар, мәгънәсез! Алдагы көннәренне уйла син кырык яшеңдә кырык тамчы бәхеткә тиенмәгән күке кызы. Бүген ярый ла җылы ояда кунасың. Ә иртәгә ни була? Ул Гафурларда бер тапкыр төн үткәргән иде. Печәнлектә. Әтисе ул көнне салмыш иде. Мич аралыгыннан дуст алып сулы чиләккә салды ата һәм шунда шикәр комы өстәде.

— Сәлимә, бакча башында Сөләйләрнең биясе утлый. Сусагандыр, хайван, шушы тәмле суны эчерт, мә!

Кызчык белә иде: дуст белән әнисе тараканнарны агулый. Әгәр аны биягә эчертсәң — ат үләчәк иде.

— Тиз атла! — дип акырды әтисе.

— Мин ана кое суы гына бирәм, — дип киреләнгән иде кызчык, әтисе чәчүрмәсеннән йолкып:

— Кушканны эшлә, мисез тавык! — диде.

Сәлимә бәрәңге буразналары арасыннан барды-барды да, чиләкне җиргә аударды. Ә әтисе тирес өемәнә посып күзәткән икән, ул кулындагы чыбыркысы белән кызчыкның аркасына сыдырды:

— Үтерәм, мисез тавык!

Кызчык ычкынып коймага таба элдермәсә, исерек атадан рәхим-шәфкать көтәсе юк иде. Ул куркуыннан көнозын урамда буталды. Ә карангылаткач, Сөләйман абзыйларның печәнлегенә менде. Анда да хәзерге кебек жылы: киндер капчыклар жәелгән ятак иде. Гафур көндезләрен шунда китап укый иде.

...Тан йокысы тирән йокы, алай да Сәлимә изрәгән гәүдәсен күтәреп торгызды. Гафур әкрен генә телефоннан сөйләшә иде. Театрда суфлерлар тавышын колак очы белән дә эләктергән хатын аны аермачык ишетте.

— Сындырганмы? Кайда, кайчан? Әйе, тугызга киләм, Рамил Габдуллович. Рәхмәт!

— Һай, күрше, кем нишләгән? — диде Сәлимә, борчылып. Бу иргә тагын кайсысы хәсрәтен өсти?

— Кичә апа чорма баскычыннан егылып кулын сындырган, ди. Гипс салганнар. Үзәктән баш табиб шылтырата. Авыл фельдшеры хастаханәгә илткән булган.

— Мингайшә апа чыдам, сөяге ялганыр, — диде хатын.

— Апа кулсыз икән, мин дә кулсыз. Сыерларны ул сава иде. Бүген Гүзәлияне дә анын бәлеше белән каршылыйсы идек.

Сәлимә үзе дә сизмәстән:

— Һай, кайгырма, Гафур! — диде. — Алты яшемнән әни белән сыер саудым мин. Авыл кызы ла. Кая Мингайшә апанын халаты белән яулыгы? Аның кебек итеп киенәбез дә, жәлт кенә сөтлебикәләрнең эшен бетерәбез. Бәлешкә дә житешәбез, бер дә янма-көймә, күрше.

Иннәрендәге канатларын жилпи-жилпи кайчан дәртләнеп очты икән күке Сәлимә?

Авыл жирендә яшәү рәвеше бер төрлерәк: кайда нәрсә куелган — күзенне йомып та капшыйсың. Зур кәстрүлләрдә су жылытып жиз комганнарга тутырды хатын. Аягына галушлар гына киде. Сыер жиленен юып сөртергә дигән ару чүпрәкләр абзар диварындагы аркылы тактада кибә, май савыты киштәдә иде.

Ак өй моржасыннан тан карасын сыегайтып ап-ак төтен ургылды. Хатынының депутат абзасына кунакханә әзерли ир. Димәк, Гүзәлиясе белән бергә олы кунак та көтелә. Ә «кунакханә» артында Сәлимәнең ишелгән йорты... Һай, йөрәккәем, түз! Түзмәсәң — типмә! Төнлә: «Иртәгә ни була?» — дигән иде. Менә иртә... Ул көнеленнән генә моңлана-моңлана сыер сава... Сөт тамчылары битенә чәчри... Мингайшә карчыктан ким эшләмәскә тиеш Сәлимә. Әллә аңарда көнләшү юкмы? Бар! Бөтен хатын-кызда да — усалында-юашында, акыллысында-жүләрендә бу хис бар! Ә ир-атта ул тагын да көчлерәк. Алар көнләшсә, бер-берсенен бугазын чәйни, бер-берсен имгәтә, бер-берсен почмактан атып үтерә.

Таң атты. Гафур анын өеннән капчык-капчык әйбер ташый иде.

— Ызбанда иелеп кенә йөрешле, Сәлимә апа. Киемнәрең белән документларың Ак өйдә булыр.

— Рәхмәт яусын, Гафур. Фатыйма әби ялгыз, анарда кышлармын инде, — диде хатын.

— «Сыерчык оясы»нда яшәрсең, Сәлимә апа!

— Һай, күрше! Син аны олы кунагын хөрмәтенә төзеткән ич! Юк, юк, мин алай әрсезләнмим!

— Сәлимә апа! — Ир, шелтә белән аны бүлдерде. — Рас, мин — хужа хәл иткән икән, бәхәсләшмә! Безнен бәлеш ничегрәк?

— Һай, анысын онытам икән!

Туган көн мәжлесләрендә артистлар анардан таба ашлары пешертә иде.

Бәлеш капкачын бары тик Сәлимә генә камырдан чәч толымы үргәндәй итеп ясый иде. Ит — суыткычта, оны — чоланда, уклавы — шкафта, нәкъ алар йортындагы шикелле, һәммәсе «урынлы» иде. Хатын, бисмилласын укып, әчегән сөткә йомырка, сыек май, тоз салып туглады. Итен шакмаклап турап, бәрәңгесен эрчеде. Тышлык куна тактада бераз хәл җыйгач, аны җәеп, тигезләп-түгәрәкләп эчлеген тутырды. «Ижат җимеше» патшалар табынын бизәрдәй матур иде. «Бәрәкәтле ризык бул», — диде хатын, аны карашы белән назлап. Бәлеш газ мичәнә кергәч, йөгерә-атлый мунча ягып җибәрде. Күңелнең җилкенүенә Гафур сәбәпче иде. Аңа Сәлимә кем инде? Ни туганы, ни дусты... Гомер бакый бөркетләр белән күкеләр бер-берсен күралмады. Сөләйман малае Сәлимә кебек үк бу дошманлыкның тере шаһиты иде. Ә ул бернигә дә карамыйча Хәмит кызына Ак өенең ишекләрен ачты.

...Печәнлектә изрәп-таралып йоклаган иде кызчык. Ат пошкырмаса, Сәлимә әле тагын йокы бүсә иде. Сөләйман абзый биясен абзардан чыгарды:

— Әйдә, җанкай, әйдә! Берничә көннән тай чабып йөрер янында. Аннан икегезне болынга куарбыз, — дия-дия ул аны бакча башына алып китте. Печәнлек биек иде, авыл уч төбендә кебек иде. Әнә, әнисенең тавышы ишетелде. Тирескә юынтык су түгә.

— Сөләйман, синең малаең өйдәме? Балалар ат көтүе сакламыйдыр ла.

— Өйдә, Гатия.

— Безнең Сәлимә өйдә кунмады. Арьяк әбиләрендәдер.

— Әбиләрендәдер, Гатия.

— Ачуланма инде, Сөләйман.

— Ник ачуланыйм ди, Гатия?

— Шулай инде... Ачуланма, — диде әнисе. Зыян-заурәте белән күршеләрен интектергән тәүфыйксыз ире өчен уңайсызлана иде шул, бичаракаем.

... Чүпрәк белән уң кулын муенына аскан Мингайшә апа хастаханәдән туры Гафурларга кайтты. Карчык Сәлимәне күреп:

— Бәтәч, моның билендә минем алъяпкыч, башында минем яулык! — диде. — Нишлисең син монда, күке кызы!

Гафур:

— Апа, әкрен, хәзер тавышыңнан күк йөзе чатный. Күрше миңа булыша, — дигәч, карчык отыры дулады:

— Тиатер уйныймы? Чәй эчергән итенеп синә елышамы?! Вәт кәмит! Бер кич кенә бүлнистә идем, ужы йортта чит катыннар!

— Сәлимә апа сыерлар сауды.

— Бәтәч, син бүлнистә Сөнчәледән кеше ялладым дидең кана!

— Врачлар янында сине котыртмас өчен әйттем, апа.

— Энем титибаш! Шушы әртискәгә малларны ышандырдыңмы? — дип, карчык пырылдап абзарда әле бер, әле икенче сыерның имчәген тартты. — Сөтен калдырып бозсын гына малкайларны, бозсын гына! — диде.

Карчык тикшереп бетергәч, Гафур:

— Ничәле, апа? — диде. — Билге куй инде.

— Өч ярым!

— Һай, бигрәк кырыс укытучы син, Мингайшә апа. — Сәлимә юри генә үпкәләгән кыланды. Югыйсә дәшмә, сыер койрыгы белән сыптырган ише генә булмас. — Ник билгең түбән?

— Чөнки сиңа минем белән ярышыр өчен өч пот тоз ашарга кирәк, күке кызы! Бу яулыгым белән алъяпкычымны терлек-туар янына япма! Аларны мин аш-су тирәсендә кайнашканда гына кулланам. Чистага гына!

— Мин дә бәлеш ясаганда гына кидем, Мингайшә апа.

— Гафур! — Карчык энесенә чекерәйде. — Нинди бәлеш ди ул? Саташа мәллә?

— Соң, апа, бүген Гүзәлия хөрмәтенә табын көйләргә иде бит. Сәлимә апа унган икән, бәлешен дә өлгертә.

— Әһә, кошкай түребездә үк кунып күкелдимени? — Мингайшә апаның йөзе каралды.

Кибәнне үзебез өйдек, үзебез үк ишик дигәндәй, Ак өй турында да шушы минутта ук әйтергә кирәк иде. Хатын уйнап-көлеп кенә:

— Түрегезгә үк кунмам, мина «сыерчык оясы» да ярый. Гафурга чиксез рәхмәт, матчам сынгач, бездә яшә, — диде.

— Авам, авам, тотыгыз! — Карчык янтайган иде, Гафур җилкәсеннән эләреп, аның гәүдәсен турайтты.

— Апа, тамаша тәмам. Өенә озатыйммы, бездә каласыңмы? Мин Сәлимә апаны урнаштырам.

Хатынның Ак өйне бер мәртәбә дә күргәне юк иде. Тыштан гына оя сыман икән ул, ә болай йокы бүлмәсе, залы белән иркен генә йорт икән.

— Сәлимә апа, тартынма, үз өеңдәге кебек яшә. Әнә, почмакта газ плитәсе. Савыт-саба шкафта. Пакетларда ипи, тоз, шикәр, конфет-прәннекләр. Суыткычта тавык ите, сөт, катык. Мунчага тулысы белән син хуҗа, — диде ир һәм, ашыкканны белдереп: — Җәһәт кенә Сөнчәлене урыйсы иде.

Сәлимә Гафурны карашыннан аңлады: Мингайшә апага алмаш эзли!

— Йөрмә, күрше, — диде ул. — Менә бит, мин бар...

## IX

...Ашкынма, тукта, басыл, Гафур. Сагындың, әйе, сагындың... Өч атнада утыз өч тапкыр бардың син аның янына! Уйларың да, әйе. Яратудан әле беркемнең дә акылдан язганы юк. Мәхәббәт саргайтып, сагыш чире генә йоктыра. Монысы әкрен үлем... Газаплы үлем...

Ир, ис тияр димәде, мичтә күмерләре көйрәгән мунчада юынып, яңа күлмәк-чалбарларын киде. Әйтерсең туй, әйтерсең ул кияү егете иде.

Гүзәлия үзе генә түгел, аның белән депутат абыйсы да кайткан иде. «Халык көтүчесе» бу якларга җыенса — хәбәр сала иде, ә бу юлысы сюрприз ясыйм диде микән? Хуҗа кеше биш кунак икән, бишкә ярыла, диләр. Гафур бер кулына хатынының сумкасын, икенче кулына зур кунакның портфелен тотты.

— Сразы өенә куалама, аякларны язып, тәмәке пыскытам әле мин, кияү, — диде Гаяз Идрисович.

Гүзәлия туп-туры эш кабинетына юнәлде. Ир, аның чишенгәнен дә көтмичә, кысып-кысып кочакламакчы иде, хатын:

— Фу, абзар исе! — дип читкә тайпылды.

— Миндәме? Нишләп икән? Хәзер генә мунчада юындым, аппагым. Күлмәгем дә яңа, — диде Гафур һәм башындагы кепкасын абайлады: — Ә-ә, кәпәч хуш исләр аңкыта икән! Терлекләр янына киелә бит, каһәр! Хәзер тәрәзәдән урамга чөям! Җә, аппагым, исәнме?

— Исән, исән! Юл алҗытты, зинһар, чыгып тор! — Гүзәлия гасабиланып сумкасын актарырга кереште. — Кая бу зәңгәр халат?

— Сагынмадыңмени, аппагым? Минем кебек, ә?

— Аптыратма, Гафур! Ай башсыз да соң мин, ай башсыз да! Халатымны Казандагы фатирымда онытканмын!

— Шкафта бүтәне юкмени?

— Анда син дә эләсең, син дә!

— Шуннан?

— Синең киемнәреңдәге сыер, ат, сарык, сөт исе минем күлмәкләремә сеңә! Күңелне болгата шул ис!

— Бу хатаны төзәтербез, аппагым. Моннан соң үзеңнең шкафың булыр, — диде күрешү шатлыгыннан исереп һич кенә дә айнырга теләмәгән ир. — Мин аның тоткаларын алтын суы белән ялтыратырмын!

— Әйдә, әйдә, берьюлы алтыннан сынымны да койдыр, мактанчык!

— Ярар, аппагым, тынычлан, — диде Гафур. — Сиңа дигән бәлеш суына.

Ә Гаяз Идрисовичның кәефе әйбәт иде.

— Ну, арба тәгәриме фермер, иптәш?

— Тәгәри, депутат иптәш.

— Таудан аскамы?

— Өскә!

— Авылда ничә ел чиләнәсең инде, кияү?

— Чиләнмим, эшлим, Гаяз Идрисович. Өч ел.

— Кайчан миниферманы мегага әйләндерәсең?

— Баегач, Гаяз Идрисович.

— Бүген дәүләт эре инвесторлар яклы, җирләрне аларга өләшә.

— Өләшеп ни файда, депутат иптәш? Хөкүмәт кредит бирә, ә алар, банкрот дип, бурычларын сыздыра.

— Синең кредитың күпме?

— Ярыйсы.

Мондый эчпошыргыч әңгәмәләр Гафурны бик ялыктыра иде.

— Яшьлегең тилертә сине, кияү, яшьлегең! Олыгайгач, терсәгеңне тешлисең син. Туксанынчы елларда бер районда илле тугыз фермер иде. Кайсы суганга егылды, кайсы бәрәңгегә, кайсы кәбестәгә. Минем Министрлар кабинетында эшләгән чак. Районның партия секретаре и мактана, и мактана! Бездә фермер хуҗалыклары чәчәк ата, янәсе. Тик чәчәкләр тиз шиңде. Алардагы яшь буын өчен әтиләренең ялгышы сабак булды, бүген хуҗалык оештырырга атлыкмыйлар. Фермер минем өчен бик ямьсез атама, кияү!

— Ә сез сессияләрдә йокламагыз, безнең ишеләргә матуррак исем табып закон кабул итегез, Гаяз Идрисович!

Кияүнең сарказмы зур кунакка ошамады.

— Максатың ни синең, Гафур Сөләйманович? — диде ул, көлемсерәп. — Сезгә, бәләкәй генә гаиләгә, кәҗә дә артык мәшәкать. Кем өчен байлык туплыйсың, кияү? Балаң юк. Сине атаң кечкенә чагында өшеткән ди Мингайшә апа. Хакмы? Колагыңа киртлә, кияү, сеңел синең гаеп белән кысыр. Әгәр ул шигырь белән җенләнмәсә, ялгызлыктан ана бүре төсле улар иде.

Зур кунак кыйммәтле ботинкалары белән аның бәгыренә басты. «Бала юк... Бала юк...»

— Ашлар суына, әйдәгез! — диде ул.

— Да, кстати, — Гаяз Идрисович төпчегән капка тимерендә сүндерде. — Кич хакимнең әшнәләре белән йөрибез. Син, сөякләрне эретерлек итеп, Ак өйне әзерләрсең, кияү. Таң алдыннан кайтып авармын мин.

Гафур сырлап-бизәкләп маташмады:

— Сезгә диванда урын түшәрбез, Гаяз Идрисович, анда әлегә күршебез яши, — диде.

— Ничек алай ул? — Кунакның чырае караңгыланды. — Безләргә хөрмәт беттемени?

— Күршебезнең матчасы ишелде, ачуланмагыз, Гаяз Идрисович.

— Да, кстати, кияү. Өстәгеләргә ярарга тырышмавың — икенче бәла. Сиңа главагыз әллә кайчан очсыз гына кредит хутлар иде, ну юк, син иелә белмәгән туры агач! Без ничә ел аралашабыз, ә син миңа берәр тапкыр да: «Гаяз Идрисович, булыш!» — дигәнең бармы?

— Мин үз көчем белән җинеп барам, — диде Гафур.

— Син юри генә яхшатлан! Миңа ярар өчен генә! Рәхмәт. Ак өй салдырдың, ну кире тартып та алдың! Синең өчен бөтенесе дә тигез икән: депутат та, күрше дә. Стоп, стоп! Бәхәсләшмик, кияү. Сенел хакына мин сине бүген гафу итәм.

Олы кунак озак тоткарланмады.

— Нишләптер яратып ашамады, дифутат. — Апасының үз фәлсәфәсе иде. — Чәнечке белән тәлинкәсендә өч бәрәңге куып тамагы туйды, ахры. Яратмаса, Күке бәлеше өчен хәсрәтләнәсем юк әле!

— Ризыкны яманлама, апа. Президент өстәленә куярлык сый иде. Бәлеш тәмле иде, әйеме, аппагым?

Ни хикмәт, Гүзәлиянең җен-пәриләре качкан, ул хәтта ки табак-савыт юып маташа иде.

— Искиткеч! — диде хатыны.

— Фи, дифутат белән сезнең авыз бер түгел лә. — Мингайшә карчыкның кулы гына сынган, теле исән иде шул.

— Апа, дифутат димәсәнә! Минем абый халык депутаты ул.

— Миңа димәгәе, сарык дифутаты булсын! Иләнгә су чәчрәтмә, кыз!

Кунак белән азрак сүзгә килешсәләр дә, Гафурның дөньясы түгәрәк иде. Гүзәлия кайтты! Шушы кичкенә генә, нәфис кенә хатын аның мөлдерәмә тулы бәхет савыты иде. Анардан башка өй шыксыз иде. Әнә хәзер диварларда нур уйнаклый! Бүлмәләрдәге авыр тынлык сулышны кыса иде, әнә, аның чишмә кебек челтерәгән тавышы ягымлы көй төсле җанны иркәли. Ләкин Гафурга шунысы да мәгълүм: бәхет савытының пыяласы бик нечкә, ватылса — уалган кисәкләр мәңге ябышмаячак иде. Гүзәлиянең холкы да кояш белән болыт, хәзер генә көлә, хәзер генә елый... Бер нечкәрә, бер тупаслана. Ләкин бит ул шушы килеш: уңы-тискәресе белән аю хәтле ирдән яраттыра иде.

Мингайшә апа тәрәзәгә табан борылган арада хатыны Гафурга пышылдады:

— Соңрак мин сиңа яңа шигырьләремне укыйм, яме?

Карчык колакка сизгер иде:

— И Аллам, кемгә шигер, кемгә кул, — диде. — Ничекләр тәһарәтләнермен икән?

Гүзәлиянең аңа да мәрхәмәте уянган иде.

— Учыңа үзем су салырмын, апа. Өеңә дә житәкләп илтермен.

— Итмичәрәк тор! — Мингайшә апа киленнең йомшартуына изрәмәде. — Монда кунам кул төзәлгәнче. Сезгә ышанып хуҗалык калдырганнар ди!

— Кун, кун апа, — диде Гафур аны җөпләп. — Тик син борчылма гына. Хуҗалыкта тәртип, мин барысын да күзәтәм.

— Һай, Аллам, күзәтә икән! Синдә күз юк бит, энем. Син — сукыр. Синең маңгаеңда ике ботак тишеге генә. Күзле ир бәндәсе Күке кызын Ак өйгә кияләштерми, аның нинди хәйләкәр икәнен күр! Ә монысы инде... — Карчык өстәл өстен сөрткән Гүзәлияне башы белән сөзгән хәрәкәт ясады. — Әйтеп тә әйтеп бетерерлек түгел! Әй, сиңа үтәмени минем вәгазьләрем, энем! Бүген дифутатыгыз кайда йоклый?

— Безнең залда, диванда, апа.

— Миңа да дибанга җәегез. Дифутат белән аркага арка терәшеп ятарбыз. Бер-ике закун да чыгарырбыз, боерса.

Олы кунак Гафурларда кунамы икән? — бу әле икеле иде. Элегрәк ир түрә абзыйлар ил-халык мәнфәгатен кайгырта-кайгырта төрле ваклыклардан арына, түбәнгә карап фикер йөртми дип уйлый иде. Ялгышкан, ахрысы. Кайберләре кетәклектәге тавыкларны да саный икән. Кайберләре

балачагыгызда ни-нәрсәләрегез өшегәненә хәтле төрттерә. Гафурда да тәти холык түгел. Сабыр төбе — сары алтын дисәләр, аның да бер түгәрәк калайга әйләнүе ихтимал. Ләкин ни хәтле генә чеметсә дә, эчтән генә «тирес корты» дип көлсә дә, Гафур Гаяз Идрисовичның кыланмышларына түзәргә тиеш. Чөнки ул аппагының туганнан туган абыйсы.

Кышкы иртә белән кышкы кич арасы ярты гына сүәм кебек иде. Бүгенге көннең ишек-тәрәзәсе ябылды. Гафурны нарат бүрәнәле серле бүлмәдә — шәм яктысында Гүзәлиясе көтә иде. Хатын үзе аның тез башларына менеп кунаклады. Ефәк төсле йомшак куллары белән муенына уралды һәм ачык изүенә кайнар сулышып өреп:

— Мин юкта нишләдең? — диде.

— Яшәдем, аппагым. Ә син?

— Мин дә. Нинди яңалыклар бар?

— Маңгаенда ак тамгалы тана бозаулады. Сарыкларның һәммәсе дә диярлек өчәрне бәрәнләде. Тегермән бинасының буяу-сылау эшләре генә калып бара. Менә, Ходай кушып, җирләрне дә рәсмиләштерсәм...

— Гарык! — Хатыны тып итеп идәнгә басты. — Мин гарык! Тагын шушы абзар, тегермән, җир! Нинди чикләнгәнлек!

— Чү, тузынма! — Гафур аны янә тезләренә утыртты. — Хәзер сине тыңлыйм, аппагым.

Гүзәлия бармакларын уйната-уйната:

— У-у, минем кызык, бик кызык! — диде. — Дусларым миңа кичәләр оештырды. Студентлар белән, мәктәпләр белән! Шигырьләремне яраттылар. Кафе-барларда дусларым белән төннәр уздырдык.

— Ул дуслар кемнәр инде, аппагым?

— Зәбирләр, Галинурлар! Безнең төркем!

— Бу төркем заманында таралган иде түгелме соң, аппагым?

— Таралса ни! Без кабат оештык.

Көнче шайтан почмактан гына Гафурга ым какты: «Кара, чибәркәең күлнең тирәнрәгенә кермәгәе!»

— Сагындыңмы дип сораган идең, сагындым! — Гүзәлия ут кебек янган яңакларын аның битенә тидерде. — Сизеләме?

— Сизелә, — диде Гафур «көнче шайтан»ны йөрәгеннән куалап. Ир белән хатынны бозыштырам дисәң — иң әүвәл көнләштер генә инде син!

— Бу шигыремне сиңа багышладым, тыңла, — диде хатын. — Исеме — «Сагыну».

Офыкларга җәелеп кояш елый,
Уза тагын көннең гомере.
Әйтерсең лә дөнья янып бара
Кала бары утлы күмере.

Тупылларның моңсу ботагында
Сискәнешә көзге яфраклар.
Үткән елның бөресеннән иде,
Тик бу язга ничектер ятраклар.

Башка кичләр төсле кич бит инде,
Төн киләсе таулар ягыннан.
Сагышларым эчкә йота-йота
Бүген сине шундый сагындым.

— Рәхмәт, аппагым, матур шигырь, — диде Гафур, чын күңелдән.

— Зәбир дә шулай ди.

— Сүзләре мәгънәле.

— Зәбир аны ятлады хәтта. Көй язам, ди. Беләсеңме, ул инде ун җыр авторы. Менә талантлы егет!

Ир, муен тамырларын бүрттереп, учына йөткерде. Бу исем аны буа иде. Әгәр ул бүген дә аның көндәше булса? Ник хатыны, уенчык робот шикелле Зәбир дә Зәбир дип кабатлый?! Тамагың ярылганчы йөткер, әмма көнләшүеңне белдереп кичнең ямен генә бозма, Гафур!

— Нишләдең син, жаныем? — Гүзәлия йодрыгы белән дык-дык аның аркасына төйде. — Сулыш юлың капланды мәллә?

— Әһе, әһе, үтә хәзер, үтә, — дип, ир, тынычлангандай итте. Ләкин ничек кенә боргалансаң да, көнләшүнең бер тамчысы тып итеп йөрәккә тамган иде.

...Ул озак кына йокылы-уяулы ятты. Башка төннәрдә ояларыннан чыгарга иренгән этләр ярсый-ярсый өрде. Ара-тирә тонык кына мылтыктан аткан тавышлар ишетелде. Аның кайтавазы өй кыегына килеп бәрелә сыман иде. Гафур тыңланды: әйе, аталар! Якындагы урманда! Өченче көн ир җәнлек-җанварларга җимнәр куйган иде. Дүртенче кыш инде ул табигать иркендәге хайваннарны ризык белән тукландыра. Алар инде «сый табыны»ның кайсы урында икәнлеген дә белә иде.

Гафур кымшангач, хатыны да уянды:

— Нишлисең син?

— Якында гына кемдер мылтык белән шаяра.

— Әй, Гаяз абыйлардыр ул. Бүген ау төне ясыйбыз, дигән иде. Сиңа ни, йокла!

— Нинди ау төне?! Кем аларга рөхсәт итте?!

Ир, сикереп торды һәм ут та кабызмыйча, киемнәренә ташланды.

X

... Карчыга сыман һаман өстендә кагынды Мингайшә кортка.

— Кичке савымның сөте әз дип хәрәмләшмә, җиленнәрен тигез тартып сау! Артыңнан тикшерәм, күке кызы!

— Минем исемем — Сәлимә!

Хатынның кайчак бәйләнчек карчыкны абзар нүешенә кысып тукмыйсы килә иде. Их, усаллык җитми шул! Әй, кушаматы белән эндәшмәгәе ни! Укасы коелмас әле.

— Колхозда ырдым-шырдым эшләгән катыннарны тотып кыйный идем, — диде карчык. Бу аның әллә янавы, әллә мактануы иде. — Синең әнкәңә генә тимәдем. Юаш иде Гатия, башы гел аска иелгән иде. Ә син тач атаң! Хәйләкәр, мәкерле, үчле Хәмит! Вәйт, әйт, ник чормаңа менеп сикерә-сикерә матчаңны сындырдың?

— Валлаһи, түшәм үзе җимерелде, дустым Мингайшә апа!

— Ялганлама, күке кызы! Син Гафурның кыз-катынны җәлләгәнен чамаладың, Ак өйгә кертәсең белдең!

— Көлдермә, дустым Мингайшә апа, хәзер энеңә тагын да якынаер өчен, сыерларын савам, әйеме?

— Газиземнең башына күкелдә генә, йонынны өтәм, күке кызы!

— Егерме беренче гасыр томанасы икән син, әпчи карчык! Күке кычкырып кына гомер кыскармый!

— Акырма, монда убыр каенанаң юк!

Юк шул, юк... Сәлимәне төннәрен йоклатмаган өч кыйссаның берсе ул каенана. Улы белән килене тарафыннан урамга сөрелгән хатын озын-озак итеп әлеге фаҗигасен тасвирлар. Йорты ишелеп, хәрабәләр арасыннан үрмәләп чыккан хатын монысын да сурәтләргә сүзләр табар, тик менә каенана турындагы кыйссасын гына сөйли алмас. Чөнки аның эчтәлеге сынар җөмләгә сыеп бетәр: «Шәрбәнбануда никахлы иренең әнкәсе яши: бер тапкыр да «киленем» димәгән җиде ят «убыр»!

Эш тәмамлангач, Мингайшә апа:

— Ярыйсы сөрдең, ярыйсы, — диде. — Ишегеңне бикләмә, күке кызы. Мужыт дифутат та Ак өйдә йоклар, — диде.

Бикләде Сәлимә. Алай-болай булса, Гафур кисәтер, һәм хатын, һичшиксез,

каядыр китеп кунар иде. Кара әле, күршеләренә әз-мәз булышкач, җанга рәхәт икән бит! Син файдалы кеше, син әрәмтамак түгел. Әллә соң, Ходаем, үзен-үзенне көчләмичә, үз ихтыярын белән шушы йортка атлыгып торуларыннын бер-бер хикмәте бармы? Актриса Фатыйма ханым шикелле ул да аңлаешсыз халәттә яши микән? Фатыйма Ибраевага, хәтере чуалгач, рольләр бирмиләр, гомум күренешләрдә генә катнаштыралар, ә андый спектакльләр ярты елга ике-өч кенә уйнала, ләкин актриса көн саен — кармы, янгырмы — Каенлык бистәсеннән килеп, театрда чуала иде. Сәлимә берсендә аңардан:

— Фатыйма апа, нишләп сез ял итмисез, нишләп салкын автобусларда йөреп интегәсез? — дип сорагач, ул:

— Үтенәм, серемне бераүгә дә ачма, сеңелкәем. Нәрсәдер театрга тартыплар китерә. Әллә мин режиссер ярдәмчесенә гашыйк микән? — дигән иде. Әллә Сәлимә дә... Китегез, кит, җүләр уйлар! Ул язмышына «ялгыз» дип тамга сугылган күке! Кәк-күк, кәк-күк...

Күршеләрнең ишегалдында ут кабынды. Анда да халык уяу икән. Хатын тәрәзә пәрдәсен шудырды. Бәй, Гафур атка атланып кая җилдерә?

...Ә Фатыйма Ибраеваның сер капчыгы ертылды. Режиссер ярдәмчесе бер үк вакытта артист та, аны гәүдәгә озын дип йә патша, йә башкисәр итәләр иде. Һәм Фатыйма апа ул киеп уйныйсы киемнәрнең кесәсенә мәхәббәт шигырьләре тыга икән.

— Бу бит җүләрлек, — дип орышты аны Сәлимә, ә ханым, монсу гына елмаеп:

— Нишлим, төннәр буе шигырь язам. Кемгә язам? — аңламыйм. Кем кесәсенә салам? — белештермим, — диде.

Сәхнәдә патшалар тәхетен биләгән режиссер ярдәмчесе образлар белән генә бөек, ә тормышта ул вак җан иде. Әфәндебез «серле мәгъшукасы»нын исемен ачыклады да, репетиция вакытында шамакайланып, шигырьләрнең рифмаларын үзгәртә-үзгәртә такмаклап җырлады. Хак, беркем дә аңа кул чапмады.

— И ялгышкан Ибраева, — диде Шакирҗан артист. — Пәлтәм ишек кырыенда гына иде. Ник мина салмаган гыйшык хатларын?

— Син карт шул, пәлтәң дә иске, — дип көлделәр аңардан.

Кара син, ниләр истә, ә! Әй, Сәлимә, Сәлимә! Кемнең күзенә төтен өрдерәсең инде, Фатыйма апаны тиктомалдан гына хәтереңнән актармадың ла! Аның кебек син дә ашкынуларың-җилкенүләрең белән янма дип үзеңне камчылавың иде ләбаса бу.

Ул йокы аралаш кына тойды: күршеләрнең капкасы шыгырдады, таен юксынгандай ат кешнәде. Кетәклектә әтәч гайрәтләнә иде: «Кикрикүк! Уяныгыз иртү-үк!» «Табигать сәгате» төгәл йөри, тәрәзә пыялалары агарган, таң дөньяга керфекләрен сирпи иде... Менә бит, Сәлимә дә эшем кешесе булды, күз ертып торып чыкты. Хәрәкәттә — бәрәкәт диләр. Мөгаен, бүген Шәрбәнбану авылын әйләнер. Күңелендәге давылны бастырыр өчен генә. Соңгы тапкыр!

Гафур малларга печән тарата, ә үзенең курткасы лычма су иде.

— Мингайшә ападан да өлгеррәк син, күрше, рәхмәт, — диде ир.

— Ә син чирлисең хәзер.

— Абзар җылы, Сәлимә апа.

— Төнлә бүре кудыңмы соң, Гафур?

— Әйе, ике аяклыларын.

— Авыл җирендә дә тынычлык юк, әйеме? Мин сиңа бер әйткән идем, Гафур. Мылтыгыңны яныңда йөрт, дип! Ә синең ул Ак өендә — чөйдә.

— Анысы искесе, әти истәлеге. Яңасын мин мендәр астына куеп йоклыйм, Сәлимә апа.

— Әй, шаяртмасана, Гафур! Мин сиңа тагын шуны әйтмәкче идем. Ике айдан өч сыерың бәбили икән.

— Бозаулый диген, Сәлима апа.

— Әйе, бозаулый. Аларга Назлыбикә, Юмакай, Алтынмөгез кебек саф татар исемнәре кушыйк, ә?

— Куш, куш, Сәлимә апа.

— Син бәләкәйрәк иден, хәтерлисең микән, Гафур? Әниең белән сез икәү берсендә үгезегезне «Мишка, Мишка», — дип чакыргач, тыкрыктан тимерче Миша дәдәй йөгереп килде дә: «Я здесь, что случилось?» — диде.

— Юк, бусын хәтерләмим, Сәлимә апа. Әгәр син фәлән елда, фәлән айда, фәлән басуда ни чәчтегез дисәң — санап бирәм. Эти чәчү-уру вакытын миннән яздыра иде. Аның кыр дәфтәре бар иде. Яшел тышлы.

— Аһ, тәтелдекләр! Сез лыбырдашканда сөт үзеннән-үзе чиләккә ага мәллә?! — дип абзарга «күз һәм колак» килеп керде. — Энем, выжт өйгә! Дифутатыгыз килде. Йа бер Аллам, ник синең өстең юеш, малай?

— Тирләдем, апа. Кая, Гаяз Идрисовичны көттермик, — дип, Гафур бәйләнчек апасыннан ычкынды, ә Сәлимә тотылды.

— Курткыга үтәрлек булып нинди тирләү ди ул? Синнән сорыйлар, күке кызы?

— Син үлем йокысы белән йоклагансың бугай, Мингайшә апа.

— Кул сызлагач, дару эчкән идем. Җә, күке кызы?

— Гафур курткасын тышта калдырган, ә төнлә җепшек кар яуган.

— Әй, бәхетсез дә бу малай! Өс-башын барлап, киптерерлек катынга өйләнмәде-е! Мәйтәм, дифутат минем белән исәнләшмәде никтер. Элгәре културни итеп: «Хәерле иртә, Мингайшә Исламгалиевна», — дияр иде. Син, әйдә, мышкылдама, эшлә, күке кызы! Мин тегеләр ни турында гәпләшә икән, тыңлап багыйм әле. Нәрсәдер кунак абзыйлары ачулы.

Сәлиманең үз уе уй иде. Утыртып бар дип Гафурны аптыратмаска кирәк. Җир туңдырды, сукмаклар такырайды, олы юлдан машиналар очып кына тора. Ул башта үзәктә эленгеләр сайлар. Тәбәнәк авыл өйләренә биш-алты метр челтәр җитә.

«Бисмилла» белән башланган иртәнең көне дә хәерле була икән: хатын универмагта бизәкле-бизәкле челтәр алды, автобус белән кире кайтып, Шәрбәнбану тукталышына төште.

Хөснулланың анасы тешсез авызында прәннеген җебетә-җебетә чәй эчә иде. Сәлимәгә сәерсенмәде ул, өстәлдәге чәшкене тастымал белән сөрткәләп:

— Мактап җөрисең икән, олан, бергәләп чәйлик, ватый кәмпит, солы пичинәсе, — диде.

— Рәхмәт, минем тамагым тук, кем... — Кем? Апа, әби, түти? Кем? — Менә минем күчтәнәчләремнән дә авыз ит. Син мине танымыйсыңдыр, кем... — Сәлимә саңгырау карчык ишетсен дип сәхнәдәге сыман катырак кычкырырга тырышты.

— Бәрәкалла, сән тиатердән, олан. Хөснулламнан хат китергәнсең, шәй.

— Без... без аның белән күптән очрашмадык шул. — Хатын иске комод өстендәге тегү машинкасын беренче килгәндә үк күргән иде. — Машинкагыз тегәме?

— Алҗапкыч җүләделәр силсәвит кызлары. Бүләккә дир, картлар бәйрәменә дир.

Сәлимә караваат башындагы мамык шәлне карчыкның җилкәсенә япты:

— Өең салкынча. Мич кайнар үзе. Җил жылысын суыра, — дип, үзалдына

сөйләнеп, ул төргәген чиште. Кайчысы сумкасында иде, тукыманы алтыга бөкләп, кисте. Тегә-тегә шомарган остага бу эш идемени!

Йортлары сирәгәеп, урамнары бушаса да, авылның күзе дә, колагы да бар иде. Менә савыты белән сөт күтәргән күршесе килеп керде.

— Абыстайгынам, театр хатыны икән! Танымадым. Турыбыздан кәттә генә уздың, апаем! Әртист әнкәсен бик хөрмәтлисез, рәхмәт яугырлары. Мөршидәттәйнең хәлен белергә җибәрделәрме тагын? Нәрсә инде монда? Син теге юлы утынга дип биргән акча акурат кына, мичкә көненә өчәр ягарлык, апаем. Картлар йорты дисәк — әбиебез елый. Нәрсә текердәтәсең син, апаем?

— Син бит Зөбәйдә исемле? Иске пәрдәләрне салдыр, зинһар.

— Абыстайгынам, әллә яңаларын эләсеңме? Нәрсәгә мәшәкатьләнәсең, апаем? Сәләмә ызбага ниемә ул? Юылмаган биткә кершән сөртмиләр!

«Мин сонлап кына, бәгырьләрем мең кисәккә теленгәч кенә, йола шартына туры китереп яшь килен ролен уйныйм. Чын йөрәктән! Шуңа үз-үземне ышандырып!» — дип ничек ул куркыныч серен уртаклашсын ди!

— Искеләре саргайган бит, Зөбәйдә.

— Мөршидәттәй, синең ызбаңны матурайталар, бәлкем, улың дус-ишләре белән кайтадыр, — диде күрше хатыны карчыкның колагына. — Элгәре заманнарда көтүләре белән синдә күңел ачалар иде әртистләр.

— Зөбәйдә, чеметем генә бал белән ак май кирәк иде.

Сәлимә челтәрләрне кадакларга эләктергән арада, Зөбәйдә бал белән май да тапты.

— Хәзер әби белән икегез дә өйалдына чыгыгыз, — диде Сәлимә. — Бусага төбенә мендәр куегыз. Шуннан соң миңа кашык белән май һәм бал каптырыгыз!

— Абыстайгынам, нинди кәмит бу?

— Репетиция, Зөбәйдә. Мин үземне сыныйм, әгәр яхшы гына уйнасам — яңа спектакльләрдә килен ролен тапшыра режиссер.

— Ни дир тиятер катыны?

Карчык өйдәге ыгы-зыгыдан зинзара иде.

— И Мөршидәттәй, тамаша, ди! Кызык өчен, ди. Хөснуллаң да безне көлдертә иде. Тәхет дип утын әрдәнәсенә кунаклый иде дә, патша сымак боерык-фәрманнар бирә иде. Менә бу катын да сиңа-миңа театр күрсәтәм, ди. Аңа кушылып безгә дә уйныйсы, ди.

— Бәрәкалла, бәрәкалла. — Карчык җанланды. — Улым кушкандыр, әнкәмнең күңелен күр, дигәндер.

Йоланың әлеге өлеше үтәлгәч, Сәлимә иңнәренә чиләк-көянтә асты. «Тау астында йөз еллык чишмәбез ага, кышын да туңмый», — дип, Зөбәйдә юлын өйрәтте. Аңа инде болай да барысы да таныш кебек иде. Гүя егерме өч ел элек ыспай гәүдәсен сыгылдырып, авыл хатыннарын көнләштереп ул чишмәдән бер су китергән иде.

Тып-тын урамнарда «яшь килен»не сынарлык җан иЯләре генә юк иде. Кып-кызыл миләш куагын сарган чыпчыгый агайлар гына җимеш тәмләүдән туктап, «абау ла, абау! Нинди матур апасы!» дигәндәй чыркылдаша-чыркылдаша Сәлимәгә сокланды шикелле.

Җиңнәрен сызганып, итәкләрен нәкъ авылча биленә кыстырып, хатын сабынлы мунчала белән такталарын ышкый-ышкый идәннәр юды.

— Вәт Мөршидәттәй, — диде Зөбәйдә. — Син шул гомер килен рәхәте күрмәгән идең, хет ичмасам театр әртистенең уенын тамаша кылдың. Маладис, апаем, роленне шәп башкардың! Зинһар, Хөснуллага үтенечебезне житкер — шушы орчык кадәр генә әнкәсен ташламасын!

Менә йола үтәлде. Йә, син канәгатьме инде, Сәлимә? Син бүтән үкенмисеңме инде? Сиртмәле тимер караватында оеган карчык бермәлне, айнып:

— Тагын кил, олан, мине онытма,— диде. Аның күзендә чарасызлык һәм ялвару иде. Хатын караватк кырыена тезләнде, карчыкның тиресе юкарып, кан тамырлары бүлтәйгән ябык кулларына орынды. Шунда кызгану хисеннән аның җаны актарылды...

— Син мина рәнҗемә... әнкәй, — диде ул.

## XI

...Кырда Гафур төн пәрдәсен ертып, гөрс-гөрс һавага атты. Аты хәтта айга сикерде. «Эз аермасаң, ис сизмәсән — урман айкама да син, улым», — дияр иде әтисе. Ужым кыры ягында болар. Быел басу чиктәшендәге чикләвек урманында өч поши кышлый иде. Гафур җайдән үк аларны үзе ияләштерде. Бу егерь Абдулга гына мәгълүм иде. Ул сатылды микәнни? Монарчы егет киек-җанварны күз карасыдай саклый, ул биләмәсендә ни кәттә түрә абзыйларга да мылтык күтәреп йөрергә рөхсәт итми иде. Абдулның утары да аланда, агач ботагы сынса да, аңа ишетелә иде.

Ир, җан-фәрманга атын куалады. Маңгаена кигезгән фонарь уты, селкенгән унайга бии-бии яктырта иде. Мөгаен, хәсрәт «аучылар» шул уттан шикләнгәндер, чөнки урман авызында ук аның каршысында ике «бүкән» калыкты. Анлашыла, шухерда торалар.

— Стоп! — диде алдагысы. — Хәзер генә син гөрселдәттеңме, мөгезле шайтан?

Ул Гафурны иярдән сөйрәп төшермәкче иде, ир аның күкрәгенә типте:

— Ычкын юлдан!

Арттагысы атның тезгененнән эләктерде.

— Гафур Сөләйманович, син икән, шаулама, яме? — Монысы авыл җирлеге башлыгы Туктар иде. — Бездә важный кунаклар. Глава белән. Гүзәлия Шакировна абыйсын эзләттерәме? Степан, живо, Гаяз Идрисовичка эндәш!

— Эндәшмә, мин үзем аны табам, — диде Гафур. — Җибәр тезгенне!

— Ярамый, Гафур Сөләйманович, ярамый! Син нәрсә, абзыйларның ашына таракан булып төшәсеңме? Алар табынында кәефләнер өчен мина биш-алты сыер асрау да житә дисеңмени, хи-хи, — дип үртәгән башлыкны ул якасыннан умырып тотты:

— Наратка асам, егет! — диде. — Ничә поши аттырдың?

— А-а, бишмәтне ертасың! А-а, синең атаң урманы мәллә, а-а!

Гафур егетне җиргә селтәде дә, чакмага басты. Урман дереллдәп куйды, биек нарат очындагы кар бүктәре тузгып, өсләренә коелды...

— Гафур абый, валлаһи газыйм, пошиларга ата алмады абзыйлар. Каядыр качкан, мәлгуньнәр! — Дүртаякланган Туктар аңа ялварды. — Мине генә үтермә! Яшь әле мин! Өйләнмәгән дә, Гафур Сөләйманович. Атаң яхшы кеше, анаң яхшы...

— Сина дигән ядрә кибеттә, — диде ир һәм атын утарга чаптырды. Абдулланың атасы йокламый иде.

— Син дә бимаза икән, Сөләйман малае, — диде Шамил карт. — Абдулла бүлнистә, сукыр эчәгесе шартлады. Юкса урманда адәм калдыклары иркенәймәс иде. Мин ни лыгырдыймдыр, Гафурҗан балам, иркенәйделәр шул. Түрә халкы бик сансызланды, безнең ишеләрне чүпкә дә санамыйлар. Шуңа Абдул өчен дә куркам. Әзрәк хәйлә белән бар, ражун барма, дим. Аларның ялганы да дөрес, дим.

— Хәйлә хатын-кызга гына килешә, Шамил абзый.

— Мина да килеште, батчи. — Картның мыегы көлә иде. — Көндез җиләк аланын трактор чистартты. Юлдагы карны эттерделәр. Салкында да туңмаган теге чишмәне әрчеделәр. Янипланетлар тәлинкәсе өчен мәйдан хәстәрлиләрме, мәйтәм. Абдулның бинүкеле белән сарай кырыеннан гына

карыйм. Көндез ике бүлемтекле багон тарттырып китерделәр. Мөрҗәле. Менә сиңа әйтим, төтенле бит багон! Ике ир чатыр чаба шуның тирәсендә. Ике сәгатьтән өч лягкувый машина күренде. Ызнамы нәчәлстуа! Битләре түгәрәк тә, шома да. Бөтенесе бервакыт багонга тулды. Бервакыт мин сиңа әйтим, аннан дуңгыз тиресе төсле тәннәре кызарган шәрә ирләр атылып чыга да, чишмәгә чума. Чума да яндагы багонга чаба. Минем тавык мие эчкән башыма шунда гына сукты: тарттырмалы мунча икән ул, яниплanетлар тәлинкәсе түгел икән. Әһә, Шамил, мәйтәм, нәчәлстуа кыргый табигатьтә кәефләнә! Ә син, мәйтәм, карт төлке, моның ахырын чамалыйсыңмы? Кәефләнгән нәчәлстуа, мәйтәм, мылтык белән уйнарга ярата. Урманда икән, үзем аучы дип кәперәя, мәйтәм. Сөләйман малае туендырган пошилар тучны боларның корбаны, мәйтәм. Абдул да аларның ниятен сизенер иде, тик ул кайнар баш, ражун барыр иде. Пошиларны мин яшел мунча себеркесе белән алдалап, утарга кадәр алып килдем дә, шалт, сарайга яптым да. Иртәгә кадәр ятсыннар, мәйтәм. Алларында ун себерке, битамин чәйнәсеннәр, мәйтәм. Бездә генә кунасыңмы, улым?

— Өйдә көтәләр, Шамил абзый. Сиңа барысы өчен дә рәхмәт! Бигрәк тә хәйләң өчен. Чынлап та, сиңа килешә! — диде Гафур, саубуллашканда.

... Гаяз Идрисовичның иртәнге визиты төнге ау белән бәйле икәнлеген калын кашлары астында бозланган күзләре сөйли иде.

— Ну, герой, иштең ишәк чумарын! — диде ул, гыж-гыж сулап. — Син кем соң урманда пылт та пылт пушкаңнан сиптерергә! Синең аркаңда Иван Ивановичның кәефе бозылды!

— Дошманнарым эзәрлекли дип коты очтымени? Алайса, сакчыларын арттырсын. Авыл урманнарында агачлар да мылтыктан ата кайчак.

— Чигәнә дөңкелдәтсәләр, «нет тела, нет дела» була иде. Бәхетең, син безнең кияү.

— Сез дә бәхетле, Гаяз Идрисович. Сез — Гүзәлиянең абыйсы.

— Нишләтер идең, калай әтәч?

Иснәнә-иснәнә бүлмәсеннән йокысы туймаган хатыны чыкты.

— Ник тавышланасыз?

— Сеңелем, ирең миңа яный, — диде абый кеше.

— Янамыйм, кисәтәм генә.

— Кем соң син житәкчеләрне кисәтергә? Урман синең шәхси милкеңме? Атаң малымы яисә? Кирәк икән, кырыгызны таптарлар, кирәк икән, елгаларыгызны кирегә табан агызырлар! Тының тартма, үз хуҗалыгың тирәсендә генә казын! Әллә Иван Иванович кебек алтынга коенган байлар сезнең сукыр куяныгызга калганмы? Кирәксә районыгыз белән сатып ала ул сезне! Төкерек ул аңа. Аның Америкада, Швейцариядә капиталы, урманы-елгасы белән менәр-менәр гектар җирләре бар!

— Хатын-кызлардан да хуже сез, ирләр! Абый, тынычлан инде, — Гүзәлия, су салып, Гаяз Идрисовичка бирде. — Син — каш өстендәге күз. Син — халык сайлаган депутат! Үз дәрәҗәң белән горурланырга тиеш. Хәзер Гафур дорфалыгы өчен синнән гафу үтенер. Әйеме, Гафур?

— Гафу сорарлык гаебем юк минем, — диде ир. — Иван Ивановичлар җир шарын колачлаганда, шушы Җиде Чишмә кебек бәләкәй генә аймакка кул сузмасыннар, мин сайлаучылар исеменнән сез — депутатка шундый үтенеч белән мөрәҗәгать итәм.

— Көл, көл, ахмак кияү!

— Гафур! — Хатыны аңа шелтәле караш ташлады. — Абыйдан гафу үтен! Тиз!

— Икенче үтенечем, Гаяз Идрисович, шундый. «Тыела» дигән сүзнең мәгънәсен сүзлектән карагыз. Ау чорында да безнең төбәк урманнарында

пошиларны ату тыела, чөнки алар әз санда, аларның токымын үрчетер өчен дистә еллар үтәргә мөмкин.

Зур кунак диварларны селкетеп шаркылдап көлде, ерылган авызын учы белән көчкә генә җыйгач, ул:

— Пошилар токымы диме? Син үзең турында кайгырт! Син, ахмак кияү, нәсел калдырырга сәләтсез печкән үгез! — диде.

Гүя йөрәкнең кыл уртасына пычак белән кададылар. Гафурның тәнен көзән җыерып, кул-аяклары тартышты. Ирен читләре күбекләнде.

— Абыйдан гафу үтен, мәнсез! — Гүзәлия чебен төсле һаман колак төбендә безелди иде. — Абыйдан гафу үтен, диләр!

Кин дөнья аның өчен кинәт кенә тарайды. Ирнең йодрыгы белән жир куәренә тондырып, аны җимерәсе килде. Әмма ул хәлсез иде, ул яралы иде. Беркемгә дә күтәрелеп карамыйча, тышка чыкты. Ишек янагына сөялгән апасы (ни гаҗәп, энесен яклап аю ботарларга әзер карчык бу юлысы шымайган иде) аңа иярде.

— Сөтләрне әчеттермә, забутка илт, — диде кортка.

— Бәлки, безгә урамнан сөт елгасы агызыргадыр, ә, апа? Ярый юк, елгасы бар.

— Нинди сүз бу, энем! Телеңнән оял димим, тел, әнә, дифутат коралы. Кулларыңнан оял! Ничаклы хезмәт куйганнан соң шәһәр түрәсенә үчегеп хуҗалык туздырттырам, ди. Көт! Атаң да урман, поши дип өзгәләнер иде, инде аңа син алмашмы? Ни дип дифутатларны ачуландырып йөрдең инде төнлә, җүләр баш?! Бүтән кычытмаганны кашыма, энем.

— Урман гына түгел әле монда, апа.

— Ә нәстәгә тәмсезләндең, алайса?

— Их, апа, апа!

— Уфылдама, сизәм, ни әйтереңне. Тагы балам юк дисең инде, энем. Юк тек, юк! Хәсрәте дә юк аның каруы. Күке кызы сиңа да, улыңа да каргыш күкелдәр иде.

Гафур түш кесәсенә тыгылды:

— Карале, апа, Сәлимә апага акча бир әле. Кешене «рәхмәт»кә генә эшләтмик.

— Үзең бир! — диде карчык. — Син аның белән дус, гел аны яклыйсың! Бидоннарны нишләтәсең?

— Төштән соң урнаштырырмын, апа.

«Сыерчык оясы»ның ишек келәсенә йомычка кисәге кыстырганнар иде. Иртән каядыр киткән иде шул күршесе. Ир эчкә узды, һәм, фуфайкасын салып, шапылдап диванга ауды. Жебедең, Гафур, жебедең. Егетлекме инде бу, йә? Түрәләр белән читләшкән саен дөнья кысылса — бөҗәккә әверелеп ярыкка посуың хәерлерәк. Йә, башыңны имә әле, туган. Гаяз Идрисович сине теле белән жинсә жинсен! Рас, син нәсел калдырырга сәләтсез. Бәхетнең ике чите китек. Шайтан алгыры, икесе китек икән, димәк, бәхет тә яртылаш кына! Гүзәлиясе әлегә бала дип сүз кузгатмый. Бәлки, эчтән генә сызланадыр, бәлки, аның шигырьләре бала булып туадыр. Язучылар һәр китабым бала кебек кадерле диярго ярата бит.

Атасы аңа үрнәк иде. Табигый ки, Гафурның да агроном Сөләйман кебек чын әти буласы килә иде. Кайчакта ул хыялындагы улы белән сөйләшеп тә ала иде. Әнә, алар ат арбасында печәннән кайта.

— Әти, бу басулар кемнеке?

— Синеке, улым.

— Урман кемнеке?

— Синеке, улым.

— Бүреләр, төлкеләр, пошилар кемнеке?

— Синеке, улым.

— Чишмә кемнеке?

— Ансы да синеке улым.

— Әти, әти! Барсы-барсыдамы?

— Әгәр «минеке» дип горурлансаң, якласаң-сакласаң, тир тамызып шунда эшләсәң — туган җиреңдә барысы да синеке, улым, — ди әтисе, йомгаклап.

...Зур кунак озайган, хатыны шатор-шотыр кульязмаларын ертып, идәнгә ташлый иде.

— Нишлисең, аппагым? — диде кәгазь өеменә гаҗәпләнгән ир.

— Нишлим, нишлим! Сиңа багышлап язган шигырьләремне юк итәм! Минем абый белән көрәшеп нәрсә отасың син?! Ул синең ише авыл мужигын кияү дип, олы башын кече итеп, безгә килә иде, ә син аны мыскыллап Ак өйдә бер бомж хатынны кундырасың! Аппагым димә миңа, син мине дә пычракка салып каралттың! Син — тупас, холыксыз, әдәпсез, мәгънәсез һәм шуның өс... өс... — Гүзәлия нәфрәтеннән тотлыкты. — ... өстенә, нәселе корыган ир бәндәсе дә икән! Менә ни өчен мин балага узалмыйм икән!

## XII

...Февраль бураннары тынган чак иде. Сәлимә Казанга җыенды. Балаларың белән әчелешле булып, хәбәрләрен дә ишетмичә яшәргә ярамый иде. Килен — чит оя кошы, ул үзенчә тәрбияләнгән, ә улы — үзенеке иде дә бит, аңа салган оеткыдан катык ясалмады, әче су гына чыпырдап утыра. Оныклар сагындырды! Гәрчә, дәү әниләре аларга бишек җыры җырламаса да, үчтеки сикертмәсә дә — нарасыйлар аның йөрәк парәм дип үстергән улының балалары иде. Гафурга ул өч көнгә китәм, диде. Үзен гаеплерәк санап әйтте ахрысы. Ир: «Син ирекле кеше, Сәлимә апа», — диде. Күршесе яңа кредитлар алып, савым сыерлары кайтармакчы иде. «Син ирекле» дисә дә, аның күзендә: «Озак торма!» дигән ялвару сиземләнә иде шикелле. «Шикелле» генә иде... Мөгаен, Сәлимә шулай күрергә тели иде.

Ул шәһәрдән, шәһәр аңардан ятсынды. Аерылганнарына нибарысы тугыз ай гына иде ләбаса! Асфальт каты иде, үкчәсен авырттырды. Төтен-сөрем белән тыгызланган һава өзек-өзек кенә сулатты. Сәлимә авыл сукмагыннан атлаган кебек иркенләп-җәелеп бармакчы иде дә, гел-гел кешеләргә бәрелде. Катык, каймак тутырган сумкасын өстерәп бишенче катка менгәндә биеклектән башлары әйләнде. «Синме соң бу, кала бичәсе?!» Ишектәге кыңгырау төймәсе өч тапкыр зеңгелдәгәч:

— Кем анда? — дип сорадылар.

— Мин! Әниегез, дәү әниегез — икесе бергә, — диде Сәлимә. Менә ул хәзер оныкларын авыл катыгы белән сыйлар, тәмле сөт эчертер. Җиде Чишмә турында чын әкият сөйләр.

— Безнең дәү әниебез юк, — диде эчтәге хатын-кыз тавышы.

— Варвара, шаярма! Мин оныкларымны сагындым!

Ишек ачылды, ләкин бу киленгә охшамаган бөтенләй ят хатын иде.

— Варваралар монда не живут, — диде ул. — Бу фатирны алар нам продали.

— Ничек?

— Понятие не имею, апа! Продали и все!

— Мин... мин бит пропискада идем, — диде Сәлимә.

— Чистая продажа, документлар тәртиптә. Претензиягез туганнарыгызга, апа!

Күрше фатир ишегеннән берәүсе муенын сузып:

— Үлеш, Сәлимә, синме бу? — дигәч кенә ул:

— Йа Аллам, — диде. — Күрәселәр бар икән!

«Берәүсе» театрның жыештыручысы Тәнзилә иде.

— Болардан берни дә төпченмә, керче безгә, кер, — дим. Тәнзилә аны үзенә таба тарткалады.

Ә күрәселәр бик якында гына иде.

— Сәлимәкәем, Фәрит сина шылтыратмадымени? Алар ярты ай элек кенә Рязаньга күченделәр, — диде Тәнзилә.

Үз баласын яманлаган ананың теле — иң гөнаһлы тел. Хатын барысыннан да хәбәрдар кебек:

— Бер әйткәннәр иде шул, — диде. — Мин әле җәйгәрәктер дигән идем. Исән-сау гына яшәсеннәр!

— Киленең, Казан чиркәүләре кечкенә, ди. Бәйрәмнәрдә тыгын, ди. Балаларым таптала, ди. Бездә гыйбадәтханәләр зур, ди.

— Син ни хәлдә Тәнзилә? Һаман театрдамы? Безнекеләр ничек?

— Чү, башта бу чиләкнең капкачын ябыйк, Сәлимә. Беркөнне улың муенына бармак калынлыгындагы чылбыр аскан.

— Минем бүләк иде ул, Тәнзилә. Айлы көмеш чылбыр.

— Чур, ай болытлар артында, Сәлимәкәем! Тәре анда, тәре! Варвара Фәритне дә чукындырмады микән? Йөрәк даруы биримме?

— Синдә бигрәк салкын, — диде хатын. Ул йон кофтасының төймәләрен каптырмакчы иде, бармаклары катты.

Бөтен тәнен суытып, йөрәккә табан боз кантары шуыша иде.

— Мәле, кайнар чәй эч, Сәлимәкәем, автобуста туңгансыңдыр син.

Баш түбәсен зыңгылдатып чиркәү чаңы кактылар. Чың-чың, чың-чың, чың-чың...

— Тәрәзәң ачык, ахрысы? — диде ул. — Бигрәк каты бәрәләр...

— Кыш көне ник тәрәзә ачыйм ди! Бездә тыныч, тавышның әсәре дә юк. Син борчылма алай ук. Инфаркт сукмасын берүк. Ярты татар чукынган бүген, Сәлимәкәем. Театрда безнекеләр ничек, дисеңме? Без әртистләр белән, синең кебек, авызга авыз түгел. Мин аларны күбрәк орышам, бәтинкә-түфлиләрегезне чүпрәккә сөртегез, идәнне таптамагыз, дим. Тегү цехында синең урының буш, сине көтәләр.

— Анламадым, кем көтә?

— Әртистләр, билгеле!

— Мин алар белән хушлашкан идем бит.

— Хушлашмагаең ни! Кәмитче Барый Хәтиев өчәр саубуллашса да, тып итеп, исәнмесез, дип янә килеп җитә.

— Кан басымы микән, колак чыңлый. — Сәлимә аркасын диванга терәде. — Су йотсам, бәлки хәлләнермен.

Хәлләнәмени! Таш астында калып изелде-сытылды инде ул! «Юлларда бәла-казалардан сакласын» дип, Сәлимә улының түш кесәсенә дога язуы тыккан иде. Аны нишләтте икән?

— Суга тынычландыра торган дару да тамыздым, эч әле, Сәлимәкәем, — диде Тәнзилә.

Әллә дару тәэсир иттеме, әллә йөрәк тибешен әкренәйттеме, хатынның керфекләре йомылды...

— Әни! Көпә-көндез йоклыйсыңмы? — Бәй, Фәрит көлемсерәп аңа карап тора ласа!

— Балам! Ярымаең кайда?

— Өзелде, әни.

— Әйдә, яңасын алам!

— Кирәкми, әни. Варварага ошамый ул.

— Син ник һаман хатының кубызына биисең, балам?! Ник синең кол төсле башың иелгән?!

— Аска тарта, әни.

— Нәрсә тарта?!

— Муендагы кош тәпие — тимер, шул тарта, әни.

— Доган кайда, балам?

— Мәчеттәге сәдакалар тартмасына бөкләп салдым. Син доганы ыргытырга ярамый дигән идең.

— Иманын саткан кеше кем дип атала, беләсеңме, балам! Мөртәт!

— Нишлим, Варвараны яратам!

— Ярат! Тик Аллаһтан курка-курка гына ярат, Фәрит!

— Бу исемне оныт, мин хәзер Федор!

— Ә?!

... Сәлимә диванга йөзтүбән капланып үкседе. Төше бигрәк куркыныч иде.

— Уятмадым, саташтың да инде, — диде Тәнзилә.

Улы турында бүтән сорамаска дип күңеленә беркетсә дә хатын:

— Варвара Фәриткә ничегрәк эндәшә иде? — диде.

— Милый, пушистый, ди. Маржаның юмалыгыннан безнең татар ирләре май сыман эри, Сәлимәкәем. Зәһәрләнсә — Федор дурачок, ди.

— Ә?!

— Әйдәле, теманы үзгәртик, Сәлимәкәем. Син черем иткәндә мин театрга шылтыраттым. Сәлимә Минханова Казанда дигәч, и шатландылар. Дүрт күз белән көтәбез, диләр. Сөекле күкебез читтә тилмермәсен, үзенең читлегендә җырласын, диләр.

— Мин читтә тилмермим, Җиде Чишмәдә — әти-әни нигезендә яшим, Тәнзилә.

— Кырык яшеннән авылда муртаясыңмы? Синең әле чәчәккә бөреләнер чагың!

— Үгетләмә, Тәнзилә.

— Ничек кенә үгетлим! Театр Финляндиягә гастрольгә җыена. Аларга күке тавышы кирәк. Биш куллап чит илгә апкитәләр үзеңне, Сәлимәкәем!

Сәлимәнең күңел канатлары беркая да талпынмый иде шул. Ул нindidер тукталышта кузгалмыйча басып тора да тора, гүя улы Фәрит җаны белән бергә тулаем гәүдәсен дә бозга катырган иде. Кичкырын утлар кабынгач, ул озак кына тәрәзәдән шәһәр дөньясын күзәтте. Бернәрсә дә үзгәрмәгән, бөтенесе дә элеккечә икән: кешеләр сугыла-бәрелә каядыр ашыга, урамнардан машина ташкыны ага... Сөремле күк йөзендә йолдызлар да балкымый. Әйтерсең, алар Сәлимә кебек ничарадан бичара авылга күченгән иде.

Югыйсә бер үк җиһан! Ә нинди зур аерма!

Монда, билгеле, аның тормышы көйләнгән иде. Хатын ялгыш та иртәгә ни булыр дип борчылмый, бертөрлерәк тоелса да, яшәвенең мәгънәсе бар иде. И Аллам, «патшалар», «генераллар», «ханбикәләр» киендергән Сәлимә иде ләбаса ул! Дүрткүз белән көтәләр ди Тәнзилә. Озын-озак тәнәфестән соң «саумы сез?» дип яңадан театр белән исәнләшүләре рәхәттер, әлбәттә.

Кичке спектакльдән соң сәхнә идәннәрен жыештырып кайткан хуҗабикә аның күңелен алгысытып:

— Иртәгә уникеләр тирәсенә сине директор Алмаз Мөхәммәтшин чакырды. Киреләнмә, Сәлимәкәем, мондый хөрмәт беркемгә дә тәтеми, — диде. — Фатирың да җайлыйбыз, ди. Миндә дә ике бүлмә, иркен, икебез дә ябык, сыярбыз, — диде.

— Рәхмәт, — диде Сәлимә. Үлчәүнең Тәнзилә ягындагы тәлинкәсе авырайды кебек. Чынлап та, театрда аның абруе зур иде. Хәтта ки директор аны кунаклар белән бер табынга утыртып сыйлый һәм:

— Бу ханым җир шарының иң атаклы тегүчесе, — дип үсендерә иде.

— Нишлим икән, Тәнзилә?

— Икеләнмә, Сәлимәкәем!

— Бу кыяфәтем белән артистларга күренерлекме соң мин?

— Үзеңнән көнләшәчәкләр әле, яшәргәнсең син, күке! Күзләрең очкынланган! Берәр мыекбайга гашыйк мәллә син дисәм, бүген авылларда аракы эчеп зәңгәрләнгән кәкре-бөкре, тешсез ирләр генә калды инде. Ахырзаманда каберләреннән кубарылган мәетләр, валлаһи!

Иртән Сәлимә үз-үзенә катгый итеп боерды: «Театрга бар!»

Барды. Әмма дингездә йөзгән ак карабка охшаган таныш бинаның баскычыннан менгәч, кире борылып мәйдандагы эскәмиягә килеп утырды. Чү, әз генә сулыш ал, Сәлимә. Нишләп әле хис бураннары котырып-котырып дулый башлады? Театр училищесына имтихан тапшырганда сина «икеле» билгесе куйдылар, әйеме? Һәм синең артист булам дигән хыял-өметләреннең канаты киселде. Баскычта үкереп-үкереп елаганда кемдер җилкәңә кулы белән орынды.

— Чибәркәем, сине кайсы җүнсезе чеметте?

Чибәркәй озын буйлы пәһлеванның шаяртуын өнәмичә:

— Беркем дә чеметмәде, абый!

— Алайса, ник көмештән дә көмешрәк күз яшьләреңне әрәм итәсең, чибәркәем, йа? Әйдә, мин аларны учыма җыям.

— Мин... мин имтиханда яндым, абый!

— Шуңа яшь түгәләр димени, чибәркәем. Икенче елга сине имтихансыз да алырлар. Хөснулла абыең гарантия бирә! — диде пәһлеван. — Син авыл кызымы?

— Авылныкы, абый.

— Кулың берәр җүнлерәк эш беләме, чибәркәем?

— Мин тегәм, чигәм, абый!

— Во, во! Самый үзе! Театрда тегүчеләргә кытлык. Киттек, чибәркәем!

Училище ишеге шулай ябылды. Инде аның йөрәгенә артист Хөснулла Минханов хуҗа иде... Казанда кар аз икән лә. Хәер, монда көн саен чистарталар. Ә авылдагы «ак мамык» тауларын яз кояшы көпшәкләндерсә генә инде. Гафур әүвәл ишегалларын көри, аннан Ак өйгә сукмак сала. Андый чакларда Сәлимәнең кулында да агач көрәк яхшы гына «җилләнә»: ул да, тузан очыргандай, кар бөртекләрен дуылдата. И аның рәхәтлеге! Бер башта күршесе, икенче башта — хатын. Ә сукмак берәү генә... Азактан бу икәүне тоташтыра ул...

Җиде Чишмәдә ни хәлләр икән? Сәлимәнең сөекледән сөеклесе, назлыдан назлысы Акмаңгай төнлә бозаулагандыр, шәт. Кытыршы теле белән биттән ялап ала иде хайван. Бөтерчек сарыкның йодрык хәтле генә бәтиләре яңа гына аякланган иде, тояклар астында тапталмас микән? Сынган кулы ялганса да, Мингайшә карчык сыерларны ничекләр сауды икән? Аның әтәче дә боеккан иде. Тәпиләрен өшеткән иде.

Йа, Сәлимә, болар синең кайгыңмени?! Авыл озаккарак сузылган төш кенә иде. Төш кенә... Җиде Чишмәдә аклыктан күз чагыла, ә монда бөтен нәрсә соры икән. Шәһәрнең кары да пычрак икән.

Хатын эскәмиягә ябышкан боз кисәген тырнап иснәде. Сөт исе сеңгән... Бозга түгел лә, кулына! Татлы һәм тансык ис! Ак өйдә — мендәрдә мыраубикә йоклаган иде, ә Сәлимә аны уятырга кызганган иде. Мич якканда Гафур мәчене абайлады микән? Акбайның савыты өйалдында иде... Гөлләргә су сиптеләр микән? Тамчы гөл матур гына тамырланган иде...

Әле синнән кичә генә аерылды ла, авыл! Ник бәгырьләргә үтеп сызландырасың, ә?

Хатын күшеккән бармаклары белән, телефонда саннар җыйды.

— Гафур!

— Әү, Сәлимә апа!

— Син кредит юллап Казанга ук килмәгәем дигән идең.

— Мин шәһәрдә, әле генә банкта эшләрне төгәлләдем. Синең барысы да тәртиптәме, акча калдырыйммы, Сәлимә апа?

Сәлимә каударланып:

— Калдырма. Үземне генә алып кит, зинһар, — диде.

## XIII

...Ул, алагаем зур таш тәгәрәтеп, тауга менеп маташа. Ә тау биек, биек, биек! Болытлар ышкылып, аның түбәсен тагын да очлайткан. Армас микән йөрәкләр, талмас микән беләкләр... Хуҗалыкта мал-туар ишәйгән саен ишәя. Апасы белән Сәлимә, ярыш игълан иткәндәй, узыша-узыша эшлиләр. Җәйгә күршесенең йортын сипләтер Гафур. Балта остасы Зариф белән бу хакта килештеләр. Зариф та, аның кебек, агроном дипломын шкаф тартмасында саклый иде. Ир ана:

— Миңа конкурент кирәк, син дә фермерлыкка кереш, бер-беребезне кыздырып торырбыз, — дигәч, оста:

— Бәласеннән башаяк, — диде. — Беренчедән, налоглар белән миемне кайнатмыйм, отчетлар белән изаланмыйм, шабашкада елына өч-дүрт өй салсам — акчам түлке үз кесәмә генә, хөкүмәтне баетасы түгел. Икенчедән, кулак дип тиргәми кеше. Авылның психологиясеңдер, мөгаен. Син эшле-ашлы икән, көнләшеп берәр ярлык тагалар. Сине бүген тотып ашарлар иде, Гафур. Узган гасырның утызынчы елларында синдәйләрне Себергә сөргәннәр. Сөләйман малае байый, трактор, машина апкайтты, диләр. Синең терәк көчле шул, терәк! Кая безгә депутат кияве белән тиңләшергә?

Дөрес, ул депутат кияве иде. Көзге ау вакыйгасыннан соң Гаяз Идрисович үпкәләп, шактый гына нурлы йөзләрен күрсәтмәде. Гүзәлия араларны җылытыр өчен Казанга түшкә-түшкә ит, каймак, катык, йомырка озаттырды. Ә беркөнне, март ахырларында, зур кунак аларның йортында пәйда булды. Ахирәт дуслар сыман Гафурны кочаклап күреште. «Сыерчык оясы»на төртеп:

— Без — чыпчыкка кайчан ояны бушаталар? — дип көлдерде.

Гафурның эчендә бүреләр улаган мәлләр иде. Берәр айдан чәчүләр башлана. Ә аның җир турындагы гаризасы каралмаган, мөгаен ул, кемдер кыштырдатмаса, каралмаячак та иде. Жирлек башлыгы халык сиңа пай җирләрен бирмибез ди, шуңа җыелышлар уздырмыйм дип кәпрәя. Гафур чарасыз иде. Авылның битарафлыгы аның канын куырды. Карт-коры, ни ялынсаң да, клубка килмәячәк. Алар безнең җыелу урыны — зиратта, дияр. «Кызыл борын» агай-эне мәгәричеңне өстәлгә куеп, бездә генә сөйләшик, дияр. Хатын-кыз: «Балаларым шәһәрдә, миңа ике дөнья — бер кәнди», — дияр. Ул беренче мәртәбә (беренче!) хатынының туганыннан ярдәм сорарга ниятләде:

— Гаяз Идрисович, мин быел җирләрне рәсмиләштереп бодай чәчмәкче идем. Нигәдер җитәкчеләрдән җавап юк.

— Син бер басуында уҗым тундыргансың диләр, кияү.

— Әйе, көзен озынга үсте дә...

— Сабак алмадыңмы, кияү балакай? Жир дисең инде, ә! Давай, теге вакыттагы кебек кырга чык та шарт та шорт ат! Үзең: «Басулар минеке!» — дип сөрән сал. Сез, авыл мужиклары, проблемаларны тавыш-гауга куптарып тиз генә чишмәкче! Сез, майламыйча гына, табада коймак чыжлатмакчы! Син шул ауда безнең уенга кушылып берәр поши сәламәсе атып, аяк очыбызга аударсаң — бүген биш-ун басу синекенә әйләнер иде.

Ә син айгыр төсле чыгымлап тәртәгә типтең! Хәзер кашык сыймый дип чалыш авызыңа үзең үпкәлә, кияү!

— Булышмыйм дисезмени, Гаяз Идрисович?

— Депутат дигәч тә, без әүлия мәллә, кияү! Бу минем хәлдән килерлек эш түгел. Чөнки сезнең җирләрегезнең хуҗасы — Иван Иванович. Ә мин синең өчен аның белән низаглашмыйм. Быел икенче срокка депутатлыкка әзерләнсәм, сайлау алды кампаниясенә акчаны Иваныч түли.

Ирнең чигәсенә тир бәрде:

— Ничек инде, ничек Иваныч хуҗа?! Бу кыр-басулар ничә гасыр Җиде Чишмәнеке иде. Элгәре бабайлар сука белән эшкәрткән аларны. Минем әти шушында йөрәк өянәгеннән егылып үлде. Учында кара туфрак иде!

— Безнең һәркайсыбыз кайдадыр йә тәгәрәп, йә батып, йә авариягә очрап, йә самолет шартлап үлә, кияү, — диде зур кунак һәм пиджак кесәсендәге бәләкәй солдат фляжкасының капкачын борып, коньяк белән тамагын чылатты. — Уф, нервыларны какшатасың син, кияү балакай. Сенел хакына гына түзәм.

— Безнең басуларда Иван Грозный нишләргә уйлый? Нәрсә чәчә? — диде йөрәге чәнечкән Гафур.

— Әкрен, кияү, әкрен! Иваныч нинди Грозный булсын?!

— Җирләребезне пычрак итеге белән таптаган баскакны ничек атарга дисез? Грозный ул!

— Арыш чәчәме, алабута үстерәме яисә нефть ятмалары эзләштерәме, Иванычның үз ихтыярында. Руслар әйтмешли, «Не твоего ума дело», кияү.

Сөт заводы директоры Әнәс Хөсәенов хакимият киңәшмәләрендә катнаша, ул район тормышыннан хәбәрдар иде. Әнәс:

— Иванович кебек капиталистлар синең басуыңда иген игәмени, сантый! Җиреңне пүчтәк кенә бәягә ала да ул, ун-унбиш тапкыр кыйбатлатып, башкаларга аткара. Анысы шунда реактив калдыклар күмә. Төнлә нурланыштан авылыгыз белән үтәли күренәсез икән, сәхнәдәш, — дип хихылдаганда, тәшвишләнгән ир:

— Теш агартма! — диде. — Безнең төбәкләргә инвестор керәмени?

— Бу хакта минем белән киңәшсәләр, Җиде Чишмә кырларына тимәгез, анда бар буе белән Сөләйманыч сузылып ятты, диярмен. Йа, йа, сәхнәдәш, мәзәк сүзгә дә каш җыерма. Сезнең кишәрлекләрегез Иванычтамы, Степанычтамы, мин белешермен.

Әнәс Хөсәеновның «раведка мәгълүматлары» аның сүнәм-сүнәм дип пыскыган өмет учагын терелтеп җибәрде.

— Синең депутат агаең шыттыра, кырларыгызны пока Иваныч атлы түрәгә бирмәгәннәр. Хаким ал дип кыстагач, тегесе уйлармын дигәндер. Ә ул безнекенә «риза» дип ишетелгәндер. Син хәзер җирлек башлыгының артына ут эл. Халык белән сөйләшеп синең файдага карар кабул итсен. Малай, киләчәктә байлар уңдырышлы җирләрне уптым үзләштерәчәк, Әнәс әйтте диярсең.

Бет хәтле бөҗәк кадалса да тәнең тиз генә төзәлмәскә мөмкин. Туктар шул бөҗәкләрнең берсе иде. Ул бу юлысы башын җүләргә салып: «Гафур Сөләйманович, миндә ике гариза, безнекеләр кайсыгызны хуплар. Син бик кытыклангач, берсекөнгә әби-бабайларны, апа-абыйларны җыям», — диде. Гафур өйдән-өйгә йөреп: «Эшләтегез мине, җәмәгать», — дип мескенләнмәгән иде, инде җыенда усал сөйләшер. «Мина өч аршын җир дә бирмәгез, әйдәгез, кулларыгызны күтәреп, Җиде Чишмәгә ясин чыгыйк», — дияр. Кискенлек әтисеннән аның. Бу холкы белән, бәлки, ул үзенә зыян гына китерәдер. Ир каты төерне йомшарта белми. Югыйсә монын бер

кыенлыгы да юк. Беркөнне Гафур сыйныфташлары Сәлих белән Барины очратты. Егетләр апын-төпен күрше авылдан кайталар, кулларында яртылаш эчелгән аракы шешәсе иде.

— Ну байыйсың, яшьти! — диде Сәлих. — Син бүген чеп-чи кулак!

— Түнтәрешләр кирәк, түнтәрешләр, — диде Бари. — Шунда кулаякларыңны богаулап без сине Себергә олактырабыз!

«Йәгез инде, туганнар, нинди кулак ди. Мин гап-гади Гафур, сезнең белән бер мәктәптә укыдык», — дип, уен-көлкегә бор бит инде, ә ул исерекләрне сүзсез генә кар суына манды...

Җыелыш булмады. Кинәт кенә сәламәтлеге какшаган Туктар Мәскәүгә дәваланырга киткән иде. Бөртек ымсынып басулар елады... Апрель кояшы туфракны корытты-киптерде. Астыртын «бөҗәк» тешләрен йөрәккә бик тирән батырды...

Дөнья ирне ике яклап кыйнамакчы иде, ахрысы: өнендә тәпиен имеп кыш буе изрәп йоклаганнан соң уянган аю сыман, аның Гүзәлиясе дә «җанланды». Кинә тауларын, болыннарны урады да:

— Мин дусларымны кунакка чакырдым, — диде.

— Кемнәрне?

Хатыны авылда беркем белән дә аралашмый иде.

— Ой, бигрәк хәтерең таркау синең, иптәш фермер! Зәбирләрне, Галинурларны, әлбәттә!

— Әһә, төркемдәшләрең икән!

— Иҗатташлар, иптәш фермер, иҗатташлар! Син каршы мәллә?

Ир кичә-бүген күңелендә нинди авырлык йөрткәнен аңлатырга теләп:

— Әзрәк кәеф кырылган чак иде. Бәлки, җәй уртасынарак...

— ...чигерик, әйеме? Кунаклар миңа кайта, миңа! Сиңа түгел, Гафур! Синең авылыңда мүкләнәм ич мин! Әллә сыер-сарыкларыңа, тавыкәтәчләреңә шигырьләремне укып ләззәтләнимме?!

— Аппагым...

— Нинди аппак?! Син мине баш-аяк каралттың инде! Әгәр син минем каләмдәшләрем өчен расхутланмыйм дисәң, кибеттән ун сумлык бомжпакетлар алыйк.

Гафур кысмырланмый, ул бары тик көнләшә генә иде...

Кунаклар дигәч, апасы пыр тузды:

— Колхоз кадәр хуҗалык сөйрәгән иренең чеметем генә хәленә керер урынга ул кәеф-сафа кормакчымы?

— Апа, шаулама! Сарык суеп, шашлыкка ит тозлыйк, тавык шулпасы пешерик.

— Күке кызы белән икебезгә егерме биш сыер, өлгермим, энем. Чүлмәк гөлең үз кунакларын үзе сыйласын, әйдә!

— Фәридә апаларга кагылыйм әле, апа.

— Бүре Фәридәсенәме? Колхоз сыерларының имчәген төкереге белән юешләтеп сава иде, шакшы хатын ул, энем!

— Ә Зифа апа ничек?

— Кәҗә Зифасымы? Беркөнне ярты ыстакан сөт илтә күсәк малаена. И, бу аның кече теленә генә җитә инде дигән идем, без сезнең Гафурыгыз төсле кулакларны әллә чиләге белән сөт чөмерергә, ди. Мәйтәм, әлкәш улың Шәкүр ник карават матрасын сасытып, пес итеп ята соң, дабай, йөз сыер асрасын, мәйтәм. Энем, балам, Жиде Чишмәдә сине чәйниләр, ә син забуттан кечтеки пакетларга сөт, каймак, катык тутырып, карт-корыга, гарип-горабага өләштерәсең. Ике түшкә сыер итен дә кисәкләп-кисәкләп тараттың. Җә, кайсысы изгелегеңә, рәхмәт, ди, кайсысы, шөкер, ди?

— Апа, ник син кешеләр турында гел начар уйлыйсың икән?

— Чөнки мин синнән алданрак тудым, энем! Син дә хатынның сыңары, вәйт!

«Сәлимә апа!» Ул да вакытым тыгыз дияр микән? Күрше хатыны Шәрбәнбану якларына ешлады. Күке кызы азгын, ирләр аулый ди апасы. Сәлимә турында Әнәс Хөсәенов та сораштыра. Һәр иртә аңа сәлам юллый. Тракторчы Хаммат Шәрбәнбану егете, мөгаен ул Сәлимәнең кем янына йөргәнен ачыклар иде. Маташма, Гафур, ир бул! Гайбәт өчен кесән бик сай синең, туган.

Күршесе Мингайшә апасы шикелле тел кашымады:

— Кунак каршылау күңелле мәшәкать ич, табын өчен йөзегез кызармас, — диде ул. — Шәһәр кешесе табигатькә мөкиббән, син бакчагызга өстәл белән артсыз эскәмия куй, Гафур. — Сандугачлар сайравын тыңлый-тыңлый таң аттырачаклар, валлаһи менә.

Дуслар дүртәү — өч ир, бер хатын-кыз иде. Гүзәлиясе һәрберсенең кочагына ыргылып үпте-кочаклады, кычкырып көлде, кулларын чәбәкләде. Әйтерсең, ул еллар буе кыргый утрауда яшәгән дә, менә хәзер ярда җан ияләре күренгәч шатлыгыннан үрле-кырлы сикерә иде. «Ока» машинасында бөгәрләнеп кайткан егетләр аякларын язгач, Гафурның «Джип» тәгәрмәчләренә типкәләп:

— Вәт шәп арба, — диештеләр. — Монда утырсаң, юл газабы — гүр газабы димисең инде!

Хатын-кыз табынга ризык ташыганда Гафур, хуҗа буларак, ир-ат затын фермасы белән таныштырырга тиеш, бу — Гүзәлиянең теләге иде. Ләкин кунак халкы әдәп өчен генә берничә сорау бирде дә, «экскурсия»дән туйды. Аның каруы алар арасындагы бердәнбер хатын-кыз иргә кырмавык кебек кадалды:

— Мин сине мактап газитәгә язам! Реклама ясыйм үзеңә, бөтен Татарстанга танытам, Гафур әфәнде.

— Вилория, синең газитәңнең тиражы сигез йөз данәме? Ә республикада ничә миллион халык? — Рәсим исемле яшь кенә егет кызның бакчасына эре генә таш ыргытты.

— Зато безнең реклама бәяләре түбән. Сез прайс-листыгызда журналыгызның бер бите ун мең сум дип күрсәтәсез, Рәсим. Значит, куш бит егерме мең! Кайсы тилесе сезгә андый акча туздырсын.

— Туздыра, ник туздырмасын! — Егет Гафурга табан башын чөйде. — Аның сөекле хәләл җефетенең көлтә-көлтә шигырьләре безнең журналда басылдымы? Басылды. Минем фермер иптәштән матди ярдәм таләп итәргә тулы хакым бар!

Боларның бәхәсенә кушылмыйча мыек астыннан гына көлеп торган ир:

— Маллата гына түләсәң, ярыймы? — диде. — Һәр шигырьгә бер тавык, бер сарык яки бер сыер, ә?

Ахырдан Гүзәлия бу сүзләре өчен аның җелеген суырыр. Син зыялы дусларымнан көлдең, син әдәпсез кара мужик, дияр.

Зәбир вәкарь белән генә өстәлнең түренә — Гүзәлия янәшәсенә утырмакчы иде, Сәлимә кырыс кына:

— Чү, җегетем, бу — хуҗа урындыгы! — диде.

Моның өчен дә хатыныннан эләгер. Ул тупас Сәлимәгез нишләп үз өендәге кебек кылана, нишләп Зәбиргә күрсәтмәләр бирә, дияр. Гүзәлиясенең күзенә әледән-әле кадалган «хата-ялгышлар чүбе» күп булыр ул кичтә.

Ашап-эчеп тукланган, кәефләнгән кунаклар чирәмгә тәгәрәште.

— Авыл һавасы сулаган өчен прайс-листта ничә тәңкә каралган, Вилория? — диде Рәсим.

— Сукыр бер тиен, әфәндем. Синең ише ныжы өчен кыйбаттыр бу?

— Ныжы нинди сүз ул, Вилория?

— Мишәрчә «саран», наданым!

Колга буй Зәбир житди иде, Галинурны битәрләп:

— Этләрмени, һау-һау өрәләр. Бу ыбыр-чыбырны ияртмик дидемме?— дидем, абзый. Ә син яшьләр дөнья буйласын, дидең. Бар, абзардагы берәр сыерның койрыгын күтәреп, менә сезгә киң вә широкий дөньягыз, диген, — диде.

Аның «тапкыр сүзе»ннән барысы да көлештеләр.

Коймага сөялгән Гафурның күзе Колга буйда иде. Гүзәлия аның кырыена чүгәләгән, ә тегесе озын үлән сабагы белән моның муенын кытыклагандай итә дә, хатын, чебен куган кебек, нәфис куллары белән уңлы-суллы селтәнә. Ә үзенең йөзе нур чәчә иде. Менә ир дә, ниһаять, аппагының бик-бик бәхетле чагын күрде. Әмма бу бәхет жебенең очы шушы Колга буй түгел микән? Көнләштерә шул, шайтан алгыры! Гүзәлия аның кемне «бораулап тишкәнен» сизде. Бакча аңа тарайды. Ул:

— Әйдәгез, Кинә тавы итәгендә учак тергезеп төн белән серләшәбез! — диде. — Сәлимә ханым, безнең сумкаларга су, җиләк-җимеш тутырыгыз! — Хатыны яны белән генә килеп, Гафурга пышылдады: — Без үзебез генә барабыз, синнән башка гына. Минем дусларым — минеке генә.

— Жылы киен, май төне салкын, — диде ир.

Кабыргаларны өтеп арка кыза иде. Ул кызар кызар да, коймага ут кабар төсле иде.

Казан кунакларын көйләп-чөйләп тауга озаткач, күршесе табынны жыештырды.

— Син дә ял ит, Гафур. Көнозын аяк өстендә бит син.

— Рәхмәт, Сәлимә апа. Сиңа да мәшәкать өсте мәшәкать.

— И-и, бу мәшәкатьмени! Ташкүмер чапмадым ла.

— Бәхетле халык!

— Болармы? Юу-ук, болар жир йөзендә иң бәхетсез кешеләр, Гафур. Ижат әһелләре арасында ике дистә елдан артык эшләдем, миңа мәгълүм. Боларның алдына тау-тау алтын өй, зиннәтле сарайлар төзе, затлы киемнәр киендер, көмеш табактан ашат, ә алар барыбер бәхетсез, чөнки жаннарына тынгы табалмыйлар! Жаннары дулкын төсле анда-монда чайкала бичаракайларның. Үзләре алар монын сәбәбен дә белми. Белергә дә теләми. Менә шулай.

— Син дә бәхетсезме, Сәлимә апа?

— Минме?! — Хатын бу сорауны көтмәгән иде. Ул каушады, алъяпкыч бавын чиште-бәйләде, чиште-бәйләде. — Шөкрана кылган саен күңел тынычлыгы артыр ди. Бүгенге көнем белән мин бик бәхетле, Гафур. Жанымның оясын таптым. Тыңлале, безнең бакчадагы төсле сандугачлар беркайда да сайрамый!

Гафур бу минутларда бары тик Гүзәлиясе турында гына уйлый иде. Дуслары — аныкы, ир бәхәсләшми. Ә хатын үзе кемнеке? Гафурныкы икән — ник ул аны читкә этәрә? Колга буй белән аулакта рәхәттер аңа... Жебегән! Ирме соң син?! Житте, дилбегәне кыскарт!

— Тыныч йокы, Сәлимә апа, — диде ул, әмма өч-дүрт адым атлагач та, күршесе йөгереп килеп аның беләгеннән тотты.

— Барма!

— Туктале, Сәлимә апа.

— Йөрәгеңне тый! Көнләшү яман нәрсә, Гафур.

— Син арыгансыңдыр, йокла, Сәлимә апа.

— Нинди ару?! Күчер дисәң — кибән күчерәм әле мин! Ә тауга жибәрмим, хәзер үземне энже муенса итеп — муенына тагам! Абау! Күлмәгең бигрәк юеш. Аркаң лычма су! Киптерик, Гафур...

## XIV

...Таң беленә иде. Ул бертуктаусыз мендәргә яшь койды да яшь койды

— Зинһар, кичер! Бу гөнаһым белән ничек яшәрмен инде хәзер?! Чатнатып яшен суксын, җир йотсын иде ичмасам! Нинди генә җәзага да риза! Мин генә гаепле, мин генә!

Гафур элгечтән күлмәген алып киде.

— Кипкән, — диде һәм үзалдына караган килеш: — Гөнаһ белән җәзаны икебезгә дә тигезләп бүлик, — диде. Аннары ир җилкәләрен калкытып, тирән итеп сулады да:

— Сәлимә, — диде.

Исеменә беренче тапкыр «апа» дигәнен өстәмәгәч, хатын тагын сытылып елады. Юрган ябынса да өшетә-калтырата иде. Әтәч кычкырды, сандугач сайрады, Казан кунаклары дөбердәп кайтып төште. Күрәсең, учак яга-яга ачыкканнар иде, шаулашып-гөрләшеп кичәге табынга өелештеләр. Сәлимә өстәлдәге ризыкларга тастымаллар гына каплаган иде, берсе:

— Фу, кырмыска бирәннәр! — дип кашык белән шак-шок өстәл кыйнады.

Ана да үз-үзен яңаклап-суккалап торгызырга кирәк. Биш кат юрган белән томаланса да, барыбер ул оят дигән заттан качалмый иде.

Мингайшә апа капкадан кергәндә хатын терлек өендә апара соса иде.

— Пәри туенда син кәләш идең мәллә, күке кызы? Күзләрең кызарган, — диде карчык. — Төн ката типтергәнсездер, кәмитчеләр!

Бакчадагылар табында «урды-жилгәрде» дә, һәрберсе печән кибәнен уеп, куыш әтмәлләп, йокларга ятты... Гүзәлия генә җил очырган яфрак төсле ары сугылды, бире сугылды һәм чиләкләр парлаган Сәлимәгә төртелде:

— Гафур заводка бик иртә китәмени?

«Мәнә сиңа мә! Өч ел бергә яшәп иреннең ничәдә киткәнен дә белмисеңмени?» — димәкче иде хатын, телен тешләде. Анамы соң кеше үртәү! Ул бу кызыйның күзенә дә карарга тиеш түгел! Сәлимә чиләккә чумар дәрәҗәдә җиргә тункайды.

— Сөт әчемәсен ди Гафур, шуна ашыга.

Гүзәлия аны биленнән сыпырды.

— Турай әле, Сәлимә. Минеке кичә ачуландымы?

Сәлимәнең кан тамырлары кайнарланып, йөрәге сикерде. «Минеке, минеке... Чү, кызкай, кичә ул синеке үк түгел иде шу-ул...»

— А-а, а-а! Чага, чага!

«Кибән-йорт»та тавыш кубып, халык «урам»га сибелде.

— Кем чага, Вилория?

— Кукшангы-ы! — дип чырылдады Вилория.

— Шул сүзне мишәрчәдән тәрҗемә итегез әле, җәмәгать! — Рәсим атлысы шаркылдап көлде.

— Шөпшә анын татарчасы, наданым, шөпшә!

Гүзәлия дусларына ярдәмгә чапты. Ходай шөпшәсе аша Сәлимәне авыр газаптан коткарды. Ул тиз-тиз генә чиләкләрне койма башына элеп, «Сыерчык оясы»на бикләнде. Тәрәзәләрне япты, пәрдәләрне корды. Әмма оят зур күзләре белән ярык-тишекләрдән күзәтә төсле иде... Йа Аллам, кешенең бакчасындагы чәчәгенә дә ымсынмаган хатын иде лә ул! Дөрес, Сәлимә уенчак һәм җиңел-җилпе иде. (Бу кимчелек микән?) Ә Җиде Чишмә аны уйчан итте. Баксаң, аңа күбрәк житдилек килешә икән. Аннан, язмыш тормышын кисәк үзгәртте: бүген ул «сәхнәдә» яңа партнерлары — Гафур, Гүзәлия, Мингайшә карчык, Туктар, Әнәс, Хөснулла анасы — Мөршидәттәйләр белән уйный. Массовкаларда Казан кунаклары да ялтырап ала.

Житди икән, хатын ялгышмаска тиеш иде. Бәлки, Гафур әлеге «ялгыш»

Сәлимә тарафыннан корылган мәхәббәт тозагы дип уйлыйдыр һәм бу төннән җирәнәдер?

...Кунакларга анысын-монысын пешерә-пешерә «Сыерчык оясы» эсселәнгән иде.

— Күлмәгенне аралыктагы бауга эләм, бир, — диде хатын. Ир, нигәдер аңа ияреп керде. Гүзәлиясе әшнәләре белән Кинә тавына киткәч, ул, көнләшепме, үртәлепме, кызарган иде.

— Муен тирәсенә бераз суккала әле, Сәлимә апа. Каешланды тәмам, — диде Гафур. Аларның берсе хатын-кыз, икенчесе ир-ат саналмый, алар кайчандыр ерак бабалары дошманлашкан нәсел кыйпылчыклары, бүген исә нибарысы күршеләр генә иде. Тәне шалкан кебек ак һәм тыгыз, җилкәләре киң иде Гафурның. Күптән, бик күптән ир назы күрмәгән Сәлимәнең анда да күнеленә әрсез-бозык уй килмәде ләса. Сөйләшүләре дә риясыз иде.

— Син басу-кырлар дип өтәләнгән идең, ә үзең быел чәчмисең дә, күрше.

— Киртәләр биек, Сәлимә апа.

— Нинди киртә?

— Җир бирмиләр. Көзгә сөрдерер дә идем.

— Ә син сорама, сөр дә чәч!

— Ул башбаштаклык дип атала, Сәлимә апа.

Бу төштә Сәлимә сүз купайтмады. Күршегә, мөгаен, аның карендәше Туктар гына аяк чала иде. Кабахәт малай! Сине, агач бүкәнен, хәйлә белән аударырга иде ул.

— Бел, Гафур, көзгә Җиде Чишмәнең барлык кырлары да синеке булачак!

— Амин, Сәлимә апа.

— Аркаңа нерв төеннәре укмашкан. Җирдән дә куәтлерәк кайгың бар кебек тоела, Гафур.

Ә менә бу төштә хатын чама хисен югалтып, тыелган чикне атлап үткән иде. Карурманнардан да куерак ир-ат күңеленнән сер капшарга ярыймени?! Кагылма инде син, кагылма!

— Гаҗәп, ни-нәрсә тоела икән?

— Син гаяр, батырып эшлисең, әмма батырып шатланмыйсың, Гафур. Нидер эчтән кимерә, нидер сызландыра сине. Мин бит инде артистлар дөньясында кайнадым, холык-фигыль дигәненә азрак чамалыйм.

— Моны кешегә әйтерлекмени, Сәлимә апа! Балам юк минем, балам, — диде Гафур. Гүя кинәт искән җилдән «карурман»дагы агач-куаклар шаулады, яфраклар лепелдәште. — Капканы ачасың — ишегалды буш. Өйгә керәсең — тагын бушлык. «Әти!» дип беркем дә кочагыңа атылмый. Мин бер бәхетсез, ә Гүзәлия өч бәхетсез. Аның бишек тирбәтәсе килмимени? Менә син, Сәлимә апа, улыңны үстергәнсең, оныкларым дип куанасың. Аларның балалары туар, ә Сөләйман малаеның нәсел чылбыры өзек.

— Синең балаң юк... — Сәлимә бу сүзләрне кат-кат кабатлады. — Балаң юк... Ә мин җүләр, кара, болар үз рәхәте өчен яшиләр дип тиргим! Юкәдә икән чикләвек. Кайсыгызда соң кимчелек дигәндәй. Турыдан соравым өчен ачуланма инде, Гафур!

— Кайсыбызда... Миндә, Сәлимә апа.

— Синдә?! — Хатын кисәк кенә ирнең йөзен үзенә таба борды. — Синдә?! Ир, шапылдап караватка ауды.

— Миндә шул, Сәлимә апа!

«Чү, Гафур, нәселе киселгән ир-атның күз карашы тоныклана, ә синең күзеңдә көзгедәге сыман, барсы да чагыла. Кырлар-урманнар, күлләр-чишмәләр, алан-болыннардан тыш анда нәни генә малай да шәйләнә түгелме соң?» — дип, эченнән генә бәхетсез ирне юатты хатын, анын

куллары да «юатты»: керпе энәләре кебек тырпайган чәчләрне сыйпады, кытыршы янакларны сыйпады, күкрәкләрне сыйпады... Якында гына гөнаһ көймәсе чайкалганын икесе дә сизмәде...

...Шөпшә кунакларны пәрмә-пәр талаштырган иде. Мингайшә карчык бикле ишекләрне ачтырып, Сәлимәне бакчага әйдәкләде:

— Күке кызы, тегеләр дөмбәсләшә, адәм ыстырамы?!

— Гүзәлия кайда?

— Бүлмәсендә шигырь яза. Мишәйт итмә, ди. Син аер тегеләрне!

— Дөмбәсләшмиләр ич, Мингайшә апа. Бер-берсе белән бәхәсләшәләр генә, — диде хатын, ләкин алай да төркем янына барып басты. Вилория белән Рәсим тел сугышы оештырганнармени, авызларыннан пулемет аттыралар иде.

— Чәнечмә мина, Вилка!

— Мин — Вилка, ә син — кашык!

— Синең кушаматың ул — Вилка! Укыганда сина исемең белән дәшми идек без!

— Ә синеке йолкыш чыпчык иде!

«Остазлар» кесә телефонында «СМС» язышa иде, менә Зәбир яшьләргә кисәтү ясады:

— Әтәчләнмәгез, туктагыз! Бүтән сезнең белән йөрүләр бетте, тузан бөртекләре!

— Ба-а, Рәсим, без синең белән тузан бөртекләре икән! Ә сез — ком тавы. — Кыз Зәбиргә ук очырды. — Яңгыр яуса — җебеп, җиргә сеңәсез!

— Сеңел, чәпчемә, диләр. Сиңа бу сыйракларың белән безнең биеклеккә җитәргә, ай-һай ерак!

— Фи-фи, синең биеклегең чыпчык тезеннән генә, абзыкаем Зәбир. Ник сез «без-без» дип шылдырыйсыз икән, кипшенгән зәңгәр кыңгыраулар! Сезнең белән сәяхәткә бик ашкындым мәллә? Үзегез кыстадыгыз.

— ОКАшкаң кирәк иде, сеңел.

— Фи, минем арбамдамени сәбәп! Чын дөресе шул, абзыкаем Зәбир: син Гүзәлия апаны күрергә тилмерәсең. Син аның өчен саргаясың. Вәт күрдең инде. Фи-фи, ә син ана нуль!

— Бу мизгелләрдә Гүзәлия ханым миңа багышлаган шигырен күнеленнән кәгазьгә күчерә, — диде Зәбир, масаеп. Әй, көчкә генә түзде Сәлимә, югыйсә ата мәченең мыегын йолкырга әзер иде. Берүк Гафур ишетмәсен, берүк! Әмма Вилория дә усал иде.

— Фи-фи, исемсез шигырьләр языла ул, аны бүген сиңа дисең, иртәгә миңа дисең. Гафур әфәнде дөнья бәһасенә торырлык асыл ир, аны синең елак гитараң белән тулай торактагы бүлмәгә алыштырамени Гүзәлия ханымыз! Өметләнмә, ком тавы!

Хәер, төркем умарта кортлары кебек гөжләде дә, тынды. Кунаклар мәш килеп учак күмерендә шашлык кыздырды, туфракта нинди үлән калыккан — шуларны өзеп, чәйнеккә тутырды. Остаз белән шәкерт әрләшмәгән дә төсле иде. Вилория «Зәбир абый» дип, тегесе «сеңел» дип аһ итеште. Әмма дингезнең өсте генә тыныч, төптә — су гөбер-гөбер кайный иде. Кулындагы кәгазен селки-селки Гүзәлия чыкты.

— Халык, бер минутлык тынлык! — диде ул. Бакчадагылар аңа текәлде. — Әле генә шедевр туды, халык!

Бу очрашудан мин генәме —
Син үзең дә качмадың.
Мине күреп бу дөньяда
Бер яңалык ачмадың.

Барсы иске, мәхәббәт тә —
Узган бездән чир булып.
Һәм калганбыз мин хатын-кыз,
Ә син гади ир булып.

Шунда аягына сиртмәләр кигәнмени, Вилория сикерергә тотынды.

— Шәп, шәп! Абзыкаем Зәбир, мин бая гына ни дип фаразладым, ә? Кем алтынны бакырга алыштыра, ә?

Остаз шәкертен күзе белән бораулап:

— Шым бул! — диде. — Йә, Гүзәлия, ахырын укы!

Тик нигә соң күрешкәндә
Йөрәкләр болай яна?
Әйтерсең лә мәхәббәт тә,
Үзебез дә өр-яңа!

Зәбир шап-шоп кул чапты:

— Браво, браво!

Вилория җинелергә теләмәде:

— Пүчтәк шигырь, — диде һәм сумкасындагы ачкычларын шалтыратып. — Мин Казанга үтүт, мәхәббәт уеныгыздан косам, тәпи-тәпи кайтмыйм дисәгез, — әйдәгез! — диде.

— Аһ бу дуамал яшьләр, — дип мыгырданды Зәбир, — Тырт та пырт! Юлыңа ак җәймә, сеңел. Шырпы кабын җил очырмасын, бездән башка җиңеләя бит ул.

Кызның тәненә шайтан төкергән иде:

— Хатын-кыз башым белән мин ОКАшкамда җилдерәм, ә синең — чалбарлы колганың тәгәрмәче дә юк, абзыкаем Зәбир!

Гүзәлия кәгазен кулында бөтәрли-бөтәрли ыңгырашты:

— Нишлисез сез, халык?! Шигыремне беркемгә дә атап язмадым мин! Туктагыз, әрләшмәгез!

Әмма төркем, пыяла сыман, чатнаган иде инде. Вилория белән Рәсим китте. Ике остаз йөгәнсез яшьләрне каһәрләп бакча чирәме таптады. Ахырдан хуҗалар «калдык-постык» кунакларны Казанга ук илтергә булды. Мөгаен, Гүзәлия ирен күндергәндер, берочтан әниләрне дә күрербез, дигәндер. Иртән: «Минеке ачуланмадымы?» дип пошынган хатын Гафурны чыбык итеп бөгә иде. Мингайшә карчык: «Ай-яй, киленнең әшнәләре чакматаш икән, гөлт-гөлт кабыналар», — дисә, Сәлимә бернәрсәгә дә шаккатмады. Икәү очрашса — гайбәт, өчәү җыелса — базар, ди. Болар исә бишәү! Биш сүз, биш фикер, биш каләм. Һәркайсы үзенчә мәңге табалмаслык бәхет сукмагын эзли. Кичкә үк дуслаша алар. Чөнки иҗатлары уртак Казанда «кайный».

Йорт ыгы-зыгыдан тынды. Кунаклар белән генә күмелгән икән, хатынның күз алдыннан әкрен генә төн шәүләсе узды. Гөнаһысы өчен яшен суксын диде — сукмады. Җир йотсын диде — йотмады. Ни хәл итәргә, йа? Аңа бит театрда да сүз каталар, ләкин ул тиз генә йөрәк капкаларын бикләп куя иде. Бу юлысы Сәлимә кулындагы ачкычы белән бергә башын да югалтты!

— Нәрсә уфырасың-пуфырасың, күке кызы? Явызлык исәплисеңме?

Хәзер карчык сирәк кенә бәйләнә, Сәлимәне яратмаса да, эшен ярата иде ул.

— Мингайшә апа, — хатын аңа кесә телефонын күрсәтте, — син бу тартмачыктан сөйләшә беләсеңме?

Хатын халат кесәсеннән Сәлимәнекеннән дә кәттәрәк телефон алды:

— Надан шту-ли әбиегез! Гафур бәбкәчем бүләге миндә!

— Мингайшә апа, без синең белән хәзер спектакль уйныйбыз. Мин —

Татарстандагы олы абзыйның хәләл җефете, ә син минем ярдәмчем ди.

— Кит булмаганны! Гумеремдә дә сиңа ялланмыйм, күке кызы!

— Апакаем Мингайшә, син ялангач җирләр өчен көенәсенме? Ә Гафур көенә. Аның бүген йокысы йокы, ашы аш түгел. Ул басу-кырларга бодай чәчәргә тиеш иде. Ә без, бөртекне тарттыргач, синең белән ипи пешерергә тиеш идек. Тегермән бодай көтә ич әнә!

— Чәчмәсә, он тарттырмаса, сиңа ни хәсрәт, күке кызы? Шәт, йомран сымак Гафурга астан гына чокыр казыйсыңдыр әле! Атаң Хәмит тә явыз бүре иде.

— Казымыйм, Мингайшә апа!

Карчык аңа сынап карады:

— Алайса?

— Гафурга ярдәм кирәк, Мингайшә апа!

— Җә, мин ялчың ди, күке кызы.

— Әүвәле игътибар белән тыңла, Мингайшә апа. Әйтик, мин фәлән номерны җыям да син: «Алло, Җиде Чишмә авылы җирлеге башлыгы Туктар Ильясовны бирегез», — дисен. Туктар «Әйе, бу мин» дигәч, син: «Мин Фәлән Фәләновнаның ярдәмчесе, хәзер сезне аның белән тоташтырам», — дисең һәм телефонны миңа бирәсең!

Кортка сыртын кабартты:

— Сез — күкеләр, сез — карендәшләр, минсез генә чүкердәшегез!

— Мингайшә апа, бүген миңа Гафур туганымнан да артык! Безгә Туктарны хәйлә белән алдырырга кирәк, — дигәч кенә карчык ипләнде.

— Тиатрене яңабаштан өйрәник, — диде.

— Әйдә, башла, Мингайшә апа.

— Әлү, әлү...

— Алло, алло, диген! О дигәндә ирененне түгәрәклә, Мингайшә апа!

— Алло, алло! Карале, кем Туктар — күке малае, мин прзидин хатыны Фәлән Фәләновнаның ярдәмчесе Мингайшә апагыз идем әле. Хәзер аның белән сөйләштерәм үзегезне, Алла каргаган нәстә...

— Валлаһи, режиссер сине сәхнәдә үк тукмак белән тукмый, Мингайшә апа! Ник син исеменне өстисең, ә?!

— Вай-вай, безнең прзидин катыннары ярдәмчесе булырлыгыбыз юкмени!

— Бар, әлбәттә, бар! Әйдә, минем сүзләрне кабатла! Туктарны ышандырырлык итеп чатнатып әйт.

Аюны да биергә өйрәтәләр, ә кортка адәм баласы иде. Ул тәмам азартка кереп, тамагын карлыктырып телефоннан «тоташтырды». Театрда Сәлимә Сәрбиназ Сираеваның тавышына гашыйк иде. Артистка ханымның сөйләме буйсындыру көченә ия иде. Ул да Сәрбиназ шикелле тыныч кына сүз башлады. Мәскәүдә «дәваланган» Туктар карындәш өендә иде. Кодрәтле исемнән аны очкылык тотты хәтта.

— Ык-ык...

— Сез кайчан фермер Гафур Айсинның җир проблемасын хәл итәсез? Бу нинди башбаштаклык?

— Ык-ык... Без, без... Ык-ык...

— Кемнәр ул «без»? Хакимият башлыгы каршы мәллә?

— Ык-ык... Халыкның фикере таркаурак иде.

— Әгәр сезнең ул фикерләрне берләштерерлек тә көчегез юк икән, ни өчен сезне авыл хуҗасы итеп сайладылар, Туктар Ильясов? Кыскасы, сентябрьдә Гафур Айсинның кулында җир документлары булмаса, үзегезгә үпкәләгез!

Мингайшә карчык кетер-кетер көлде.

— Ай-яй, килештерден дә күке кызы! Чып-чын әртис икән син! — диде.

— Берүк Гафурга белгертмә, яме?

— Белгерткән ди! Азагы гына хәерле тәмамлансын, йа Аллам! Тизрәк бөтен теләкләренә ирешсен, бәбкәчем.

Хуҗалар Казаннан тиз әйләнде. Гүзәлия кәефсез иде, итәкләрен фырфыр җилләтеп, өйгә кереп китте, ә Гафур ишегалдында калды. Аның күзенә чалынмавың хәерлерәк иде. Хатын алмагач куакларына ышыкланып кына Ак өйгә таймакчы иде, ир:

— Күрше! — диде. — Син хәзер гел шулай качып йөрерсең микән? Сусадым, бакчадагы өстәлгә чәй чыгармасаң — янам, — диде.

Оятыннан үзе дә ялкынга чолганган Сәлимәнең аяк табаннары кызышты. Ул җиргә баскан саен үлән көя сыман иде.

— Сыеграк эчәсеңме, Гафур?

— Ничек тә ярый. Син дә утыр, күрше. Безнең күке нишләптер моңланмый?

— Басылды ул, Гафур.

— Минем өчен генә кычкыр әле, Сәлимә.

— Кәк-күк, кәк-күк...

— Ник ике генә тапкыр? — диде ир. — Мин әллә ике генә көн яшимме?

Күз яшьләре белән таң аттырган хатын, күрәсең, күз яшьләре белән кичкә дә керә иде. Әлбәттә, Сөләйман малае шаярта иде, ләкин бу шаярту бәгырьне телем-телем кисә иде.

— Әгәр син дә апаң шикелле безнең нәсел каргышына ышанасың икән, мин ерак бабагыз өчен кичерәм сине! Кичерәм! Син яшә, Гафур, озак яшә!

## XV

...Ат арбасының тәгәрмәчләре шыгыр-шыгыр итә. Алар, аталы-уллы, басу чигеннән баралар. Офык читләре буй-буй алсу бизәкләр белән бизәлгән...

— Синең өчен шатландым әле, улым. Атаң Сөләйман иңләгән чакрым-чакрым басуларны син чәчәсең, боерса, син, улым. Икмәкле авылның гомере озын аның, улым.

— Ә миңа шатланырга ярамый. Шатлык арты хәсрәт килә, әти.

— Без, ирләр, хәсрәтләргә бирешмик, улым. Ник соң әле син боек, улым. Хәзер мин атны туктатам, син төш, бөркет кебек кулларыңны як-якка җәй һәм бөтен көченә кычкыр, улым. Кычкыр! Күкләр ярылсын, җир тетрәсен, улым!

— Нәрсә дип кычкырыйм соң, әти?

— Күкрәгеңне ни яндырса — шуның исемен әйтеп кычкыр, улым. Җиңеләйтер, бәлкем.

— Б-а-л-а-а-а-м!

Чираттагы төшләрнең берсе иде бу. Әтисе тагын аның белән «очрашты». Күкрәгеңне ни яндырса шуның исемен әйтеп кычкыр!» — ди мәрхүм. Тик җиңеләйтмәде. Нәсел җебе киселгән иде шул..

Атна ахырында авыл җирлеге башлыгы җыелыш турында белдерү язды. Көн тәртибендә — җир мәсьәләсе иде. Моңарчы басу-кырларны бирдермәс өчен аяк терәп карышкан Туктар Ильясов хәзер, киресенчә, көн саен Гафурны тинтерәтте: «Гафур Сөләйманович, пыжымламагыз гына, яме? Гафур Сөләйманович, үтенәм, җыелышка соңармагыз. Әби-чәбиләрне, абый-бабайларны нык кына игәүләдем, кишәрлекләрегездә үзебезнең егет чәчсен, урсын, дидем».

Туктарның кинәт кенә Гафур ягына авышуы акылга сыймый иде. Август башында һич көтмәгәндә район хакимият башлыгын алыштырдылар.

— Ну кандаладан котылдың, туган, — диде Әнәс. — Каныңны эчте абзый!

Монысы киңәшмәләрдә районнагы фермер хуҗалыкларының исемлеген төзегез, мин шәхсән, һәрберсе белән танышам, без аларның моң-зарларын тыңлап, ярдәм итәргә тиеш, ди. Янасы белән точно дуслашып, бер кашыктан ашыйсыз икән, туган.

Кәнәфи хуҗаларына табынмаган Гафур андый «кашыклар»га кызыкмый иде. Гаяз Идрисович кына бик сызланды.

— Да-а, әшнәләрне чүплиләр, — диде. — Фирдус Мотыйгович быел безнең округтан депутатлыкка кандидатуранны күрсәтәбез дигән иде. Ох-ох! Иван Ивановичны да прокуратура тикшерә хәзер. Ох-ох! Аңа таянырга юк та юк инде!

Сәлимәләрнең йортын төзекләндергәч, хатын үзенә күчкән, Ак өй бушаган иде. Зур кунак, хәтта ки, аның ишеген дә ачмады.

— Кунмыйм, кыстамагыз, — диде.

Соңгы көннәрдә апасы:

— Энем, күке кызы әллә нишләде, — дип хафаланды. — Ашый да коса. Чире бавырында аның. Йөзе сарысу. Кеше баласы бит, брачларда дәвалансын иде.

— Ул сау-сәламәт, апа.

— Сәламәт икән, алайса, нигә ябыга? Әллә мәйтәм, Шәрбәнбанудагы нәмәстәсенең катыны көнләшеп агулаган микән?

— Нинди «нәмәстәсенең катыны», апа?

— Әй, бигрәк беркатлы син, энем. Атна саен шул авылга теркелдәтә. Знамы, сөяркәсе янына!

Гафур күршесенең «чире» кайчан башланганын белә иде. Сандугачлы май төненнән соң «сырхаулады» Сәлимә. Шуннан бирле ул үзен гаепле санап эчтән генә сызадыр, мөгаен. Шуңа нервылары какшагандыр. Ир-ат, күрәсең, мондый «хаталар»ны җиңелрәк кичерәдер. Ял кирәк күршесенә, ял!

— Сәлимә, без сине башкалага җибәрмәкче идек. Ике-өч атнага, теләсәң — берәр айга.

— Абау, Казангамы? Нинди йомыш белән, Гафур?

— Балаларыңны юксынгансыңдыр.

— Мин юксынган белән ни. — Хатын шомырт ашаган, аның кабарынкы уймак иреннәре дә, бармаклары да шәмәхә төскә буялган иде.

Ирексездән май төне ирнең йөрәген чемердәтте. Шуннан бирле Сәлимә апа түгел инде, апа түгел...

— Мин бит сезне алдадым, Гафур. Авызым тулы кара кан булса да, төкермим дидем. Улым белән киленем фатирымнан куды бит мине. Нишлим, авылга кайттым. Тик үкенмим, Җиде Чишмәне яратам мин. Сиңа рәхмәт, туганым да синең шикелле кайгыртмас иде.

— Үзеңә рәхмәт, Сәлимә. Апа сул кулым, ә син — уң кулым. Бәлки, ял йортына барырсың, ә?

— И Алла, эшсез үләм ич анда!

— Дәваланырсың, Сәлимә.

— Мин авырмыйм ла, Гафур!

Апасы, билгеле, һаман үзенекен тукыды. Аның диагнозы «төп-төгәл» иде:

— Күке кызының бавыры шешкән, энем!

Карчык кырмавык белән бер тамырдан иде, Сәлимә сау-сәламәт дип ышандыргач та, ызәрлекләвеннән туктамады. Ул:

— Шәрбәнбануда кайсы ир бәндәсен аздыра икән, шпиун кебек эзенә төшәм, валлаһи, — дигәч, Гафур ачуланып аяк типте:

— Кеше тормышына тыкшынмыйк, апа!

Аның үз йортында да «эзләр» чуарланган иде. Кечә Гүзәлия аңа куен дәфтәрен сузды.

— Мә, бу шигырьләрдә мин чагылам. Укы да, сиңа кайсы ошый, тамгала, — диде. Ир укыды. Ә берсен хәтта үзеннән-үзе ятлады!

Исемнәрең кычкырып әйталмадым,
Гайбәт телләреннән яшердем.
Сине очраткач та үзгәрдем мин,
Мең картайдым, мең кат яшәрдем.

Өметләрем минем таңнар төсле.
Атмас кебек беркөн офыкта.
Син булганга гына яшимдер мин,
Җансыздыр мин, җансыз син юкта.

Төннәр житсә, күк йөзенә карап,
Сине уйлыйм, минме бәхетең?
Тып-тын күңелемне давыллатып -
Яратам дип әүвәл син әйттең.

Рәхмәт димме, каһәр яудырыйммы,
Без адашып кергән дөньяга.
Таңнар көтәм. Яшьле күзләремнән
Йолдызларын коеп төн ага.

Гафур һәр җөмләдән, һәр сүздән мәгънә эзләде. Гүзәлия кемнең исемнәрен кычкырып әйтә алмый? Кемне гайбәт телләреннән яшерә? Хатыны аны тагын көнләштермәкче буламы? Гафур: «Әй, ни язсаң да яз!» — дип кул селтәргә җыенмый, әмма шунысы кызганыч, аппагы белән икесе арасындагы упкын зурайган саен зурая иде.

Гүзәлия «Скайп»тан сөйләшә иде. Экранда «дус»ның чалшайган битен күреп, ир тамак кырды. Хатыны ризасыз гына:

— Нишләп шакымыйсың? — диде. — Әдәпсез дә инде син, Гафур! Без, Зәбир белән, бер шигырьне көйгә салабыз. Комачаулама!

Аңа борылып чыгып кына китәргә иде, ә ул, тотты да, компьютерны сүндерде.

— Маймылың сакал-мыегын кырсын!

— Зәбир минем иҗатташ дустым!

— Мин түзәм-түзәм дә, бер шартлыйм, Гүзәлия!

— Шартла! Син — эгоист, син бары тик үзенне генә кайгыртасың!

— Ялгышасың, сине бәхетле итәр өчен мин барысын да эшләргә әзер, Гүзәлия!

— Әзер? Ничек? Терлекләрнең санын арттырыпмы? Чиләк-чиләк сөт саудырыпмы? Җир даулапмы? Миңа алар ниемә хаҗәт?!

Ир дорфалыгы өчен үкенә иде инде. Ут нәни генә шырпыдан дөрли шул. Их, алтыннардан да кыйммәтрәк ул, сабырлык!

— Минем дөньям сиңа бик тармени, Гүзәлия?

— Ә минеке сиңа киңме соң, Гафур?

— Ник мондый сагышлы шигырьләр язасың, Гүзәлия?

— Читлектә сайраган кошның тавышы моңлы, чөнки ул тоткын, Гафур!

— Ирегеннне кысмыйм бит мин, Гүзәлия.

— Ә кем хәзер генә компьютерны сүндерде? Гафу үтенмә! Синең ише тәкәбберләр тезләнсә дә башын имәс.

— Безнең җаннар бүген аеры-чайры яши. Сизәсеңме, без бер-беребездән ерагаябыз, Гүзәлия, — диде ир, көрсенеп.

— Ә без берләшик, әйдә! — хатыны ирония белән елмайды. — Хәзер мин пычрак халат киям, яулык бөркәнәм һәм абзар себерәм, тизәк түгәм. Бәрәнге белән бүрттергән бодайны болгатып, тавыкларга сибәм. Кич белән икебезнен дә сөйләшер уртак сүзләребез була. Икебездән дә тирес исе пырный. Шәп!

Гафур да көлде:

— Юк, без иҗат аша берләшик! Икебез дә шигырь сырлыйк. Өстәлнең бер очында — син, икенче очында мин. Көн язьйк, төн язьйк! Мәхәббәт чишмәсе саекса — хисләр тутыга. Хисләр тутыкса — Җир шары түңкәя дип лаф орыйк! Шәп!

Һәрчак сыйпап-иркәләп, җаена гына төшеп торган иреннән мондый ук каһкаһә көтмәгән Гүзәлиясе күзендәге нәфрәтен ана бөркеде:

— Мин сине күралмыйм! Күралмыйм!

## XVI

...Түренә утыртып кадер-хөрмәт күрсәтергә өлгермәде. Өлгермәде. Тәкъдир Хөснулла анасын улы артыннан ук «мәңгелек йорт» ка ашыктырган иде.

Шәрбәнбану зиратында ике туфрак өеме әле суынмаган да иде. Зөбәйдә, аклангандай:

— Кичтән Казанда Хөснулла үлгән, иртән таң алды — Мөршидәттәй... Әртистнең катыны белән балалары акурат унда кайттылар да, эсседә бозыла дип, юып-кәфенләп ике мәетне дә җирләделәр. Сиңа хәбәр итәрлек идеме соң, апаем! Аннан, син аларга беркем дә түгел идең лә.

— Беркем идем, Зөбәйдә, беркем идем! Мин әбинең беренче килене идем.

— Әстәгъфирулла! Хөснулның синдәй катыннары бар идемени?! Ә без, киленем үзенә апкитә дигәч, Мәршидәттәй акылдан язган дия идек.

— Әйе, авылдагы өемне рәтләткәч, әнкәйне үземә алдырмакчы идем.

— И рәхмәт яугыры! Изге күңелле катын икән син, апаем. Ирең риза идеме?

— Ирсез мин.

Зөбәйдә күзе белән анын буй-сынын үлчәде дә:

— Үзең түгәрәкләнәсең, үзең ирсез дисең. Сез әртистләр сәер халык икән, — диде.

— Тазардым әле, Зөбәйдә. Билләрем юанайды.

— Алай да брачта тикшерел. Бүсер-фәлән түгелме, апаем.

— Түгел. Йә, хуш, Зөбәйдә!

— Чирләмә, апаем!

Сәлимә калкулыкларга соңгы тапкыр караш ташлады: «Аллаһ урыныгызны җәннәттән әйләсен».

Бу анын теләге, ә разыйлык Кодрәт иясеннән иде. Гәрчә, җилбәзәк Хөснулла бәхетен җимерсә дә, хатын ана үпкә сакламый иде инде. Кайчандыр канап интектергән иң тирән ярасының җөен вакыт ямаган иде. Беренче иренең шуклыклары Хөкемдар тарафыннан кичерелер, бәлки, ә менә ояттан бөтен әгъзалары тартышканда Сәлимә ниләр дияр? Ахырзаманга кадәр яшисе дә бар әле, һәм җавапны да шушы фани дөньяда тотасы...

.... Май төне ана «бүләк» калдырды. Анардан котылырга уйламады да хатын. Ул болай да муеннан гөнаһка баткан, тагын шуңа икенчесен дә китереп өстәргә теләмәде. Аннан битәр, үзе ялварып сорамаган, үзе көтмәгән «бүләк» Сәлимәгә генә аталмаган иде. Әмма хатын кеше тормышын ватарга җыенмый, димәк, «бүләк» мәңгелек сер булып, күңел төпкелендә ятачак иде.

Урман авызыннан таягына атланган убыр кебек җилләнеп Мингайшә карчык килә иде, уйларына күмелгән Сәлимәгә качарга соң иде инде. Бу айларда йортта киң халаттан йөргән хатынның күлмәге тар иде, гәүдәсенә сыланган иде, ул, кызарып, муенындагы яулыгын аскарак тартты, ләкин корсак өлеше капланмады.

— Әтәчем! — Энәгә җеп саплаган кортканың үткен күзеннән яшерәм димә икән! — Син, күке кызы, көмәнле ләса! Ә мин чирле дип Гафурның башын катырам тагы. Менәтерәк әкиятнең азагы! Атасы кем?

— Син аны белмисен, Мингайшә апа.

— Шәрбәнбану җегетләре электән үк мут иде. Без, Җиде Чишмә кызлары, аларның сыртына талчыбык белән сыдыра идек. Әй, күке кызы, күке кызы! Хурланмыйча ирләр артыннан сөйрәләләрмени! Адәм ыстырамы бит! Корсагың белән аламы соң?

— Алмый, Мингайшә апа.

— Өйләнгәнмени мыекбай?

— Өйләнгән. Ә син урманда нишлисең, Мингайшә апа?

— Мин дә үземә бабай караштырам, хи-хи! Оятың ояда икән, күке кызы. Без шул ирләр белән чуалмадык, ялгыз картайдык. Танышым Дир-дир апа ни хәлләрдә икән дип Шәрбәнбануга барышым, чын дөресе.

Карчык, чынлап та, таягына атланган убыр иде. Сәлимә кичке савымга чиләкләрне парлаганда ул кайтып та житте. Бал корты чагып шешкән төсле иреннәрен бүлтәйтеп, ары-бире йөренде, нидер әйтергә җыенгандай бер хатынга табан талпынды, бер кире китеп, абзар тирәләрен әйләнде. Бакчада салам өемен сәнәк белән яшь бозаулар аранына ташыды һәм, хәле бетеп, сарай бусагасына ишелде.

— Каяле, кил... — Карчык Сәлимәгә кул изәде. — Дир-дир апа үлгән икән бит, и Аллам. Элгәре безнең калхузлар бер иде. Без яшь чакта Дир-дир бригадир иде. Буа катыны иде ул, шуңа аның «диде» се, «дир» иде. Без аңа кушаматы белән генә эндәшә идек, ачуланмый иде, бахырым.

— Урыны җәннәттә...

— ... булыр, булыр, иншаллаһ. Мәрхәмәтле апай иде. Син аның шулай икәнен үзең дә чамалагансыңдыр, күке кызы! Син Дир-дир Мөршидә килене икән. Күршесе, рәхмәт яугыры, Зөбәйдә, серләрегезне тиште. Син ул авылда ирләр белән эшерелмәгәнсең. Ә көмәнең кайдан? Җилдәнме, әстәгъфирулла!

— Зинһар, төпченмә, Мингайшә апа,

— Син дә йөрәгемә кан саудырма, күке кызы!

Карчык сугарга җыенгандай бармакларын йодрыкка төйнәде. Чирләшкә кортка кинәт кенә терелде.

— Корсагың очлы, ир бала табасың син. Жә, Алла хакы өчен дим, әйт, атасы кем? Карт төлке сизми дисеңме? Чирлегә сабыштым да, моны алдадым дисеңме? Алдарсың, мә! Үлән борынлаганнан бирле синең бит-йөз комачтай кызыл, баш түбән. Хәтәр инде, жегетеннән оялган яшь кызлар күк кыланмышларың, күке кызы.

Сәлимә каушавыннан карчыкның берәм-берәм бармакларын куптарды. Һай, әбиеннең куллары тимер иде! «Нишләдең син, күке кызы?!» — дип, колагына тондырса, тәгәрәп үләчәк иде хатын.

— Баланың әтисе... әтисе гаиләле ир, Мингайшә апа. Без ялгыштык. Минем аңа бернинди дәгъвам да юк. Ышан, яме?

Әй, шунда Казан кунакларының берәрсен әйтеп котыл инде! Нәкъ май үләннәре калыккан вакытта алар Гафурларда иде бит. Ә ул ялганнардан арыган иде. Әйдә, сукса — суксын кортка! Әйдә, Сәлимә туп кебек тәгәрәсен!

— Әтисе — Гафур, — диде хатын һәм берникадәр җиңеләеп, тактадагы бидоннарны төшерергә тотынды.

Карчык калтыраган йомшак тавыш белән:

— Чү, чү, авыр күтәрмә, кызым, — диде.

## XVII

Иртәгә ни була? Иртәгә? Гафур: «Кем ул, Сөләйман малае! Бөтен уе — баеп, акча күрәү», — дип чәпчегән авылдашлары каршында нотык сөйләп, имтихан бирә. Мескенләнеп, шыншып, кулын сузса — аны кызганырлар иде. Хәтта кишәрлекләрен бушлай тапшырырлар иде. «Пай җирләре өчен ай саен менәр тәңкә түләсен»,— дигән таләпләрне аңа җиткерделәр инде. Андый комсызларга: «Җәмәгать, әлегә мин кредитлар белән хуҗалыгымны торгызам», — дисәң, торгыз, энем, үз кесәңне калынайтасың бит, диячәкләр. «Җиде Чишмәгә җан

өрәм»,— дисәң, «тапкыр» агайлар тагын бот чабар. «Этләр көн-төн өрә дә, вәләкин авыл үлә», — диярләр. Кызма, Гафур, кызма! Һаман кара исәп белән булашма. Син атаң чәчкән-урган кыр-басуларны, урман-әрәмәлекләрне, киек кошларны, җанварларны, Кинә тауларын, болыннарны йөрәгеңә якын иттең. Гүя авыл табигатьтән генә гыйбарәт иде. Ә авылдашларыңны — кәкресен-бөкресен, турысын-чалышын, айныгын-сәрхушен, мыштымын-шар-шарын, хәтта ки әләкчесен яраттыңмы? Гайбәтеңне сатсалар да ярат! Көнләшсәләр дә ярат! Тиргәсәләр дә барыбер ярат! Ятимнәргә, ярлы-ябагайларга дәүләтеңнән өлеш чыгарып кына мөнәсәбәтләр җайланмый, Гафур! Кешеләрне ризыктан битәр җан берләштерә, Гафур! Җыенда, мөгаен, халыкның үзе кебек үк гади генә сүзләр кирәктер. Ә бәлки сәхнәгә баян белән менәргәдер? Бармаклар калынаеп, тупасланды, билгеле. Кул һөнәренә карап үзгәрә ахрысы.

Ир чәчелгән-сибелгән уйларын һич кенә дә бер төенгә төйни алмады. Төйним дигәндә генә Гүзәлия чишеп ыргыта иде.

Хатыны иртән үк уянып, бүлмәсендә кыштырдый. Кәгазь ерта да кәгазь ерта.

— Нишлисең? — дигәч, ул:

— Дөньямда тәртипсезлек, җыештырам, — диде.

Җыелышка әзерләнеп Гафур бүләк турында бөтенләй оныткан иде. Иртәгә Гүзәлиясенең туган көне дә бит әле! Һәр ел шушы көндә ир белән хатын Кинә тавына йөгерер, Гафур, яшь чактагы кебек исәрләнеп:

— Гүзә-ә-ә-ли-ә-ә! — дип җиһанны дер селкетер иде. «Баш очындагы болытлар исемемне сеңдерә дә, ләйсән яңгыр иттереп җиргә яудыра. Тамчы саен мин, тамчы саен мин!» — дип сөенер иде хатын.

Бу мизгелләрне иртәгә дә кабатларга иде. Кайвакытта, җитдилектән качып, иләс-миләсләрнең кушкаен гына үскән урманында адашырга кирәк иде. Тик май төнендәге кебек башны гына җуймаска иде...

Апасы белән күршесе бакчада алма җыя иде. Сәлимәнең хәрәкәтләре ипле-җайлы, әйтерсең, куактагы энҗеләрне сак кына учына салып, кәрзингә тезә иде. Болар капыл гына ничек дуслашты икән? «Күке» дип нәсел дошманының күзен ачтырмаган карчык, теленнән баллар тамызып, «кызым», ди. Әгәр язмыш Гафурга шушы хатынны насыйп иткән булса? Әгәр Гүзәлия урынын Сәлимә биләсә? Йа, чын мәгәр, ул хәзер үк иләс-миләсләр урманында адашты!

Ишек тупсасына кадәр каерылды. Ике зур сумкасын өстерәп өйдән хатыны чыга иде. Өстендә юл киемнәре. Ир аптырады. Болай төянеп кая бара?!

— Ераккамы, Гүзәлия?

— Казанга!

— Озаккамы?

— Бөтенләйгә. Үтенмә, үгетләмә, каһәрләмә, Гафур! Минем дә синең шикелле үземчә яшисем килә. Минем дә аранңары сүздән корылган шигърият дигән хуҗалыгым бар, — дип, Гүзәлия ишегалдындагы машинасының багажнигына сумкаларын томырды. — Капкаңны ач!

Утлы шар Гафурның күкрәген өтеп, бугаз төпкелгә сикерде. Ул шалдыр-шылдыр капканың бикләрен ычкындырды. Җаның гөлбакчаларны тарсына икән, ирекә оч, сандугач!

Урам җиле үзгә икән... Әрсезрәк икән... Әнә, ишегалдын ничек бутый. Өф-өф машина төтенен тарата, көз сарысы суккан яфракларны бөтергәләп уйный...

— Капканы яп! Мәетле йорт төсле ник аны тутырук ачтың? — дип, апасы килеп басты. —Тәки сине санламады, чүлмәк гөле, и бер Аллам!

— Аның исеме Гүзәлия иде, апа.

«Иде, иде...» Үткән заманда гына яшәде микән алар? Әле куып тота... Әле куып тота... Тик ничә көнгә? Ничә сәгатькә?

— Мәгәр хәзер сыгылсаң — мәңге тураймыйсың, энем. Чүлмәк гөлләнең туфрагы ташкалада, бәбкәчем.

— Анын исеме Гүзәлия иде, апа.

— Буең озын, чүгәлә, Сөләйман малае!

Карчык анысы үзе дә гәүдәгә таза иде.

— Утырыйм мин, апа.

Ирнең йөрәге хәлсезләнгән, җаны бер тотам калмыйча, Гүзәлия артыннан чаба иде...

— Мәйлең, — диде апасы һәм шытырдатып уң колагын борды.— Бүтәнчәләй шыпан-шыпан гына күрше бакчасының алмасын татыма, угры!

Май төненең шаһитлары юк иде. Сәлимәме? Шуннан бирле оятыннан бөрешкән хатын явыз карт Диюгә эч серен түгә димени!

— Икенчесен дә умырып тарт, апа.

Гафур муенын кыйшаткан иде, карчык:

— Шунысына канәгать бул! — диде. — Гөнаһлы инде син, энем. Колак җәзасы гына аз инде сиңа. Ялгызак катыннарның кочагында җылынырга җизнән дә мачтыр иде.

Кичә Дума күперен төзекләндерәләр иде. Машиналарны бер сызыктан гына уздыралар, шуңа анда чират иде. Гүзәлия, шәт, күпердә тоткарлангандыр.

— Бөркет нәселе ирләре чыпчык ауламый иде. Күзе очлы иде. Син абындың, энем. Шәһәр кызы сукырайтты сине.

— Апа, кичкә сөйләшербез, минем ашыгыч эшем бар, — дип калкынган ирнең сул колагына үрелделәр.

— Атаң Сөләйман акыллы иде, ахыры хәерсез тәмамланган эшкә керешмә, дияр иде. Юлыннан кире әйдәмә катыныңны. Чыпчык үз куагында чыркылдаса гына бәхетле, энем. Син моны беләсең, шулай икән, никләр йөрәгеңне бастырмыйсың, бәбкәчем?!

— Колаклар кызышып яна, апа.

— Артыграк бордым шу-ул. Сөенечемнән, ахры, энем.

— Сиңа рәхмәт, апа. Күршең белән татулашкансыз. Күке кызы дип чәнечмисең. Өч көнлек дөньяда нәрсә бүлешәбез без.

— Сәлимә кызым кебек инде, Гафур. Шәрбәнбануда ирләр аздырмаган икән, каенанасы Дир-дир апаны баккан икән ул. Сезнең төсле үк мин дә гөнаһлы, бәнахакка кешегә яла ябып. Өч гөнаһ без бүген. Дүртенчебезнең менәтерәк, туасы нарасыйның, нәсел дәвамчысының безнең хаталарыбызга түчны катнашы юк. Бала диден, бала дип сыкрадың, кимчелек миндә дип үз-үзеңне табаладың. Син камил, энем, һәр яктан да. Хәзер бар, улыңның анасына булыш! Кәрзиннәрне үзең күтәр, кире беткән!

Гафурның җилкәсеннән гайрәтле Мингайшә карчык эттеме, җил эттеме, хәер, бөркетләр читтән ярдәм көтми, канатларын җилпеп үзләре оча, мизгел эчендә ир алмагач куагы янында иде.

Артында апасы чәрелдәде:

— Куагында тәмлерсен, яшелләрен өзмә, күке кызым!



Халисә
Мөдәррисова

## БЕЗГӘ ИНДЕ ЯЗЛАР КАГЫЛМАСЛАР...

***

Тамчы суга бу җәй дөнья мохтаҗ
Зарыга ялан, кырлар, урманнар.
Басуларда иген урынына,
Теткәләнгән корама юрганнар.

Ярлар белән ярлар тоташмый, — дип
Кемнәр әйтә ала? Тоташа!
Сак белән Сок түгел, урман булып
Урман кочаклаша ут аша.

Җиһаннарны кочар булып очар
Адәм тын алалмый эсседән.
Бал кортлары очмый, балык йөзми,
Кеше көнләшәлми кешедән.

Нәрсә соң бу? Ходай җәзасымы?
Җир-бишекнең зары тотамы?
Онытылган оят, кылган гөнаһ,
Укылмаган исраф догамы?

Әллә каргышымы юл чатында
Хәер сорап торган ананың?
Соңгы сулкылдавы, рәнҗешеме
Чүплектәге нәни баланың?

Масаюың хәттин ашкан бәндә,
Син тик — кеше, кодрәт түгел син!
Бер кайнар җәй җитә — яңгырсыз җәй,
Җиңеп кара тәмуг эссесен!

«Мин-мин», — диеп күкрәк сугып кара,
Бармак янап кара җиһанга.
Кисәтүеме, бу җәй табигатьнең
Килмәсме, дип, кеше иманга.

Халисә МӨДӘРРИСОВА – *шагыйрә, прозаик; татар, башкорт телләрендә чыккан «Көмеш дага», «Шамахә төн», «Балан» һ.б. китаплар авторы. Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Башкортстанда яши.*

**Җаннар коргаксыган бу заманда**
**Рух кыйралган, аңа дым кирәк.**
**Мохтаҗларга җылы куллар кирәк,**
**Изгелек һәм тыйнак моң кирәк.**

**Имгәтелгән ялгыз күңелләргә**
**Карлар яуган, бозын актарыйк.**
**Соскы белән күмер йөреткәндәй**
**Җаннан-җанга җылы кайтарыйк.**

**Тәрәз төпләрендә «миһербан» дип**
**Исемләнгән гөлләр үстерик.**
**Балаларның шәфкать бакчасына**
**Җан-коедан алып су сибик.**

**Яңгыр явар берчак, тугай, кырлар,**
**Һәм басулар туеныр пар-дымга.**
**Тулып сулар агар, әмма бүген**
**Мохтаҗ әле суга бар дөнья.**

***

**Күккә чөеп җан яндырган**
**Яшене...**
**Кайда хисләр, кипкән чишмә**
**Яшеме?**

**Кемдә гаеп, үзебезме,**
**Язмышмы?**
**Тәкәбберлек, горурлыкмы,**
**Ялгышмы?**

**Нык эзләсәң, ни эзләсәң –**
**Табыла.**
**Онытылсынмы? Кусаң, күңел**
**Абына.**
**Моңлы җырдан сүз онытылса,**
**Көй кала,**
**Кайда сөю? Ник ярадан**
**Җөй кала?**

## Уфа

**Ал нурга коенган урамнар,**
**Һавада ак сирень исләре.**
**Моң булып чакыра, иркәли,**
**Уфамның җыр тулы кичләре.**

**Һәр сукмак, чәчкәдә — якты наз,**
**Саклана мәхәббәт серләре.**
**Яшьлекнең үзенә гашыйк ул**
**Уфамның йолдызлы төннәре.**

**Агыйдел күпере өстендә**
**Алтын ай, ярында таллары.**
**Дим җырлый, тибрәлә, талпына,**
**Уфамның бәхетле таңнары.**

Яшьлек — ул мәңгелек хатирә,
Сагыныр кемнәрдер — кемнәрне.
Яктырсын һәрвакыт күңелдә,
Уфамның кояшлы көннәре.

***

*«Пустых небес прозрачное стекло...»*
А.Ахматова.

Буш күкләрдә тоныкнакыс нурлар
Ак бүректән ойый соры өйләр.
Әле улый, әле әрнеп елый,
Әле җырлый тышта исерек җилләр.

Кышлар керә, хисләр инде айнык:
Борчылу юк, җырла, елап кара...
Безгә инде язлар кагылмаслар,
Күзләрнең дә төсе уңып бара.

Әрнеп җырлап, әле әрнеп елап
Бу дөньялар бездән калып бара.

## Тор, балам!

Бала чакта иртән йокыдан
Нәнәм мине көйләп уятты:

«...Тор, балам, тор, балам,
Казанны алалар,
Безне дөрләп янган
Утларга салалар...»

Белмәсәм дә чорлар «фасылын»
Күңел тойды җырның асылын.

Алды нәнәм мичтән икмәкне,
Һәм учакка куздан ут якты.

Бәрелә-сугыла вакыт ташына
Тарихлардан өннәр ашкына.

Чор да ерак бездән, Казан да,
Канда, бар тартылу азанга.

Шом һәм шөбһә күңел төбендә:
Ныклы микән шәһәр тегендә?

Бирешмәсме тагын чорларга
Калмас микән миңа җырларга:

«...Тор, балам, тор, балам,
Халыкны басалар,
Телләрне «кисәләр»
Рухларны «асалар».

Канлы бәетләргә тулма, ил,
Ваемсыз һәм гамьсез булма, ил!

Тел һәм ирек булса, ил булыр,
Көчле, кучле татар шул булыр.

***

Исеңдәме, син киткәндә
Көзгедә кипте тыным,
Калтыранган иңсәләрем,
Иелгән башлы сыным?

Үкенәсең, сагынасың,
Теләп тә сагынмаска...
Ни әйтергә?
Тырышамын шул көннән соң
Көзгедә чагылмаска!

***

Кирәкми, искә төшермә,
Ачма келә, җай табып,
Ул чакның ихлас хисләре
Тышкы ишектәй ябык.

Бикле алар, ачылмаслар,
Ачкыч югалткан серен.
Юк, көлдән учак терелмәс,
Аңламас кыш яз телен.

Карлы җилне сөзә тышта
Нечкә бармаклы сирень.

## Көзге сөю

Кыеклап яңгыр сибәли
Соңгы нур көлтәсенә,
Күшеккән кош кереп качты
Наратлар бөдрәсенә.

Усакларның кочагында
Чайкала көзге ялкын,
Тыелган сөю шикелле
Әле ут, әле салкын.

Көзнең соңгы җылы җиле
Тәрәз капкачын ачты,
Минем күңелем дә шулай
Бер болытлы, бер якты.

Өрфиядәй пәрәвездә
Тирбәлә каурый–канат.
Язда кем дә сөя ала,
Син мине көздә ярат.

Көземдә мине ярат!

# Исәнме, җыр!

*Башкортстанның халык артисты*
*Идрис Кәлимуллинга.*

**Исәнме, җыр! Саумы, тылсымлы көч,**
**Әйтерсең син яшерен ярату,**
**Күккә ашу, болытларны кочу,**
**Упкыннарда җанны канату.**

**Җыр ул — батыр, кыю, Икар кебек**
**Егылса да аша күгенә,**
**Җыр үлемсез, учак өсләрендә**
**Феникстай кабат терелә.**

**Исәнме, җыр! Саумы, мөкатдәс көй,**
**Күңелләрне тутыр, моңландыр,**
**Елат, юат, җанның юшкынын ю,**
**Серең белән гавәм куандыр,**
**Матурлыкның көче шуннандыр,**
**Исәнме, җыр! Халкың белән бул!**

***Редакциядән:***
*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аны бәйрәме белән ихлас котлыйбыз, иҗат уңышлары, исәнлек-саулык телибез.*

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире ияләренә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**

# ИҢНӘРЕҢДӘ КАНАТ БАРДА...

Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы каршындагы «Идел» яшьләр үзәге инде менә гасыр башыннан бирле ел саен ил күләмендә яшь язучылар бәйгесе оештыра. «Иделем акчарлагы» дип атала ул. Шушы вакыт эчендә әлеге бәйгедә җиңүчеләр һәм катнашучылар арасыннан дистәләгән яшь әһле каләм үсеп чыкты. Хәер, сез инде, хөрмәтле укучылар, журналыбызның «Ак җилкән», «Яңа исемнәр» һәм «Яшьләр иҗаты» сәхифәләрендә аларның иҗаты белән һәрдаим танышып барасыз. Бу юлы Илүзә Гайнетдинова белән Алмаз Мансуровның хикәяләрен тәкъдим итәбез. Илүзә дә, Алмаз да — «Иделем акчарлагы — 2012» бәйгесе лауреатлары.

«Сәгатьләр буе хыял дингезендә йөзә алам. Дусларым, мине яратып, «хисле таракан» дип йөртәләр. Шигырьләр, хикәяләр язам. Бер дә йокларга яратмыйм, йокы — ул вакытны бушка уздыру. Шуңа, йоклап ятканчы дип, төнге өчкә кадәр тәмләп Мәһдиев романнарын укыйм. Көләч, шаян һәм шат күңеллеләр белән бик тиз уртак тел табам. Скрипка уйнарга өйрәнәсем килә. Киләчәккә планнарым зурдан: адвокат белеме алган журналист булу», — ди Илүзә. Быел ул Апас районының Каратун урта мәктәбен тәмамлый.

Алмаз исә — Казан егете. Ул да быел КФУның филология һәм сәнгать институтын тәмамлап йөри, «Ялкын» журналында эшли.

«Калада тусам да, бала чагым Саба ягындагы авылда, гүзәл табигать кочагында, чын безнеңчә милли әби-бабай мохитендә үтте. Ә хәзер исә – «яшь чагым, җүләр чагым»! Эзлим, табам, югалтам... Һәрхәлдә, бернәрсәгә дә битараф түгел мин. Шуңа күрә дә канатлана-канатлана яңа шигырьләр, хикәяләр язам», – ди Алмаз үзе.

Илүзәнең шаян-шук, Алмазның лирик-драматик хикәяләрендә – беренче иҗат яралгыларында – әле җитешеп бетмәгән урыннар байтак. Әмма алардан иң мөһиме – ихласлылык бөркелеп тора. Кырыс әдәби таләпләрне алга таба куярбыз... Яши-яши, яза-яза камилләшерләр!

Яшьләрнең үзләре белән дә, әсәрләре белән дә танышкач, шагыйрь Марис Нәзировның инде җырга әверелгән мәгълүм шигъри юллары хәтергә килде:

*Очмыйча син түзеп кара –*
*Иңнәреңдә канат барда!*

Очыгыз! Хәерле очышлар сезгә!

**Марат ЗАКИР**



# Илүзә Гайнетдинова

## Өмә

Якшәмбе... Авылда беренче язгы өмә көне бүген. «Байлар болыны»н кыш буена җыелган чүп-чардан чистартасы бар. Авыл халкы дус-тату, бердәм яши, шуңа күрә дә авыл рәисе Күркәм Рөстәмнең (ике сүзнең берендә «күркәм» сүзен кыстырганга, шундый күркәм кушаматлы да инде ул) белдерүләр тактасына элгән чакыруын күрүгә, Балтайның үзәге булган сельпо кибете каршына җыелды авылдашлар.

И, җыелып та күрсәтте соң халык! Мәдинә апаның армиядән кайткан улы дисеңме, савымчы Айгөл, тимерче Рәдиф дисеңме, мәктәптә укучы җыен малай-шалай дисеңме — барысы да бар. Хәтта акылга җинелрәк Радик та шунда.

Бар да бар, тик рәис үзе генә күренми әлегә. «Күркәм»не көтеп торганда, хатыннар бер кучкә җыелып гайбәт сатарга кереште.

— Ишеттегезме, Гөлнурның малае маржага өйләнгән икән!

— Анысы пүчтәк, менә Сажидәнең ыштансызы дүрәк Радик белән сугышкан ди!

Әллә үз исемен ишетеп, әллә болай гына — хатыннар янына Радик та килеп басты.

— Исәннәрмесез, апакайлар!

— Исәнме, наным, — диеште хатыннар (безнең авылда үзеннән яшьрәк кешегә шулай дәшү гадәте бар).

— Ник наным булыйм мин? Республиканың эчке эшләре буенча депутаты мин!

Шунда Чая Миләүшә:

— Депутат булгач, халыкны кайгырт инде син. Бар, безгә кибеттән симәнке алып чыгып бир әле! — дип ярып та салды.

Менә хәзер кызык хәл булачагын сизенеп, хатыннар колакларын торгыздылар, көлешә үк башладылар.

— Бирәм, ник бирмәскә! — диде Радик. — Тик миңа моның өчен нәрсә булыр?

— Без сиңа җыелышып рәхмәт әйтербез!

Шуны гына көткәндәй, Радик кибет ишегенә юнәлде. Күп тә үтмәде, бер капчык симәнке күтәреп килеп тә чыкты.

Һәммәсе «ах!» итте.

— Вәт, Миләүшә, вәт, чая тәре! — дип, Миләүшәгә сокландылар. Тегесе дә, шуңа бик разый булып:

— Шулай ул, сорый белеп сорагач! — дип мактанып алды. Симәнке белән Радик сыйласа да, бар рәхмәте Миләүшәгә булды.

Миләүшә юл буе үзенең зирәклеге вә осталыгы белән рәхәт горурланып барды.

Бу хәлдән соң берәр атна үтте. Бакчадан кызын алып кайтып килгәндә Миләүшәгә кибетче Галия очрады.

— Син бурычынны кайчан түләргә жыенасын? Отчет бирәсем бар лабаса, шуның хәтле сузып йөрмәсәң! — дип тезеп китте ул.

— Нинди бурыч?

— Соң теге 546 сум инде. Симәнке өчен.

Хатынның һаман аңламавын күреп:

— Өмә көнне Радикка яздырып алып чыгарга кушкан симәнке өчен бурыч! — дип әйтеп салды кибетче.

Тагын бер атнадан Миләүшә бурычын түләде дә, моннан ары Радик белән бәйләнешкә кермәскә ант итте.

## Онытылмас дәрес

Озын тәнәфес вакыты иде. 9нчы сыйныфларның бүлмәсендә һәрвакыттагыча ыгы-зыгы, шау-шу, этеш-төртеш... Агылый белән Тагылый сыман гел бер-берсенә ияреп йөргән, тик бер генә көн дә ачуланышмыйча тора алмаган Алсинә һәм Гөлсинә «Орифлэйм» компаниясе чыгарган яңа сәгать турында фикерләшә. Айдар белән Айнур иртәгә «Ак Барс»ның ничә гол кертәчәге хакында гәп куерта. Радик шигырь яза, Алсу оекбаш бәйли, «хыялый» кушаматлы Зөфәр мәхәббәт турында китап укый, Фәрит белән күзлекле Кәримә шахмат уйный. Кыскасы — һәркемнең үз шөгыле...

Шулвакыт «колакчын» кушаматлы Фәрит имән бармагын иреннәренә тидереп:

— Шухер!!! Габдуллыч килә!!! — диде.

«Габдуллыч» дигәннәре инде мәктәптә утыз елга якын мәктәп директоры булып эшләгән Усман Габдуллович иде. Сыйныф тынып калды. Һәммәсе дә үз партасына ашыкты. Менә кабинет ишеге ачылып китте дә, ишектән Усман Габдуллович белән кулына китап-дәфтәр күтәргән, таныш булмаган бер яшь кенә кыз керде. Күзлекле Кәримә класста чыш-пыш таратты. «Яңа физика укытучысы икән!» — дигәне ишетелде. Ул арада сүзне директор алды:

— Ишеткәнегезчә, физика укытучысы Мәдинә Сәлимовна лаеклы ялга чыкты. Таныш булыгыз, бүгенге көннән алып сезнең сыйныфка физика дәресләрен Роза Марсовна укытачак. Яшь укытучы белән... Галимов! Ник тартасың ул Алсинәнең чәчен!!! ... Яшь укытучы белән үзегезне тәртипле тотыгыз, — диде. Аннары укытучыга борылды: «Булды, Роза Марсовна, сыйныф белән сезне таныштырдым, эшегезгә иртәгәдән керешә аласыз. Фән буенча методик планнарны Мәдинә Сәлимовнадан алырсыз», — дип сөйләнә-сөйләнә чыгу юлына юнәлде. Яшь укытучы исә аңа ияреде.

Әлеге яңалык сыйныфта зур кызыксыну тудырды. Һәрберсенең яңа укытучыны ничек тә булса сынап карыйсы килә иде. 9 нчы «б» сыйныфы укучыларының һәркайсының башында төрледән-төрле мәкерле фикерләр туды. Сүзне Алсинә белән Гөлсинә башлады:

— Хәтерлисезме, без киләсе дәрескә контроль эш эшләргә тиеш идек. Һәм план буенча аны безгә Роза Марсовна барыбер эшләтәчәк. Әйдәгез, тактага сабын сөртәбез, һәм аңа язу мөмкин булмаячак! — диделәр.

— Урындыгын кисеп куярга кирәк аның! — диде Фәрит.

«Хыялый» Зөфәр исә:

— Мәхәббәт турында сораулар бирергә кирәк аңа... — диде хыялый күзләрен йомып.

— Миндә уенчык тычкан бар. Идән буенча шуны жибәрергә кирәк. Мин

беләм: шәһәр кызлары тычканнан курка, — диде Алсу.

— Туфлиләрен күрдегезме, туфлиләрен! Идәнгә су тамызып куйсаң, таела да егыла! — диде күзлекле Кәримә.

— Контроль эш дәфтәрләре бер дәрескә югалып торса да ярый, — дип әйтеп салды Радик.

Икенче көнне физика дәресенә барысы да әзерләнгән иде. Такта сабын белән юылган, укытучы урындыгы киселгән, контроль эш дәфтәрләре югалган һәм ишек төбендә зур булмаган күлләвек ялтырап ята...

Дәрескә чакырып кыңгырау чылтырады. Коридордагы шау-шу бер мәлгә зурайды, тик тиз арада кимеде дә, чөнки барысы да сыйныфларга таралып беттеләр. Бары җыештыручы Тәслимә апа гына көнбагыш орлыгы ашаучыларны орыша-орыша идән юа башлады.

Бу мизгелдә 9нчы «б»лар аеруча дулкынлана иде. Сыйныфның 9 укучысы да бу дәрестә ни-нәрсә буласын көтә. Ишек ачылды. Укытучы керде. Балалар торып бастылар.

— Исәнмесез, укучылар! Хәерле көн! Утырыгыз! — диде Роза Марсовна.

Тик нигәдер күлләвеккә таеп егылмады, аны бөтенләй күрмичә янәшәсеннән узып китте.

— Укучылар, Мәдинә Сәлимовнадан сораштым, ул сезгә контроль эшкә әзерләнегез, дип әйткән булган. Шуңа күрә бүген контроль эш эшләячәкбез. Биремнәр ике вариантта. Тактага язып сезнең вакытыгызны алмас өчен, һәрберегезгә дә биремнәр аерым биттә булачак, — диде. Шуны гына көткәндәй, Агылый белән Тагылый бер-берсенә карашып алдылар. Аларның күзләрендә чиксез гаҗәпләнү чаткылары ярылып ята иде.

Укытучы биремнәрне таратып чыкты да, өстәлгә сөялеп тора башлады. Фәрит дәшмичә булдыра алмады:

— Утырып торыгыз, Роза Марсовна.

— Рәхмәт, Галимов. Мин, баскан килеш, сезнең күчерү-күчермәвегезне карап торам.

...Калган планнар да тормышка ашмады. Алсу ничә тапкыр уенчык тычканын идәнгә атып карамасын, укытучы аны күреп кычкырмады. Зөфәр дә үзенең сорауларын бирергә кыймады.

Дәрес беткәнен белдереп, кыңгырау чылтырады. Укытучы сүз алды:

— Дәресләрегез бетте, димәк, тактадагы сабынны юып ала аласыз, идәнне дә сөртеп чыгыгыз, урындыкны төзәтегез, контроль эш дәфтәрләре урынында булсын. Иртәгә сезгә беренче дәрес — физика, тикшерәм! Өй эше: номер унсигез. Сау булыгыз!

Бу юлы бөтен сыйныф шаккатты. Һәммәсе дә бер-берсеннән шикләнде.

Алты дәрес беткәч, 9нчы «б»ларга кереп карасагыз, анда урындык төзәтеп ятучы Фәритне, ышкый-ышкый такта юучы Алсинә белән Гөлсинәне, идән сөртүче Кәримәне, контроль эш дәфтәрләрен кая куярга белмичә басып торган Радикны һәм тырышып-тырмашып физика китабын укучы Зөфәр белән Алсуны күрергә була иде.

Их! Барып чыкмады бит әле бу яшь укытучыны сынау... Аның инде моңарчы өч ел Казан мәктәбендә укытканын да, халыкара мөгаллимнәр конкурсында «Яшь укытучыны мәктәптә нинди сынаулар көтә?» дигән гыйльми хезмәте белән катнашып, Гран-При яулаганын да белми иде шул әле бу «башкисәрләр»...

## Буыннар алмашы

— Әй, балам, бигрәкләр дә сәер уеннар уйныйсыз да инде! — диде дәү әнисе Илүзәгә. — Шул бер уенда сикерәсез дә, җырлыйсыз да, биисез дә.

— Әй, дәү әнием, нигә исең китә? Берние дә юк бит аның! Без «Мин

калам — син чык» дигән уен уйныйбыз. Кем нинди санамыш белә — шуны әйтә. Мин менә мондыйны әйтәм:

Әке-бәке, сыерчык,
Син – калып тор, ә син — чык!

— Ә аннары?

— Аннары шул чыгучы кеше җәза үти. Ул җәзаны без үзебез уйлап табабыз. Кемнедер сикертәбез, кемгәдер биергә кушабыз.

— Үзегез тагын әллә ниләр беләсез!

— Дәү әнием, ә сез нинди уеннар уйный идегез? «Бәреп чыгарыш» уйный идегезме?

— Нишләп чыгарыш?

— Кит инде, шуны да белмисеңме? Сезнең балачак бигрәк күңелсез булган икән, уеннарыгыз да юк әнә.

— Әй, бәбкәм, ялгышасың! Без уйный торган уеннарның исәбе-хисабы юк иде. Ул «Уникe таяк» дисеңме, «Лапта», «Качыш», «Әбәкле», «Бәрә-бәрә»...

— «Бәрә-бәрә»?

— Әйе. Безнең авыл елга буенда урнашкач, аннан кайтып та тормый идек. Шуның ярындагы кызыл комнан кечкенә курчаклар ясыйбыз, аннары киптерәбез. Алар таш булып ката. Шуннан соң тигез җиргә барып, аларны тезеп куясың. Вак чуерташлар җыеп киләсең. Шул таш курчакларга төбәп атасың. Курчак егылса — синең белән бергә уйнаучының башына чиертәсең, ә инде ватылып ук китсә — ул синең бәбкәләреңне куып килә. Менә ул чемпионат иде! Сезнең ярышларыгыздан һич кенә дә ким түгел. Бәбкә сакларга дип төшәбез дә, көне буе шуны уйнап ятабыз. Мин гел күрше малае Габдулла белән уйный идем. Малайлар җинелсә, безнең авылда зур гарьлек санала иде. Мин ул «Бәрә-бәрә»не оста уйныйм, ә Габдулланың килеп чыкмый, гел отам тегене! Әй, ачуы чыга да иде соң!

— Кызык булган икән шул. Иртәгә мин моны үзебезнекеләргә дә өйрәтәм әле. Без дә уйнарбыз!

— Уйнагыз, бәбкәм, уйнагыз!

Шулчак ишек ачылды. Аннан мәктәп букчасы күтәргән Рәис күренде.

— Сәлам, дәү әнием! Нихәл, сеңлем! Ни турыда болай гәп корасыз?

— Дәү әни миңа үзләренең балачак уеннарын сөйли. Ул вакытта бигрәк кызык булган икән!

— Берсе дә без уйный торган «Мафия»га җитми инде!

— Мафия?! Миңа да өйрәт әле?

— Савыт-сабаны тиз генә юып алсаң — өйрәтәм!

— Юам-юам, өйрәт кенә! — дип бер урында гына басып тора алмый торган сеңлесе, шатлыгыннан очына-очына аш бүлмәсенә йөгерде.

— Әстәгъфирулла! — дип куйды шунда дәү әниләре.

...Замана балалары исә беркавымнан замана уены дигәннәренә керештеләр...

## Минем тылсымлы каләмем

Айзиләләрнең мәктәбендә әдәбият дәресләре бик күңелле үтә. Укытучылары Ләйлә Рөстәмовна бик әйбәт шул, шуңа шулай ул. Һәр дәрес үзенә бертөрле. Алар әле бөтен сыйныфлары белән укылган әсәр буенча гәп коралар, әле бәхәсләшеп, үпкәләшеп алалар, әле уртак фикергә килеп, янә юктан да кызык табып, чыркылдаша башлыйлар.

Бүген дә нәкъ шулай булды. Шәүкәт абый Галиев шигырьләре белән танышкач, укытучы апалары болай диде:

— Балалар, мәктәбебездә «Күз ул нинди?» дигән тема буенча иҗади бәйге бара. Катнашырга теләүчеләр шигырь, хикәя, рәсемнәрен тәкъдим итсеннәр. Менә, мәсәлән, Гөлзилә шигырь иҗат итә ала. Хәтерлисезме, сыйныфташыгызның әниләргә багышланган шигыре икенче урын алган иде бит!

... Айзилә белән Гөлзилә кечкенәдән гел бергә: балалар бакчасына бергә йөрделәр, мәктәптә дә бер парта артында утыралар, күршедә генә яшиләр. Өстәвенә, исемнәре дә охшаш: аерма ай белән гөлдә генә. Тик менә бүген Гөлзиләне өстен куюлары гына бөтен эшне бозды. Айзиләнең күкрәгендә көнчелек уты кабынды.

— Хе! — дип уйлады ул. — Аның хәтле генә мин дә булдырам инде! Гөлзиләсен күр әле: борынын күккә чөйгән, елмаеп утыра бирә! Юк инде, мин җиңел генә бирелмәм, шундый итеп язармын! Шаккатырсыз! — дип, үз алдына максат куйды.

Тик шигырь алай җиңел генә килеп чыкмый икән шул. Уйлады, ишекле - түрле йөренде, кулларына, битенә сызгалап бетерде, ләкин файдасы булмады... Дәфтәр битендә «Менә сары көз житте» дән башка сүз язылмады...

Инде караңгы төшеп килә. Айзилә ачуыннан каләмен идәнгә атып бәрде. Шулвакыт... кинәт бүлмә күзгә күренеп яктырып, нурлар уйный башлады. Каләм, идән уртасында күпмедер вакыт бөтерелеп торганнан соң, нәни аякларына басты һәм каршысындагы кызга карап күз кысты. Айзиләнең маңгаена салкын тир бәреп чыкты, тавышы калтырады:

— Сииин к-к-кем?

— Мин — тылсымлы каләм булам. Синең кебек аптырашта калган кызларга төрле киңәшләр бирәм, укуларында булышам.

— Нигә алайса миңа шигырь язарга булышмадың?

— Мин сине инде күптән күзәтәм. Теләгеңне дә беләм. Тик сиңа шуны әйтәсем килә: дустыңнан уздырам дип, көнләшеп түгел, күңелең кушканны эшлә.

— Ничек инде — күңелең кушканны эшлә?

— Әйт әле, син күбрәк рәсем ясарга яратасыңмы, әллә шигырь язаргамы?

— Рәсем ясарга, билгеле.

— Димәк, синең күңелең рәсем ясарга тели. Һәм шулай эшләргә кирәк тә. Бәйгегә бит рәсемнәр дә кабул ителә. Ничек уйлыйсың?

— Яхшы фикер! Рәхмәт сиңа, тылсымлы каләм!

— Зур үс, акыллы булып үс, Айзилә! Сау бул!

Янә нурлар бөркелде, очкыннар чәчелде. Каләм, урынында бөтерелеп торгач, тынып калды. Айзилә дә һушына килде. Күпмедер вакыт әйтелгәннәрне исенә төшереп утырды. Аннары, каләмне алып, кадерләп түргә утыртып куйды да карандашлар, буяулар алып килеп, рәсем ясарга кереште.

Рәсем, чынлап та, бик уңышлы килеп чыкты. Елга ярында үсеп утыручы агачлардан күксел-кара су өстенә соңгы сары яфраклар коела. Күктә кояш саран нурларын сибә, кошлар туган яклары белән саубуллаша...

Икенче көнне Ләйлә Рөстәмовна да Айзиләне мактап туя алмады. Тик менә Гөлзилә генә күңелсез иде бүген. Нишләптер сүзгә дә кушылмады, элеккегечә чыркылдап көлмәде дә.

Өенә кайткач та, Айзилә озак кына тылсымлы каләм турында уйлап утырды. Әйе, зур сабак бирде ул аңа. Моннан соң ул гел күңеле кушканны эшләр, дустыннан көнләшеп, шигырьләр язып азапланмас.

Ә бу вакытта Гөлзилә өендә тырышып-тырышып рәсем ясап маташа иде. Их, аңа да биреп торасы иде бу тылсымлы каләмне!



Алмаз
Мансуров

# ДОГА

## 1

Аяк очларына гына басып йөргән Наташа бүлмә уртасында тукталып калды. Урын өстендә яткан каенанасына тагын бер тапкыр күз салды да, авыр сулап, тәрәзә янына барып басты.

Җил ияртеп килгән соры болытларга сокланып карады ул. Алар бөтен күк йөзен каплап алганнар да, ялга туктаган юлчы кебек, ялкау гына асылынып төшкәннәр. Яңгыр, күңелләргә моң салып, пыскып ява да ява. Гүя бар дөньяны сагыш пәрдәсенә төрергә, үз ихтыярына буйсындырырга тели ул.

Шуңа күрәдер, йорт каршындагы карт милләш тә моңаеп башын игән, юешләнеп, сыгылып төшкән. Ә теге койма буендагы күгәрчен нигә бөрешеп утыра?!

«Хәзер өенә керәбез!» — дигән сыман тәрәзәгә шыбыр-шыбыр коелучы яңгыр тамчыларына игътибар итте Наташа. Аларның биешкәнен күзәтү дә кәефен күтәрмәде аның. Яңгыр тамчылары пыяла тузанында түгел, ә күңеле түрендә ямьсез эз калдыралар төсле тоелды аңа.

— Нишләргә соң?.. Нишләргә...

Инде ничә көннәр бимазалаган шушы сорау аның күңелен кабат борчып куйды. Нишләргә соң? Белми шул Наташа. Белсә, каенанасын савыктыру, һич югы хәлен җиңеләйтү өчен кулыннан килгәннең барысын да эшләгән булыр иде.

Чарасызлыктан, борылып, бүлмә эченә күз салды ул. Нәрсәдер эзләгәндәй, диварларны, өй эчендәге җиһазларны җентекләп карап чыкты. Икеләнеп торгандай итте дә, кабаланып каршы як почмакка китте.

Игътибарын стенага беркетелгән изге сурәткә юнәлтеп, бер тын басып торганнан соң, ул авыз эченнән генә нидер пышылдап, берничә кат чукынып алды. Сурәт өстеннән кара япманы салдырып, читкә ыргытты. Почмакка карап, идәнгә тезләнде.

Тынлыкны сискәндереп, бүлмәгә ялвару сүзләре таралды.

— Боже... — диеп пышылдады Наташа, кайдандыр эчтән ургылып чыккан җан авазы белән: — Боже, помоги! Исцели мать!

Аның күзләре дымланды. Тәгәрәп төшкән күз яшьләре белән күңеленнән изгелек суырылып чыккандай булды. Ул бар күңелен догага салды. Урын өстендә ятучы карчыкка саулык-сәламәтлек теләде. Ходайдан аның гомерен озайтуны сорады. Наташаның агарынган йөзенә нур кунды, ә яргаланып беткән иреннәре туктаусыз дога сүзләрен кабатлады.

— Наилә, кызым... — Тавыш, куркып кына, диварларга сарыла-сарыла Наташа утырган почмакка үрмәләде. Ят телдәге догадан, изге сүзләрдән

бераз өркеде булса кирәк, бераз калтыранып торды да, шул авазга үрелеп, бүлмә эчендә эреде.

Наташа аны бөтенләй ишетмәде. Чөнки күнеле белән бу гөнаһлы җирдән аерылып, күккә күтәрелгән, изгеләр дөньясының ишеген шакыган иде инде. Ул бары тик хыяллары, уйлары белән ялгызы калган. Аның өчен күп нәрсә әһәмиятен югалткандай тоелды. Әйе, әйе, чөнки бөек зат бар. Бу һичшиксез шулай. Ул безгә гомер бирүче дә, алучы да. Һәм ул мәрхәмәтле булачак.

Тавыш кабатланды.

— Кызым...

Наташаның зиһене ачылып киткәндәй булды. Каенанасы эндәшә икән ләбаса. Тик ул ашыкмады. Иң элек бар күнелен биреп доганы тәмамлады:

— Всевышний, мы чтим и служим тебе верой и правдой. Прошу тебя, помоги!

Теләкләрен эчтән генә кат-кат кабатлап, озак кына чукынды да, кара яулыгының бер чите белән күз яшьләрен сөрткәләп, хатын тиз генә урыныннан торды. Изге сурәтне каплап куйганнан соң, карчык янына ашыкты.

— Уяндыңмы, әнкәй? Что-нибудь надо?

— Авызым кипте, килен. Чәй эчәсе иде...

— Хәзер, әнкәй! Хәзер...

Наташа, бөтен шартын китереп, чәй хәстәрләргә кереште. Бөтнек, мәтрүшкә, карлыган яфраклары белән тәмләп пешерде. Файдасы тимәсме дип, чокыр төбенә калын гына лимон кисәге дә салырга онытмады.

— Менә, әнкәй...

— Бисмилла һи-ррахман иррахим.

Карчык күтәрелеп, төсен җуйган иреннәрен чокырның читенә тидерде. Бер йотым чәй йотты да, башын янадан мендәргә салды.

Хәле юк шул аның, хәле...

Наташа чынаякны якындагы өстәлгә куйды. Сөйләнә-сөйләнә каенанасының урын-җирләрен рәтләде, мендәрен җайлады:

— Менә күрерсен, әнкәй, тиздән терелерсең. Алай борчылма син, тынычлап ял ит. Нәрсә кирәк булса да, читенсенмә, сора. Әлегә берни дә кирәкмиме? Ещё что-нибудь надо?

Әбекәй килененең күзләренә тутырып карады да, авыр сулап, моңсу гына пышылдады:

— Дога кирәк, кызым! Дога...

Әбекәй күзләрен йомды. Наташа, ял итсен дип, аның яныннан китеп барды. Тик карчыкның иреннәре һаман бер үк сүзләрне кабатлады.

— Дога кирәк! Үзебезчә, хак мөселманча дога...

## 2

Урамнарның карарлыгы калмаган. Ыржайган авыз кебек ялтырап яткан чокырларга су тулган. Юешләнгән кызыл балчык та аяктан эләктереп алырга, кәлүшләргә сыланырга гына тора.

Ядкәр бер нәрсәгә дә игътибар итмәде. Ачылып киткән күк йөзенә дә, болытлар аша сүрән генә саркып чыккан кояш нурларына да әһәмият бирмәде. Бары үз уйларына гына бирелеп, койма янәшәсендәге үләнле коры җирдән атлавын белде. Ялгыш кына койманың юеш такталарына ышкылып китсә дә, тукталып тормады, киемнәрен каккалады да, юлын дәвам итте.

Үз өйләре турына кайтып җиткәч, иң беренче нәүбәттә койма аша үрелеп тәрәзәләренә күз салды. Парланган пыяладагы эре су тамчыларын күреп, авыр сулап алды.

– Әнинең хәле җиңеләймәгән, аякка басмаган икән... – диеп куйды ул ирексездән.

Бер карасаң, мондый хыяллар сәер дә инде. Әле бүген иртә белән генә авыр хәлдә урын өстендә ятып калган карчык ничек шулай тиз генә аякка бассын ди?! Баскан очракта да тәрәзәләрдә гаме булмас иде.

Ә бит сау-сәламәт вакытта ул аларны һәрвакыт карап торды, сөрткәләп куйды. Тәрәзәләр өйнең күзгесе, яме диләр түгелме соң? Алар чиста, пакъ булган чакта гына өй эченә җылы якты нурлар үтеп керә, хуҗаларның да, башкаларның да күңелләре яктырып китә. Шуңа күрә дә Ядкәрләрнең йорты һәрвакыт якты, нурлы була иде.

Капка келәсенә тотынгач та озак кына кермичә торды ул. Ярсыган күңел дингезенең үз ярларына кайтканын, өметсезлек дулкыннарының бераз булса да тынганын көтте Ядкәр. Аның карт әнисе янына елмаеп кайтып керәсе, шул елмаюы белән кадерле кешесенең сырхаулап торган тәнен дә, газапланып яткан җанын да бераз гына булса да дәвалыйсы килде.

Ниһаять, келәгә басып, авыр капканы этте.

– Привет, — диеп каршы алды аны Наташа, эшеннән туктамыйча гына.

Башын да күтәрмичә җир себерүче хатынына озак кына карап торды ул. Аннан эндәшүне кирәк тапты:

– Әнкәйнең хәле ничек?

– Плохо... – диде Наташа. Аннан бер мәл себеркесенең сабына таянып торды да, үксеп елап җибәрде.

– Саташа әни... Ишетәсеңме, саташа.

– Соң...

– Һаман дога сорый.

– Ишетәсе килгәч...

– Укыйм бит инде. Гыйбадәт кылам...

Ядкәрнең карашы хатынының күзләре белән очрашты. Безнең кавем түгел шул, күп нәрсәне аңламый. Иман, дин төшенчәләренә дә үзенчә бәя бирә. Хак мөселманнар гына янган хисләрне дә татымаган. Их!

Аның Наташага әллә ниләр әйтәсе, гомер буе җыелган үпкәсен шушы мизгелдә ачып саласы килде. Кузгалган хисләрен йөгәнләве җиңел булмаса да, ул үз-үзен кулга алырга тырышты.

– Да ну тебя! — Ядкәр ачу белән кулын селтәде дә, өйгә кереп китте.

Өйалдында чишенгәндә әнисенә әйтергә сүзләр эзләде. «Хәлләрең ничек, әни?» — диеп керергәме икән? Әллә «мин кайттым, әни», – дисенме?! Бәлки тын гына барып янына утырыргадыр? Әйе, шулай итәр ул.

Бүлмәгә кергәч тә, ишек төбеннән ары уза алмады. Ерактан гына әнисенә күз салды. Йоклый ахры, ярар, ял итсен. Чыгып китим инде, дип кенә торганда, әнисенең ягымлы тавышы ишетелде:

– Кайттыңмы, балам?

– Әйе, әни. Хәлләрең ничек соң ?

– Аллага шөкер, улым. Ару гына әле. Болай булса, ярый инде.

Ядкәр урындык алып әнисе янына барып утырды. Карчыкның җыерчыклы кулларын учларына алып, тынып калды. Яшь тамчыларын күрсәтмәскә теләп, карашын стенадагы сәгатькә юнәлтте.

Ә бит аның беркайчан да елаганы юк иде. Кечкенә чакта да, егылса да, кыйнап борыныннан кан җибәреп кайтарсалар да, тешләрен кысып түзде. Ә бүген, бүген нәрсә булды соң?

Гомере буе бимазалап килгән яшьлек хаталары баш калкыттымы? Нигә ул үзенең вөҗданын, рухын сатты әле? Нигә соң җанын иблискә буйсынырга мәҗбүр итте? Болай булуын теләмәгән иде бит. Биреште Ядкәр, биреште.

Ә хәзер? Әнисе авырый. Үткәннәре, иман, изгелек белән бүгенге көнгә

кадәр бәйләп торган соңгы җеп өзелергә тора шикелле? Әгәр Аллаһ әнисен мәңгелек дөньяга чакырса, ул изге догаларны, миллилекне мәңгелеккә югалта түгелме?

Янакларыннан тәгәрәп төшкән күз яшьләре урын өстенә тамды. Берничәсе әнисенең кулына да эләкте. Ул гаҗәпләнеп улының йөзенә карады:

– Ни булды, балам?! Ир кешегә болай утыру килешми...

Ядкәр, әнисенең иненә башын салды да, ихлас сүзләрен пышылдады:

– Ялгыштым мин, әни! Сүзеңне тыңламадым...

– Чү, балам. Тынычлан. Үткәннәрне уйлап яшәмә. Бүгенгесе шөкер бит. Дөрес, кайчандыр бик нык рәнҗегән идем мин сиңа. Ә хәзер... Бары бер теләгем. Наилә кызым ни әйтсә дә, үтенеп сорыйм, мине хак мөселманча җирлә...

– Алай димә инде, әни. Яшисең әле син, яшисең.

– Амин, балам, шулай булсын.

Бүлмәдә тынлык урнашты. Ана да, җилкәләре салынып төшкән, кечерәеп, мескенләнеп калган ир дә сүз тапмадылар. Тик каяндыр өйгә кергән чебен генә, әңгәмәне җанландырып җибәрергә тырышкан сыман, безелдәвен белде. Менә ул, челтәрдәге ябылып бетмәгән ярыктан кереп, пыялага бәрелде. Бөтен егәрен җыеп тышка, иреккә, яктылыкка омтылды.

Ядкәр, җай чыкканга сөенеп, кабаланып урыныннан сикереп торды да, күз яшьләрен сөртте. Тәрәзәгә барып, чебенне тотарга тырышты, учлары белән пыялага бәргәләде. Бераз азапланганнан соң, бармаклары арасындагы чебенне тоеп, елмаеп куйды. Әһә, эләкте.

Кайвакыт кеше дә шул чебен хәлендә кала. Ниндидер бер тарлыкка килеп керә дә, чыга алмый. Гомере буе еракта гы яктылык, җан тынычлыгы хакында хыялланып яши, шуңа омтыла. Тик пыяла кебек күренмәс җепләр аны ычкындырмыйлар. Кешене тотып калучы, хыялларын мәңгелеккә сытучы берәрсе табыла.

Шундый уйларга бирелеп торганда, ул әнкәсенең тавышын ишетте:

– Балам, кил әле бирегә. Әйтәсе сүзем бар.

Ядкәр, карават янына килеп тезләнде.

– Тыңлыйм, әни.

– Егет чагыңны искә төшер әле, улым. Ләйсәнне хәтерлисеңме?

Ана самими, өмет тулы карашын баласына төбәде.

– Хәтерлим.

Ничек хәтерләмәскә инде... Әле хәзер дә, шул исемне ишеткәч, йөрәге кысылып куйды. Ярата иде бит ул аны... Беренче һәм гомерлек мәхәббәте! Ләйсән! Әйе, әйе. Зәңгәр күзле... Зәңгәр күзлеләрнең чәче гадәттә сары була. Ә Ләйсәннеке кап-кара иде. Әле кыз аны бер толымга үреп иненә дә салып куя. Үзе һәрвакыт елмаеп тора.

Хат ташучы булып эшли иде Ләйсән. Ядкәр һәрвакыт аның җил-җил атлап килгәнен көтә. Балкып чыккан кояш кебек, ул күренүгә урам яктырып китә. Капка төбендәге әбиләрнең йөзенә елмаю куна, бөкре бабайларның сыннары тураеп киткәндәй була.

Тагын бер нәрсә хәтеренә кереп калган: чая да, һәм шул ук вакытта тыйнак та Ләйсәнгә барча кеше: «кызым» — дип дәшә иде. Ядкәрнең әнисе дә шулай эндәште, яратып, үз итеп эндәште.

– Хәтерләсәң, шул, — диде хәлсез тавышы белән әнисе. – Шәт, онытмагансыңдыр, Ләйсән сиңа кульяулык чигеп биргән иде. Вәгъдә билгесе. Син әнә шул кульяулыкны алганда, минем каршымда: «Ни генә булса да, язмыш ничек шаярса да, Ләйсәнем, сине мәңге онытмам», — дидең. Әле алай гына да түгел, «Вәгъдә итәм, кульяулыкны гомерем буе саклармын!» – дип тә өстәдең. Вәгъдә – иман, балам. Ә син оныттың.

Ләйсәненне югалту белән, кулъяулыкны миңа бирдең дә, теләсә нишләт, дидең. Соң булса да, хатаңны төзәтәсем килә, улым.

Кай арада алып куйгандыр, әнисе мендәр астыннан шул кулъяулыкны тартып чыгарды. Ашыкмыйча гына җәйде, җыерчыклы куллары белән сыпыргалап, бизәкләренә сокланды, төреп улына сузды.

– Ал, балам.

Ядкәр сак кына кулъяулыкны алды. Шул бит, шул, Ләйсәннең бүләге. Тәүге тапкыр тоткандагы кебек. Таушалмаган, төсләре дә уңмаган. Ул аны кулларында бераз әйләндергәннән соң, кадерләп төреп куен кесәсенә салып куйды.

Ә бит яшь чагында ул бәхетлерәк иде. Шул көннәре күз алдыннан үткәндәй булды.

Ядкәр басынкыланып калды. Күңел түрендә саклап йөрткән ярасы ачылган кебек тоелды. Гүя шул ярадан кан саркый. Шуңа да аяклары да, куллары да хәлсезләнә бара...

Әнисе аның халәтен аңлагандай, йомшак кына улына дәште:

– Бар, балам, бер урамнарны урап кайт әле син.

– Ярар, әнкәй!

Ирнең хәленә керергә теләгән сыман, аның артыннан ыңгырашып ишек ябылды. Ядкәр бер нәрсәгә дә игътибар итмәде, иңенә курткасын элде дә, урамга чыкты. Ишегалдында эшләрен төгәлләп килгән Наташаның сүзләре дә колагына чалынып кына калды:

– Ичмасам, башыңа ки!

Ул туктап тормады. Капкадан чыкты да, салмак кына атлап, авыл кырыендагы тауга таба китте.

### 3

Табигать белән икәүдән-икәү генә калгач, җиңел сулап куйды Ядкәр. Колак төбендә сызгыручы җил тавышы да, агач яфраклары лепердәве дә алҗыган күңелен сыйпап тынычландыргандай булды.

Аның өчен газаплы көннәр әнисе авырып түшәккә егылганнан соң башланды. Ни генә әйтмә, йортта ул хуҗа иде бит. Ә хәзер барысы да Наташа кулына калды. Шул көннән башлап өйнең нуры качты, ризык тәме бетте.

Бер караганда, әллә ни үзгәрмәде дә кебек. Наташа да уңган хатын. Вакытында ашарга пешерә, кош-кортларны да җиренә җиткереп карый, өйне дә пөхтә тота. Тик Ядкәрнең күңеленә барыбер нидер җитми. Ул моны аеруча аш өстәле янына утыргач тоя.

Әтисе вафатыннан соң Ядкәрнең урыны һәрвакыт түрдә булды. Ул өстәл янына килмичә берәү дә ризыкка кагылмый. Ядкәр урнашкач кына, әнисе ап-ак тастымалга төрелгән ипине алып килә, бисмилла әйтеп, тастымалны чишә, икмәкне күкрәгенә терәп калын-калын телемнәр кисә. Бер телемне, янә бисмилла әйтеп, Ядкәр алдына куя һәм иненнән сыйпап ала. Бала чактагы бу гадәтне улы ир уртасы булгач та ташламады ул.

Баксаң, әнә шул изге сүзне, әнисенең ихлас күңелен, үз итүен, назын сагына икән Ядкәр. Ашап бетергәч тә алар икәүләп амин тоталар. Дөрес, ул үзе дога сүзләрен белми. Ләкин әнисенең бүлмәне тутырган йомшак тавышын тыңлап, чын күңелдән Аллаһка рәхмәт әйтә, учлары белән битен сыпыра.

Әнкәсе авырый башлагач, боларның барысын да сагынып искә аласы гына калды шул... Чөнки Ядкәр өстәл янына утырганда хәзер ипи киселгән, аш күптән салынган, суына да башлаган була. Бүлмәдә дога ишетелмәгәч, тамак туйса да, җан азыгы җитми, күңеле китек кала.

Әле җитмәсә әйләнә-тирәдәге авыр тынлык та зур газаплар китерә Ядкәргә. Ул әнисенең саф татар телендә өйне яңгыратып торган тавышын сагына. Әле җырлап җибәрә иде аның әнкәсе, әле шигырь такмаклап ала...

Ә Наташа нәрсә? Маржа бит ул. Җырласа да, тавышында моң юк. Шигырь белән әйтсә — сүзләре күңелгә ятышсыз...

Әнисе кечкенә чагында аңа гел: «Аллаһ күктә улым, Аллаһтан курык», — ди иде. Курыкмады шул Ядкәр, уйламады да. Ә ул чынлап та күзәтеп торган икән. Әнә бит, хәзер нинди авырлыклар каршында калдырды аны.

Ядкәрнең Ходайга аз булса да якынаясы, башын җиргә орып, тәүбә итәсе килде. Шуңа күрә дә ул икеләнмичә тау башына юл алды.

— Саумысез, чыршылар!

Ир тамагына килгән төерне йотып җибәрергә тырышты. Яшел ылысларны кулы белән сыйпаштырды. Табигать чыршыларны нишләп шулай итеп яраткан икән? Ел әйләнәсе ямь-яшел утыралар. Бәлки бу безгә Аллаһы Тәгаләнең бер ишарәседер? Нәрсә дип әйтергә тели икән ул? Иманыгыз шушы чыршылар кебек нык булсын дип?!

Ядкәр саргаеп коелган ылысларга тезләнде. Йөзе белән җиргә капланды.

Сулый бит җир, сулый. Аның җылы тыны тәнне иркәли, җанны дәвалый.

— Ходаем, — диеп пышылдады Ядкәр, — Ходаем, кичер.

Тагын нәрсә әйтсен инде? Аның бар булганы: акылы, хисләре, җаны, үткәне, киләчәге — барысы да шушы сүзләргә салынган. Дога укыр иде — белми.

Ядкәр торып утырды. Бераз тынычлангач, тау итәгендә җәелеп яткан авылга күз салды.

Авыл тын... Авыл йоклый. Урамнарда бернинди хәрәкәт тә сизелми. Яралы чагың шул синең. Миллилегең какшаган чагың. Бүген һәр икенче хуҗалык урыслашты түгелме?

Әнә, офыкта тагын бер авыл күренә. Анда да шул ук хәл. Ә тегесе бөтенләй урыс авылы...

«Мин исән әле, исән!» — дигәндәй, авыл талпынып куйды. Мәчет манарасы моңлы дога сүзләрен сузды. Ир, дымланган күзләрен сөртеп, шул авазга ияреп авылга таба төшеп китте.

## 4

Ядкәр нидер булганын өенә якынлашканчы ук сизеп алды. Ачык капка, ишегалдындагы кара яулыклы карчыкларны күреп аның йөрәге кысылып куйды. «Бедная Наташенька», «покойница» кебек сүзләр аның колагына чалынып үтте.

Йә, Ходам!

Ул, беркемгә дә игътибар итмичә, өйгә атылып керде. Бүлмәне тутырган маржа хатыннарын аралый-аралый барып, әнисе янына тезләнде:

— Калдырма, мине, әнкәй. Әнием...

Ядкәр башын әнисенең җансыз учына салды, бармакларын сыйпады. Акчасыз, малсыз-йортсыз да яшәп булыр иде. Тик...шушы әни куллары җылысын тоймыйча яшәп булырмы икән?! Ядкәр, Наташаның кулын иңендә тоеп, башын күтәрде:

— Кайчан? — диеп кенә сорый алды ул.

— Недавно. Азан тавышын тыңлап ятты да... Мәңгелеккә күчте.

Ядкәр урыныннан сикереп торды да, хатынын җилтерәтергә тотынды:

— Наташа, әйт шул маржаларыңа. Китсеннәр. Әнине татарча җирлибез... Хәзер, Бибикамал апага кереп әйтәм...

— Ядкәр?!

— Каршы килмә, бу — әнинең васыяте!

Кире кагып булмаслык нык тавыш белән әйтелгән сүзләр Наташаны чарасыз калдырган иде

...Калганын төштәге кебек кенә хәтерли Ядкәр. Өйгә ак яулыклы әбиләр җыелды. Тынлык урнашты. Барысы да башларын түбән иеп, тын гына тәсбих тарттылар.

Әнисен соңгы юлга тиешенчә әзерләделәр. Ап-ак кәфенлеккә төргәч, карчык тагын да пакъләнеп киткәндәй булды.

Боларны күреп Ядкәр бер нәрсәне аңлады: дин кешеләрне берләштерә икән. Ничек башкарып чыгармын икән диеп борчылган ир, бар нәрсәнең дә үзеннән-үзе табигый эшләнүен күреп, гаҗәпкә калды, Ходайга кат-кат рәхмәт укыды.

...Менә әнисен җир куенына тапшырыр вакыт та җитте. Кабер янында басып торучы, күзләре кызарган Ядкәр җебеп төшмәскә тырышты. Тик... Булдыра алмады. Тыелгысыз аккан яшьләрен башкаларга күрсәтмәс өчен бер читкә китеп басты.

Мулла укыган доганы күзләрен йомып тыңлады ул. Йә, Аллам, моңлы, шифалы сүзләр ничек җанга үтеп керәләр, күңелне кузгаталар...

Ләхет такталарын тезгәч, Ядкәр кулындагы төргәген дә җир куенына салды. Тәсбих, намазлык белән нишләсеннәр инде алар хәзер? Өйдә кадерсезләнеп ятканчы, шушында калсыннар...

Каберне күмә башладылар. Мулла кабаттан изге сүзләрне карчык рухына багышлады.

– Урының җәннәттә булсын, әнием!

Мулланың тавышы, һәр кабергә туктала-туктала, зират буенча таралды. Җил тавышына кушылып, агач башларына үрмәләде, ботакларга уралды.

Ядкәр, муллага кушылып, хак мөселманча дога сүзләрен кабатлады...

---

## «Казан утлары» елъязмасы



*Журналыбыз 1922-1930 елларда «Безнең юл», 1930-1932 елларда «Атака» һәм «Яңалиф», 1933-1965 елларда «Совет әдәбияты», 1965 елдан «Казан утлары» исеме белән дөнья күрә.*

**Апрель**

80 ел элек (1933) «Совет әдәбияты»нда Мирсәй Әмирнең «Безнең авыл кешесе» хикәясе, Гомәр Толымбайның «Татар фольклоры фронтында» исемле мәкаләсе;

55 ел элек (1958) «Совет әдәбияты»нда Фатих Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы» романы;

45 ел элек (1968) «Казан утлары»нда Мәдинә Маликованың «Казан каласы – таш кала» повесте, Нажар Нәҗминең «Татар теле» шигыре;

35 ел элек (1978) «Казан утлары»нда Шәйхи Маннурның «Чын сөю бармы?» исемле лирик повесте, Камил Кәримовның «Тәнәфес» хикәясе;

30 ел элек (1983) «Казан утлары»нда Гамил Афзалның «Туган илдә Тукай рухы» исемле шигырьләр циклы;

25 ел элек (1988) «Казан утлары»нда Роберт Батулланың «Юл буенда зәңгәр чәчәк» повесте, Ибраһим Салаховның «Тайгак кичү» роман-хроникасы, Зөлфәтнең «Шундый чагы әле җанымның» исемле шигырьләр циклы дөнья күрде.



Рифат
Сәлах

# ҖИҺАННЫҢ БАР ЯКТЫЛЫГЫ ҮЗГӘ...

## Таш өстендә үскән куаклар

**Күңел рәсемемә һәрчак шулай,
Сеңеп калыр инде бу яклар.
Таш кыядан миңа карап тора
Таш кыяга үскән куаклар.**

**Берни каралталмас күңел тулы,
Азатлыкның якты кояшын.
Таш кыяга ныгып үскән куак
Югалтмаган икән кыйбласын!**

**Күр, могҗиза —
Аллаһ могҗизасы,
Бер гыйбрәт бу аңлый алганга.
Башны ию кирәк түгел икән
Таш өстендә генә калсаң да!**

**Ашың булса әгәр,
Башың булса
Күкләреңдә аең бер калкыр.
Үзебез дә илсез-җирсез килеш
Таш өстендә үскән куактыр!**

## Яшел күзле яз

**Язны эзлим... Түбәләрдә кояш,
Яз сулышын бөрки кояш үзе.
Сусаганмын ахры яшеллеккә,
Яз һәрвакыт була яшел күзле.**

**Алмагачлар көтеп ала язны,
Озак тормас, шытар яшел бөре.
Челтер-челтер тамчы тама өстән
Сафландырмак булып яшьлегемне.**

---

Рифат СӘЛАХ (1987) – *шагыйрь; «Күңел бөртекләре», «Яшел ай», «Ташта үскән гөлләр» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

Күк түрендә фирүзәдәй болыт,
Наратлары гүя яшел үзән...
Алмагачлар әрнеп миңа карый —
Ниләр көтә алар яшел күздән.

Чагылдыра кояш күзләремне.
Сагындыра офык, билгесезлек.
Язны эзлисеңдер... Аңлыйм, аңлыйм:
Яз һәрвакыт була яшел күзле.

## Ялгышларым

Бөтен дөньям сихерләнгән кебек...
Өзгәләнәм, әрним, үртәләм.
Кинәт кенә бер елмаеп көлеп
Кем коткарыр мине бу хәлдән.

Таныш түгел дөнья күз алдымда.
Дөрес эшлим, диеп ялгышам.
Мең хатадан дәва табармынмы,
Төшеп калмас өчен тормыштан.

Бу бөтенләй дөм караңгы төннәр!
Ак төннәрем үткән, югалган.
Төзек язмышыма тагын кемнәр
Бер мәгънәсез тынлык юраган.

Аңлый алмыйм... Дөнья үзгә хәзер..
Дөнья хәзер башка — төссез гамь.
...Ялгышларым, ахры беркайчан да
Аерыла алмам мин сездән.

***

Бу төннәрнең серлелеге бездә.
Син эзләмә якын-тирәдән.
Безнең өчен генә нур бөркелә
Чык тамчысы төшкән үләннән.

Бу төннәрнең серлелеге — бездә,
Син тоясың аны, дикъкать ит.
Башын ия гөлләр һәрбер эзгә,
Ул эзләрдә безнең бергәлек.

Син бөтенләй башка төрле бүген,
Керфегеңә кунган бөтен сер.
Йә, елмайчы, бер генә кат үбим,
Иреннәрең нурга күмелсен.

Бу төннәрнең бөтен сере бездә,
Йолдызлар да, ай да безнеке.
...Җиһанның бар яктылыгы үзгә...
Ә кайчандыр җилләр үз иде.

## Күзгә ямь

Миңа багышлап иң изге
Догаңны укы гына.
Карашымда берни дә юк —
Күземдә йокы гына.

Синең дә мондый халәтне
Тойганың бардыр инде.
Юлларымда — сары яфрак,
Күз тулы яңгыр инде.

Син мондый урамда ямь дә
Тапмавың гаҗәп түгел.
Ә мин тоташ гүзәллектә —
Табигать гаҗәп бүген!

Бу яктылык күренәдер
Сиңа да. Кара инде.
Дөнья ямен күрмәүчегә
Сагышлар кала инде.

## Үзгә балачак

Ишегалды. Сары яфрак.
Томан. Таган. Балачак.
Кемнәрнеңдер сабый чагы
Шулай истә калачак.

Ә безнең балачак бүтән,
Башка иде хыял, җир:
Киң урамнар. Елга-күлләр,
Таулар. Таган. Туган ил.

## Үзе генә белгән

Урам тулы гөрләвекләр ага...
Бөтен гавәм тулы яз бары!
Кар суыдай эреп бетәрме бер
Күңел язы, сөю назлары.

Мин берьялгыз...
Бу гавәмдә ялгыз!
Бу — сәмави хисләр, моң яңа!
Һәркем үзе генә яшидер ул,
Үзе генә белгән дөньяда!

## Сагынам...

Сагынам мин сине өр-яңадан...
Элеккечә түгел, башкача.
Синең йөргән эзләр очрый миңа,
Ә күзләрең миннән... Аһ, кача.

Синең арттан йөгерәсе иде,
Белсәм юлың каян үткәнне.
Әкияткә алып кайтыр идем,
Син сагынып идең... Үткәнне.

Эх, күңелең синең!.. Белсәм иде –
Ниләр уйлап, барсын ташлавың.
Син булмагач, моң да, хисләр дә юк,
Мин башкача яши башладым.

Алларыңнан синең үтәр идем,
Китәр идем, әгәр теләсәң.
Бу дөньяда ничек яшим соң мин
Синең яшәвеңне белмәсәм?

## Сау бул!..

Гомергә ялгыз калдырып
Китүләр җанга авыр.
Мин ул дөнья, кырыс дөнья...
Гомергә китәм, сау бул!..

Мәңгелек булмас мәхәббәт
Бер сүнсә нәрсә гаҗәп?
Сиңа авыр. Үземә дә.
Күңелгә генә рәхәт.

Күпме алданган гомерең...
Алданган икән мин дә.
Озын гомер насыйп булсын
Киләчәк сөюеңә.

Гомергә китәм. Исән бул!
Дәшмичә калу авыр.
Яраттым. Артык яраттым.
Һәм китәм синнән. Сау бул!

---

## Электрон почта да төпсез түгел

**Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кульязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.**

**Хатлар исә, жинел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.**

**Редакциянең электрон адресына фәкать кечкенә күләмдәге язмалар (хатлар, документлар, фикерләр һ.б.) гына кабул ителә.**

**Электрон адреска күләме 5 биттән арткан язмалар жибәрелгән очракта, почта аша аның оригиналын (кәгазьгә басылган вариантын) алгач кына әсәр кабул ителгән санала.**



Рашат Низами

# СҮЗГӘ — МӘРХӘБӘ!

ЭССЕ

*Җирдә тагын бер могҗиза яши:*
*Үтеп туфрак, еллар аркылы, —*
*Безнең көнгә кадәр килеп җиткән*
*Китап сүзе, кеше акылы.*

## Автордан

*Мин фән кешесе түгел, галимлеккә дәгъва кылмыйм. Бу хезмәтемә исә озак еллар буе бөртекләп әзерләндем. Аның бер селтәнүдә барып чыкмаслыгы миңа көн кебек ачык иде. Шунлыктан, кулымнан килгәнчә һәм хәл кадәри эзләп тапканча, махсус сайлап диярлек, бик күп әдәбият (фәнни, философик, публицистика, трактат, афоризмнар) укыдым, карашымны киңәйттем, үземә кирәк булган фикер хәзинәләре тупладым.*

*Сүзләр, тел һәм телдәге сүзлек составы кайчан, ничек барлыкка килгән? Сөйләмебез сүзләрдән тора икән, кеше ничек, ни рәвешле, ни сәбәпле сөйләшә башлаган соң? Бик тә зур, галәми һәм борынгы сорау болар. Бер шагыйрь әйтмешли, әлеге сораулар «кагыласы итте миңа да...» Тынычлыгым качты. Кайчак төн урталарында сикереп торып, каләм һәм ак кәгазь өстенә ташлана идем. Шушы сорауларга җавап табу, мәсьәләгә үземнең карашларымны белдерү үҗәт бер максатка әверелде.*

*Каләм иясе буларак, бер дә курыкмыйча һәм икеләнмичә әйтәм: минем күзаллавымча, бу дөньяның яртысы диярлек сүзләр атомыннан да тора... Әйе, нәкъ шулай. Иксез-чиксез галәмдә Сүз планетасы да булган, бар һәм яши дип уйларга кирәк. Һәрбер система, хәтта абстракт төшенчәләр рәтендә булса да, әлеге системаны барлыкка китерүче нинди дә булса принципка нигезләнә. Ә принцип үзе каян килә? Бу сорауга минем җавап таба алганым юк әле.*

*Бу гаҗәп тә түгелдер: чөнки тормышта — кешеләр дә, фәндә - галимнәр дә җавапларга караганда сорауларны күбрәк бирә бит.*

*Сүз һәм сүзләр дөньясына сәфәр-сәяхәтебезне башлап җибәрик, укучым! Безгә бу сәфәрдә уйлану һәм бәхәсләшү, фикер чакмаларын чәкәштерү, ә бәлки әле яңа ачышлар ясар өчен дә мәйдан җитәрлек булачактыр. Чын ихластан бер теләгем дә бар: белемем җитмәү, яисә ашыгу-ашкыну сәбәпле, минем бу фәлсәфи уйлануларымда хаталар, уңышсыз урыннар да юк түгелдер; ул битләрне төзәтеп, тулыландырып укысагыз, моның өчен бары рәхмәтле генә булырмын.*

---

Рашат НИЗАМИ (1950) — *шагыйрь, прозаик; «Кызыл җәй», «Тормыш трамвае», «Җыр һәм мылтык» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

## 1. Сүзләр кайчан, ничек яралган?..

*Тел шикелле универсал*
*Бу дөньяда бер генә.*

Нури Арслан.

«Ничек яралган?» дигән сорауга җавап эзләргә керешкәнче, иң элек галиҗәнап сүзнең бер сыйфатына игътибар итик әле.

Без мәктәптә укыганда, өстән-өстән булса да, гравитация һәм Ньютон законнарын, Пифагор теориясен өйрәнгән идек. Эйнштейнның чагыштырмалык теориясе дә колакта эленеп калган. Менә хәзер, дөньякүләм танылган даһиларның әлеге ачышларын азмы-күпме яхшырак аңлаган кеше буларак, сүзгә бәйле рәвештә, аларны тагын бер кат күздән кичерәсе килә.

Гравитация — (латин сүзеннән) авырлык һәм тартылу дигәнне аңлата. Дөньялыкта үз-үзенә урын тапкан бөтен нәрсәләргә үзара тартылу көче хас. Кояш системасындагы барлык планеталар «парады» шушы канун белән яши һәм хәрәкәт итә. Бу бөек әйләнешнең (гигант карусель!) яктылык тизлеге белән бәйләнеше бар дип тә уйларга кирәк.

Чагыштырмалылык теориясе 1905 елда А. Эйнштейн тарафыннан нигезләнә. Андагы сан һәм формулаларга безнең (филологларның) көче җитә торган түгел. Кыскача һәм гади генә итеп әйткәндә, монысы да тарту-тартылу көченә бәйле. Әйтик, Кояш системасына кергән Җир билгеле бер сәгатьләр аралыгында кануни төгәл әйләнеш ясый — кояш тирәли дә, үз күчәре тирәсендә дә...

Боларны ни өчен аңлатырга азапланам? Чөнки, минем бик нык ышануымча, сүзләр дә үзара тартылу сыйфатына, ягъни бер-берсенә йогынты ясау — энергетика көченә ия. Алар, умарта күчедәй, бергә оешып, тупланып яши. Моны исбатлау кирәкмидер, моның шулай икәнлеге көн кебек. Халыкның әйткән гыйбарәсе дә нәкъ менә шуны раслый: «Сүз сүзне тартып чыгара». Бу гыйбарәне миңа әтием дә еш әйтә торган иде. Халыкта моның әле тагын да камилләшкән өч варианты бар: сүз арты сүз, сүз иярә сүз, сүз ара сүз.

Инде төп соравыбызга якын килик.

Бу сорауга Библия (Инҗил) бер җөмлә белән җавап бирә: «Иң әүвәле Сүз булган». Бу кыска, әмма искиткеч күпмәгънәле җөмләгә без әле алдагы бүлектә тукталырбыз.

Элегрәк мин: сүз иң әүвәле күктә, күкнең дә җиденче катларында яралган булырга тиеш, дип уйлый идем. Ә күктә... болыт, ай-кояш һәм йолдызлардан тыш, тагын ниләр бар соң? Дин аңлатуынча, Алла һәм аның фәрештәләре.

Сүз — бөек сер. Аның килеп чыгышы турындагы уй-фикерләрне, бу могҗизаи күренешне бары эволюцион үсештә, табигать һәм тормыш-яшәешкә бәйле рәвештә аңлатырга кирәктер.

Дөньяны сүзләр ярдәмендә аңлау-аңлату һәм үзләштерү — фәкать кеше психологиясенә хас нәрсә. Ни генә дисәк тә, кош-кортлар һәм хайваннар сөйләшә белми, нигәдер аларга мондый «талант» бирелмәгән. Күке әнә: «Күк-кү», әтәч: «Кикри-күк!» дигәннән ерак китә алмый. Ат пошкыра белә, арысланнар ырлый. Дельфин авазлар чыгара. Попугай исә кешедән откан берничә сүзне генә сакаулап әйтә ала...

Сүз кешедән башка тулы канлы, актив рәвештә яши алмый.

Сорау туа: мәгарәдә яшәүче, аның диварына яфрак яисә чакматаш ярдәмендә кыргый хайваннар сурәтен ясаучы борынгы бабаларыбыз (беренче рәссам!) аңа кадәр кайда яшәделәр икән? Маймыллар сыман, җиләк-җимешкә бай урманда, агач башындамы? Ихтимал, шулайдыр ул. Ут һәм яшеннән, ерткыч хайваннардан курку инстинкты аларны мәгарәгә «куып» керткән.

Беренче ымлык-авазлар...

Иң беренче сүзләр...

Алар кайчан барлыкка килгән?

Фантазияне уйнатсак, ташбалта һәм башка эш коралларын уйлап таба белгән борынгы кешенең аны ничек итеп сүзләрне дә уйлап тапканын күз алдына китерү кыен түгел.

Җилбәзәк яфраклар шавы... Төрледән-төрле кошлар авазы... Киекләрнең иркә туйлары... Тагын-тагын... Табигатьтәге мең авазлар — менә болар барысы да иң борынгы кеше күңелендә беренче авазларны, беренче сүзләрне барлыкка китерүгә сәбәп булган, булышлык иткән. Иң башта ымлыклар, мимика, аннары «чиле-пешле» беренче сүзләр ярдәмендә кеше дөньяны танып-белүгә таба акрынлап гигант адым ясаган. Әлеге дә баягы, ул хаос хәлендә яшәп яткан күренешләр һәм вакыйгаларга сүз ярдәмендә үзенең мөнәсәбәтен белдергән. Ә инде минутлар, сәгатьләр, еллар һәм киләчәк турындагы белемнәрен билгеле бер тәртипкә салу турында әйткән дә юк.

Иң борынгы кешене күпмедер дәрәҗәдә яңа туган сабый белән чагыштырырга мөмкин. Сабый туа, үсә башлый. Яше тулыр-тулмаста әле юньләп сөйләшә дә белми. Дөньяны, тирә-юньне танып-белү нәтиҗәсендә, ул әкренләп беренче сүзләрне әйтә башлый. Гадәттә, аның иң беренчеләре безнең өчен «әттә, әннә» була. Әнә шулай сөйләшергә өйрәнеп китә ул, сүз байлыгын арттыра, телен чарлый.

Менә үзебезнең гаиләдән бер мисал.

Ике-өч яшьлек оныгым Әмир теләсә кайсы машинаны «бибикә» (неологизм!) дип кенә җиббәрә иде. Аның кычкыртуын, сигнал бирүен истә калдырып булса кирәк. Төрле бала төрлечә бит ул. Ә менә өлкән оныгым Камил өч-дүрт яшендә үк инде 15 ләп автомобильнең маркаларын төп-төгәл әйтеп бирә иде: «Лада», «Ока», «Мерседес», «Ауди», «Тойота» һ.б. Ул кечкенәдән машиналар белән җенләнде. Ә менә Әмир өчен «гамун» (гармун) һәм «бж-ж...»лар (кер юу машинасы) якынрак иде.

Яңа туган бала бернинди сүзне дә, хәрефне дә белми, авазларны да юньләп аермый әлегә. Әмма... өлкәннәргә, әти-әнисенә һәм тора-бара үзенең ишләренә карап, конкуренция инстинкты һәм яхшы мәгънәсендәге көнләшү аны бүтәннәрдән калышмаска, хәтта «беренче» булырга өнди, алга чакыра...

Күз алдына китерик: иң зирәк, иң акыллы «гомосапиенс» та иң беренче авазларны, сүзләрне әйтә башлаган икән, ул үзенең кан кардәшләрен уздырырга, беренче булырга тырышкандыр. Ташбалта, яисә беренче эш коралларын уйлап тапкан шикелле, сөйләшергә өйрәнгәндә дә ул үзендәге «мин» өчен аңнан тыш та, ягъни биологик инстинкт буенча да көрәшә белгән.

Борынгы бабаларны сөйләшергә кем өйрәткән соң? Иң борынгы кешеләр тиктомалдан гына сөйләшеп китмәгән, әлбәттә. Табигатьтәге күк күкрәү, яшен яшьнәү кебек дәһшәтле күренешләр аларны куркуга салган... Бөтен нәрсәне кырып сала, пешерә һәм яндыра торган ут галәмәте дә аларны уйланырга, «баш ватарга» мәҗбүр иткән. Бу күренешләргә карата ул иң борынгы чорда билгеле бер авазлар, ымлыклар, интонация һәм мимика белән шулай ук үзенең мөнәсәбәтен белдергән...

Сүз әйтәсе килү куәсе борынгы бабаларыбызның канында әнә шулай гел «уйнаклап» торган. Ә сүзгә ерак әле... Менә шуңа да ул мәгарә һәм кыя ташларына уеп (неолит чоры) төрле сурәтләр ясаган. Бу, һичшиксез, беренче аваз һәм ымлыкларның сурәт рәвешендәге кайтавазы, сүзләрне уйлап табудагы бөек талпыныш, бөек ачыш булган!

Безнең Эрага кадәр яшәгән философ Геродотның таң калырлык язмалары бар. Халыкара сугышлар тарихын язып калдырган хезмәтендә менә мондый гыйбрәтле юллар бар: «Скифлар Дария патшага кош, тычкан, бака һәм биш

ук сурәте төшерелгән «хат» юллыйлар. Мәгънәсе болай: әгәр персианнар кош кебек оча белмәсә, тычкан кебек җир астына качар әмәлен тапмаса, бакалар сыман тумгәктән тумгәккә сикерә белмәсә, — скифлар аларны ук ярдәмендә һәлак итәчәк, янәсе...

Мондый да дипломатиянең тарихта булганы бар микән?!

Шулай итеп, иң борынгы кешеләр ым аша, рәсем-сурәтләр, аннары инде сүз һәм сөйләм аша тирә-юньгә үзенең мөнәсәбәтен белдергән.

Астрономнар булмаса, йолдызлар яшәр һәм яктырыр идеме соң? Һичшиксез, беркемгә бәйле булмыйча, яши бирерләр иде. Ә менә кешеләр тумаса, аларның аңы булмаса, сүзләр нишләр иде икән? Юк, алар бөек әйләнешкә кермәс, бары абстракт шәүлә рәвешендә һавада «очып» йөрерләр иде. Кешелек җәмгыяте, озын-озак Эволюция спирален кичеп, сүзләр хәзинәсен акрынлап баеткан, тел, милләт, цивилизация кебек бөек казанышларны тудырган, аларны билгеле бер кануннар рәвешендә калыплаган, эзгә салган.

Тел генә түгел, саннар белән дә шулайрак. Математиклар барлыкка килгәнче үк, саннар мириадасы вакыт һәм пространство кинлегендә алдан ук планлаштырып куелган алгоритм рәвешендә яши биргән. Кеше аңы, кеше акылы менә шушы сүзләр һәм саннар хаосын билгеле бер тәртипкә салган, фәнни һәм гамәли кулланылышка кертеп җибәргән. Әйтик, фән буларак, тел белеме үзе генә дә әллә ничә тармакка бүленә: лексика, грамматика, синтаксис, морфология, диалект, фразеология һ. б.

Сүздән һәм саннардан аермалы буларак, йолдызлар әнә предмет, чынбарлык рәвешендә яши. Аларга карап, безнең борынгы бабайлар иң матур, шигъри исемнәрне уйлап таба белгәннәр дә соң! Киек каз юлы, Җидегән йолдыз, Казык йолдыз, айдагы Зөһрә кыз... Менә шуларны уйлый торгач, «Күктә — татар галәме» дигән шигырь дә язган идем. Аның бер генә куплетын сезнең игътибарга тәкъдим итәм:

Җидегән йолдыз көлемсери
Җиде чатка нур чәчеп.
Миллион яшьлек бу йолдызлык
Үз телендә әйтеп бирсен
Татар кауменең яшен!..

Моның белән татар бабаларыбызның бик борынгы нәсел икәнлеген ассызыкларга тырыштым.

Минем ышануымча, сүзләрнең «чишмә башы» юк. Алар мәңге булган, алда әйткәнебезчә, хаос хәлендә дә, кристаллашып та телсез-өнсез килеш галәмдә яшәгән һәм оеп яткан. Әнә, ноталар барлыкка килгәнчегә кадәр үк, музыка булган ич...

Галиҗәнап сүзнең могҗиза икәнлеген бер дә икеләнмичә һәм иң югары ноталарда авыз тутырып әйтергә мөмкин!

## 2. Ач сереңне, илаһият!..

*Әгәр Алла булмаса,*
*аны уйлап табарлар иде.*
Лев Толстой.

Коръәндә сүзнең килеп чыгышы турындагы сүрә яки фикерләрне очратканым булмады минем. Ә менә Әнгам (терлек) сүрәсе, Тәүбә сүрәсе, Нух сүрәсе, хәтта Ай һәм Кырмыска (нәмел) сүрәләре һәм башкалар — барлыгы 114 сүрә бар...

Библия исә (Инжил): «Ин әүвәле сүз булган...» — дип аңлата. Бу җөмлә мине тәмам әсир итте. Чөнки ул минем, Галәмдә Сүз планетасы булган, дигән фаразыма шактый туры килә. Ә инде җөмләнең дәвамын укыгач, күңелдә күп кенә сораулар, икеләнү-шикләнүләр туды. Әйе, «Бу сүз — Алла», — диелгән иде аның дәвамы.

Мин алдагы бүлектә сүзләр мириадасының эволюцион яралышын исбатларга омтылган идем ләбаса. Юк, минем һич кенә дә диннәргә, Аллаһыга тел-теш тидерергә уйлаганым булмады. Сүзгә, аның килеп чыгышына карата үз фикерем оешкан икән, минем бу хакта язып чыгарга, шәт, хакым бардыр.

Диннәрнең начары юк (тәре походларын искә алмаганда). Безнең Ислам дине дә, башка традицион диннәр кебек үк, элек-электән кешеләргә диндарлык рухын сеңдерә һәм якыннарга булган хөрмәтнең, әхлакның мәңгелек кыйммәтләрен ирештерә. Әлеге кыйммәтләр төрле милләтләр һәм башка халык вәкилләре белән уртак тел табарга, бер-берсен аңларга ярдәм иткән.

Үзебезнең Коръәнгә, аның сүрә һәм аятьләренә игътибар итик әле. Сез анда бер-бер начарлык яисә тәкъвадан тайпылу сүзләре табарсыз микән?.. Киресенчә, Коръәннең барлык битләре гуманизм һәм яхшылык, яктылык нурлары белән сугарылган. Ислам дине безгә мөселман өммәтендәгеләрнең күңеленә фәкать яхшылык орлыклары чәчәр өчен дөньяга килгән. Аерым алганда, ул безне гадел һәм шәфкатьле булырга, урлашмаска, көнләшмәскә, гайбәт сөйләмәскә, байлыкка табынмаска, кешеләрне һәм якыннарыңны түбәнсетмәскә, хәмер эчмәскә, күңел сафлыгына, тагын-тагын әнә шундый бик күп уңай сыйфатларга ия булырга өнди һәм чакыра. Вәгазь сөйләүче дин әһелләре безгә боларны бик тә үтемле, тәфсилле итеп аңлата.

Кыскасы, Ислам дине халкыбыз өчен элек-электән әхлак һәм тәрбия мәктәбе булган. Татар халкын, тарихта ул ничаклы тетрәнүләр һәм һәлакәткә дучар ителмәсен, милләт буларак аны туган телебез һәм дин саклап калган — бу хакта һәммәбезнең күп тапкырлар ишеткәне һәм укыганы бар.

Менә шуңа күрә дә сакалбай Маркснын: «Дин — халык өчен әфьюн ул», — дигән сүзләре белән берничек тә килешә алмыйм. Бу — хата фикер. Хәтерлим: без мәктәптә укыганда коридорның бер почмагындагы плакатка бу җөмлә эре хәрефләр белән язып куелган иде. Без ул чакта бу сүзләрнең асыл мәгънәсенә төшенерлек дәрәҗәдә түгел идек, билгеле.

Инде алдагы фикер сөрешен дәвам итсәк, Сүзме беренче, әллә Алламы беренче булган? дигән сорауның тууы бик табигый.

Бу уңайдан үзеннән-үзе «Тавыкмы, әллә йомыркамы беренче туган?» дигән сорау искә төшә. Дөньяда мәңгелек бәхәс бара, әмма... әлеге четерекле сорауга ни галимнәрдән, ни динчеләрдән берәүнең дә җавап бирә алганы юк әле.

Аллага ышану яки ышанмау бик борынгыдан, элек-электән килә. Динчеләр катгыян (догма) рәвешендә Алла бар дип аңлата. Иллюзионистлар һәм фокусникларның, хәтта вулканнарның да серенә төшенеп була. Ә менә кешелек аңында могҗиза булып яшәп килгән илаһи Алланың серенә төшенү һич мөмкин түгелдер. Чөнки дин тәгълиматы аңлатуынча, ул — кеше кыяфәтендә түгел, аны күрергә бернинди күзнең көче-колачы җитмәс, ул абсолют яшәешкә ия, шуңлыктан һәрдаим бар, булачактыр...

Бабам Низаметдин авылыбыз мулласы иде. Әбием Гайшәбикә, абыстай булмаса да, дини китапларны үзендә саклаган һәм укыган булса кирәк. Аның болай дип әйткәннәре хәтеремдә: «Бу дөньядагы барлык нәрсәләрне Ходай Тәгалә яраткан. Ходай үзе уңда да, сулда да түгел, аста да, өстә дә түгел, ул тирә-юньгә, һәр тарафка бөртекләп, күзгә күренмәслек булып чәчелгән...»

Хәзер уйлыйм: авылда яшәп ятса да, минем әби үзенә күрә бер философ булган!

Бөек акыл ияләреннән Платон, Сократ, Әбугалисина, Ньютон, Гегель Алланың барлыгына ышанганнар — язылган-әйткән уй-фикерләре шуны раслый. Ләкин, фантаст язучы Адлер Тимергалин аңлатканча, «галимнәрнең фәнни тикшеренүләре аларның иманы һәм ышануларыннан аерым яши». Ягъни аларның фәнни шөгылендә дин йогынтысы чагылмый...

Материалистлар исә Алланың барлыгын танымый. Дөньяның башы һәм ахыры юк дип, үзләренең гипотеза һәм фаразларын алга сөрәләр. Аларның үз аршины. Фән «дөньяның Алла тарафыннан яратылуын» кабул итәргә теләми. Кыскасы, ике якның ызгышларсыз, тын гына барган көрәше-тартышы бүгенгәчә дәвам итә.

Аллага ышану яки ышанмау һәркемнең үзеннән, шәхси карашыннан тора диярлек. Мохитнең, тәрбиянең һәм социаль-иҗтимагый фикерләр ташкынының йогынтысы да юк түгел. Совет заманында Ишмөхәммәтов кебек уртакул һәм өстәгеләр җырын җырлаучы галимнәр тырышып-тырышып Тукайдан атеист ясарга керештеләр... Үзгәртеп кору җилләре исә башлагач кына «бәләкәй Апуш»ның тыелган күп кенә шигырьләренә юл ачылды:

> Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!
> Рәхмәте бик киң аның, һәрдаим таян син Аллага!

Шагыйрьләрнең дә төрлесе бар. Илһамланудан үзен күккә чөеп, үзенең гайрәтен күрсәтергә теләптер, «Мин» дигән шигырендә Сәгыйть Рәмиев әнә нинди дәһри юлларга хәтле «барып» җитә:

> ...«Мин!» дидисәм,
> Миңа зур бер көч керә,
> Аллалар, шаһлар, кануннар
> Булалар бер чүп кенә!

Мәҗит Гафури үзенең бер шигырендә «Юктырсың ла, Алла!» — дип, аның барлыгын шик астына алмакчы була. Эчтәлек белән тулаем танышканнан соң аңлашыла: әдипнең канкойгыч сугышларга, тормыштагы гаделсезлекләргә кискен протест белдерүе бу...

Тагын бер гаҗәп мисал — буддачылар, гомумән, Алланы танымый икән.

Узган ел дөньякүләм танылган язучы һәм философ Чыңгыз Айтматовның Норвегиядә язылган «Таулар авышканда» («Когда падают горы») дигән өр-яңа романын укып чыккан идем. Андагы баш герой, журналист Арсен Саман үзенең бер мәкаләсендә менә ниләр яза. Мәгънәсе бозылмасын, төгәл бирелсен дип, аны оригинал телендә бирәм:

«Слово выпасает Бога на небесах, Слово доит молоко Вселенной и кормит нас тем молоком из рода в род, из века в век. И потому за пределами Слова нет ни Бога, ни Вселенной и нет в мире силы, превосходящей силу Слова, и нет в мире пламени, превосходящего жаром пламя и мощь Слова».

Мин бу сүзләрне сокланып, көнләшеп, гаҗәпләнеп һәм шатланып укыдым! Көнләшеп дигәнем — «без бу кадәр дә колачлы, образлы, фәлсәфи тирәнлек, нәфис тел белән яза алыр идек микән?» дигән сорауга бәйле рәвештә, билгеле. Шатланып дигәнем — бередәге төп фикер, әлеге дә баягы, минем «Галәмдә Сүз планетасы булган» дигән фаразыма тәңгәл килә диярлек. Мактану дип кабул итмәсәгез иде: әмма татар канлы өлкән әдипнең әлеге фикере (теория дияргә дә була) татар канлы оныгы фикере белән

мәгънәсе ягыннан якынча туры килә икән — мона ничек шатланмыйсың ди! Моны үзеннен татар булуың белән ихластан горурлану дип тә аңларга кирәк.

Журналист Арсен мәкаләсеннән өзек, дидек. Ә дөресрәге, Айтматов үзенең бу персонажын өлешчә резонёр сыйфатында файдаланган. Ягъни роман авторы үз фикерләрен, әйтергә теләгән сүзләрен укучыга аның аша житкерә... Әдәбият тарихында моның мисалларын күпләп табарга мөмкин. Ә бу отышлы алым. Әгәр персонаж аша түгел, автор үз теле белән әйтеп-сөйләп бирсә, әлеге сүзләрнең асыл мәгънәсе ничектер бүтәнчәрәк кабул ителер иде.

Минем үземә студент чаклардан ук инде пантеистлар тәгълиматы якын. Алар өчен барча табигать — үзе Алла. Аларның принцибы буенча, «Дөньяда бар булган бөтен нәрсә — Алла үзе». Димәк, Жир, Кояш, Галәм — могжизага тиң илаһи күренеш, ә галижәнап Вакыт өчен — кичә, бүген, иртәгә дигән төшенчәләр юк...

Дин тәгълиматы өйрәткәнчә, әгәр Алла бөтенесен эшли ала икән, нигә ул сугыш һәм кан коюларга юл куя, кешеләргә — үзенең газиз балаларына Жир тетрәүләр, су басулар, жимергеч өермәләр юллый?.. Бу сорауларга төпле җавап бирүче әүлия заты бар икән, күрсәтегез миңа ул кешене...

Язмыш, тәкъдир, ләүхелмәхфүз тактасы дибез. Бу серле-тылсымлы тактага очраклы (!) хәлләр дә теркәләме? Әгәр чынлап та бар икән, ләүхелмәхфүз тактасын кирәк кадәренчә гуманистик рухта язып-үзгәртеп булмый микән? Бик текә, хәтәр, четерекле сораулар. Җавапларын үземнең дә табып бетергәнем юк әле.

## 3. Сүзгә кадәр ниләр булган?..

*Аң шикелле, тел дә*
*бик борынгылардан.*

Карл Маркс.

Чыннан да, Жир планетасы, тереклек иясләре, борынгы кеше кавемнәре кайчан барлыкка килгән соң? Боларны азмы-күпме ачыкламый торып, без сүзләр планетасына якыная алмабыздыр.

Кояш системасындагы планеталарның килеп чыгышын һәм эволюциясен өйрәнүче галимнәр галәм дөньясы, моннан 15–20 миллиард еллар элек, коточкыч шартлау нәтиҗәсендә барлыкка килгән дип аңлаталар. Кояш системасы соңрак формалашканга күрә, без яшәгән Жир шарының гомере 8 миллиард булуын исәпләп чыгарганнар. Бу саннар якынча, билгеле. Шартлауга кадәр ниләр булганын хәзергә фән төгәл генә әйтеп бирә алмый. Бу мәсьәләгә хәтта физиклар һәм астрономнарның да «теше үтми». Шунысын да әйтик, бүгенге заман фәне «дөньяның илаһи көч тарафыннан барлыкка килүе» дигән дини догматлардан ерак тора. Алар уйлавынча, мондый догматка таяну җиһандагы катлаулы күренешләрнең асыл мәгънәсен ачарга комачау итәчәк.

Тереклек өчен кирәкле булган су, һава, кислород ничек барлыкка килгән? дигән сорау куелса, шуны әйтергә мөмкин: болар хакында фәндә гипотезалар байтак һәм аларның күбесе — ышандырырлык. (Мин аңлы рәвештә бу өлкәгә кереп тормыйм, безнең бит тема башка).

Югары фикерле башлаган адәм кавеменең килеп чыгышы турында беренче бүлектә шактый әйтелде. Боларга өстәп, тагын кайбер фикерләрне дәвам итик әле.

Мәктәптә укыганда ук безне, кеше маймылдан килеп чыккан, дип өйрәттеләр. Дарвинның бу сәер һәм бик тә контраст теориясендә шактый

дөреслек бар шикелле. Күз алдына китерик: агач башыннан төшкән «маймылсыман кеше» ... тураеп баскан, кулына таяк алган, эш кораллары ясарга керешкән. Мәгарәсен ташлап, төрле бамбук-агач ише нәрсәләрдән шалаш, корылма төзү һөнәренә өйрәнгән һ. б.

Хезмәт белән шөгыльләнү аларның карашын һәм уйлана белү горизонтларын киңәйткән. «Акыллы кеше», агачтан агачка сикерүче маймылдан аермалы буларак, табигатьтә һәм тормыштагы күренешләргә, шулардан алган тәэссоратка карата сүзләр уйлап табып, үзеннән «мин» дигән кисәкчәне дә кушкан. Иң беренчел сүзләрне уйлап тапкач, аның аңы-акылы да яхшырак үсеш алган, баш мие дә фани дөньяны танып-белүдә үзенең функцияләрен киңәйтә барган. Шатлык яки нәфрәт, соклану яки иситмәү, мәхәббәт яки дошманлык... Шуның кебек капма-каршы категорияләр хиссияте сүз һәм тасвирлама сораган, билгеле. Кеше дөньялаша барган саен дөнья үзе дә «кешеләшә» барган.

Тарих тәгәрмәче алга таба әйләнмәктә...

Булачак цивилизация үзенең беренче җимешләре белән тарих сәхнәсенә күтәрелә башлый...

Гаҗәеп факт: атаклы шумерлар безнең эрага кадәр үк инде чөйязмалар белән эш итә башлаган... Рәсемнән — авазларга, аннары сүзләргә күчү процессы әнә шулай гасырдан гасырга дәвам иткән, кешелекнең үсешен чарлаган, киләчәкнең яңа капкаларын каерып ачкан.

Гасыр һәм җир катламнары арасыннан табылган данлыклы Фест дисбесе дә чөйязмалар рәтенә керәдер. Ул фәкать шартлы тамгалар тезмәсеннән тора. Безнең күренекле язучыбыз, тарихи романнар авторы Нурихан Фәттах аны, сүтеп-җыеп дигәндәй, үзенчә «укып-шәрехләп» чыкты, әйләнмәле тарихи бу түгәрәк төрки кабиләләр кулы белән язылган дигән фаразны алга сөрде. Н. Фәттахның бу күләмле язмасы заманында иң элек «Казан утлары» журналында басылып чыкты. Аның бу кыю язмасын укып күпләр шатланды. Кемнәрдер моңа шикләнеп һәм тәкәбберләнеп карады (бар бит бездә көнләшеп яисә теләсә нинди яңалыкны кире кага белүчеләр!). Тыючы юк бит, алайса бүтән галимнәр яисә филолог-белгечләр үзләренчә укып карасыннар тарих төпкеленнән табып алынган бу археологик табышмак-дисбене. Хакыйкать шунда табылыр...

Фест дисбесе, һичшиксез, сүзләр әйтергә теләүдән туган таш китап. Аның ватылмыйча-имгәнмичә тәгәрәп безнең көннәргә хәтле килеп җитүе — үзе бер могҗиза!

Дарвин дигән идек... Соңгы елларда ничектер аның гасырлар сынавын узган тәгълиматына каршы фикер-гипотезалар калкып чыга башлады. Нәрсә, Дарвин бабай хаксыз булды микәнни? Боларның кайсысына ныграк ышанырга...

Төгәл хәтерләмим, кайсыдыр газетада: маймыллар... кешедән килеп чыккан, дигән фаразны укыгач, бу мәсьәлә белән кызыксынган кеше буларак, мин бик тә гаҗәпләнеп калдым. Юк, бу — укучыны җәлеп итәр өчен уйлап чыгарылган «кайнар» мәкаләгә охшамаган иде. Авторларның үзләренчә исбатлары да бар: янәсе, ниндидер сәбәпләр аркасында, борынгы заманда кешеләрнең бер өлеше урман һәм джунглиларга барып сыенган, агач башларына үрмәли башлаган, кыргыйлашкан, тәмам йөзен дә, яшәү рәвешен дә үзгәрткән...

Бу урында сирәк хәлгә, әмма тормышта булган фактка тукталып узасы килә. Ялгышлык белән бүре өненә эләгеп, шунда үскән сабый бала ирексездән бүреләр холкын үзләштерә, хәтта дүрт аякта мүкәләп йөри башлый. Алар белән табын уртаклашып, чи ит ашарга да өйрәнә. Әгәр кешеләр арасына әйләнеп кайта икән, ул барыбер кешечә сөйләшә

һәм фикерли алмый. Чөнки «бәләкәй маугли» бүре өнендә яшәгәнгә һәм янәшәсендә үзе кебек яшьтәш малайлар һәм өлкәннәр булмаганга күрә, сөйләшергә өйрәнү өчен үрнәк тә, биологик конкуренция (көнләшү) инстинкты да «эләкмәгән» анарга...

Янадан сорау куясы килә, чыннан да, Дарвин бабай буталмады микән? Чөнки котсыз-ямьсез, шәрә артлы маймыллардан шундый да матур йөзле, нәфис-камил гәүдәле кеше заты килеп чыгуына ышану шактый кыен...

Күптән түгел Кения археологлары өр-яңа табылдыкларга, дөресрәге, ин борынгы кеше сөякләренә тап була. Шуларга нигезләнеп, алар борынгы бабаларыбызның ырудан-ыруга, нәселдән-нәселгә берсен-берсе дәвам итүләрен, бердәнбер уртак «шәҗәрә» агачына ия булуларын шик астына куя. Аларның табылдыклары «эш белүче кеше» белән «туры басып йөрүче кеше»нең 500 мең еллап янәшә яшәгәнлекләрен раслаган. Янәшә диярлек яшәсәләр дә, кешелекнең бу ике тармагы икесе ике төрдән (инде башка галимнәр фаразынча) якынча моннан 2—3 миллион ел элегрәк яшәгән уртак бабадан килеп чыккан. Логика, мантыйк бар шикелле. Ә менә уртак баба дигәнең кем ул — фәнгә әлегә билгесез. Әгәр уртак бабаның, чыннан да, булганлыгы якын киләчәктә нигезле итеп расланса, бүгенге антропология фәнендә йөз сиксән градуска борылыш ясалырга мөмкин.

Британия антропологлары «акыллы кеше»нең пәйда булу вакытын һәм урынын ачыклаган. Аларнын нәтиҗәсенә караганда, тышкы кыяфәте ягыннан бездән әлләни аерылып тормаган homo sapiens моннан 200 мең еллап элегрәк Африкада пәйда булган. Анын бүтән кыйтгалар буйлап таралуы исә күпкә соң башланган.

Монысы нык ышандыра. Чөнки Африка континентында яшәү шартлары Европадагыга караганда күпкә яхшырак булган. Бу — иң элек кулаякларның турайтылуына ярдәм иткән йомшак климатка бәйле. Аннары инде, планета буйлап тарала башлагач, борынгы бабаларыбыз шундагы табигать шартларына бәйле рәвештә Африка геннарын акырынлап җуя барган...

Хөрмәт катыш сокланамын: галимнәр һәм археологларның хезмәте энә белән кое казуга тиң ләбаса!

Бүлекнең азагын кызыклы гына бер чагыштыру белән тәмамлыйсы килә. Сүзебез — керамика турында.

Керамика (грек сүзеннән алынган) — Җирдә билгеле булган иң борынгы казылмаларның берсеннән санала. Беренче керамик әйберләр яна Эрага кадәр биш мең еллар элек, ягъни таш гасырга аяк баскан чорларда ук күренә башлый.

Көнбатыш Германиядә чыга торган фәнни-популяр «Гео» журналы 1987 елны «Таш гасырга әйләнеп кайту» дигән мәкалә бастыра. Анда мондый юллар да бар: «Материалларны куллану җәһәтеннән кешелек тарихы таш, бронза һәм тимер гасыры дигән чорларга бүленә. Безнең заманны атом гасыры дип атарга күнеккәнбез. Ә менә алдагы эпоханың керамика гасыры дип аталуы бик ихтимал».

Беренче карашка бик сәер шикелле, шулай бит? Әйдәгез, хыялны эшкә җигеп, таш гасыр башына күз салыйк... Кызыл үзле балчыкның йомшаклыгы кешеләргә бик борынгыдан билгеле булган. Әнә шундый үзле балчык кәлҗемәсен учак өстенә (беренчеләрдән!) элеп куярга уйлаган кеше үзенең бер дигән материал уйлап тапканын, ерак киләчәктә анын киң таралачагын белми дә калгандыр, билгеле. Йомшак һәм төрле рәвешкә бөгелүчән үзле балчык утта «пешкән»нән соң каты ташка әверелгән. Яндырылган балчыктан ашар һәм азыкны саклар өчен савыт-саба ясаганнарын күз алдына китерү кыен түгел.

Бу урында университет студентларының яраткан мөгаллиме, язучы Мөхәммәт Мәһдиевнең лекциядә сөйләгән бер детален искә төшерүне кирәк саныйм.

— Борынгы кешеләрнең берсе итле сөяк кисәген ялгыш учак өстенә төшереп җибәрә. Учак сүнгәннән соң алып-татып караса, пешкән иттән дә тәмле нәрсә юк икән! Кешеләрнең чи иттән пешкән иткә күчүе әнә шулайрак башланган...

Мөхәммәт абыйның үзе уйлап чыгарган фантазиясе булгандыр бу, бәлки, әмма дөреслеккә бик тә мач килә. Бу деталь минем хәтердә нык уелып калды. Борынгы заман, борынгы кешеләр белән кызыксынуым нәкъ менә шуннан соң башланды түгел микән әле?

Ярый, әйләнеп кайтыйк яңадан керамикага.

...Бүгенге керамиканы фаянс чынаякка яисә иң тупас кирпечкә генә кайтарып калдырып булмый. Менә кыскача гына кайбер мәгълүматлар: төрле кушылмалар белән ясалган заманча керамикалар атом электростанцияләрендә, термоядер синтез аппаратларында кулланыла. Космик корабльләр атмосфераның тыгыз катламнарына үтеп кергәндә аларның корпусын керамик капламалар саклый. Керамика шулай ук самолет, прибор төзелешләрендә, электроника һәм промышленностьның башка тармакларында кулланыла.

Менә шуның шикелле, ым һәм төрле ымлыклардан, авазлардан башланган беренче сүзләр тора-бара камилләшә, шомартыла, үзенең «таблица»сын таба, төрле тармакларга бүленгән фән буларак оеша, җәмгыятьнең көчле бер коралына әверелә, цивилизация баскычына күтәрелә.

Сүзнең могҗиза икәнлеге — бәхәссез.

Үз чиратында сүзләр бездән җан сорый, кадер һәм мәрхәмәт сорый. Без моны онытмасак иде.

Сүзгә кадәрниләр булганын чал тарих үзе генә белә. Ләкин ул дәшми, серләрен ачарга атлыгып тормый. Сфинксның үтәли карашыдай, ул безгә бары текәлеп-сынап карый һәм әйтә кебек: «Сезнең буын төзергәме, әллә җимерергә килдеме дөньяга?..»

## 4. Могҗиза һәм тылсым дөньясы...

*Сүздән дә олы берни юк.*

Шекспир.

Дөньяда җиде могҗиза бар, диләр: Мисыр пирамидалары, Семирамида бакчасы һ.б. Кешелек таныган шушы җиде могҗиза минa үпкәләмәсен, әмма кешенең сөйләшә һәм үзара аңлаша алуын мин дөньяда беренче могҗиза дип бәяләр идем!

Җир шарында меңләгән телләр барлыгы мәгълүм. Галимнәр аңлатуынча, һәр булмыш һәм яшәп яткан тел билгеле бер мәдәни, тарихи һәм социаль җирлектә калыплашкан, шул җәмгыятьнең аерылгысыз өлешенә әверелгән. Акыл көче югарырак булган саен, бу халыкларның теле, мәдәнияте, язма әдәбияты да югарырак булган. Тарихта моның мисалларын эзләп табу кыен түгел.

Без бөтенләй игътибар итми торган бер гап-гади хакыйкать бар: безнең сөйләмебез төрледән-төрле төсләрдәге һәм мәгънәдәге сүзләрдән тора. Сүзнең формуласын кыскача гына болай дип бәян итәргә мөмкин: сөйләмдә мөстәкыйль берәмлек буларак кулланыла торган аваз яки авазлар системасы.

Әмма сүзнең ике яклы табигате барлыгын истән чыгармаска кирәк. Аның тышкы ягы — авазлар белән тәгъбир ителүе (язуда хәрефләр белән), ә инде эчке ягы — конкрет бер мәгънәгә ия булуы.

Галәмне, тирә-юнебезне атомнар, электрон һәм молекулалар чорнап алган шикелле, без сүзләр чолганышында яшибез. Шунысы кызык: әгәр кешеләр сөйләшергә өйрәнмәсә, дөньяда авазлар да, сүзләр дә булмас иде. Сүзләр галәм бишегендә һаман «ятим» булып яшәп ятыр иде... Әгәр безнең Җир шарында нинди дер кара тәкъдир яки гарасат аркасында тоташтан телсезләр яшәп ятса, без никадәрле мәдәни һәм рухи байлыклардан мәхрүм калыр идек. Сүз дигән могҗизада барлык нәрсәләр — хәтта минутлар, айлар, еллар, кичә-бүген-иртәгә дигән вакыт төшенчәләренә хәтле тәгәл чагылышын таба. Гәрчә вакыт безнең аңыбыздан тыш һәм ана бәйсез рәвештә яши. Менә шуңа күрә без аны, күпме генә категорияләргә бүлсәк тә, иллюзия рәвешендә кабул иткәнбез килеп чыга...

Әйтик, фал әйтүчеләр уйлаганча, көннәрнең берендә ахырзаман (апокалипсис) килеп җитте, ди. Вакыт мәңге үз көчендә калачак. Материя һәм Энергия, күпмедер үзгәреш кичерсә дә, сакланып калырлар. Дәрдемәнд әйтмешли: сөт калыр, Ватан китәр. Ә менә сүзләр, кешенең аңында яшәүче берәмлек буларак, юкка чыга түгелме соң? Тагын бер сорау: ахырзаман (кыямәт көне) җитсә, Алла да юкка чыгачакмы, әллә... объектив рәвештә яшәп калачакмы?

Бу сорауларга беркем дә җавап таба алмастыр, мөгаен.

Җир шарында аерым-аерым халыклардан илләр, дәүләтләр һәм җәмгыять оешкан шикелле, кешелек тарихында аерым-аерым, бөртек-бөртек сүзләрдән җөмләләр, кешеләр арасында үзара аңлашу, уй-фикеренне дөньяга җиткерү өчен сүз дәрьясы барлыкка килгән. Табигатьтәге нинди дер югары көчләр йогынтысындамы, әллә әйтер сүзгә ифрат зур ихтыяҗ булганлыктанмы, кешелек мәйданына никадәрле сүзләр дәрьясы ярдан ташып чыккан!

Лексика фәне телнең сүзлек хәзинәсен өйрәнә. Татар телендә 50 меңгә якын сүз байлыгы бар (шуларның 10 меңе алынма сүзләр рәтенә керә). Халыкта киң таралган диалектларны, ымлык, бәйлек, теркәгеч, кисәкчә һәм кереш сүзләрне дә өстәсәк, бу сан күпкә артачак, билгеле.

Сүз — табигать һәм тормыш-көнкүрештәге нинди дә булса күренешне, вакыйгаларны, кайсы да булса төшенчәне иң кыска (үлчәме) тәгәллек белән әйтеп, атап бирү, гомумиләштерү мөмкинлеге. Әйтик, без «агач» дибез, ә бит алар ничәмә-ничә төрле: имән, юкә, миләш һәм башкалар. «Агач» дигән бер сүз исә барысын да гомумиләштереп аңлата.

Һәр сүзнең чынбарлыкка һәм яшәешебезгә бәйле ачык, тәгәл һәм тирән мәгънәсе бар. «Кояш» дибез икән, безнең күз алдына ут шары, аның кайнарлыгы һәм кул җиткәс биеклектә талгын гына яшәп ятуы күз алдына килеп баса. Сүз ул беренче чиратта үзара (кешеара) сөйләшүгә, аралашуга, аңлашуга хезмәт итә. Кыскасы, аның «иңнәренә» бөек миссия, илаһи вазыйфа салынган. Тормыш-яшәешне сүзләрдән тыш, аралашу-сөйләшүдән башка күз алдына китерегез әле: тирә-юнебездә нинди бушлык һәм тәртипсезлек манзарасы пәйда булыр иде...

Без яшәгән дөнья материя, энергия, информация берләмлегеннән тора. Материя һәм Энергиянең ни-нәрсә икәнлеген без инде яхшы беләбез. Ә менә информация кыры фәндә ныклап өйрәнелмәгән әле.

Сүз — боларның соңгы икесенә турыдан-туры бәйле нәрсә. Сүзләр кырын күпмедер дәрәҗәдә шахмат тактасы һәм андагы фигуралар белән чагыштырырга мөмкин. Акыл һәм логикага (мантыйк) бәйле шахмат уенында такталагы фигураларның кайсы вакытта кайсы урынга куелуы иң әһәмиятле шарт булып тора. Фәлән мең сүзләр-фигураларның кайсы вакытта, нинди урында һәм ничек итеп әйтелеше яки язылышы бик мөһим. Сүз остасы Фатих Хөсни үзенең бер мәкаләсендә: «Урынындамы сүзләр-солдатлар?» дигән сорау куя һәм каләмдәшләрен һәр сүзгә, һәр җөмләгә игътибарлы булырга чакыра.

Әйе, дөрес һәм урынлы куллана белсәң, сүзләр затлы-фәһемле фикергә әйләнә, энҗе-мәрҗән булып ялтырый, сәвами нур чәчә... Ә инде арзанлы, очсыз, тупас, тар мәгънәле һәм жаргон сүзләр сөйләмне дә, әдәби телне дә бизәми, киресенчә, чүп үләне шикелле, матурлыкның ямен ала.

Поляк галиме Ян Парандовский язучы хезмәте турындагы китабын «Сүзләр алхимиясе» дип атаган. Монардан да төгәлрәк итеп әйтү мөмкин микән?!. Әйе, химия түгел, сүзләргә билгеле бер тылсым өреп, алардан могҗиза ясауны, илһам дигән биеклеккә күтәрелүне күздә тотып әйтелгән тыгыз-саллы төшенчә бу. Китапта «Сүз» дигән аерым бер бүлек бар һәм анда автор, «Сүз — бөек сер» дигән постулатка таянып, өр-яңа ачышлар ясый, күзәтүләрен уртаклаша.

Могҗиза. Сер. Тылсым.

Татар теле хәзинәсендә болар өчесе дә тирән чагылыш тапкан. Безнең туган телебез талгын чишмәдәй челтери, тулы елгадай горур ага, карурмандай моңлы шаулый. Бу телдә без төсләрне, күкләр биеклеген, тойгы һәм фикернең йөз төрле төсмерләрен, күңел тирбәлешен, психологик кичерешләрне кешеләргә генә бирелгән авазлар аша авыз тутырып сөйли, аңлата һәм ак кәгазь битен тутырып яза алабыз.

## 5. Сүзләр, сүзләр ни сөйли?..

*Матур сөйли белү —*
*фикер сәнгате ул.*

Б. Паскаль.

Кешеләрнең, агачларның һәм суның гына түгел, сүзләрнең дә уңай яки тискәре энергиясе бар, дидек. Күзгә күренмәс бу күренеш, сүзнең әлеге сыйфаты дипломатиядә, рәсми очрашуларда, дуслык-туганлыкта, гомумән, аралашуның барлык төрләрендә чагылыш таба. Мәхәббәттә бигрәк тә шулай. Әйтик, «яратам» сүзен генә дә әллә ничәмә төсмерләрдә әйтеп була: ихластан һәм асыл мәгънәсендә, наз яки ирония белән, ачулы яисә нәфрәтле тон белән һ. б. (Композитор Салих Сәйдәшевнең дусларына хөрмәтләп, якын итеп әйтә торган сүзе — «бәгырь» булган).

Һиндларның «омара вазанги» дигән борынгы һәм изге гыйбарәсендә куәтле уңай энергия бар, дип санала. Бу тәкъбир аларда акыл һәм тирән уй-фикер уята икән.

Ә бездә, татарда, бармы тылсымга ия шундый сүзләр? Мисалны күпләп китерергә мөмкин. Берничәсен генә искә төшереп үтик: «Сөбханалла!», «Алланың рәхмәте белән», «Хәерле иртә!», «Рәхим итегез!», «Мәрхәбә!» һ. б.

Сүзнең формуласын ачыграк күзаллау өчен аны түбәндәге схемага салырга мөмкин: сүзләр, җөмләләр һәм, ниһаять, уй-фикерләр гәрәбәсе. Менә шушы «өчпочмак» тормыш-яшәешнең олуг урамыннан кызыл җеп булып сузылып та, сызылып та бара инде.

Халыкның көче, акылы, зирәклеге, халәте рухиясе аның мәкальләрендә һәм фразеологик хәзинәсендә аеруча нык чагыла. Боларга тагын киная, канатлы сүз, ирония, тәгъбир-гыйбарәләр, телбизәкләр, эпитет һәм метафора, сүз җилемнәрен өстәргә мөмкин. Һәр ияккә сакал бар, һәр сәбәпкә мәкаль бар. Бу байлыкларны туплау, төпле аңлатмалар белән нәшер итүдә күренекле һәм колачлы шәхесләребездән Нәкый ага Исәнбәт титаник хезмәт башкарды: «Татар халык мәкальләре» (3 томда), «Татар теленең фразеологик сүзлеге» (2 томда). Алар Татарстан китап нәшриятында 1959—1989 еллар эчендә басылып чыкты һәм халыкның өстәл китабына әверелде диярлек.

Халыкта «йомры сүз» дигән гыйбарә дә бар бит әле. Монысы нәрсә аңлата? Лексик элемент буларак, мәгънәсе ягыннан ул телбизәк, канатлы

сүз дигән берәмлекләргә туры килә. Халык сөйләмендәге камил, зирәк һәм матур (образлы) әйтелгән сүзләр бу. Аны икенче төрле «түгәрәк сүз» дип тә әйтәләр. Мөкәммәл формага салынган Кояш, Ай, Җир шары һәм башка планеталар да түгәрәк. Борынгы кешеләр Җирне таба шикелле яссы һәм аны өч кит балыгы күтәреп тора дип уйлаганнар. Тамырдан ялгыш булса да, тәүге кешеләр Җирнең формасын һәм таяну ноктасын күзаллауда беренче «ачышлар»ын әнә шулайрак ясаган.

Борынгылар димәктән, Җирнең геологик тарихында Бозлык чоры, ягъни көчле салкынаю һәм гаять киң мәйданнарда тоташ боз катламы барлыкка килү дәвере дә булган ич. Менә шул чорда Азиядә яшәүче кабиләләрнең күпчелеге бозлы «күпер» аша кыйтгадан-кыйтгага күченгәннәр... Америкада яшәүче төп җирле халыклардан майя һәм акцет кабиләләр теле белән төрки-болгар теле арасында күп кенә уртаклыклар табарга мөмкин. Академик галимебез Әбрар ага Кәримуллин үзенең китабында һәм хезмәтләрендә бу уртаклыкларны фәнни нигездә исбатлап чыкты.

Сүзләр, җөмләләр, фразалар сулыш ала...

Сөйләмдә бу бигрәк тә шулай. Тон һәм интонацион үзгәрешләр сөйләү тавышына әллә ничаклы төсмерләр бирә ала. Бу уңайдан Чеховның фикере кызыклы. Ул болай ди: «Барлык заманнарда да тел байлыгы һәм ораторлык сәнгате янәшә барганнар». Әйе, борынгыдан алып бүгенге көннәргә кадәр ораторлык, матур һәм оста итеп сөйләү сәнгать итеп саналган. Тагын шунысы бар: яхшы һәм ышандыргыч итеп сөйләр өчен сөйлисе теманы, предметны яхшы белү кыйммәт. Әйтер сүзен яхшылыкка һәм дөреслеккә хезмәт итсә генә аның кадере зур, затлы була.

Әйе, сүз кадере тормыш-яшәештә дә, әдәбият-сәнгать дөньясында да мөһим урын алып тора. Безнең татар телендә илле меңгә якын сүз исәпләнә, дидек. Менә шулардан дөрес, фәһемле һәм нәтиҗәле файдалана белик, замандашым! Әлбәттә, сүзгә осталык сәләте белән фикерләү көче тәңгәл килмәскә дә мөмкин. Мәсәлән, Әмирхан ага Еники үзенең әсәрләрен бәрхеттәй йомшак-нәфис тел белән яза иде. Сөйләгәндә исә, кыска һәм бик салмак сөйләгәнгәме, мин аны оста оратор димәс идем. Бауның озыны, сүзнең кыскасы яхшы, дигән безнең бабайлар. Кыскалык — үзенчәлекле категория. Ана өйрәтмиләр, кешегә тумыштан бирелә бугай ул.

Тагын бер деталь. Бервакыт өендә очрашып әңгәмә үткәргәндә (ул 20 еллап элек «Идел» альманахында басылып чыкты) мин Әмирхан агадан болай дип тә сораган идем:

— Сезнең каләм һәм хыял куәте көчле, ә нигә роман язмыйсыз?

— Роман тикле романга каян сүз табып бетермәк кирәк... — дип җаваплады әдәбиятыбыз аксакалы.

Ораторлар (һәм чичәннәр) турында тагын берничә фикер әйтеп китәсе килә.

Яхшы ораторлар, һичшиксез, һәр сүзнең, һәр фразаның бердәм һәм ритмик агышын оста тоя торган кешеләр. Алар — талант иясе: ут яндырып сөйли белә: сүзләрдән — очкын, кирәк икән ялкын чыгаралар! Ораторлар, сөйләү осталыгыннан файдаланып, сүзләр, фикер һәм җөмләләр ярдәмендә эмоциональ шартлау тудырырга сәләтле. Сөйләгәндә иң урынлы сүзләрне сайлап ала белмәүчеләрнең исә уй-фикерләре, әйтер сүзләре болганчык була — ни акылга, ни йөрәккә дигәндәй тәэсир итми.

Пушкинның «Пәйгамбәр» шигырен белмәүче бик сирәктер. Ул аны «Глаголом жги сердца людей!..» дигән сүзләр белән тәмамлый. Искәртеп үтик — сөйләшкәндә дә, язмада да фигыль иң күп кулланылышта йөри, беренче урында тора диярлек. Фигыль, ни әйтсәң дә, хәрәкәт ул! Оран һәм шигарә ташлау мөмкинлеге дә...

Тел ачкычларын безгә кем биргән?

Табигать, тормыш-яшәеше, фикер ияләре, әмма барыннан да элек сабый чаклардан ук әти-әни биргән. Әгәр бала «әти» сүзләрен әйтеп үсми икән, ул инде чын татар түгел, ә бәлки — булачак маңкорт, гибрид... Теле ачылгач та бала: «әттә-әннә» дип әйтә белә икән — аның дөньяны танып-белүе, хезмәт биографиясе башланды, старт алды дигән сүз. Әйе, ялгышмадым, сөйләргә өйрәнү — бала өчен күңелле дә, авыр да булган эш, хезмәт ул.

Сүзләрне өлкәннәр уйлап тапкан, буын арты буын аларны үзләштерә һәм кабатлый гына. «Сандугач» сүзен алыйк. Безнең татар бәләкәй генә, күзгә бик күренмәс соры бу кошка нинди матур, шигъри исем тапкан да соң! Шагыйрьләр исә «былбыл» сүзен яратып куллана. Туфан Миңнуллин хәтта Татарстан китап нәшриятында «Сандугачым-былбылым» (1985) дигән сувенир китап бастырды. Анда «Сандугач» сүзе белән башланып киткән 700гә якын халык җырлары — дүртьюллыклар тупланган! Темалары — искиткеч киң: ватан, ил-җир, мәхәббәт, сагыну, моң-зар һ. б. Мисалга бер генә куплетны укып китик:

Сандугачлар сайрашалар,
Туган илем гөл, диеп;
Туган илнең, туган җирнең
Кадерләрен бел, диеп.

Төрле халык бер үк кошка үзләренчә итеп төрле-төрле исемнәр уйлап тапкан. Әйтик кызылтүш дигән кош бар. Күренеп тора: безнең бабайлар аңа бу исемне түше кызыл булган өчен кушканнар. Руслар исә аны «снегирь» дип йөртәләр. Чөнки бу кош кар өстендә бөтерелеп йөри, карда коенырга да күп сорамый.

Сандугачка ни өчен шундый исем кушканнар — монысын ачыклау кыенрак. (Г. Зәйнашеванын бер җырында әйтелгәнчә, «таң тугач» сүзеннән түгел микән?). Әмма шунысы хак: сандугачның кайда да үз теле, аның җырын башка телләргә тәрҗемә итеп булмый.

Сүзләрдән торган җөмләнең тәэсир көче булырга тиеш. Бер генә мисал. Кемдер: «Шәраб сал миңа», — дисә, моның бернинди тәэсир итү көче юк. Ә инде: «Сакый[1], сәрхуш ачылыгын тутыр әле чәркәгә!» — дисәң, монысы инде —серлерәк һәм тәэсирлерәк тә булыр.

Татарда: «Ярамаган сүз сөйләмә», — диләр бит әле. Равил Фәйзуллин үзенең бер шигырендә шушы темага бөтенләй икенче яктан килә:

Ярамаган сүз, дисең...
Ник ярамаган булсын!
Әйтергә дә ярамагач,
Нигә яралган соң ул?

Әйе, сүз — әйтер өчен яралган. Әмма... инде дә дөресен әйтсәк, үзебезне әдәп-әхлак тарафдары дип санасак, «ярамаган сүз»ләр рәтенә сүгенү, ләгънәт, бәддога кәлимәләрен, шулай ук гайбәт һәм ызгышу сүзләрен кертергә мөмкин.

Бу уңайдан бер мәзәк (анекдот) искә төшә. Беренче класста укучы малай дәфтәрен тотып әнисе каршына килә һәм әйтә: «Әни, мин урысча өч хәрефле сүз яздым». «Ул бит бик әшәке сүз!» — ди әни кеше һәм дәфтәр белән малайның башына суга... Малай, билгеле инде, әтисенә зарлана. «Ә син нәрсә дип яздың?» — дип сорый әти кеше. «Дом», — дип җавап бирә улы. Ачуы чыккан ата кухняга бара да шул ук дәфтәр белән хатынының

[1] Сакый — мәҗлес

башына суга. «Нәрсә өчен бу?» — дип аптырый хатын. «Йорт турында уйларга кирәк», — дип катгый җавап бирә ире. Өч хәрефле сүгенү сүзенә килсәк, чыннан да, күпләрнең — бигрәк тә яшьләрнең башына кереп «оялаган» ул.

Сүз кешегә уй-фикерен яшерү өчен дә бирелгән, дигәнне ишеткән-укыган бар. Дөреслек бардыр бу гыйбарәдә. Тормышта шома кешеләр моңардан оста файдалана, андыйларны очратканыгыз бардыр. Ә инде министрлар, дипломатлар һәм ил башлыкларын әйткән дә юк. Сталин һәм Гитлер 1939 елда үзара һөҗүм итешмәү турындагы пактка кул куялар. Ә үзләре бер-берсеннән яшертен генә зур сугышка әзерләнәләр. Туплар һәм танклар беренче залп бирү белән әлеге пактның ничек итеп «көлгә» очканын һәркем яхшы белә...

Сүз бездән зур җаваплылык сорый. Чөнки бер сүз белән теләсә кайсы сугышны башларга яки туктатырга мөмкин.

## 6. Сүзләр картаямы?..

*Ай белән тургай*
*картаймый, алар гел булачак...*
Ибраһим Гази.

Уенчык калейдоскоп кулга тотып әйләндергәләсәң генә хәрәкәткә килә, үзгәреш арты яңа сурәтләрне китереп чыгара. Сүзне хәрәкәткә китерүче, аны туендырып торучы көч — җәмгыять.

Сүз социаль-иҗтимагый тормышка турыдан-туры бәйле. Алыйк безнең Эрага кадәрге борынгы чорны. Әле бернинди цивилизация — авыллар, шәһәрләр юк, промышленность һ. б. юк. Бары мәгарә тормышы... алачыклар тезмәсе... кабиләләр оешу... аннары инде ашау-яшәү, биләмәләр өчен көндәшлек барлыкка килү (эволюция!). Без борынгы бабаларның иң беренчел сүзләрен-сөйләмнәрен белә алмаячакбыз, билгеле. Һәрхәлдә, алар җиргә, суга, утка, ташка, эш коралларына бәйле булгандыр.

Ул заманның сүзләрен искергән дип әйтергә буламы? Буладыр, ләкин картайган-тузган дип түгел... Аларның күп өлеше, агачыннан өзелеп төшкән җимешләр кебек, вакытында һәм бик тә табигый рәвештә яңа формация — колбиләүчелек строена, андагы яңача аралашу һәм сөйләмнәргә юл биргәннәр. Безнең Эрага кадәр моннан 4 мең еллар элек тарихта әнә шундый текә борылыш барлыкка килә. Физик хезмәт белән акыл хезмәте күзгә күренмәс чикләр белән кыл урталай бүленә. Физик хезмәттән азат ителгән колбиләүче сыйныф вәкилләре, аңлашыла ки, сәясәт, сәнгать һәм фән белән шөгыльләнгән. Аларның тел составы ничек баеганын, үзгәргәнен чамалау кыен түгел.

Алмашка килгән феодализм җәмгыяте телне баету, аны яңа сүзләр белән тулыландыруда шулай ук үзенең билгеле бер өлешен керткән. Бик тә мәгълүм берничә сүзне генә искә төшерик: бояр, помещик, оброк, мануфактура һ.б. Болар инде, чыннан да, картайган, яшисен яшәгән сүзләр. Хәзер алар күбрәк әдәбиятта, бигрәк тә тарихи әсәрләрдә яши.

Яңа идеяләр, җәмгыятьтәге фәнни-техник үзгәрешләр, икътисади тормыш, мәдәният, әдәбият һәм сәнгатьнең алга китүе, яңа иҗтимагый-сәяси мөнәсәбәтләр барлыкка килү — болар бар да телнең сүзлек составы үсеп-үзгәреп, камилләшеп торуына җирлек биргән.

Безгә шактый якын тарих — патшачылык (капитализм) заманнарында никадәрле яңа сүзләр сәхнәгә менгән! Бу яңа кискен борылыш татар теленең сүзлек составында да киң чагылыш тапкан. Иренмәстән, аларның истә калырдайларын бер җепкә тезеп чыгасы килә: хан, дворян, купец, алпавыт,

губернатор, кантон, өяз, казый; сугыш коралларыннан — ук, җәя, сөңге; эш коралларыннан — сука, чабагач, киле, шүре һ.б.

Ике сүзнең «феномен»ына аерым тукталасы килә.

Фермерлык хуҗалыклары беренчеләрдән булып XIV гасырда Англиядә оеша башлый. «Фермер» сүзе шул вакытта барлыкка килә (француз теленнән ясалган — аренда, түләү дигәнне аңлата). Бактың исә аның төп нигезләрен үзенең фәнни хезмәтләрендә безнең академик Чаянов язып калдырган була. Большевиклар исә, бу тәгълиматны кире кагып, тоталар да, дуамалланып һәм крестьянны талау исәбенә, колхоз дигәннәренә ябыша...

Шунысы кызык һәм контраст: безнең өчен югалган, инде тәмам онытылган «фермер» сүзе, һавадан төшкән кебек, авыл хуҗалыгы тормышына ялт итеп әйләнеп кайтты! Хәзер авылларда фермерлыкны бик тә үстермәкче булабыз, әмма йөз ел чамасы вакытны суга салганбыз икән шул...

«Губернатор» сүзен дә әнә шундыйрак язмыш сагалап торган икән, фаразан. Большевиклар бу сүзне кырып-себереп тарих сәхнәсеннән алып ташлаган иде. Вәләкин, «обком секретаре» дигән вазыйфа үзенең яшәвен-мәгънәсен югалткач, шушы буш урынга Мәскәү көчләп диярлек «губернатор» сүзен тагып куйды. Совет заманында тәрбияләнеп үскән менталитетка никадәр ят тоелмасын, әлеге сүзгә кешеләр һәм җәмгыять инде ияләшеп килә.

Сүзебезне дәвам итеп, безнең буынга яхшырак таныш булган совет чорына таба якын килик.

Совет чоры тел составын баетуга («чуарлауга дип әйтсәк тә була) шулай ук шактый өлеш кертә. Бу аңлашыла: чөнки революция давылы, аннары инде социализм һәм коммунизм төзү идеяләре җәмгыятьнең барлык катламнарына тирән үтеп керә, өр-яңа сүзләр һәм атамалар сорый. Галимнәр билгеләп үткәнчә, актив лексика телдә туган яңа сүзләр исәбенә туктаусыз тулыланып, баеп тора. Мәсәлән, аклар, кызыллар, инкыйлаб, ликбез, кызыл почмак, кумхуж, нэпман, райком, сельсовет, председатель, секретарь, бухгалтер, партия, юлбашчы, мәктәп, пионер, комсомол, вожатый һ.б. Шушы типтагы неологизмнар тора-бара халыклашып китә һәм актив сөйләмгә күчә.

Шиксез: совхоз, колхоз, колхозчы дигән сүзләр пассивлашып, сөйләмнән төшеп калып, тарихта гына үзләренә урын алачак, билгеле. Ә менә «коммунизм» сүзе, минем уйлавымча, үзенең урынын, кешелек аңында ныгып калган позициясен тиз генә бушатырга ашыкмастыр. Коммунизм идеясе үзенең асыл табигате белән, һәрхәлдә, яхшылыкка, матур киләчәккә таба өнди.

Заманалар алга барган саен неологизмнар һаман саен үрчеп-туып тора. Моның иң ачык мисаллары: космонавт, космодром, атомщик, программист, компьютер, интернет, сайт, кредит, менеджер, дизайнер, ипотека, маркетинг... Хәзер аларны укыганда яки әйткәндә теленне сындырырдай һәм тиз генә аңлашылмый торган «кәттә»ләре дә очрап куя әле.

Сүз башым бит шүрәле дигәндәй, без бит «сүзләр картаямы...» дигән сорауга җавап эзләргә тиеш идек.

Тарихта сүзләр эволюциясе булганмы — булган, моны исбатлау кыен түгел. Тел — тере организм кебек: туа, яши һәм үлә дә... Борынгы латин телен әнә үле тел дип исәплибез. Үз заманында никадәр куәтле, дәрәҗәле тел саналган ул! Латин теле ни өчен үлгән соң? Мин бу сорауга җавап бирергә әзер түгелмен, укучы мине гафу итсен. Хәзер үле теллөрдән саналса да, ул бөтенләй үк юкка чыкмаган. Бүгенге көнгә кадәр медицинада һәм фәннең төрле тармакларында (барыннан да элек термин буларак) «гөрләтеп» яши, кулланылышта йөри.

XVIII гасыр азакларында Европада шундый бер вәзгыять килеп туа:

әдәбиятта, барыннан да элек прозаик жанрда, аерым алганда, канцелярия һәм физика, математика, химия, экономика фәннәре буенча махсус сүзләр-терминнар уйлап табарга кирәк була. Аңа кадәр болар барысы да латин телендә гамәлдә йөргән. Милли үзанның уянуыдыр, күрәсең: устав, декрет, боерык дигән формулировкаларны һәм андагы җөмләләрне һәр халык, һәр дәүләт, һәр милләт үз телендәге чаралар ярдәмендә бәян итә башлый. Менә шуның нәтиҗәсе буларак, XIX гасырда Европа, рус һәм татар әдәбиятында да өр-яңа тел катламы күтәрелә, жанр һәм тел байлыгы ягыннан яңа бер сикереш ясала.

Күрәбез: агачлар ел саен яфракларын алмаштырган кебек, гасырларны кичә торгач, күп кенә иске сүзләр дә ирексездән өр-яңа кардәшләренә юл бирә башлый. Шул ук вакытта кайбер иске сүзләр, әрфия «күлмәк» ябынып, янадан тел-сөйләш-язу мәйданына кабат әйләнеп кайта. 1990 еллар башында Татарстанның суверенитеты игълан ителгәч, милли хәрәкәт аеруча куәт алган елларда, моның мисаллары бик нык артты: икътисад (экономика), сәясәт (политика), җөмһүрият (республика), сәнәгать (промышленность), мөхәррир (редактор), союз (берлек) һ.б.

Бүгенге татар әдәби теле халык теленә бик якын. Бу дөрес гамәлдер, шулай булырга тиеш. Борынгы, иске сүзләргә астөшермәләр (аңлатмалар) бирү Хәйям, Тукай, Дәрдемәнд әсәрләрен нәшер иткәндә аклана. Әдәби әсәрләрдә иске сүзләрне куллану тенденциясе көчәеп китте шикелле: әйтик — фәләк (фәрештә), сөбхәтләшү (киңәшү), сәмави (илаһи), кария (авыл), мәүзуг (тема), шәкел (форма), инкыйлаб (революция), инсан (кеше), тәфтиш (шәрехләү), һәдия (бүләк) һ.б. Әнә шундый сүзләр унышлы кулланыламы — укучы үзе әйтсен. Икенче караганда, әгәр татарча бик яхшы аңлашыла торган халыкчан сүзләребез бар икән, нигә әле телне чуарларга? Без бит халыкка хезмәт итәбез. Киң катлам халык массаларына аңлашылмый, «барып җитми» торган сүзләр белән эш иткәндә шулай ук чама хисе кирәк.

Күпме генә тырышсак та, бүгенге заман кешесе революция сүзен — инкыйлаб, республиканы — җөмһүрият, самолетны — очкыч дип сөйләшми, редактор сүзен — мөхәррир дип атамый инде. Архаизмнар, ягъни искергән атамалар (ислах — реформа, шивә — диалект, мөгаллим — укытучы) халык телендә шулай ук киң чагылыш тапмый. Боларны көндәлек матбугатта, барыннан да бигрәк фәнни һәм әдәби кулланылышта очратырга мөмкин. Минем үземә, мәсәлән, мөхәррир сүзенә караганда латин теленнән кергән редактор (redactus) сүзе күбрәк ошый. Республика сүзе дә — латиннан (менә сиңа үле тел!). Бу сүзләр, чарлана торгач, тәмам интернациональләшкән, халыклашкан, алардан кача алмыйсың.

«Спорт» сүзенә дә тукталыйк булмаса. Без матбугатта көн саен укый, телевизордан көн саен ишетә торган бу популяр сүз этрусклардан (римлеләрнең борынгы токымы) килә. Бик тә заманча яңгырый торган әлеге сүзнең яше — өч мең еллар тирәсе.

Тел картаямы, дидек. Картаер өчен иң әүвәле туарга кирәк бит әле. Бу урында ирексездән икенче бер сорау да ярала: ә тел хәзинәсе ни хисапка баеган соң? Артык җәелмичә һәм мисаллар белән мавыкмыйча, төп чыганакларын санау белән чикләнәм:

1. Татар теленең үз сүзләре, үз фонды җирлегендә туган хәзинә.

2. Чит һәм кардәш телләрдән кергән сүзләр (гарәп, фарсы, инглиз, француз, немец, грек, латин, итальян һ.б.).

Татарлар географик яктан һәрвакыт диярлек Гареп белән Шәрык урталыгында яшәгәннәр, «тел вә лөгать алмашканнар». Икенче чыганакта без моның ачык чагылышын күрәбез.

Безнең телдә рус теленнән кергән алынмалар да байтак. Күпләр, бигрәк тә филолог галимнәребез, аларның рус теленнән кергән килеш язылуын тәнкыйть итәләр. Уңышлы һәм телебезгә ярашлы дигәннәрен нигә әле кулланмаска? Тупас яисә авыр яңгырый торганнарын үз телебезгә тәрҗемә итү дә бик мәслихәт. Әйтик, шайба — алка, болельщик — җанатар, вертолет — боралак. Ә инде заманында «колхоз» сүзен «күмхуҗ» дип аударырга тырышулар бары ирония тудыра.

Тарихи «декабрист» сүзен «декабрьче» дип тәрҗемәләү дә көлке тудырыр һәм аңлашылмас иде.

Моннан егерме-утыз еллар элек Бразилиянең «Рабыня Изаура» сериалын караганнан соң бездә «фазенда» (бакча дигәнне аңлата) сүзе сөйләм теленә кереп киткән иде, әмма ул озын гомерле булмады шикелле...

Кемнәрнеңдер эсперанто дигән ясалма телне гамәлгә куярга тырышуы миндә бары гаҗәпләнү уята. Әгәр Җир шарында бер генә тел калса, бу — кешелекнең иң зур хатасы булыр иде. Урман-кырлар һәм болыннарның бөтен матурлыгы — андагы агачлар, чәчәкләрнең күп һәм төрле булуында лабаса!

Бүлекнең азагын, әдип Ибраһим Гази фикеренә таянып, болай тәмамлыйсы килә: «Ай, тургай, сүзләр картаймый, алар гел булачак...»

## 7. Дөньяны сүз бизәр...

*Бер сүз өчен актарасың*
*Меңәр тонна сүзләр рудасын!*
Вл. Маяковский.

Әдәбият, чыннан да, төрле жанрлар багында һәм сүзләр сагында торучы бөек көч ул.

Фән кешеләренең эш коралы — беренче чиратта акыл, интеллект. Төрле фаразларча юл ярып, алар ачыш ясаучылар. Әдипләрнең эш коралы исә — сүз, хыял, фантазия. Ләкин шушы ике төрле һөнәр ияләре арасында гаҗәеп бер уртаклык бар: хезмәте, иҗаты белән алар матурлык һәм гармониягә омтылалар, стихиячел хаосны билгеле бер тәртипкә, мантыйкка салалар, хакыйкать нурын эзлиләр һәм табалар. XIX гасырның күренекле галимәсе С.Ковалевская: «Күңелендә шагыйрьлек юк икән, математик булу мөмкин түгелдер», — дип юкка гына әйтмәгәндер.

Шагыйрь — матурлык илчесе. Ул тормыштан һәм табигатьтән алган тәэсирләрен мәрҗән итеп тезә, аның шигърияте колакларны иркәли, күңелне үстерә, күзләрне сөендерә. Әдипләр өчен сүз — изге нәрсә. Әһле каләм ияләре сүзләр ярдәмендә эстетик кыйммәтләр тудыра, хакыйкать һәм матурлык дөньясына тәрәзә ача. Әгәр әсәрдә сүз сулышы юк икән, моны талантсызлык билгесе дип бәяләргә кирәк.

Заман барыбызга да, ягъни үзенең гражданнарына текәлгән һәм ул бездән бик күп сорауларга дөрес, этрафлы җавап көтә. Кая барасыз? Ни уйлыйсыз, ни язасыз... Сугыш-үтерешләрдән, гаделсезлек кылудан кайчан туктарсыз? Әле болар сорауларның бер өлеше генә, саный китсәк, исемлекне озын-озак дәвам итеп булыр иде.

Заман беренче чиратта әдипләргә, шагыйрьләргә текәлгән. Чөнки ныклы, төпле, йогынтылы сүзне нәкъ менә алар әйтә белә. Акыл ияләренең бик күбесе сүзне коралга тиңләгән. Анатоль Франц: «Сүз аяусызны юк итә, крепостьларны җимерә», — дип язып калдырган. Солженицын да аның фикерен куәтли: «Сүз бетонны җимереп уза ала».

Әйе, язучы — физик-биологик яктан гына җәмгыять баласы, кирәксә һәм көче житсә, сүзләр ярдәмендә ул җәмгыятьне дер селкетә ала!

XIX гасырда ике кыйтгадагы ике китап кешелеккә чын-чынлап тарихи йогынты ясый: Бичер Стоунның «Том агай алачыгы» романы Америкада коллыкны бетерүдә искиткеч роль уйный. Ә инде Чернышевскийның Шлиссельбург төрмәсендә язган «Нәрсә эшләргә?» романы черек Россияне айкап ташлый, кешеләрне революция юлына этәрә.

Тел байлыгы белән фикер байлыгы — язучы өчен кошның ике канаты кебек. Әдипнең төп максатларыннан берсе — гап-гади сүзләргә куәт өрү, аларны художестволы, сурәтле һәм йогынтылы көчкә әверелдерү. Сүзләр хәзинәсен кешелек тарихында миллион буыннар чарлаган, аны баеткан, саклаган. Без барыбыз да — гади крестьяннан алып президентларга кадәр — буыннан-буынга тапшырылган әнә шул мәңге саекмас хәзинәдән файдаланабыз.

Әмма, бик тә гадиләштереп әйтсәк, чынбарлыкта Галинеке — Галичә, Иванныкы Иванча килеп чыга. Чөнки стиль — кеше ул, кешенең сөйләмдәге яки язганнарындагы чагылышы, кайтавазы. Достоевский, һәркемнең үз грамматикасы бар, дигәнрәк фикер әйтә. Аяз Гыйләжев яза: «Мөхәммәт Мәһдиев теле — Илһам Шакиров моңнары, Рөстәм Яхин фантазиясе шикеллерәк». Һай, бигрәкләр дә дөрес һәм матур әйтелгән!

Бетховен органда уйнау осталыгын болай аңлата: «Бу — бик гади эш. Тиешле клавишларга бармак белән дөрес баса белергә генә кирәк». Тел белән дә шулайрак. Бөтен хикмәт — энҗе бөртегедәй сүзләрне ничек итеп уйната алуга, аларның төсен-балкышын, тәэсир көчен ни дәрәҗәдә оста, урынлы файдалана белүгә бәйле. Әйе, сүзнең кадерен, аның йогынты көчен беркайчан истән чыгармаска кирәк.

Чаллыдагы каләмдәшем Айдар Хәлим минем бер соравыма болай дип җавап язды: «Сүз йә матурлыкка соклану, мәхәббәттән мөкиббән китү, йә нәфрәттән, гарьләнүдән ярала. Минем үземдә шагыйрьлек, укый-яза башлагач та, матурлыкка һәм батырлыкка сокланудан яралды, дип әйтә алам... Миндә кешеләрне матурлык тойгысы аша тәрбияләү, шул тойгы аша Гаделлек Патшалыгын урнаштыру теләге туды».

Язучының максаты — җәмгыять сафында бер адым алданрак атлап бару, үткәнне, бүгенгене һәм киләчәкне җитерәк күрү һәм чаң сугудан гыйбарәт. Евтушенко: «Фикер, әйтер сүз — биографиянең бер кисәге», — дип кистереп әйтә. Моның белән килешми мөмкин түгел. Әйе, әйтер сүзең булса, кеше кесәсенә йөгереп керәсе юк, алар үзләре синең йөрәгеңнән кайнап чыга!

Шагыйрь Зөлфәт яза: «Шулкадәр дә хикмәтле, серле дөньяда ни бар, анда нинди гамәлләр кылына — шуларның һәммәсенә дә кеше дигән әкәмәт зат сүзләр уйлап тапкан. Һәм ничәмә-ничә телдә диген әле!..»

Чирек гасыр диңгезләр кичеп, Италияне гизә башлагач, язучы Миргазиян Юныс итальян телен өйрәнә башлый һәм гаҗәпләнә: бездәге сабын — аларда «сабон», ә пыяла дигәнең «фиала» дип атала икән. Очраклы хәл түгел бу, әлбәттә. Аттила ярты Европа һәм Азияне яулап алган чакта үзара сөйләмнәр, тел вә лөгать алмашу көчле булган, болар — шуның бер дәлиле.

Янәдән шагыйрьләргә әйләнеп кайтыйк.

Тар карашлы, телгә ярлы «юка» кешеләргә караганда зиһенле кеше, сүзләр байлыгыннан һәм телбизәкләрдән оста файдаланып, акыл орлыкларын, матурлык нурларын күбрәк чәчә. Шагыйрьләр — әнә шундыйлар җөмләсеннән, аларга «йолдыз җене» кагылган. Теге заманнарда ук безнең борынгы шагыйрьләребез сүзләрдән энҗе-мәрҗән коя белгәннәр! Моның иң яхшы үрнәкләрен мисал рәвешендә карап китик:

Арыслан хәлдән тайса да,
Бер сарыклык көче бар.

*(«Идегәй» дастаныннан)*

Әйләнде бу батыр яшь тирәли, —
Җир әйләнгән кебек Кояш тирәли.

*(Сәиф Сараи)*

Шыбырдап яуган яңгыр һич ташка кунмас,
Акылсызга сүз әйтсәң дә башка кунмас.

*(Акмулла)*

Хөкемеңнән куркып, и шаһиҗан,
Көчле көчсезгә тидермәс зыян.
Бүре берлә куй бергә су эчәр,
Үрдәк берлә карчыга бергә очар.

*(Мөхәммәдьяр)*

Безгә якынрак торган заманнардан:
Очты дөнья читлегеннән
тарсынып күңелем кошы.

*(Тукай)*

Ни газизрәк — бу ватанмы?
Аһ, туган каумем газиз!
Сөт калыр, ватан китәр!

*(Дәрдемәнд)*

Кайсыгызның кулы җылы?
Бәйлисе бар йөрәкне...

*(Хәсән Туфан)*

Бу мисаллар аңлатмага мохтаҗ түгел. Тикмәгә генә «Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт белән», — дип әйтелмәгән. Шунысы хак: әгәр сүзләр дәрьясын, уй-фикерне хәрәкәткә китерүче көч — идеяләр, теләк-хыяллар, кешелекле тойгылар, сагыш яисә романтика булмаса, тел байый алмас, киресенчә, коргаксып һәм тоныкланып калыр иде. Сүзләр «чәчәк ата» аламы? Ничек кенә әле... Сез халыкның сөйләменә (сөйләшүенә) колак салыгыз, тыңлап карагыз: күңеленне яулап алырдай, аударып салырдай никадәрле гыйбарәләр, мәкальләр, канатлы сүзләр, киная, чагыштырулар, сурәтләр һәм тел бизәкләре анда! Дөньядагы барлык телләр төгәллеккә, матурлыкка, камиллеккә омтыла. Бу алгарыш татар теленә дә турыдан-туры кагыла.

Фразеология — прозада, метафора - шигърияттә тел-сурәт чараларының атасы, нигез ташы дип әйтергә мөмкин. Әйтик, энә күзе, диләр. Ә чынлыкта энәнең күзе бармы? Юк, билгеле, чынбарлыкта ул — кәтүк җебен саплар өчен уелган кечтек кенә гади бер тишек. Әмма шулкадәр ышандыра ки, без бу җанландыруга тәмам ияләнеп беткәнбез. Әбиемнең: «Улым, энә күзен саплап бирче», — дигән сүзләре әле дә булса хәтердә.

Такташның «нечкә билле апрель җиле» дигән юлларын искә төшерик. Матур, образлы, истә калырлык итеп әйтелгән! Юкса күзгә күренмәс җилнең ничек инде нечкә билле булырга мөмкин? Ә поэзиядә бу ышандыра. Йөрәк — табиб өчен кешедәге мөһим бер орган. Йолдызлар — астроном өчен өйрәнү-тикшеренү объекты. Шагыйрь өчен исә бу сүзләр — илһам, мәхәббәт, романтика чыганагы, хис-кичерешләрне сурәтләгәндә иң нык таралган шигъри төшенчәләр. «Йөрәге тибүдән туктады» дигән биологик җөмләне шагыйрь «йөрәге шартлады», «йөрәге ертылды» кебек метафоралар белән әйтеп сала икән, бу бик табигый һәм аңлаешлы. Җилнең дә авазы бар әнә, ләкин ул сөйләшә белми. Шагыйрь исә, хыял-фантазиясен эшкә җигеп, «Җил монологы» дигән шигырь язарга мөмкин.

Сүзнең зур көчкә ия булуы халык мәкальләрендә дә әйтелә. Шуларның берсе: Тел белән төенләгәнне теш белән дә чишә алмыйсың.

Бездәге яшь буынның сүз байлыгы, тел запасы чагыштырмача шактый ярлы. Аларның сүгенү сүзләренә еш мөрәҗәгать итүе шунардан түгел микән? Рәхәт һәм җайлы ич — кирәкле яисә тиешле сүзләрне эзләп «интегәсе» дә юк...

Трибунага чыктың, яисә кулыңа каләм алгансың икән, син инде үз өстеңә зур җаваплылык йөкләдең дигән сүз. Сүз көче, сүз кадере, тәэсир куәте һәркемнең үз кулында. Һәммәбезгә хәерле юл... Мөдәррис Әгъләм әйтмешли, сүзгә — хәерле юл!

Халык мәкале дөрес әйтә: дөньяны сүз бизәр.

## 8. Синонимнар бакчасында...

*Сүзләр — чәчәк, нәтиҗәсе - җимеш.*
Әл-Хәрази.

Иң элек мондый сүзләрнең ни-нәрсә икәнлеген искә төшереп үтик. Тел белемендә синонимнар дип төшенчә һәм мәгънәләре ягыннан тәңгәл килгән яки бер-беренә якын торган сүзләр атала. Татар телендә синонимга иң ачык (абсолют) мисаллар: сандугач — былбыл, кайгы — хәсрәт-сагыш һәм башкалар.

Язучылар, шагыйрьләр иҗат процессы барышында синоним дигән лексик термин барлыгын бөтенләй диярлек «сизмиләр», билгеле. Әмма урынлы һәм оста куллана белгәндә, алар әдәби әсәрнең тукымасын, палитрасын баеталар, тел-стиль чарасы буларак, һаман бер үк сүзләрне кабатлаудан коткаралар. Тел байлыгы җәһәтеннән караганда аларның, исем һәм фигыльләрдән кала, иң актив кулланылышы әнә шуның белән аңлатыла.

Әйтик, кешенең халәте-рухиясен төгәл һәм ачык әйтеп бирү өчен генә дә татар (авторлары гына билгесез) дүрт-биш сүз уйлап тапкан: күңел, җан, вөҗүд, калеб, бәгырь. Сөйләмдә һәм әдәби әсәрләрдә шуларның иң актив кулланылышта йөргәннәре — күңел һәм җан: күңелем әрни, җаным сызлый... Бигрәк тә шагыйрь әлеге ике сүз белән шигърияттә ат уйната, өр-яңа образлар һәм тәгъбирләр белән укучы йөрәгенә тәэсир ясый. Соңгы өчесе исә пассив кулланылышта йөри.

Синонимнар «бакчасы»ннан истә калырдай тагын берничә мисал:

Кеше: матур, сылу, гүзәл, чибәр, күркәм, нәфис;

Төрмә: өтермән, хабесханә, таш капчык.

Үлем турында исә халыкта дистәдән артык синоним бар: әҗәл, вафат, һәлак булу, арабыздан китү, гарешкә ашу, бакыйлыкка күчү, дөнья кую, аяк сузу, шәһит китү, корбан булу, өзелү, җан тәслим кылу...

Күрәбез: синонимнар сүзтезмә яки фразеологик әйтем рәвешендә дә булырга мөмкин икән. Ачык мисалы: сәламәтләнү — аякка басу.

Башкалабыз Казанда физиология, медицина, психология һәм биология өлкәсендә эшләүче замандаш галимебез Альфред Мусаяф улы Мостафин бар иде. «Бар» иде дип әйтәм, чөнки рәхимсез үлем аны безнең арабыздан вакытсыз алып китте. Ул — Казан фәнни иҗат академиясен (КАНТ) оештыручыларның берсе. Фән өлкәсендәге хезмәтләре, ачышлары өчен аның кандидатурасын 1996 елда Мәскәү һәм Казанның күренекле галимнәре Нобель премиясенә тәкъдим иткәннәр иде. Әмма... нигездә яһүдләр кулындагы мәртәбәле халыкара бу премияне татар кавеменә бирергә ашкынып торалар дисеңме?!. Хәер, монысы инде бүтән тема.

Альфред Мостафинның хезмәтләре һәм эзләнүләре бихисап һәм төрле

юнәлешләрдә. Безне барыннан да элек аның психолингвистика өлкәсендәге эшчәнлеге кызыксындыра.

Ул студентлар катнашы (ярдәме) белән күп кенә тикшеренүләр, тестлар үткәрә. Тестның турыдан-туры беренчел мәгънәсе — сорауларга җавап бирү дигән сүз. Җаваплардан шунысы ачыклана: биологик инстинктларга барып терәлдеме — сүзләр-синонимнар төркеме бик күпкә җыйнала икән. «Ашау» сүзен тәңгәлләштерүче утызлап синоним табылган. «Курку» сүзенә — 10. «Алдарга» дигән сүз рекорд куйган: 41 вариантта! Ә менә «дөресен сөйләү» дигәнгә алмаш таба алмаганнар. «Кеше үтерү» («Убить человека») дигән графага исә казанлылар арасыннан 60лап сүз җыйганнар. Гаҗәп бит бу...

Аңлашылса кирәк, әлеге тестлар рус телендә алып барылган. Татар телендә үткәрсәк тә якынча нәкъ шушы саннар нәтиҗәсе килеп чыгар иде. Ләкин минем максатым бу түгел.

Шулай да ике сүзгә махсус тукталып китәсем килә. Рус телендә «любовь» һәм «слово» дигән сүзләрне алмаштырырлык синоним табып булмый. Татар телендә дә «мәхәббәт» һәм «сүз»не алыштыра торган синоним табу кыен. «Сөю» дияр идең, ләкин бу сүз бүтәнчәрәк мәгънәне, биопсихологик халәтне аңлата. «Мәхәббәт» дигән сүз исә кешелек тарихындагы бу бөек, илаһи күренешнең иң әһәмиятле һәм закончалыклы билгеләрен, иң асыл сыйфатларын аерып алып, бер фокуска туплаган зуррак абстракцион төшенчә. Кызык бит: сүзнең үзенә килсәк, бездә «сүз»не алмаштырырлык бүтән сүз шулай ук юк. «Кәлимә» дияр идең, монысы бик тә борынгы, тар һәм ирониягә тартым мәгънәсендәрәк...

Кыскасы, синонимнарның муллыгы буенча безнең татар теле — чемпионнарның берсе дип әйтергә мөмкин. Әле боларга парлы сүзләрне дә китереп өстәсәкме!.. Татар телендә (һәм, гомумән, төрки телләрдә) сүзләр пар-пар булып киләләр. Кайбер үрнәкләрне генә искә төшерик: җир-су, дус-иш, моң-зар, гореф-гадәт, кием-салым, олысы-кечесе, ипи-тоз, йорт-кура һ. б. Болар үзләре — синонимнның яңа бер төре.

Шулай да чукчаларның «кар» сүзен кырык төрле сүз-синоним белән әйтеп бирүләре — рекордка тиң. Бу аңлашыла да, аларда бит — тоташ кар диңгезе... Ә менә кубалылар, кар күрмәгән кавем, алар белән ярыша алмый инде. Әле дә истә: Фидель Кастро Мәскәүгә беренче тапкыр эш визиты белән килгәч (60 нчы еллар), «Пионерская правда» газетасы аны «Кар күрмәгән кеше» дип язып чыкты.

Рус телендә «Жизнь» дигән сүзгә дә алмаш юк. Бездә исә мәгънәсе ягыннан аңа бик тә якын булган «гомер» сүзе бар: тормыш юлы — гомер юлы.

Инде дә килик телебездәге «моң» сүзенә. Аны башка телләргә берничек тә тәрҗемә итеп булмый. Тәрҗемәгә бирелми торган бу сүзнең асылын башка телләрдә аңлатыр өчен аерым фраза, аерым җөмләләр сорала — моны берәү дә кире кага алмастыр.

«Моң» сүзенә аңлатма, төп билгеләмә бирүе дә кыен. Аңа синоним табу да мөмкин түгел. Менә шундый хикмәтле, тылсымлы сүз. Ул барыннан да элек җыр, музыка дөньясына кагыла. Татар милли сәнгатенә генә хас бу сүзне музыка белгече Г.Әхмәров эстетик кына түгел, әхлакый категория дип тә бәяли. Аның фикеренчә, бу сүз татарларның борынгы тарихи Ватанына бәйле рәвештә барлыкка килгән.

Моны азмы-күпме аңлар һәм күзаллар өчен, чыннан да, ерак үткәннәргә һәм тарихыбызга караш ташлау кирәктер. Без хәзер «тарихи Ватаныбыз» дигәндә Татарстанны, аның башкаласы шәһәре Казанны күздә тотабыз. Ә бит иң борынгы бабаларыбыз Каф тавы итәгендә гомер сөргәннәр. Татарның, өч тармакка бүленеп, бүгенге Болгария җирләренә, Себер кинлекләренә һәм

урманга бай Идел буйларына урнашып калулары да тарихта мәгълүм нәрсә. Борынгы Ватаныңны, аның табигатен, тормыш-көнкүрешен сагыну — код, ностальгия рәвешендә буыннан-буынга күчә килгән, билгеле. «Мон»ның этногенезик тамырлары менә кая барып тоташа... Моны, икенче төрле итеп, халыкның коллектив эмоциональ хәтере дип тә атарга мөмкин. Безнең халыкның күңел төпкелендә әнә шундый аваз дулкыннары ята.

Сөйләмдә һәм халык телендә синонимнарның иге-чиге юк. Каләм әһелләре — язучылар исә үз чиратында өр-яңа образлар һәм метафоралар ярдәмендә синонимнар бакчасын элек-электән, гомер буе баетып килгәннәр.

## 9. Сүзнең муены нечкә...

*Төшнең муены нечкә —*
*ничек юрасаң, шулайга таба борыла.*
Халык сөйләме.

Алдарак, сүз сәясәттә — телне яшерү, яшертен уй-ният-фикерләрне «пәрдә»нең теге ягында калдыру өчен дә кирәк ул, дигән идек. Ленин сүзләре белән әйтсәк, сәясәт пычрак эш. Шулайдыр, ләкин сәясәттә дә маңгайга бәреп әйтелгән, туры мәгънәсендәге сүзләр-гыйбарәләр еш очрап тора.

Игътибар иткәнегез бар микән: ил тәхетенә яңа бер хаким-юлбашчы менеп утырдымы, аның үзе яисә яраннары тарафыннан, һичшиксез, өр-яңа диярлек терминнар, атамалар, гыйбарәләр уйлап табыла. Алар бернинди тоткарлыксыз шундук иҗтимагый-сәяси әйләнешкә, худка җибәрелә.

«Вертикаль хакимият», «Закон диктатурасы», «халыкара терроризм», «бәдрәфтә манчу» — болары В. Путинның сәясәт капчыгыннан.

«Үзгәртеп кору», «тизләнеш», «кеше кыяфәтле социализм» — болары М.Горбачев вакытында бик популяр иде. «Суверенитет» — Б. Ельцин заманында бу сүз халык теленнән төшмәде! «Йолдызлар сугышы», «Явызлык империясе» — болары исә океан артыннан, АКШның элекке президенты Рейган авызыннан чыккан сүзләр.

Безнең беренче президентыбыз М. Шәймиев тә сәясәт лексикасына үз өлешен кертте. Өч кенә гыйбарәне исә төшерик: «Базарга йомшак керү», «Татарстан моделе», «Булдырабыз!».

Гаҗәпләнәсе юк, тарихта моның традицияләре зур һәм еракган килә. Әйтик, социализм чорында нинди генә атама һәм гыйбарәләр уйлап чыгарылмады! «Мәңге тере» (аңа кадәр бер генә фиргавенгә, ханга, патшага шушы кадәре төче мактауның эләккәне булмагандыр, мөгаен). «Сталин — это Ленин сегодня» (ләкин үлгәннән соң Сталинны берзаман Мавзолейдан чыгарып кара җиргә күмделәр). «Дөрес юлдан барасыз, иптәшләр!» Җәмгыятьтә үзгәреш җилләре исә башлагач, аны «дөрес юлдан барасызмы...» дип үзгәртеп тә карадылар, ләкин соң иде.

Мәгънәсе бозылмасын дип, тагын берсен тәрҗемәсез генә әйтеп китәм: «Коммунизм неизбежен, потому что он необратим».

Менә шундый парадокслар!

Ленин-Сталин заманындагы тагын кайбер терминнарны аңлатмаларсыз гына күздән кичерик әле: «сыйнфый дошман», «пролетариат диктатурасы», «нэпман», «кулак», «басмачы», «халык дошманы» һ.б.

Гомумән, дошман эзләү — Россиягә аеруча хас күренеш. Урта Азия халкына карата «басмачы» дип, әфган халкына «душман» дип мөһер сугуларын, урыс армиясенә карата йөз дә сиксән градуска борып куйсак, мәсьәләнең асылы тамырдан үзгәрә! Нәрсә, теге чакта үзбәк яки таҗиклар

Россиягә башлап һөҗүм иттеме әллә? Бәлки, җитмешенче еллар башында күршебез Әфганстан СССРга каршы үзе сугыш игълан иткәндер? Юк шул, фактлар киресен сөйли, «интернациональ ярдәм»нең ни икәнен газиз улын югалткан гап-гади авыл агае да яхшы белә. Менә шуларны күздән кичергәч, кемнең басмачы, кемнең оккупант икәнлеген чамалагыз инде...

Соңгы елларгарак кайтып төшик. Чечняның азатлыгы, мөстәкыйльлеге өчен көрәшүчеләргә нинди генә атама һәм ярлыклар тагылмады: сепаратист, боевик һәм, ниһаять, бандформированиеләр... «Конституцион тәртип урнаштырабыз...» дигән булып, никадәрле җимерекләр һәм канлы ботка ясалды! Азатлыкны яулау — бер хәтәр булса, аны икенче халыклар кулыннан көч, корал белән тартып алу — икеләтә-өчләтә хәтәр. Әмма сәясәтчеләр дә, таш маңгайлы генераллар да шушы хакыйкатьне һич тә аңларга теләмиләр.

Сүзләр, сүзләр, сүзтезмәләр...

Хәтерлисездер: совет мәктәбендә безнең һәммәбезгә «Коммунизм төзүченең мораль кодекс»ын өйрәнергә туры килде. Аның тексты зал коридорында эленеп тора иде. Анда пунктлап-пунктлап тырыш хезмәт, халык байлыгын саклау һәм арттыру, коллективизм һәм иптәшләрчә ярдәм, шәхси һәм иҗтимагый тормышта намуслы, гадел булу, халыклар арасындагы дуслык һәм туганлык турында никадәрле кешелекле фикерләр язылган иде. Әмма үтәлдеме соң шушы алтын кагыйдәләр, шушы күркәм йолдызлыкка таба төбәп бара алдыкмы?

Юк шул, ике мораль: ягъни кәгазьдә — бер, чынбарлыкта икенче төрле яшәүче җәмгыятьнең әхлагы какшады, олы юлдан читкә тайпылды. Бу, барыннан да элек, партократ һәм номенклатура әһелләренә карый иде, билгеле.

Әйе, әйтелгән-язылган сүзләр, идея-ниятләр бик тә изге, гуманистик рухта да булырга мөмкин, ләкин аңа нинди юллар, нинди әхлак белән барасың бит — ахыргы нәтиҗә әнә шуңардан килеп чыга. СССРда социализм җимерелүнең төп сәбәбен дә иң элек менә шулардан эзләргә кирәк.

Бабам Низаметдин әйтә торган иде: «сүзнең муены нечкә — кайсы якка каерсаң, шунда таба борыла». Шактый дөрес әйткән бит, шайтан алгыры!..

## 10. Сүзгә — мәрхәбә!

*Сүз — җәмгыятьнең иң көчле,*
*иң бөек хезмәтчесе.*

R. N.

Бездән никадәр ерак (!) булмасын, күз алдына китерү читен түгел: буын арты буыннар дәрелфаныйлыктан дәрелбакыйлыкка күчкән, ләкин алар тудырган һәм иҗат иткән сүз байлыгы, халык теле, дәверләр кичеп, мәңге саекмас хәлендә исән калган. Бу урында «кешегә рәхмәт, сүзгә рәхмәт...» дип дога кылсаң да бик урынлы булыр.

Элек тә шулай булган, хәзер дә шулай: сүз (һәм акыл) ярдәмендә тормыш-яшәештәге, табигатьтәге әллә ничаклы серләр һәм күренешләрнең үзәгенә, түренә үк үтеп керергә мөмкин. Борынгы кеше күреп тә, тотып та була торган су, җир, ут кебек атамаларны уйлап тапкан икән, бу — аларның аваз белән тәгъбир ителүе генә түгел, билгеле бер мәгънәгә ия булуы да. Кешенең абстракцияләү сәләте киң колачлы сүзләрне дә тудырган һәм дөньяны танып-белүгә хезмәт иткән: яшәү, гомер, белем, батырлык, ирек, көч, горурлык. Сонрак, табигать һәм андагы предметлар, күренешләрнең үзенчәлекләрен өйрәнә һәм ача башлагач, кислород, водород, атом кебек

сүзләр барлыкка килгән. Боларны күреп, кулга тотып булмый, ләкин факт: дөньяви төзелештә материя ярымабстракт хәлдә яши бирә.

Бу дөньяда сүзләр магиясеннән дә көчлерәк нәрсә бар икән? Сөйләгән сүз бары «эфир»га очарга мөмкин, ә менә ташка, китапка басылган сүзнең көче һәм кыйммәте беркайчан югалмый. Халыкта «китап сүзе» дигән гыйбарә акыллы, зирәк сүз дигәнне аңлата.

Шунысы хак: әгәр кешелек хәрефләр һәм китап басуны уйлап тапмаган булса, без әле һаман да борынгы бер җәмгыятьтә яшәп ятар идек...

Аңлашу һәм аралашу чыганагы буларак, сүзнең тагын бер вазыйфасын әйтеп узасы килә: эшләнгән эшкә, хезмәткә сүз белән бәя бирелмәсә, аның кыйммәте шуның кадәр генә — ул бары һавада «эленеп» калачак. Сүз һәрвакыт, һәркайда һәм безнең һәр шөгылебездә кирәкле элемент, көчле корал.

Тагын әле телне тоемлау дигән нәрсә дә бар дөньяда. Бу яктан язучылар — иң сизгер, иң нечкә тоемлы халык. «Мәдәни җомга» газетасында тел галиме Илдар Низамов, күренекле язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Туфан Миңнуллинның телгә үтә дә сак килүе, аларны дөрес, зирәк һәм үтемле файдалана белүе хакында күләмле мәкалә язып чыкты. Бу үрнәк һәм тәфсилле мәкаләдән соң миңа әлеге темага яңалык өстәүнең кирәге дә калмады шикелле.

Тагын шунысы дөрестер: телбизәкләр дә мулдан булырга тиеш. Чәчәннәрчә матур итеп сөйләү һәм җырларны башкару өчен шулай ук табигать биргән аерым осталык, сүз һәм фикер байлыгы кирәктер.

Иҗатын 1920-30 елларда башлаган Ленинград прозаигы Илья Бражнин язучылык турындагы бер китабында («Сумка волшебника») сүзне очар кошка тиңли. Бу урында ничек инде Мостай Кәримнең «Күкрәгемнән кошлар очырам...» дигән канатлы сүзләре искә төшмәсен, ди!

Намусы һәм күңеле чиста, изге ниятле кешенең сөйләме, төс-кыяфәте дә ачык һәм ышандыручан булган. Син, укучым, моның мисалларын яхшы беләсеңдер.

Татарстанның суверенитетын дәгъвалаган көннәрдә без кемнәрнең генә утлы чыгышларын тыңламадык! Ләкин шушы ораторлар арасында ут яндырып сөйли һәм толпаны (яхшы мәгънәсендә) үзенә карата белгән берничә шәхес кенә хәтердә: Зәки Зәйнуллин, Роберт Батулла, Фәндәс Сафиуллин, Фәүзия Бәйрәмова, Әзһәр Шакиров... Бәгырьләре авыртканга күрә чыгыш ясый йә артистлар, йә язучылар... Кызыл сүзләрне мулдан сибүгә караганда дөресен һәм ихластан сөйләү алтын бәясенә тиң иде ул чакта.

Зоология фәнен яхшы беләм дип мактана алмыйм. Әмма биология фәнендә, бер сүз белән әйткәндә, конкуренция дигән гаҗәеп бер термин бар. Никадәр сәер тоелмасын, менә шушы конкуренция дигән нәрсә хәтта телләр арасында да яшәп килә. Бу капма-каршылыкны үзебезнең мисалда да күреп-белеп торабыз ич: рус теле татар теленең әһәмиятен һәм аның ролен кулланылыштан юкка чыгарырга, аны йотарга тели. Бу — конкуренция инстинкты гына түгел, барыннан да элек Россия күләмендә алып барылган сәясәт һәм шовинизм җимеше.

Бездә рус теле, гомумән, «киллер»га әйләнеп бара. Немец драматургы Г.Лаубе бик тә дөрес һәм акыллы сүзләр әйтә: «Халыкның теленә һөҗүм итү — аның йөрәгенә һөҗүм итүгә тиң». Ә менә Путин, 309 нчы маддәгә кул куеп, Россия Федерациясендә милли телләрне кысрыклауга һәм аның мөмкинлекләрен чикләүгә «яшел ут» кабызды. Янәсе, мәктәпләрдә туган телдә укыту чикләнергә тиеш...

Мондый мөнәсәбәт хәтта дин кадәр диннең дә мәгыйшәтенә үтеп керде.

Бер генә диндә дә үзенең дини бәйрәмнәрен чит телдә уздыру юктыр дип беләм. Ә менә без хәзер Гает һәм Корбан бәйрәмнәрендә дә урыс телен бик еш эшкә җигәбез: янәсе, вәгазь вә үгет-нәсихәтләр яшьләр һәм татарчаны яхшы белмәүчеләр аңына барып җитсен...

Дөнья мәйданында да тын һәм гаугасыз ярыш дәвам итә: мировой инглиз теле рус теленең функцияләрен көннән-көн, елдан-ел кысрыклый бара. Ничек итепме? Компьютер, интернет, сайт һ. б. шундый технология ярдәме белән.

Шөкер, гасыр катламнарын кичә-кичә телебез яши, дәвам итә, иҗтимагый тормыштагы үз урынын даулый. Ул — агрессив тел түгел, аның кояш астында яшәргә тулы хакы бар. Бу хакта шагыйрь Равил Фәйзуллин алтмышынчы елларда ук бик тә дөрес әйткән:

Минем телем —
меңәрләгән ишләре күк
тыйнак тел ул.
Басынкы ул:
халыкара конгресслар,
парламентлар ачып йөрми,
акча, чеклар битенә менми.
Сугыш ачмыйлар минем телемдә,
капитуляция дә ясамыйлар...

Кайсын гына алсак та, телдәге сүзләр беркайчан да сугышны мактамый, аңа дан җырламый. Чөнки теләсә кайсы сугышның синонимы — бераү генә: үлем... Хәрбиләр китереп чыгарган сугыш һәм сугыш кораллары сүзне дә үтерергә мөмкин. Чөнки яу кырында башын салганнарның әйтелмичә калган әйтер сүзләре дә утлы кораллар тарафыннан һәлак ителә, мәңгелекнең салкын куенына кереп югала. Әйтик, Россия-Чечня сугышында катнашкан 18-19 яшьлек солдатларның күпмесе сөйгән кызына «яратам... мине көт...» дигән сүзләрен әйтә алмыйча кара туфракка күчтеләр...

***

Безнең язмыш-яшәешкә Табигать тарафыннан бай һәм тылсымлы татар теле бүләк ителгән. Ул — безгә бушлай бирелгән хәзинә. Онытмыйк: туган тел бездән зур төгәллек, нәфислек, сакчыллык, мәхәббәтнең сафын тели. Без аның кадерен белсәк, килер буыннар михрабына кадәр сакласак иде.

Халкыбызның зур бер казанышы буларак, татар теле — рус теле һәм башка чит телләрнең байлыгын, матурлыгын тәрҗемә аша бөтен киңлеге белән әдәбият сөючеләр күңеленә илтеп җиткерә ала, бу — бәхәссез.

Ватанына, туган ягына булган мәхәббәтне туган теленә булган мәхәббәттән башка күз алдына китерү дә мөмкин түгел.

Аннары... Достоевскийның «Дөньяны матурлык коткарачак» дигән сүзләренә ияреп шуны әйтәсе килә: кеше сөйләшә һәм елмая белсә генә дөнья азмы-күпме яхшыга таба үзгәрер.

Могҗиза буларак, сүз — безгә кадәр дә яшәгән, бездән соң да яшәр, иншалла!

Менә шуңа күрә йомгаклау өлешен «Сүзгә — сәлам! Сүзгә — мәрхәбә!» дигән канатлы сүзләр белән тәмамлыйсым килә.

*2000 — 2012 еллар.*
*Казан — Олы Мишә.*

# УЙМАК УЙЛАР

## РАШАТ НИЗАМИНЫҢ СҮЗ ТУРЫНДА КАНАТЛЫ СҮЗЛӘРЕ

** Туган тел — диңгез, ә сүзләр диңгездән бер тамчы.*

** Сүз энә күзеннән чыкса гына алтынга әверелер.*

** Вакыт биләмәсендә күп нәрсәләр онытылыр, юкка чыгар, — әмма өч хәрефле «әни» сүзе мәңге калачак.*

** Поляклар татарга һәйкәлдән ат куя, урыслар татар теленә «мат» куя.*

** Әгәр өтер дөрес куелмаса, җөмләнең кабыргасы сынык булыр.*

** Бер каптырмалы җөмләләр озын гомерле булмый.*

** Сүз белән кыйнаган кермәсә, чыбык белән кыйнауның файдасы юк.*

** Акыл — сүз белән, матурлык күз белән үлчәнә.*

** Карбызның пиндилеген чыңлатып, кешенең кемлеген сөйләтеп беләләр.*

** Әгәр мәгънәсе зәгыйфь икән, җөмлә бик тиз үләргә мөмкин.*

** Сүзгә су кушсаң, сыеклана.*

** Сүз белән ныгытылган фикер таулар күчерергә сәләтле.*

** Теләсә кайсы сугышны бер сүз белән башларга яки туктатырга мөмкин.*

** Әйтер сүзең булмаса, телеңне тешлә.*

** Кешенең сүзләренә караганда кайчакны күзләре күбрәкне сөйли.*

** Тел ачкычлары бирелсә, хәйләкәр төлкедән һәм мимика остасы маймылдан да шәбрәк сөйләүче булмас иде.*

** Тапкыр сүзле кеше теле белән таш яра.*

** Еланга тел — сөйләр өчен түгел, чагар өчен бирелгән.*

** Сүз белән артык мавыксаң, эшли торган эшең ташланыр.*

** Туры сүз утта янмый, суда батмый.*

** Кешеләрне хәйран иткән дә, вәйран иткән дә — сүз.*

** Сүзнең күләгәсе булмый.*

** Пегасны очырлау өчен йөгәнең көмеш җепләрдән үрелгән булырга тиеш.*

** Дөньяның яртысы сүз һәм мәхәббәт нуры белән яктыртылган.*

** Авызыңа алтын теш куйдырып кына авызыңнан алтын сүз чыкса икән ул!*

** Ызгыш-талашлы өйдә шайтанның эше көйле булыр.*

** Әдәби бөкрене дә кабер генә турайта.*

** Шагыйренә карап, сүз — ташка яки икмәккә әверелә.*

** Талантлы язучы үзенең каләмен һәм әйтер сүзен ак кәгазь өстендә биетер.*

** Нәрсә-нәрсә, ләкин әйтер сүзләреңне ломбардка илтеп тапшыра алмыйсың.*

** Вәгъдә сүзе биргәннән әле бирәүнең дә бөлгәне юк.*

** Гарип күңелдә төзек сүзләр була алмый.*

** Иң борынгы кешеләрнең берсе: «Бу — минеке!» — дигәннән соң тарихта шәхси милекчелек башланган.*

** Хәтта алтын күгәрергә мөмкин, әмма затлы сүз беркайчан тутыкмас.*

** Кешеләрне сокландырасың яисә каш астыннан мыскыллы елмаятасың килсә, уй-ниятләреңне сөйләп бир.*

** Яхшы затның әйтер сүзе дә туфрак сыман йомшак була.*

** Кош сайраганны аңлар өчен кошлар телен яхшы белергә кирәк.*

** Матурлыкка күз кирәк, дөреслеккә сүз кирәк.*

** Сүзнең зурысы яки кечкенәсе булмый.*

** «А»дан «Я»га кадәр булган хәрефләрне тиз ятларга мөмкин, ә менә тормыш әлифбасын гомер буе өйрәнәсең.*

** Балыклар сөйләшә белсә, тиктомалдан кармакка килеп капмас иде.*

** Язмыш беркайчан сөйләшми, ул тәкъдиреңне сүзсез генә хәл итә.*

** Телең пәке булса, тәнеңә ук кадалыр.*

** Сакау белән маймылга әлифба кирәкми.*

** Телдән әйтелгән сүз җилгә очарга да мөмкин.*

** Паспортына «русская береза» дип язылгач, татар каеннары милләтсез калды.*

** Язылмый калган шигырь үзен-үзе сагына.*

** Сүз һәлак булса, эш тә һәлак була.*

** Әйткәнең бер хикмәт булса, әйтеп бетермәгәнең тагын да хикмәтлерәк.*

** Күп һәм озын сөйләү — зирәклек билгесе түгел.*

** Кеше күбрәк сөйләгән саен аның ахмаклыгы яки зирәклеге ныграк ачыла.*

** Кызларның күңел тәрәзәсен шакыр өчен татлы-шифалы сүзләр табуың фарыз.*

** Начар сүзләрне — яманлык, яхшы сүзләрне безгә дөреслек үзе әйтеп тора.*

** Әйтеләсе сүзләрдән башка бер генә идея дә чынга аша алмый.*

** Дөрес әйтелгән сүзне балта белән дә юна алмыйсың.*

** Фикердә ялгышсаң — сүзләр, сүзләрдә ялгышсаң эшләр хәртиләнә.*

** Яхшы фикергә таба сүзләр, магнит сыман, үзләре тартыла.*

** Сүзләрнең кыскалыгы фикер киңлегенә хезмәт итәргә тиеш.*

** Яңгыравык фразалар һаваны ярырга мөмкин, ләкин алар йөрәккә барып җитми.*

** Бәхәс кул сугышы белән төгәлләнсә, дөреслек гарип хәлгә төшә.*

** Яман белән бәхәсләшү теш сызлаудан да яманрак.*

** Бәхәстә дурак җиңүче була алмый.*

** Бәхәстә җиңгән кеше дустын югалтырга мөмкин.*

** Әйтер сүзең озынга һәм болганчыкка китсә, бу — үзеңдәге кимчелекне яшерергә тырышу билгесе.*

** Эзоп теле яртылаш сөйләшүгә урын калдырмый.*

** Анекдотларга караганда канатлы сүзләр ныграк истә кала.*

** Сүз кылыч йөзен сындырырга мөмкин.*

** Тау белән үзәннәр икесе ике телдә сөйли һәм җырлый.*

** Ахмак сорауларга да акыллы җавап табарга мөмкин.*

** Кеше буш сүзне күбрәк сөйләгән саен ахмаклыгына таба якыная.*

** Халыкара сәясәттә сүзләр түгел, төрле калибрдагы идеяләр өстенлек итә.*

** Фикере сай булган кеше тасма телләнеп сөйләшер.*

** Юморда йомры сүз кыйммәтле.*

** Телбизәкләр бакчасына керү өчен күңел бизәкләрең дә мулдан булырга тиеш.*

** Төрмәдә диварлар да сөйләшә.*

** Көндәшең кызып китсә, аның авызын юмор белән томала!*

** Шигърият тормыштагы хаосны орфия пәрдә белән каплау сәләтенә дә ия.*

** Кыскалык — талант сеңлесе, ләкин гонорарның үги анасы.*

** Акыллы бер җөмлә чиле-пешле романны сугып егарга мөмкин.*

** Пычакның үткене, сүзнең тапкыры кыйммәт.*

** Корыган агачның суты, мәгънәсез сүзнең тозы булмас.*

** Әгәр әдәбият чишмәләре корый икән, безне бернинди икътисад та коткара алмый.*

** Каурыйлы каләм затлы кулда гына затлы сүзләрне тәсдыйк итәр.*

** Язучы каләме тукран тормышына тиң: һаман җан тырмашып эшләгән саен ул хакыйкатьнең үзәгенә юл яра.*

** Матур итеп сөйләү сүзләргә генә түгел, эш-хәрәкәтнең асылына да нык бәйле.*

** Такылдыкның иреннәре йомылмас.*

# «И МӨКАТДӘС МОҢЛЫ САЗЫМ, УЙНАДЫҢ СИН НИК БИК АЗ?»

ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ ВАФАТЫНА 100 ЕЛ ТУЛДЫ...

Мәҗит
Гафури

## Г.Тукай вафатыннан соң

**Көтмәгәндә кайгы салды безгә бу көндә фәләк[1]:**
**Әй сөекле яшь шагыйрькәй, син югалдың иртәрәк.**

**Тар күреп бу чикле тормышны үз башына,**
**Кайтты «нәфсе мөтмаиннәң» инде үз «Алласына».**

**Гали рухың бу түбән дөньяны һич тиңсенмәде,**
**Тик бүтән дөньяга китте, ул бөтенләй үлмәде.**

**Үлмәдең син, чөнки бу көн һәр татар күңлендә син,**
**Бетмәдең син, һәр кеше сүзендә син, телендә син...**

**Һичвакытта чыкмас истән монда кыйлган эшләрең,**
**Һәрвакыт сөелеп укылыр бар «Күңел җимешләре» ң[2].**

**Син сөеклесең, сине шулай сөя һәрбер татар,**
**Сиңа каршы ихтирам һәрбер татар күңлендә бар.**

**Югалуың – зур авырлык, һәммәбезгә син әрәм,**
**Бар кешеләрдән дә артык мин елап хәсрәтләнәм.**

[1] Фәләк. - язмыш.
[2] «Күңел җимешләре» - шул исемдәге шигырьләр җыентыгы.

# ТУКАЙ — МӘҢГЕГӘ ХАЛЫК КҮҢЕЛЕНДӘ

Шагыйребезнең вафатыннан соң Җир шарын дистәләгән революция тетрәтте, мәңгелектәй тоелган империяләр чәлпәрәмә килде. Искермәс-тузмас кебек тоелган тәгълиматлар тутыгып, күгәреп, юкка чыктылар.

Ә Тукай иҗаты «халкымыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф раушан көзгесе»дәй, тарихыбыз белән сугарылган, моңыбызга, халык иҗатына төрелгән хәзинә булып калды.

Тукай — безгә тарих тарафыннан татарлыгыбызны саклау өчен бирелгән ядкәр. Ул үзенең кыска гына гомерен чәчми-түкми милләтенә хезмәт итүгә багышлый. Гомеренең тәүге көннәреннән башлап соңгысына кадәр халык белән яши, аның авыр язмышын үз язмышы рәвешендә кичерә. Моның шулай икәнлеге аның «Милли моннар»ында бигрәк тә ачык чагыла:

*Ишеттем мин кичә: берәү җырлый*
*Чын безнеңчә матур, милли көй...*

Бу «берәү» дигәне — «Болгар» кунакханәсендәге күршесе шагыйрь Сәгыйть Рәмиев. Ул җырлый, шагыйрьнең күз алдына исә чал тарих килеп баса. Җыр аның күңелендә бөек чорыбыз һәм коллык упкынына төшкән «мескен булып торган өч йөз ел» арасындагы контраст картинаны тудыра. Күз алдына үрнәк һөнәрчелеге, сүүткәргечләре булган, дөньяга кәрван юллары белән тоташкан Болгар килеп баса. Дустының җырлавы анарда үткәнебезне сагыну хисләрен уята.

Әйтерсең лә, аның үз күңеленнән дә «сызылып-сызылып» милли хисләр сугарылган әнә шул җыр туа. Гүя ул җырчыга кушылып җырлый, халкыбыз тарихын күз яшьләре белән юа, җырчы белән бергә үзе дә «өзелеп-өзелеп кенә әйтеп бирә татар күңеле ниләр сизгәнен.»

Әйе, ул татар күңеле ниләр сизгәнен һәрвакыт барлап, үз күңеле аша уздырган, халкының үткәнен һәм үзе яшәгән бүгенгесен барлап, аңа үз бәясен бирә килгән. Ул чыннан да, үзе әйткәнчә, коеп куйган шагыйрь генә түгел, сәясәтче дә, җәмәгать эшлеклесе дә.

Без анын «Шүрәле»сенә бер авыл егете Былтырның урман җене белән булган мавыктыргыч маҗаралары итеп кенә карарга күнеккән. Ә бит монда шагыйрьнең күпләребез игътибар итмәгән үткән тарихыбызга карашы да чагылган. Шагыйрь Чыңгыз гаскәре төшенчәсен урмандагы бихисап агачлар белән чагыштыру өчен генә кулланмый. Аның күз алдына кылт итеп борынгы бабаларның батырлыклары, дәүләтләре килеп баса, тарихның пәрдәсе ачылган кебек була, анарда уфтану хисләрен уята: «Аһ, — дисең, — без ник болай соң? Без дә хакның бәндәсе!».

Әйе, без ник болай соң? Без кемнән ким? Кайда ул безнең дәүләтләребез, кодрәтебез? Боларның берсе дә юк. Алар «бер дә булмаган төсле кырылдылар да беттеләр, эзләре дә калмады», — дип яза Тукай. Ул милләтенең мескен, кол рәвешендә булуына борчыла. Бөеклегебезгә кайту хыялы белән яна. «Кайчан соң, и факыйр милләт, бәһарын (язын), Кайчан китәр кичең, килер нәһарың (көндезең). Килерме әллә кабергә мин сөрелгәч, Кыямәт көндә мин үлеп терелгәч?», — дип, милләтенең, бигрәк тә яшьләрнең акырын уянуына борчыла. «Бара милләт зәгыйфь, абныр-абынмас, Сүнә яшьләрдә ут кабныр-кабынмас».

Шагыйрь 1905 ел революциясенә зур өметләр баглый. «Без Бишенче елны бер көнне уяндык таң белән». Аның бу сүзләре шул ук вакытта XIX-XX гасыр чикләрендәге татар алгарышына өмет баглавы. Чыннан да, шушы елларда

татарларның меңләгән тираж белән чыга торган китаплары, утыздан артык газета-журналлары, берсеннән-берсе сәләтле дистәләгән язучылары, журналистлары, театр, музыка сәнгате барлыкка килә. Халкыбызның милли горурлыгы уяна, ул, бер газета язганча, гүреннән торып өстеннән кабер туфрагын кагып төшерә дә, горур рәвештә янә тарих мәйданына чыга. Милләт абынудан туктый, яшьләрдә сүнмәс дәрт туа. Татар, Тукай язганча, үлмәгән дә, йокламаган да, бары тик хушы гына киткән була. Ул 1552 елда башланган, Габделбарый Баттал сүзләре белән әйткәндә, урыс җәһәннәменнән, мескенлектән чыга башлый. Аны милли хисләр биләп ала.

Шушы янарыш дулкынында милләтебезнең тарихи хәтере хәрәкәткә килә, үз тарихы белән кызыксынуы беренче урынга чыга. Иж Буби шәкертләре әйтүенчә, «бер нәрсәне дә яшермәстән, үткәнебезне һәм бүгенебезне ачыкларга» вакыт житә. Шушы ачыклау эшен Шиһабетдин Мәрҗани башлап җибәрә. Һади Атласи, Гайнетдин Әхмәрев, Газиз Гобәйдуллин кебек тарихчылар аны дәвам итәләр. Аларның хезмәтләре халкыбызның милли горурлыгын уята.

Тукай тарихчыларыбызның эшчәнлеген күзәтеп бара. Ул бигрәк тә иң беренчеләрдән булып тарихыбызны барлый башлаган Шиһабетдин Мәрҗанине олылый. Ләкин ул, профессионал тарихчылардан аермалы буларак, үткәнебезне иң әүвәл халык иҗаты аша төсмерли. Тарихыбызны «туплар да атмаган, уклар да кадамаган» рәвештә күрә, аны тутыкмас күзгегә тиңләп, халыкның тарихи хәтерен уяту чыганагы, дип саный.

Шагыйрь тарихыбызны халык иҗатының җәүһәре булган җыр-моң аша да төсмерли. Ул аларга гашыйк. Аларны тыңлаганда «аркадан каннар йөгерә», ди ул, һәм моңыбызның «алтынын коймаска» өнди. Бала чагында урман буенда ат көткән вакытларында Сәйфетдин вә Гайнетдиннәрнең учак кырыенда «җырлаган җырлары һәм дә моңлы күңелләреннән чыккан хиссият утлары минем йөрәгемә тәэсир итәләр иде», бу «җырлаулар» минем күңелемнең иң нечкә кылларына тукыналар», дип язган Тукай.

«Мин кечкенәдән үк җырчы идем. Кайда ишетсәм дә, җырлау тавышын салкын кан белән тыңлый алмый идем». «Кечкенәдән үк күңелемә урнашкан җырулар сөймәкемнән миндә туган телебезне сөю туды.» «Яшәсен халык әдәбияты, яшәсен туган тел!» Күренә ки, монда җыр аша туган телебезгә мәхәббәт ярылып ята. Тукай шушы мәхәббәтне җыр-моң аша яшь буынга сеңдерүне беренче урынга чыгара. Кешенең балалык чорына махсус игътибар бирә, чын татар булуны баланың дөньяга килүе белән үк башларга кирәклеген аңлап эш итә. Шагыйрьнең балаларга багышланган шигырьләрендә әйтерсең лә җыр, моң, туган тел бер җепкә тезелгәннәр.

Тукай иҗатында юкка гына бишек җырларына махсус игътибар бирелмәгәндер. Җыр, аның көе, тел — татар кешесенең гомерлек юлдашы. «Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән, аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән». Ана кеше моң аша баласының Аллаһ Тәгалә биргән туган телен ача. Әбисе мавыктыргыч әкиятләр белән аны баланың күңелендә ныгыта, анда аны камил рәвештә урнаштыра. Тукайның «Бишек җыруы»нда «Әлли-бәлли көйләрем, хикәяләр сөйләрем, сина теләк теләрем, бәхетле бул диярем» дигән сүзләр язылган. Монда ананың моң һәм тел аша Аллаһ Тәгаләдән бала өчен изге теләкләр теләү нияте ята.

Тукайның «Ана догасы» нда бу бигрәк тә матур чагылыш таба. Авыл киче, тирә-як тып-тын, халык йокыга талган, хәтта этләр дә өрми. Күктә нурлы ай калкып, тирә-якка нур чәчә. Тик бер өйдә генә ут сүнмәгән. Анда бер ана намазлык өстендә Аллаһыдан теләк тели. «Ходаем, — ди, — бәхетле булсайде сөйгән газиз углым!» Күзеннән тамчы-тамчы яшь тама. «Карагыз, — ди шагыйрь — шул догамы инде Тәңре каршына бармас?»

Ул гомумән баланың итагатьле, мәрхәмәтле, эшсөяр рәвештә зур дөньяга чыгуын беренче урынга куя. Баланың үзенә мөрәҗәгать итеп, «Тынма, эшлә, и, сабый! Бел, Тәңредән эшләргә — көн, Эшләп аргачтан, бирелгәндер тыныч йокыга төн», дип, аны кояштан үрнәк алырга чакыра. Кояшның иртә торып, таң аттырып, көнозын күктә

йөзеп, дөньяны яктыртып арыганнан соң «ирнеп кенә тауга батуын тасвирлый. «Син кояштан үрнәк алсаң, иҗтиһат итсәң һаман, Күк арасында кояш күк ялтырарсың берзаман!» — дип, аны якты киләчәккә чакыра. Искиткеч төсмерле, мавыктыргыч рәвештә язылган «Эш беткәч уйнарга ярый» шигыренең иseme үк шагыйрьнең бала күңелендә хезмәткә ихтирамны арттыруга багышланган. Балаларга атап язылган дистәләгән әсәрләрендә ул аларга милли хисләр сеңдерүне җыр-моң, халык иҗаты аша татарлык оеткысын салуны беренче урынга чыгара.

Тукай татар җырларына нечкә кыллар белән тукылганнары өчен генә түгел, телебезнең сакчысы булганнар өчен дә гашыйк. «Халык җырларына әһәмият бирергә кирәк дип кат-кат әйтелде инде. Ни өчен әһәмият бирергә кирәк? Шуның өчен ки, чын халык телен, чын халык рухын безгә тик халык җыруларыннан гына табып була. Аннан башка кайдан табасың?» Әйе, кайдан табасың?

*Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен,*
*Тибрәтмәкче булсаң иң нечкә кылларын,*
*Көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен,*
*Кирәк түгел мәгънәсе юк көлке, уен.*

Бу, әлбәттә, яшәештә уен-көлкегә урын булмаска тиеш дигән сүз түгел. Тукай иҗатында аларга да шактый урын бирелгән. Тик менә шагыйрь һәрвакыт диярлек халык күңелләрен кузгата, аның нечкә кылларын тибрәтә торган көйләргә өстенлек бирә килгән. Аларны ул милли рухыбызны ныгыту чыганагы итеп санаган. Тукайга, күрәсең, моңыбызның эченә үтеп керердәй сәләт иңдерелгән, аның сихри көчен аңлардай мөмкинлекләр бирелгән.

Ул халкын, аның иҗатын бөтен җаны-күңеле белән сөйгәнгә күрә үзенең кыскадан кыска гомеренең шактый өлешен моң һәм халык әдәбиятын барлау һәм җыйнауга багышлый. 1910 елны Шәрык клубында укыган лекциясендә аларның берсен — ачкыч, икенчесен йозак дип бәяли. Ачкыч белән яки моң аша халык күңеленә үтеп кереп була, йозак белән яки халыкның бертуктаусыз байый барган җор, шигъри теле белән аны саклап була. Чыннан да, бары тик гасырлар буе буыннан-буынга күчеп, үзенә үткән бай вә фаҗигале тарихыбызны сеңдерә барган моң һәм әдәби мирас кына ачкыч белән йозак рәвешендә яши алалар. Болар күпмедер дәрәҗәдә игезәкләрне хәтерләтәләр.

Тукайның шушы искиткеч чагыштыруын бүгенге иҗат кешеләре дә үзләренә күрсәтмә итеп кабул итсәләр, бу, бәлки, милли моңнарыбызны, җырларыбызны каплап, томалап бара торган бүгенге мәнсез-мәгънәсез җырларга киртә булыр иде. Ә киртә кирәк, чөнки тел һәм милли моң — милләт сакчылары.

Тукай юкка гына шактый җырларның тарихын өйрәнеп, аларны төрле яктан анализламаган. Ул аларның бабаларыбыз тарафыннан калдырылган «иң кадерле вә иң бәһале бер мирас» икәнлеген аңлап эш иткән. Болгар шәһәрләре, Болгар авыллары «беттеләр, эзләре дә калмады», әмма алар «халкыбыз күңелендә «һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф раушан көзгеседер», дип язган шагыйребез. Ул тәгаен мисаллар белән халык җырларының яшәү көзгесе икәнлеген күрсәтә алган. Аларны укыганда Тукайның рухи дөньясы халыкчанлык хисе белән сугарылуына тагын бер кат инанасың.

Тукай шактый күп җырларны җыеп, туплап кына калмый, аларның тарихы турында мәгълүмат та бирә. Мәсьәлән, «Тәфкилев» көе мөфти Тәфкилев кызының француз егетенә булган бәхетсез мәхәббәтенә багышланган. Шагыйрь бәхетсез мәхәббәтнең тамырлары шактый тирән икәнлеген аңлап эш иткән булса кирәк. Анын «Җырлар дәфтәр»ендә «Хан кызы көе» дә булган. Тик ул аннан ертып алынган. Кем белә, бәлки, ул Алтын Урда ханы Туктамыш кызының бәхетсез мәхәббәтенә багышланган җырның берәр варианты булгандыр. Туктамыш ханның кызы Нәнекәйҗан караим егетенә гашыйк була. Хан, әлбәттә, башка диндәге егеткә кызын бирергә теләми. Кайгысыннан кыз текә кыядан сикереп, үзен үлемгә дучар итә. Шушы җырны ишеткән Зәки Вәлиди «Анын көе «Тәфтиләү»не хәтерләтә иде, дип язып калдырган. Димәк, җырның көе, әлбәттә,ниндидер үзгәрешләр белән

саклана килгән, сүзләре исә һәрвакыт диярлек заман фаҗигасенә җайлаштырылган булып чыга.

Тукай аша без «Ашказар» көен дә шундый ук бәхетсез мәхәббәт тудырганлыгын беләбез. Бу хәл анын тарафыннан тупланган, тикшерелгән башка җырларның сүзләре һәм моннары да «ачкыч белән йозак» мөнәсәбәтендә яшәгәнлекләренә дәлил булып тора.

Шул ук вакытта Тукай халык иҗатының бертуктаусыз байый баруына да игътибар иткән. Ул аларның үзе ишеткән төрле вариантларыннан мисаллар китереп, шуның белән халыкның үзендә җырга нигез салучыларның туа торуына ишарә ясаган.

Шагыйрьнең «Халык әдәбияты» мәкаләсенең «Туган тел» шигыре белән тәмамлануы очраклы түгелдер. Ул тикмәгә генә милли гимныбызга әверелмәгән инде.

Бәлки, Тукай аларны тупламаса, бу халык җәүһәрләренең күбесе инде онытылган да булыр иде. Нинди генә җырлар юк монда.

Җырларыбызны җыеп туплау кебек зур эшне яшь шагыйрь Җаекта (Уральск) вакытта ук башлап җибәргән һәм аны гомере буе дәвам иткән. Әгәр дә без Тукайны халык җырларын җыю традициясен башлап җибәрүчеләрнең беренчеләреннән булган дисәк, әллә ни зур хата булмастыр. Анын «Сабах» нәшриятында чыккан дәвамчыларына үрнәк булып торырдай җырлар җыентыгы шул турыда сөйли.

Ул Җаекта үткәрелгән әдәби-музыкаль кичәгә багышланган бер мәкаләсендә «Тәфкилев», «Әллүки», «Сакмар суы» кебек җырларны «карт аталарыбызның чын йөрәгеннән чыккан» дип, «туган һәм туачак балаларыбызның күңеленә яңа-яңа милләт хисләре... саба җиле шикелле, рух өрәчәктер», дип язган.

Шулай булсын да иде. Милли хисләр белән сугарылган «саба җилләре» бүгенге музыкаль сәнгатебезгә дә рух өреп торса икән. Гөлсем Сөләйманова, Зифа Басыйрова, Фәридә Кудашева, Флера Сөләйманова, Зөһрә Сәхабиева, Ания Туишева, Рабига Сибгатуллина, Нажия Теркулова, Габдулла Рәхимкулов, Хәйдәр Бигичев, Илһам Шакиров, Мирсәет Сөнгатуллин, Идрис Газиев, Фердинанд Сәлахов, Шамил Әхмәтҗанов, Айдар Фәйзрахманов, Искәндәр Биктаһиров, Миргаяз Шәрәфиев кебек җырчыларыбызның иҗатларын баеткан кебек.

Аларның иҗатында Тукаебызның бу сүзләре язылмаган закон рәвешендә яши. Аллага шөкер, бүгенге яшь җырчыларыбыз арасында да андыйлар юк түгел. Телевидениенең ТНВ каналында бара торган «Җырлыйк әле!» һәм бигрәк тә ГТРКның радио тапшыруларында бу шактый яхшы чагыла. Тик шулай да бездә үзешчән сәнгатькә игътибар җитми әле. Ә бит халык иҗатына, анын җыр-моңына гашыйк яшьләр нәкъ шунда үсеп чыгалар.

Тукай татар шигъриятенең төзелешенә, бигрәк тә анын үтемле якларына махсус игътибар биргән. «Без татарларның шигырь сөйли торган бәхерләре (үлчәүләре – И.Т.) гаять гүзәлләр. Бер татар шигырен әллә ничә төрле көйләргә-җырларга мөмкиндер һәм хәтта татарлар җырлый торган көйгә рус шагыйрьләренең шигырьләре дә килеп торадыр», дип язган ул. Күренекле рус этнографы мәрхүм профессор Евгений Прокофьевич Бусыгин бу турыда һәрвакыт сөйли, бик күп рус җырларының татар көйләре белән сугарылганлыгын ассызыклый иде. Шаляпинның җырларында да татар элементлары барлыгы турында язып чыгучылар булды. Татар моңына төрелеп, аннан рухланып яшәгән җырчының иҗатында моңның шулай булмавы мөмкин дә түгел. Заманында «Тәфтиләү», «Озын су», «Мөхәммәдия», «Ашказар» кебек татар халык җәүһәрләрен скрипкачы Козлов, Трейтер кебек җырчы тикмәгә генә башкармагандыр.

Татар моңы – борынгы төркиләр моңы. Ул үзенә киң далаларда яшәгән борынгы бабаларыбызның эчке хисләрен сеңдергән. Бер вакыт безнең тарих факультетында стажировка үтүче кытай профессоры Чянь-Бин: «Ә бит бездә сезнең музыкагыз. Без аны сездән алып, бөтен Ерак Көнчыгышка, Япон утрауларына кадәр тараттык», – дигән иде. Бу чыннан да шулай. Профессор Марсель Бакировның хезмәтләрендә бер-ике мең ел элек Кытай императорларының төркиләр янына, аларның көйләрен язып алу өчен, композиторлар җибәрү фактлары күрсәтелгән. Шулай булгач, нишләп аны татарлар белән йөзләгән ел янәшә гомер кичергән руслар үзләштермәсен икән?

Юк, мин һич кенә дә рус музыкаль культурасын шик астына куймыйм. Ул бөек. Әмма борынгы рус халык җырларының татар моңнары белән дә аваздашлыгына шикләнмим.

Тукай исә моны бик яхшы тоемлаган. Ул нәкъ шунлыктан Пушкинның бер шигырен татар көенә җырлау мисалын китергән.

«Еду, еду в чистом поле,
«Жизнәкәй» (2 кәррә)
Колокольчик динь- динь- динь...
«Балдызым, ялгызым» (бер кәррә).

Боларны язган вакытта аның алдында русларның «Народные песни» китабы булган. Тукайның шигырьләре дә, барлык язмалары да могҗизави моң булып яңгырый. Аңа халык шагыйре исемен бернинди указ белән дә бирмәгәннәр. Халык үзе биргән исем ул. «Мине әгәр синеке дип исәпләсәләр, мин бәхетле», дип язган шагыйрь. Ул милләт хыялын барлык хыяллардан да татлырак санаган: «Әгәр милләт мине, илтифат итеп, искә алса, шул минем максатым, теләгем һәм бәхетем». Теләге кабул була.

Халык аның үлеме турындагы хәбәрне гомум кайгы рәвешендә кабул итә. Бу көнне барлык татарлар да елыйлар, чөнки алар үзләренең бөек сүз патшасын югалттылар, дип язган «Кояш» газетасы. Шул көндә чыккан газеталар, шагыйрь үзе калдырган 500 сум акчага Тукай фондын булдыру максатыннан «Тәрҗеман» газетасы үзеннән 100 сум өстәде һәм башкаларны да шушы башлангычка кушылырга чакырды, дип язганнар.

Һәммә җирдә, Кытайның Голжа шәһәреннән башлап Петербургка, Әстерханга кадәр булган барлык җирләрдә дә диярлек, Тукай җәмгыятьләре барлыкка килә. Шагыйрьгә багышланган кичәләр үткәрелә. 1913 елның 14 ноябрендә Казанда Тукай җәмгыяте оеша.Ул үзенең төп максаты итеп мохтаҗ язучыларга ярдәм итүне билгели. Әстерханда да Тукай җәмгыяте булдырыла, аны күренекле әзәрбайҗан җәмәгать эшлеклесе Нәриман Нәриманов җитәкли. Бу шәһәрдә 1914 елда сигезенче мәчетнен указлы мулласы Абдрахман Умеров «Тукай Уральскийда» исемле китап чыгара. Саратовта мәүлет бәйрәме вакытында Тукай шигырьләре янгырый, аңа фатиха укыла.

Мәкәрҗә ярминкәсендә аның сайланма әсәрләре һәм аерым әсәрләре күпләп сатыла. Петербург университетында һәм андагы хатын-кызлар курсларында Тукай исемендәге ике стипендия булдырыла. Инде искә алынган Голжа шәһәреннән хаҗга баручылар да әлеге стипендия фондына 50 сум акча кертәләр. Германиядәге Шакир әфәнде аның рәсеме төшерелгән открыткалар ясатып, аларны сатудан килгән акчаны шулай ук аның исемендәге стипендия фондына бирәчәген әйтә.

Мондый эшләргә каршы төшүчеләр дә табылмый түгел. Мәсәлән, Оренбургта һәм Читада ике студентның Тукай иҗатына багышланган лекцияләре тыела. Казанда шушы эшләрне башкарырга тырышкан ике укытучыны эштән чыгаралар. Ләкин төрки һәм ислам дөньясында шагыйрьнең даны шулкадәр киң таралган була ки, аңа ихтирам йөзеннән туган халык хәрәкәтен беркем дә, берничек тә туктата алмый.

1913 елның апрелендә Бакуда рус телендә нәшер ителгән мөселман газетасында «Каспий»да «Дагестани» имзасы белән «Мөселман язмалары. Бер үлем тирәсендә» дип аталган мәкалә басыла. Анда мондый сүзләр бар: «Сүзе белән йөрәкләрне яндырган шагыйрьнең истәлеге һәркем өчен дә кадерле. Сигез ел буе иҗтимагый эшләрдә катнаша килсәм дә, әле беркайчан да мөселманнарның сәнгать остазын /жрец/ югалтулары өчен бу кадәр кайгырганнарын күргәнем юк иде... Идел буе мөселманнары культура һәм аң дәрәҗәләре белән без кавказлыларны уздырдылар. Русия мөселманнары үз шагыйрьләренең бәясен аңладылар һәм аңа тиешле бәя бирә башладылар».

Тукайны төркиләр генә түгел, барлык башка мөселман халыклары да яраткан, үз иткән. Күренекле таҗик язучысы Садретдин Әйнидән, революциягә кадәр Пушкин белән Лермонтовны белә иденме, дип сораганнар. Ул моңа, әйе, белә идем, Тукай аша, дип җавап биргән.

«Мине әгәр синеке дип исәпләсәләр, мин бәхетле», «барлык уем кичен дә,

көндезен дә сезнең турыда, милләтем» дип язган шагыйрь.. Ул милләт хыялын барлык хыяллардан да татлырак санаган. «Әгәр милләт мине, илтифат итеп, искә алса, шул минем максатым, теләгем һәм бәхетем».

Ул шушы рәвештә яшәгән һәм милли хисләр кичереп якты дөнья белән хушлашкан. «Күнел кошы» бу дөнья читлегеннән тарсынып киткән булса да, рухы халкыбыз күнелендә. Ул безгә яшәү көче биреп тора. Тукайлы халык – мәңгелек халык.

**Индус ТАҺИРОВ**

---

***

**Мәктәбем дә, телем дә ул Тукай,**
**Тукайдагы кебек тел кайда?!**
**Мең елдан соң да бер синең, илем,**
**Кайтасыңны беләм Тукайга.**

**Сибгат ХӘКИМ**

## Габдулла Тукайга

**Белмим, кайсы таулар күкрәгеннән**
**Һәйкәлеңнең ташы, тимере, –**
**Тик син үзең халык йөрәгеннән.**
**Халык мәхәббәте – синең исемең,**
**Халык гомере – синең гомерең.**

**Әхмәт ФӘЙЗИ**

***

*Тукай - үзенең замандашлары, яшьтәшләре өчен генә түгел, үзеннән бик күпкә яшь кешеләргә дә, киләчәктә туачак балаларга да замандаш булган шагыйрь. Тукай һәр буынга яшьтәш. Тукай һәр буын белән яңара. Чөнки Тукай - гасырлар шагыйре.*

**Сәгыйть АГИШ**

***

*Тукай - бөек шагыйрь, ләкин шул ук вакытта Тукай табигать тарафыннан язылган үзе бер бөек шигырь, буыннан буынга җырлана торган шигырь, буыннан буынга серләре ачыла барган шигырь, шат шигырь, кайгы-хәсрәтле шигырь, тугрылыклы, зур вөҗданлы шигырь, дошманнарына аяусыз, көрәшче шигырь.*

**Нажар НӘҖМИ**



*Тукайның вафатына 14 көн кала, 1913 елның 1 апрелендә хастаханәдә төшерелгән иң соңгы ике фоторәсеме.*






*Шагыйрьне соңгы юлга озату. 1913 елның 17 апреле.*

# ТУКАЙ ӘСӘРЛӘРЕ — ГРАММОФОНДА

Бөек шагыйребез Габдулла Тукайның вафат булуына быел йөз ел... Кеше гомере өчен йөз ел ул бик зур вакыт, ә менә милләтебезнең олы язмыш юлына нур сипкән иң якты йолдыз — Габдулла Тукаебыз өчен бер гасыр — ул мәңгелекнең башлангычы гына. Татар классигының милләт өчен эшләгән эшләре, аның бәһаләп бетергесез әдәби мирасы шулай дип әйтергә мөмкинлек бирә. Туган халкына намуслы хезмәт итүне төп максат итеп куйган Шагыйрьнең сөйгән халкының кайгысы, шатлыгы, киләчәге турындагы әчкерсез борчылулары белән сугарылган мирасын безгә, бүгенге көндә яшәүчеләргә генә түгел, киләчәк буыннарга да өйрәнәсе дә өйрәнәсе әле.



*IX — XX гасырларда кулланышта булган граммофон.*

Менә шул өйрәнәсе мирасның үзенчәлекле бер өлеше — ул да булса Г.Тукай әсәрләренең шагыйрьнең замандашлары — жырчылар, артистлар тарафыннан граммофон тәлинкәләренә яздырып калдырган фонограммалар. Әйтергә кирәк, Г.Тукайның Уральскидагы чорында ук иҗат ителгән беренче шигырьләре газета битләрендә басылып чыгуга халык арасында тарала. Беренче әдәби-музыкаль кичәләрдә яңа иҗат иткән әсәрләрен шагыйрь үзе укып ишеттерә, аның белән бергә мәдрәсәдә белем алган шәкертләр башкарган Г.Тукай шигырьләрен дә халык тарафыннан бик жылы кабул итә. Шагыйрьнең әсәрләрен беренче татар артистлары сәхнәгә күтәрә, тора-бара аның иҗат җимешләре халык арасында популяр булган көйләргә җырлана да башлый. Шуның өчен дә XIX гасыр башында Рәсәйдә киң колач җәйгән граммофон индустриясе өлкәсендәге беренче татар язмалары арасында Г.Тукайның да әсәрләре булуын табигый хәл дип карарга кирәктер.

Гомумән, беренче рус революциясеннән соң граммофонның шәһәр мәдәнияте тормышындагы урыны турында «Казан утлары» журналы битләрендә язып чыккан идем инде[1]. Буржуаз мөнәсәбәтләрнең чәчкә аткан чорында Рәсәйдә үзләренең эшчәнлеген алып барган һәм коммерциянең файда китерү ягын караган граммофон ширкәтләре милли язмаларны да аудиоиндустрия базарына чыгаруны читкә атмый. Тавыш язу сессияләрендә катнашкан артистлар үзләре дә бу эшләре өчен азмы-күпме булса да гонорар алганнар[2].

Граммофон өлкәсендәге эзләнүләр барышында татар артистларының тәлинкәләрдәге һәм дисклардагы язмалары менәрчә тираж белән чыгарылып сатылуы, аларны төрле милли басмалардагы рекламалар аша чагылуы ачыкланды. Тәлинкәләрдәге сакланып калган җырлар, шигырьләр, хикәяләр, монологлар белән бергә төрле мәгълүмат тупланган махсус каталоглар өстендә эшләү барышында

[1] Татар җыры — йөз ел элек. // Казан утлары, 2008. №10. –153-165 Б.; Граммофон тәлинкәләре ни сөйли? // Казан утлары, 2011. №10. 134-145 Б.

[2] Әйткәндәй, ул чакта Рәсәйдә граммофон ширкәтләрендә артистларга, һәр язган әсәр өчен сәләтләренә, осталыкларына, популярлыгына һәм тәлинкәләрнең сатылуына карап уртача 5 тәңкәдән алып 500 тәңкәгә кадәр акча түләгәннәр. 500 ләләр әллә ни күп булмагандыр, ахыры, һәрхәлдә, бу турыдагы булган мәгълүматлар шуңа күрсәтә. Әйткәч әйтим инде, Октябрь революциясенә кадәр Рәсәйдәге иң зур гонорарлы артист — ул бөек рус җырчысы Ф.И.Шаляпин. Аңа бер җыр, романс, яки ария яздырган өчен 2000 тәңкә гонорар түләгәннәр.

бу өлкәдә Г.Тукай әсәрләренең язмалары да халык арасында популяр булуын күрсәтте. XIX гасыр башында үзенчәлекле кинкүләм мәгълүмат чарасы ролен үтәгән граммофон Рәсәйнен күп төбәкләрендә яшәгән татарларга башка язмалар белән беррәттән шагыйрьнең әсәрләре теркәлгән язмаларны житкерде, Г.Тукайның дөнья күргән китап һәм җыентыклары белән бергә аның иҗатын тирәнрәк өйрәнү мөмкинлеген бирде.

Классик шагыйребез әсәрләренең беренче аудио-язмаларына кагылышлы мәгълүмат юк дәрәҗәдә, аларның билгелесе күренекле китапчы, галим, библиограф Исмәгыйль Рәминең (1895-1969) «Әдәби сүзлеге»ндә китерелгән зур булмаган белешмә. Анда автор 1910-1913 елларда «Пате» граммофон ширкәте Г.Тукай әсәрләре буенча язылган пластинкалар сериясе чыгаруы турында билгеләп уза[3].

Төрле чыганаклар өстендә эшләү вакытында шунысы ачыкланды: Г.Тукайның әсәрләре французларның «Пате» ширкәтеннән башка Рәсәй территориясендә үзенең эшчәнлекләрен алып барган «Граммофон», «Зонофон», «Лирофон», «Метрополь-рекорд», «Русское Акционерное Общество Граммофонов» (РАОГ) ширкәтләре тарафыннан чыгарыла.

Эзләнүләр барышында миндә бер сорау туды: Тукайның әсәрләрен граммофон тәлинкәләренә беренчеләрдән булып кемнәр яздырган соң? Кайсы ширкәттә, нинди шәһәрдә, ничәнче елны, нинди студиядә яздырганнар? Шуны ачыклау юлында байтак чыганакларга — традицион басма чыганаклар (газета-журналлар, китаплар, җыр җыентыклары, каталоглар) һәм традицион булмаган чыганаклар (граммофон тәлинкәләрендәге, «Пате» дискларындагы язмалар, тәлинкәләрдәге этикеткалар) мөрәҗәгать итәргә туры килде. Бу ачыклаулар юлында күренекле инглиз дискографы А.Келли әфәнденең «Рус язмалары каталогы» һәм «Көнчыгыш язмалары каталогы» аеруча ярдәм итте. Алга куйган мәсьәләне чишүдә сакланып калган граммофон язмалары, әлбәттә, төп чыганак булып калды.

Монда шуны әйтеп үтәргә кирәк: кайбер басма чыганакларда шагыйрьнең әсәрләре теркәлгән граммофон язмаларының дөньяга чыгуы Г.Тукайның вафатыннан файдаланган коммерсантларның эшчәнлеге белән бәйле булуына ишарәләү күренә. Моның белән бөтенләй үк ризалашып бетеп булмый. Дөрес, 1913 елда, шагыйрьнең үлеменнән соң бер ай үтмәс борын аның әсәрләреннән торган тәлинкәләрнең сатылуга чыгуы турында «Вакыт» газетасы үзенең бер рекламасы аша хәбәр итә. Ләкин тиз генә арада каядыр, нинди дә ширкәткә барып әсәрләрнең фонограммаларын яздырып, аларны тәлинкәләргә бастырып чыгару ике-өч атналык эш түгел. Әгәр дә тәлинкәләр сатылуга куелган икән, бу граммофон ширкәтләре тарафыннан инде элегрәк язылган фонограммаларга даими рәвештә кайтып, аларның тиражларын кабатлауны аңлата. Шулай итеп, Г.Тукай әле үзе исән чакта ук аның әсәрләре граммофон тәлинкәләренә яздырылган була. Ул гына түгел, граммофондагы язмалар Г.Тукайның 1906-1909 еллар арасында иҗат иткән әсәрләрен үз эченә ала. Түбәндә барачак сүз моны тиешле дәрәҗәдә дәлилләр дип уйлыйм.

Бүгенге көнгә билгеле булган мәгълүмат буенча шуны әйтеп була: Г.Тукай әсәрләренең иң беренче граммофон язмасы 1908 елның февраль аенда дөнья күрә. Инглизләр карамагында булган «Граммофон» ширкәте һәм аның бүлендек предприятиесе «Зонофон»ның Мәскәүдә узган тавыш язу сессиясендә Г.Тукайның «Татар кызларына. Сөям дә, сөймим дә... » (№ X-101122)[4] дигән шигырен музыкант, актёр, режиссёр Ильяс бәк Кудашев-Ашказарский (1884-1942) яздыра. И.Кудашев-Ашказарскийның язмалары турында А.Келлиның «Рус каталогы»нда болай дип язылган: «Россиядәге беренче һәм бердәнбер Мөселман сәйяр драма артистлары труппасының житәкчесе Ильяс Бәк Кудашев-Ашказарский башкаруында сатирик хикәяләр, сценалар һәм поэмалар (Одалар), Казан»[5].

Г.Тукайның «Татар кызларына. Сөям дә, сөймим дә... » әсәре беренче тапкыр «Уклар» журналының 1906 елгы июль (2) санында «Шүрәле» имзасы белән басылып

[3] Рәми И., Р. Даутов. Әдәби сүзлек. Казан: Тат. Кит. нәшр. 2001. 257 Б.

[4] Монда һәм түбәндә: җәяләр эчендәге саннар граммофон ширкәтләре чыгарган каталогларда теге яки бу язманың номерын күрсәтә.

[5] A Complete Numerical Catalogue of Russian Gramophone Recordings made from 1899 to 1929 in Russia and elsewhere by The Gramophone Company Ltd. Compiled by ALAN KELLY with the cooperation of the EMI Music Archive, London, 2009.

чыккан була. Шунысы кызыклы, Г.Тукай үзе исән чакта бу шигырь аның бер җыентыгына да кермәгән[6]. Бу әсәрендә шагыйрь, бер яктан — татар кызларының матурлыгына, әдәплелегенә, эчке гүзәллегенә мәдхия җырласа, икенче яктан — шул кызларның язмышы заяга үтүенә, аларның хокуксыз булып, абыстайлар кул астында наданлыкта яшәвенә, киләчәкләренең өметсез булуына эче поша, бу хәлләрне тәнкыйть астына ала.

Әйтергә кирәк, Г.Тукайның әсәрләре шул чорда концерт-гастроль эшчәнлеге алып барган башкаручыларның репертуарында даими яңгырап тора. Аеруча бу өлкәдә Г.Тукайның укытучысы һәм остазы, татар халкының беренче профессиональ җырчыларыннан булган Камил Мотыйгый (Камил Мотыйгый-Төхфәтуллин, 1883-1941) уныш казана. Җырчы Г.Тукай сүзләренә җырларны әдәби-музыкаль кичәләрдә, үзенең аерым концертларында гына башкарып калмый, ул аларны граммофон тәлинкәләренә дә яздыра. Г.Тукайның шигырьләре аша К.Мотыйгый үзенең җырларында мәхәббәт темасын яңгырата, кыюлык белән үз чорына хас булган социаль темаларны күтәрә, җырлары аша байлыкка, ялганлыкка каршы чыга, татар милләтенең киләчәге турындагы борчылуларын алгы планга куя. К.Мотыйгыйның Г.Тукай шигырьләренә башкарган җырларның беренче язмалары «Зонофон» ширкәтенең Мәскәүдәге студиясендә 1910 елның 7 сентябрендә тормышка аша. Фортепианога кушылып җырчы граммофон тәлинкәләренә «Тотса мәскәүләр якаң» (№ 4-102922), «Кемне сөяргә кирәк» (№ 4-102925), «Зиләйлүк» («Эштән чыгарылган татар кызына») (№ 4-102926), «Ләззәт вә тәм нәрсәдә?» (№ 4-102929), «Мәгъшукамә» (№4-102930) җырларын яздыра.



*Камил Мотыйгый*

Французларның «Пате» ширкәте 1911 елда Мәскәүдә узган татар сессиясе барышында үзенең дискларына К.Мотыйгыйның башка җырлары белән беррәттән Г.Тукайның «Мәгъшукамә» (№ 25740), «Татар кызына» (№ 25741), «Пар ат» (№ 25745)[7], «Туган шәһәр чәйханәсе» («Хатирәи «Бакырган»» шигыренә) (№ 25886), «Тотса мәскәүләр якаң» (№ 25887), «Кемне сөяргә кирәк» (№ 25888), «Кечке азан» (№ 25890) шигырьләренә башкарылган җырларны, шулай ук, фортепиано аккомпанименты белән яздыра.

Франция Милли китапханәсене[8] аудиовизуаль документлар департаменты коллекциясендә К.Мотыйгый башкарган «Мәгъшукамә», «Туган шәһәр чәйханәсе», «Тотса мәскәүләр якаң» һәм «Кичке азан» җырларының язмалары булуы ачыкланды, ул язмаларны тыңларга, өйрәнергә мөмкинчелек туды. К.Мотыйгыйның язмышы һәм иҗаты мине күптәннән кызыксындыра. Шуның өчен дә аның репертуарын ачыклау, язмаларын өйрәнү барышында миндә бер проект туды: табылган граммофон язмаларына нигезләнеп җырчы репертуарын реконструкцияләү. Бу теләгем тормышка ашты һәм бүгенге көндә К.Мотыйгыйның 11 җыры минем концерт репертуарымда урын алды. Татарстанның халык артисткасы, танылган музыкант М.Хәбибуллина җитәкчелегендәге инструменталь трио белән бергә без ул җырларны «Татарстан — Яңа гасыр» радиосы фонды өчен дә яздырдык. Бу язмалар арасында Г.Тукай шигырьләренә «Мәгъшукамә», «Туган шәһәр чәйханәсе», «Тотса мәскәүләр якаң» һәм «Кичке азан» җырлары да бар.

1911-1912 еллар арасында Мәскәүдә урнашкан тагын да бер граммофон ширкәтендә татар язмаларының сессиясе тормышка ашырыла. «Метрополь-рекорд» ширкәтенең 1911 елда чыгарылган татар тәлинкәләре арасында К.Мотыйгыйның фортепианога кушылып Г.Тукай шигырьләренә җырланган язмалары бар: «Бән егъламай, кем егъласын» («Хатирәи «Бакырган»» шигыренә), «Тотса мәскәүләр

[6] Габдулла Тукай. Әсәрләр. — Академик басма. — Алты томда. 1 том: Шигъри әсәрләр (1904-1908). Казан: Татар. кит. нәшр.., 2011. Искәрмә һәм аңлатмалар, 337 Б.
[7] Бу җырның көен К.Мотыйгый үзе язган.
[8] Bibliothegue nationale de France, departement Audiovisuel (BnF)

якан», «Кичке азан», «Кемне сөяргә», «Мәгъшукамә», «Нәрсәдә ләззәт», «Пар ат», «Татар кызына».

Ә менә жырчының 1913 елдагы язмалары арасында Г.Тукай шигырьләренә жырланган әлегә ике генә язмасы булганы ачыкланды. «Кичке азан» (№ 8576) һәм «Тотса мәскәүләр якан» (№ 8579) әсәрләренең язмаларын Санкт-Петербург шәһәрендә урнашкан «Русское Акционерное Общество Граммофонов» (РАОГ) ширкәте үзенең граммофон тәлинкәләренә бастырып чыгара. Шулай итеп, бүгенге көндә К.Мотыйгыйның Г.Тукай шигырьләренә башкарылган жырларның 22 язмасы булуы ачыкланды. Кайбер жыр язмаларының исемнәре кабатланса да, сакланып калган тәлинкәләрне өйрәнү вакытында без бер үк исем астында башкарылган жырларның бер-берсеннән аерылып торуларын күрәбез. Кайбер очракта монда жырчының шигырь строфаларының урыннарын алыштыруы ачыклана, башкарылган жырның тональлеге һәм аккомпанимент характерының үзгәрүе, жырның йомгаклау өлешенең (коденциясенең) төрлечә башкарылуы ишетелә. Монда бер үк жырны төрле вакытта, төрле музыкантлар белән төрле ширкәт студияләрендә язу шундый нәтижәгә китерә. Мәсәлән, К.Мотыйгый башкарган «Тотса мәскәүләр якан» жырында югарыда әйтеп узган үзенчәлекләр бик ачык шәйләнә. Әлбәттә, башкару сәнгатендә менә шундый вариантлылыкны өйрәнү жырчының стилен, манерасын ачыклау юлында зур роль уйный.

XX гасыр башындагы татар жырчылары арасында үзенең репертуарында Г.Тукай шигырьләренә башкарган жырлар булуы белән тарихка кереп калып, бүгенге көндә исеме бөтенләй онытылган бер жырчыны искә алып китү кирәктер. Ул — Троицк шәһәрендә (хәзерге Чиләбе өлкәсе) яшәгән жырчы-гармунчы Мөхәммәтжан Гобәйдуллин. Аның төрле ярминкәләрдә, бәйрәмнәрдә татарның күренекле жырчысы-гармунчысы Мирфәйзә Бабажанов белән бергә чыгышлар ясап йөрүе билгеле. Бу жырчы турында мәгълүмат бик аз булганга, халык шагыйре Мәжит Гафуриенең «Вакыт» газетасында «Татар жырчысы» исеме астында басылып чыккан мәкаләсе безнең өчен бик тә мөһим бер чыганак булып кала. Автор үзенең мәкаләсендә М.Гобәйдуллин турында житди карашлы, көчле, чиста, матур тавышлы, тирән хисле, моңлы жырчы булуы турында яза. Аның жырлау манерасына самимилек һәм ижади күтәренкелек хас булуын билгеләп уза. М.Гафури М.Гобәйдуллинны чын мәгънәсендәге «милли жырчы» дип атый. Язучы белән жырчы таныш булалар, аралашалар: М.Гобәйдуллин ике тапкыр М.Гафури белән Уфада очраша. Бер очрашу турында шагыйрь болай дип яза: «Менә якын арада Мөхәммәтжан әфәнде, Мәскәүгә «Общество Граммофон» га барып жырлап кайтып килгәндә, Уфага дәхи төште. «...» Бер-ике көн булса да, милли жырчымыз белән утырып калдым. «...» Мөхәммәтжан әфәнде үзенең матур тавышы белән мөхтәрәм шагыйремез Габдулла Тукаевның «Теләнче», «Алтынга каршы», «Тотса мәскәүләр якан» вә гайре шигырьләрене «...» тәэсир иттерерлек дәрәжәдә килештереп жырлый, гармунны уйный иде. Мин, борыннан Габдулла Тукаев шигырьләренең мөфтүне булуы өстенә, аның матур шигырьләрене матур тавышлы бер агыздан ишеткәч, бигрәк тә мөфтүн булдым[9], күнелемдә онытылмаслык бер хиссият калды. Югарыда мәзкүр сәрләүхәле[10] шигырьләрне Мөхәммәтжан әфәнде граммофонга жырлаган. Тиз көннән матур тавыш белән жырланган матур шигырьләрне, яңа көйләрне һәркем ишетә алачактыр...»[11].

Үзенең мәкаләсендә М.Гафури М.Гобәйдуллинның граммофонга язылу урыны дип Мәскәү шәһәрен күрсәтә. Монда безгә бер аныклык кертү сорала. «Граммофон» ширкәте һәм аның «Зонофон» бүлендек предприятиесендәге язмаларны документаль теркәү тиешле дәрәжәдә куелган була. Шуның өчен дә «Граммофон» ширкәтенең «Россиядәге язу сессияләренең көндәлеге»ндә язмаларның урыны һәм даталары турында төгәл мәгълүмат бирелә. Бу «көндәлек» Лондон шәһәрендә урнашкан ЕМІ тавыш язу ширкәтенең архивларында сакланган документлар, фонограммаларның

[9] Мөфтүн булдым — сокландым.
[10] Мәзкүр сәрләүхәле — исемнәре аталган.
[11] М.Гафури. Әсәрләр. 4 томда. 3 том. Проза һәм публицистика (1902-1917). Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. — 348,349 Б.

матрица номерлары нигезендә А.Келли тарафыннан төзелгән. Менә шул ышанычлы чыганакка таянып без М.Гобәйдуллинның язмалары Мәскәүдә түгел, ә Санкт-Петербургта башкарылып чыгуын беләбез. Күрәсең, җырчы-гармунчы Россиянең төньяк башкаласына Мәскәү аша баргандыр дигән фикер туа. М.Гобәйдуллинның 23 җырдан торган сессиясе 1910 елның 14 сентябрендә Санкт-Петербургта уза һәм озак та үтми тәлинкәләре «Граммофон» җәмгыяте тарафыннан Рига шәһәрендә чыгарыла. Ә инде М.Гафуринең «Татар җырчысы» мәкаләсен «Вакыт» газетасы бер айдан соң, 1910 елның 14 октябрь санында бастыра.

Шулай итеп, татар граммофон язмаларының каталогларында күрсәтелгәнчә, «мәгълүм татар җырчысы» М.Гобәйдуллин граммофонга Г.Тукай шигырьләренә яңа көйләр белән җырланган «Тотса мәскәүләр якаң» (№ X-4-102933), «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр I» (№ X-4-102935), «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр II» (№ X-4-102936), «Теләнче» (№ X-4-102937), «Ләззәт вә тәм нәрсәдә?» (№ X-4-102938), «Алтынга каршы» (№ X-4-102939), «Дөньяда торыйммы? — дип кинәшләшкән дустыма I» (№ X-4-102940), «Дөньяда торыйммы? — дип кинәшләшкән дустыма II» (№ X-4-102941), «Дөнья» («Дөнья» көенә) (№ X-4-102947) җырларын яздыра.

Кызганычка каршы, әлегә кадәр М.Гобәйдуллинның язмалары кергән тәлинкәләрне табарга насыйп булмады. Әгәр дә инде М.Гафури мактаган җырчының язмалары табылса, мин уйлыйм, безнең барыбыз өчен дә бер зур куаныч булыр иде.

Күптән түгел Г.Тукайның 2011 елда басылып чыккан «Сайланма әсәрләрен»дәге шигырьләрне укып, кайберләрен сакланып калган граммофон язмалары белән тагын да бер тапкыр тикшереп, чагыштырып утырганда күзем 1 нче томдагы ике юллык «Бәет»кә төште. Томның искәрмә һәм аңлатмаларында бу бәетнең Г.Тукайның «Алай-болай» исемле фельетоны эчендә бирелгәнлеге әйтелә. «Бәет»тә «Бәянелхак» газетасы нәшире Әхмәтҗан Сәйдәшевнең динне яхшылап белмәгән килеш яшьләргә дин сабаклары биреп маташуы тәнкыйтьләнә[12]:

*«Бәгъзеләрмез бик суфи, көн дә биш намаз укый;*
*Бурычка йөз мең алгач, аны кесәгә салгач...»*

Бу ике шигъри юл миңа бик таныш кебек тоелды һәм мин инде аны кайдадыр башкачарак рәвештә ишеткән идем төсле. Шунда «Пате» дискындагы бер язма келт итеп искә килеп төште. Казан татар хоры башкаруындагы «Ай, Дунай» (№ 25958) дип аталган җыр иде ул. Дөресрәге, хор һәм солист башкаруындагы шәһәр кысаларында «татар текстларын рус көйләренә» җырлау традициясенең бер үрнәге. Менә ул җыр текстының башлангыч өлеше:

*Солист: «Безнең байлар бик суфи, көн дә биш намаз укый... »*
*Хор: «Ай, Дунай, вай, Дунай,*
*Ай весёлый, шулай!»*
*Солист: «Мәскәүдән йөз мең алгач, аны кесәгә салгач.. »*
*Хор: «Ай, Дунай, вай, Дунай,*
*Ай весёлый, шулай!»*
*Солист: «Кулда ун тәңкә калгач, кыладыр ул барып хаҗ ...»*
*Хор: «Ай, Дунай, вай, Дунай,*
*Ай весёлый, шулай!» һ.б.*

Җырның күләме, хор җырлаган кушымтаны искә алмаганда, сигез юл тәшкил итә. Бу ике текстны чагыштырганда түбәндәгене күрәбез: Г.Тукайда беренче шигъри юл «Бәгъзеләрмез бик суфи...» дип башланса, җырда — «Безнең байлар бик суфи...», ә икенче юлы беренче очракта «Бурычка йөз мең алгач...», икенчесендә — «Мәскәүдән йөз мең алгач...». Монда Г.Тукайның 1906 елда язган «Бәет»е белән «Пате»

[12] Габдулла Тукай. Әсәрләр. — Академик басма. — Алты томда. 1 том: Шигъри әсәрләр (1904-1908). Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. Искәрмә һәм аңлатмалар, 336 Б.

ширкәтенең 1911 елда Мәскәүдә яздырган «Ай, Дунай» җыры язмасы текстының ике юлы арасында аерма ике сүздә генә һәм ул аерма шигъри юлларга салынган мәгънәне бер дә үзгәртми. «Бәет»нең ике юллыктан сигез юллык шигырьгә әверелүе, әлбәттә, гаҗәпләндерә. Бер яктан, шигырьнең икеюллыгы, бәлки, фольклорлашу процессы барышында бераз үзгәрү һәм күләме артуны кичерсә, икенче яктан, «Ай, Дунай!» җырының калган юллары да Тукаебызныкы булырга мөмкин бит дигән фараз туа.

XX гасыр башындагы концерт-гастроль тормышының бер үзенчәлеге — ул татар сәхнәсенә, татар эстрадасына нәфис сүз осталары, сатира һәм юмор жанрындагы комиклар, куплетчылар килеп чыгуы һәм аларның эшчәнлеге активлашуы. Бу эшләрдән татар театрының күренекле шәхесләре дә читтә калмый. Татар сәхнә сәнгате өлкәсендә эшләгән артистлар үзләренең репертуарларын граммофон тәлинкәләренә дә яздыралар. Язмалар арасында безне, әлбәттә, Г.Тукай әсәрләре җәлеп итә.




*«ПАТЕ» ширкәте чыгарган К.Мотыйгый башкаруындагы җырлар тәлинкәсе.*

Югарыда искә алып киткән И.Кудашев-Ашказарскийдан башка күренекле актер һәм режиссер, татар профессиональ театрына нигез ташы салучыларның берсе, Г.Тукайның замандашы, шәкерттәше, дусты Габдулла Кариев (1886-1920) бу төр эшчәнлектә үзен актив күрсәтә, репертуарындагы әсәрләрнең кайберләрен граммофонга яздыра. «Пате» ширкәтенең 1911 елда чыгарылып бүгенге көнгә кадәр сакланып калган дисклары арасында Г.Кариевның да язмалары булуы, аның тавышын ишетү безнең өчен аеруча куанычлы. Франция Милли китапханәсе коллекциясендәге татар язмалары арасында артист башкаруында Г.Тукайның ике әсәре фонограммасы булуы ачыкланды. Беренчесе — «Ысулы кадимче» — көлке (№ 25951), ә менә икенчесе — язманы тыңлаганда гына, очраклы рәвештә, һич тә көтелмәгәндә пәйда булды. Аңлатып үтәм. Г.Кариев яздырган дискның чокырлатып бастырылган этикеткасында «Зилзилә» (көлке) (№ 25955) дип аталган хикәя күрсәтелгән. Бу кыска гына сатирик әсәрдә пәрәмәч камырына төшкән таракан белән бәйле ыгы-зыгыны зур давыллы вакыйгага — зилзиләгә әверелдерүчеләрдән көлү күрсәтелгән. Мондый хәлләр турында, ихтыярсыздан, Г.Тукайның үзе яшәгән «Амур» номерларыннан көлеп язган юллары искә килеп төшә: «Казанда бер хәрчәүнәче үзенең пәрәмәч сата торган номерларына «Амур» дип исем кушкан. Вәхәлбуки «Камыр» дип атау тиеш иде (анысы да тараканлысы)»[11]. Кыскасы, Г.Кариев менә шул «Зилзилә»сен 1 минут эчендә сөйләп бетерә дә, ике-өч секундтан дискның шул ук ягында, үзе ук, «Теләнче» дип, башкарылачак шигырьнең исемен игълан итә һәм әсәрне укып та куя:

*«Кыш, буран, салкын һава, яфрак кадәрле кар төшә,*
*Җил куа карны, һаман да кар «төшәм» дип тартыша.*
*Сызгыра җил, ыжгыра, тик кар буранын арттыра;*
*Шул вакыт мәсҗед катында дөм сукыр бер карт тора ...»*

Язмадагы бу әсәр Г.Тукайның 1907 елда иҗат иткән «Теләнче» шигыре булып чыкты. 2 минут 30 секунд барган әлеге бу язманың яңгыравын ишетү минем өчен, чынлап әйтәм, зур бер ачыш булды һәм бик тә шатландырды.

Дөресен әйтергә кирәк, Г.Кариевның язмалары шактый сыйфатлы. Монда граммофон тәлинкәләренә хас кыштырдаулар юк дәрәҗәсендә, шуның өчен дә ул укыган Г.Тукай әсәрләренең тексты бер дә югалтылмыйча, аңлаешлы итеп бирелә,

[11] Габдулла Тукай. Әсәрләр. — Академик басма. — Алты томда. 2 том: Шигъри әсәрләр (1909-1913). Казан: Татар. кит. нәшр.., 2011. Искәрмә һәм аңлатмалар, 374Б.

омтылыш белән укылган шигырьләрдә эмоциональ тәэсир көче бар. Бу язмалар аша без Г.Кариевның зур осталыкка ия булган артист икәнлегенә тагын да бер тапкыр инанабыз.

1909 елның июль аенда «Граммофон» ширкәте вәкилләре татар язмаларын эшләргә Казан шәһәренә киләләр. Шул чорда язылып алынган күпсанлы номерлар арасында Г.Тукайның кайбер әсәрләре дә бар. Әйтик, тавыш язу сессиясенең 21 июлендә XX гасыр башында татарлар арасында популярлык казанган танылган куплетчы, хикәяче Г.Камаев Г.Тукайның «Тотса мәскәүләр якаң» (көлке) (№ 4-102816) шигырен куплет итеп җырлый һәм «Ысулы кадимче» (№ X-101117) исемле әсәрен укып яздыра. «Ысулы кадимче» шигырен Г.Тукай 1908 елда иҗат итә. Бу сатирик шигырендә автор үзенең зәһәр үткен укларын фәкать үз мәнфәгатьләрен кайгыртучы, әхлак кануннарын аяк астына атып бәргән икейөзле динчеләргә юнәлтә. Башка бик күп әсәрләрендәге кебек шагыйрь монда үз иҗатының төп идеясен — татар җәмгыятен яңарту, торгызу идеясен алга таба сөрә.

Татар эстрадасының башлангыч чорында үзенең эшчәнлеге белән популярлык яулаган тагын да бер куплетчы, комик актёр Г.Мамай укуында Г.Тукайның өч әсәре граммофон тәлинкәләренә языла. Германиянең Лейпциг шәһәрендә тупланган «Лирофон» исемле зур булмаган предприятиенен 1910 елгы язмалары арасында Г.Мамай башкаруында «Тотса мәскәүләр якаң» (№ 6001), «Ысулы кадимче» (№ 6006) һәм «Хатынлар хөррияте» (хәҗәр) (№ 6008) исемле әсәрләр дөнья күрә.

Шулай итеп, минем өчен бик тә кызыклы булган бу эзләнүләр барышында шунысы ачыкланды: Тукаебызның замандашлары граммофон тәлинкәләренә җырлап һәм укып яздырган әсәрләре саны бүгенге көндә 40ка барып җитә. Киләчәктә бу юлда безне яңа ачышлар көтүенә, әлбәттә, ышаныч бар, шагыйрь әсәрләренең язылуы турындагы яңа мәгълүмат һәм иң кадерлесе, яңа язмаларның табылуына зур өмет баглана.

Сакланып калган язмаларны, каталоглардагы мәгълүматларны тикшереп чагыштырганнан соң башта шундый бер сорау туа. Г.Тукайның нинди әсәрләре башкаручыларның репертуарында өстенлек иткән, шагыйрь иҗатында күтәрелгән нинди темалар күпсанлы граммофон тәлинкәләре аша тыңлаучыларга җиткерелгән соң? Моның өчен безгә тагын да бер тапкыр граммофон язмаларына мөрәҗәгать итү сорала. Бер генә мисал. Әлегә кадәр билгеле булган язмалар арасында башкаручыларның барысы да дип әйтерлек, Г.Тукайның «Тотса мәскәүләр якаң» әсәренә мөрәҗәгать итә. Ул әсәр укыла да, җыр рәвешендә башкарыла да. Классик шагыйребезнең бу үткер сатирик шигъри юллары 1908 елда, Рәсәйдә кара реакциянең үтә көчле чорында язылган була. Ул гына да түгел, цензура бу шигырь турында үзенең документларында «нежелательно» дигән сүз кулланган булуы да билгеле. Монда шагыйрьнең принципиальлеге һәм кыюлыгы алгы планга чыга. Г.Тукайның бу әсәре редакцион төзәтмәләр белән 1911 елда гына дөнья күрә. Ә граммофон язмаларына килгәндә җырчы К.Мотыйгый Г.Тукайның бу әсәрен «Зонофон» (1910 ел), «Пате» (1911ел), «Метрополь-рекорд» (1911 ел) һәм «Русское Акционерное Общество Граммофонов» (1913 ел) ширкәтләренең тәлинкәләренә һәм дискларына яздырып чыгара. Җырчы М.Гобәйдуллин һәм комик актер Г.Мамай башкарып чыккан бу әсәрнең язмалары 1910 елда дөнья күрә. Ә менә Г.Тукайның «Тотса мәскәүләр якаң»ны беренче булып, шигырьнең дөньяга чыгуына бер ел үтмәс борын, 1909 елның июль аенда «Граммофон» ширкәте куплетчы, хикәяче Г.Камаев башкаруында язып ала. Шулай итеп, Г.Тукайның шигырендә куелган «Ни кыйлырсың, хаҗи абзам, тотса мәскәүләр якаң? Как ты будешь отвечать там, тотса мәскәүләр якаң ?... » кебек сораулар заманасы өчен бик тә көчле яңгырый. Илдә барган сәяси тормышны, Рәәй хөкүмәте ягыннан татар-мөселманнарга булган карашны чагылдырып, үз чоры өчен бик тә актуаль теманы күтәргән бу әсәр татар башкаручылары өчен үзенчәлекле бер программа булып чыгыш ясаган түгелме соң?

Әйе, Г.Тукай татар тарихындагы фаҗигале вакыйгалар турындагы уйланулар, халкының киләчәге турындагы борчылулар белән сугарылган әсәрләр иҗат итә. Аның шигырьләрендә милләт тормышындагы ямьсез күренешләрне, җитешсезлекләрне тәнкыйтьләү һәм аларга каршы көрәш мотивлары яңгырап тора. Ә инде Тукаебызның әсәрләре граммофон тәлинкәләрендәге язмалар аша XX гасыр башы тыңлаучысының күңеленә барып җитеп анда тирән милли тойгыларны уятуын без бер могҗиза итеп кабул итәбез. Шагыйрьнең «Кечкенә азан», «Ысулы кадимче», «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр» «Хатирәи «Бакырган»», «Дөньяда торыйммы? — дип кинәшләшкән дустыма», «Алтынга каршы», «Эштән чыгарылган татар кызына», «Теләнче» һ.б. әсәрләрендә күтәргән, милләтне борчыган сораулар йөз елдан соң да үзенең актуальлеген югалтмадылар дисәк тә ялгышмабыз.

Әйе, халкыбызның сөекле шагыйре, бөек Тукаебыз безгә нинди бай мирас калдырган! Әйдәгез, аны укыйк, аны тыңлыйк, ул әйткәннәргә колак салыйк! Безгә моны аңлар өчен үтеп киткән бер гасыр вакыт җитми калды микән?!

**Идрис ГАЗИЕВ,**
*Россиянең атказанган, Башкортостанның*
*һәм Татарстанның халык артисты,*
*С.Юлаев исемендәге дәүләт*
*премиясе лауреаты.*

---

*Киләсе санда укыгыз!*

## СЕЗДӘ НИЧЕК, БЕЗДӘ ШУЛАЙ САТАЛАР КИТАПЛАРНЫ

«Нурихан Фәттахның архивын барлау, тәртипкә салу белән шөгыльләнгәндә кызык кына бер язма – 1952 елгы рәсми хисап килеп чыкты. «Балтач районында китап сатуның торышы» дип атала. Бу отчетны язган вакытта Нуриханга 24 яшь булган.

Документтан аңлашылганча, районда ул чактагы китап сату эше канәгатьләнерлек булмаган. Ул заманнардан соң 60 ел вакыт үткән. Кызык, шул ук Балтач районында китап сәүдәсе эше бүгенге көндә ничек тора икән? Отчетта күрсәтелгән кимчелекләр бетерелде микән?

Язучы Нурихан Фәттахның хатыны Руфина Фәттахова.»

Әлеге бик тә актуаль сорауга җавап әзерләүне үтенеп без танылган журналист Рәфыйк Шәрәфиевкә мөрәҗәгать иттек. Киләсе санда Нурихан абый архивында саклаган документ та, журналист мәкаләсе дә басылачак.

# БЕЗ БЕТӘБЕЗ ИНДЕ, СЕЗ КАЛАСЫЗ

## КҮПТӘН ОЧСЫЗЛАНГАН КЫЙММӘТЛӘР, БЕРКЕМ ЯРЛЫКАМАС ГӨНАҺЛАР ХАКЫНДА

*Исемнәре билгеле галимнәр (мәсьәлән, Стивен Хокинг дигән атаклы космолог һәм физик), инде хәтсездән, кешелек өчен төп куркыныч кайдандыр читтән, йә булмаса табигатьтән түгел, ә бәлки адәми затның үзеннән, аның акылыннан, дөресрәге, тыелгысыз акылсызлыгыннан, сансызлыгыннан дип киләләр.*

### Аллаларга бетсә сан

Кеше дигән «аңлы» зат, фәнне һәм техниканы иярләп, инде күпме еллар акча, табыш, байлык, уңайлыклар дигән, үзе уйлап чыгарган кыйммәтләр артыннан чаба да чаба. Тыелгысыз, дуамал һәм мәгънәсез чабыш бу. Шул чабыш-куышка, без яшәгән бүгенге чынбарлыкка, ярты дөньяны басып алган куллану «бизгәгенә» кайчагында дикъкать белән, күзне ныграк ачып карыйсың-карыйсың да, без ничек яшибез, кая барабыз, без кемнәр соң, кешеләрме, әллә комсызлык акылын, иманын алган, томалаган ерткыч приматлармы дип, гаҗәпләнеп, үз-үзеңнән булса да сорап куясың. Сорауга җавап таба алмый бер тын гаҗизләнгәч, ярар, юк белән баш катырмыйм, чокынмыйм әле дип гавам арасына «кереп югаласың», уйламыйча, төпченмичә яшәүнең җиңеллегенә, рәхәтенә куанып куясың. Әмма ләкин, «кая барсаң да кара сакалың артыңнан калмас» дигәндәй, үзеңнән бөтенләй качып та булмый икән шул...

Борынгы фарсылар билгеле бер дәвердә ялган белән урлашуның ни-нәрсә икәнен белмәгәннәр дип укыдым күптән түгел. Менә бит, ичмасам, нинди заманнар, нинди халыклар да булган икән. Менә шул фарсылар, беләсезме, ни өчен грекларны күралмаганнар? Базарлары өчен. «Ялганлашырга, алдашырга махсус урыннар тотучы халык турында нинди яхшы сүз сөйләп булсын инде», дип көрсенгәннәр алар.

Без бүген менә базар мөнәсәбәтләре ныклап чәчәк аткан, нәфес идарә иткән бик тә четерекле һәм каршылыклы дөньяда яшәп ятабыз. Паразитар, куллануда һәм комсызлыкта чаманы белмәгән кешелек табигатьтән, җирдән бар нәрсәне алып торса да, алмашка берни дә бирми. Алучылар, туздыручылар, рәхәтлек эзләүчеләр җәмгыяте без. Кеше чын кеше булып та бетә алмаган, хайванлыктан да узган инде. Тирә-якта сансызлык һәм затсызлык, рухи бушлык тантанасы. Шунлыктан борынгы фарсыларны кабатлап: «Бүгенге тормыш-яшәеш, чынбарлык хакында, шушы дөньяның күпчелек өлеше турында нинди дә булса яхшы сүз әйтеп буламы?» дип сезнең дә сорыйсыгыз килмиме? Кайберәүләрнең, бәлки, киләдер дә. Минем дә килә. Бик килә. Аптырарга кирәкми, кайбер «тинтәкләр» шулай гомер буе гаделлек, камиллек эзли инде ул, таба алмаса да. Абсолют күпчелеккә генә күптән диңгез тубыктан, күпчелек андый тирәнлеккә төшеп казынмый, чокчынмый. Күпчелек бәхетле – ул дөнья куа, бүксә тутыра, күңел ача. Ә азчылык, уйлый-анализлый белгәннәр,

киресенчә, гаҗәпләнә, хафалана һәм бу сорауга берничек тә уңай җавап бирә алмый. Иң аяныччы — берән-сәрән булган азчылыкның нәрсәне булса да үзгәртерлек мөмкинлеге дә юк һәм, ихтимал, беркайчан булмас та. Азчылык — йогынтысыз.

Борынгы греклар... Бүгенге дөнья — антик чордан бик күп нәрсәләр алган дөнья. Күрегез, хәтта кечкенә һәм зур шәһәрләрдәге бар булган Мәдәният йортлары, театрлар да Парфенонга охшатып салынган. Ә беренче демократия, шәхси милекне күз карасыдай саклаучы законнар кайда туган? Шул ук борынгы Грециядә. Оста төзүчеләр, һөнәрчеләр булганнар, ләкин аллаларын ихтирам итмәгәннәр. Алар турында кырыкмаса кырык төрле мифлар чыгарганнар, кырын ятып шәраб эчә-эчә, алардан көлгәннәр.

Караңгы урта гасырлар узгач реставрацияләнгән, яңартылган, әмма, кызганычка каршы, деформациягә — гарипләндерүгә, ипсезләнүгә дә дучар ителгән, чиксез индивидуализм, мин-минлек сеңдерелгән дөнья — бүгенге Көнбатышта аллаларга сан бармы соң? Юк! Христиан диненең ул җәмгыятькә берәр йогынтысы, тәэсире булса, Европада башкала саен диярлек кызыл фонарьлар урамнарына урын табылыр идеме? Хатын-кызлар бала табудан качар идеме? Өерләре белән гомосексуалистлар, парад оештырып, үзләренә өстәмә ирекләр сорарлар идеме? Андагы күпчелек, дөньясын онытып, доллар, евро дип аталучы яшел, зәңгәр фантикларга – кәнфит кәгазьләренә табыныр идеме?

Үзләрен христиан санаучылар Гайсә пәйгамбәр турында мифлар чыгарып аңардан көлмәсәләр дә, барыбер алласызлар, имансызлар, мал җыюга, азгынлыкка бәйлеләр җәмгыяте анда. Төрледән-төрле рәхәтлекләр чакырып, ымсындырып, «яшәп, теләгәнеңне алып кал» дип торганда килешмичә читкә китеп кара. Китә алмыйлар. Беркемнең дә үзенә чик куясы, инстинктларны тыясы, кыса эчендә каласы килми. Шунлыктан, Көнбатыш культурасында аллалар булып аллалар да приватизацияләнгән һәм шул җәмгыятькә җайлаштырылган. Аллалар — номиналь, форма, исем, мода өчен, ә руханиләр исә вәзгыятькә йогынтысыз туй генераллары. Анда гына түгел, алардан килгән бар шакшылыкны йотып баручы илдә – Рәсәйдә дә нәкъ шулай ул.

Бүгенге затсыз дөньяның күпчелек бәлаләренең башы — имансызлык һәм алласызлык, шул хәл-халәт алып килгән «алтын бозау», алга-артка карамыйча шуңа табыну икәнен исбатлап маташырга кирәкмидер дә, бәлки. Шул исәптән, Рәсәйнең кыргый киңлекләрендәге аяныч вәзгыятьнең дә «тегендәгеңә», ягъни Көнбатыштагы «гөнаһлылар оҗмахы»на караганда мәгънәлерәк, иплерәк була алмаганлыгын да. Киресенчә, биредәге, бездәге яңарак кына яралган ул «оҗмахның» күпкә начаррак икәне исбатлауларсыз да күренеп тора. Иң кызганычы, ихтимал, шулдыр — русларга йоккан, аларда булган һәм көчәеп торган чирләр аларныкы гына түгел, буйсындырылган башка милләтләрнеке, шул исәптән без татарларныкы да бит.

## Җан сораучы бушлык, яки «Бармакларыңны сана!»

Глобализация, унификация, урбанизация, эмансипация, башка бик күп шундый «...ция»лар, идеаллар дефициты, бушлык тудырган, гөнаһлы рәхәтлекләре белән күпләрне ымсындырып, кеше затының бар булган рухи маякларын, кыйбласын каплап торган Көнбатыш... Ә бит тыштан барысы да яхшы сыман: ялтырап торган гипер һәм супермаркетлар, ыспай киенгән кешеләр, чиста урамнар, зиннәтле машиналар. Әмма эчтә шөбһә, бушлык. Чөнки инанулар, мәгънәле ориентирлар юк. Акча белән мал, алар артыннан чабу инану була алмый. Ул шайтан коткысы гына була ала. Шул сәбәпле, тыштан ялтыраса да, эчтән көпшәк, черек ул җәмгыять. Алай ук түгел инде, дисезме? Шулай булмаса, ни өчен соң хәтта дөнья күләмендә иң тыныч, тормыш кимәле иң югары саналган Швеция белән Норвегиядә үз-үзләренә кул салучылар башка илләрдәгедән, уртакул һәм хәерче дәүләтләрдәгедән күпкә артыграк? Ни өчен ул илләрдә антидепрессантларны, йокы даруларын башка җирләргә

караганда күбрәк кулланалар, учлап диярлек эчәләр? Бәлки, Көнбатыш кешесе гомеренең заяга үткәнен аңлап алгач онытылырга тырыша, яки үзе теләп хушлашадыр андагы мәгънәви бушлык белән?

«Өченче дөнья» әнә, нинди генә фәкыйрь булмасын, суицидның (үз-үзеңә кул салу) да, күңел төшенкелегенең дә, күпчелек очракта даруларның да нинәрсә икәнен белми. Проблемасызлыктан, дөнья җитеш булуданмы ул швед гаиләсе дигән шапшаклык, мөгез чыгару? Рухсызлык китергән оятсызлыктан, җаннардагы пычраклыктан ул. Өстәмә, яңа, моңарчы булмаган, күренмәгән рәхәтлекләр, маҗара эзли-эзли андагы кеше кая гына барып җитми. Этләр генә дүрт-бише бергә җыелып буталыша, өегә. Инде адәм баласы да шул дәрәҗәгә төштеме?

Акча культы турында сөйлисем дә килми. Куллану культы. Комсызлык. Болары турында искәртми булмый. Адәми зат әйбер җыя. Ул — әйбер һәм куллану колы. «Беренче дөнья»да туып, безгә күчеп килгән кыбырсык, ашкын, комсыз мохит аны шуңа өйрәтә. Әйбер җыеп ул бәхетле булырмын дип уйлый. Бер дигән машинасын аңа кабаланып кәттәрәккә алыштырырга кирәк. Шаукым! Тузмаганны, яңаны – киемме ул, фатирмы, җиһазлармы, барысын-барысын да һәрдаим алыштырып торырга ашкына ул. Өч кешегә унҗиде бүлмәле өй, йә, нәрсәгә инде? Берьюлы, бер үк вакытта биш бүлмәдә торып булмый бит. Кирәклектән түгел, әлбәттә, туймас тамаклыктан, карунлыктан. Язылмаган закон, кагыйдә шундый – бар да танышларыңныкыннан артык булсын. Ә реклама дигән коткы? Анысы котыртып, ымсындырып тора, ясалма, кирәкмәгән ихтыяҗ тудыра. Комсызлыкны тагын да үсендерә.

Фарсылар яратмаган антик чордагы грек базарлары нәрсә генә соң ул? Беләсез микән, хәзер шундый гыйбарә бар: эшкуар белән кул биреп күрешкәннән соң шундук читкәрәк китеп бармакларыңны санап чык. Берәресен чәлдермәгәнме? Урта гасырларда рибачыны (процентка акча бирүче) кешегә дә санамаганнар. Ә бүген банкир кем? Әйе, ул – бүгенге базарлы җәмгыятьнең каймагы. Һавадан акча ясаучы оятсыз зат. Тик туксан тугыз процент халык өчен ул — кумир. Шулай булгач, мондый җәмгыять үзе баштүбән куелмаганмы соң?

Гаҗәп түгелме: намуслы – мескен, әхлаклы – тиле, геройларга да, романтикага да урын юк. Геройлык культы шома эшмәкәр культы, акча культы белән алыштырылган.

Бүген намуслы һәм намуссыз кеше арасында аерма юк. Дөресрәге, намуссызны гаепләү юк. Җәмгыятебездәге, илебездәге бүгенге иң мәгънәсез принципларның берсе – тотылмаган, димәк, карак түгел. Караклар белән бүгенге җәмгыять көрәшә алмый, теләми, гаделләрдән исә көлә. Көрәшергә тиешлеләр үзләре үк карак. Шәһәр саен «могҗизалар кыры» үсеп чыкты. Әллә андагы күпчелек ул купшыдан да купшы сарайларны намуслы хезмәт, хәләл көч түгеп торгызганмы? Каракның карак икәнен, ришвәтченең – ришвәтче, гангстерның — гангстер икәнен бөтенесе белә. Шул исәптән, прокуратура белән полиция дә. Әмма легендар персонаж Жеглов әйткән гыйбарә — «Вор должен сидеть в тюрьме!» — бүген пучтәк сүз.

...Термодинамикада энтропия дигән термин бар. Заманында, КАИда укыганда, авиация электроникасына әллә ни кагылмаган шул термодинамика курсын безгә дә укыганнар иде. Рәхмәт укытучыларга. Истә дә калды, һәм, әйтергә кирәк, соңгы елларда бу сүзне социологиядә дә, башка өлкәләрдә дә бик теләп куллана башладылар. Энтропия — системадагы тәртипсезлекне, энергетика кимүне, хаос дәрәҗәсен билгеләүче күрсәткеч. Һәм «алдынгы җәмгыятьләрдә», һәм аларга сукырларча иярүчеләрдә ул кызу үсештә хәзер.

Менә саныйк әле. Мораль аспектта без аска тәгәрибез. Дини яктан, иман ягыннан да, аска, гаилә торышы буенча да аска төшә барабыз, тәртип урнаштыра алмаган декларатив һәм декоратив законнар да безне түбәнгә сөйри. Без инде күптән сәламәт тә түгел — дару белән медицинага йөз процентлы бәйлелектә. Ягъни җан да рух чирле, тән дә чирле.

Исәр шоу бизнес, телевидение, андагы маймыл-кумирларга табынучы

миллионлаган фанатлар армиясе. Шуңа өстәп, мәңге кимемәс наркоманнар, фәхеш бизнесы, йөзләрчә тапкыр күбәйгән Содом белән Гоморра. Көнбатышның культурасына, яшәү рәвешенә ияреп яшәгән хәзерге җәмгыятебездә энтропия ярсып ташый. Ә ул – бетүгә юл инде. Сүз иртәгә үк тәгәрәп үлү турында бармый, әлбәттә. Әмма система үзенең ныклыгын, эчке көчен, энергиясен җуйганнан-җуя бара. Системада хаос көчәя.

Постиндустриаль цивилизация — үзенең әҗәлен чакыручы, әҗәленә ашкынучы юньсез цивилизация. Акыллы кешеләр моны индустриаль чор үсештә, чәчәк ата башлаган чорда ук чамалаганнар. Освальд Шпенглерның бер гасыр диярлек элек үк язылган данлыклы «Европа кояшының баюы» да («Закат Европы») тикмәгә генә тумагандыр. Шпенглер һәр культура, шул җөмләдән бүгенге Көнбатыш культурасы да аны тудырган халыкның коллектив рухы (яки рухсызлыгы), һәм ул тере организм дип белдерә. Ул организм нининдидер бер килбәтсез мутант булган нисбәттә дә. Һәр организмның яшәү срогы бар. Срок чыктымы – ул үлә. Начар, ипсез культура булса, агония тизләнә. Аннан соң үлгән культурага алмашка шуның киресе, капма-каршысы туа.

Шпенглер әйтүенчә, иртәме-соңмы, Көнбатышта, андагы гавам исән калган хәлдә, бүгенге шәрә, җимергеч техницизмга алмашка иҗади һәм рух үсешен алга сөргән яңа культура туачак. Оныклар, Алла боерса, камил һәм ипле җәмгыятьтә яшәрләр дигән өмет юк түгел. Әле яңа гына, 2010 елда Сахара климатында яшәп алмадыкмы? Дуамал техноген җәмгыятьнең табигатькә салган зыяны турында язып тормыйм, чөнки ул үзе аерым бер һәм олы тема.

## Көнчыгышта — өмет чаткысы, Көнчыгышта — иман яктысы

Кояш көнбатышта батса, көнчыгышта чыга. Бу табигать законында безнең дәвергә кагылышлы тирән символик мәгънә ятмыйммы?..

«Беренче дөнья», аягын тәмам сузганчы, калган дөньяны әхлакый җимерә, тоташ агулый, тончыктыра, үзе артыннан төмүгка сөйрәп китә алмастыр да, бәлки. Җир шарында иман югалмаган почмаклар да бар бит әле. Гәрчә алар әлегә җирдәге гомуми «һава торышын» билгеләмәсәләр дә. Ислам дөньясы бар. Бердәнбер дип әйтерлек дөрес яшәргә омтылучы мәгънәле дөнья бар.

Кайда дөреслек, кайда ялган; кайда иман, кайда гөнаһ? Без, бары да буталган шушы мохиттә җан асраучылар, икеләнеп, боргаланып, ни әйтергә белмәгәндә, алар акны карадан бик яхшы аера, бәяне кистереп куя. Үзен ихтирам иткән мөселман кешесе өчен Көнбатыш дөньясы – азгынлык оясы. Мөселман кешесе өчен Көнбатыш хатын-кызларының да күбесе – сөйрәлчек. Ислам дөньясында номиналь, исем өчен генә булган аллалар, пәйгамбәрләр дә юк. Көнбатыш кешесе элекке һәм бүгенге аллаларын таптап узып, алар урынын үзе алды. Суперэгоизм тудырды. Барысы да аңа булсын. Чүпрәк-чапрактан, тимер-томыр, техникадан башлап бер нәрсә белән дә чикләнмәгән ирекка кадәр. Әмма алай булмый шул...

Адәми зат акыллы түгел, ә бары тик акыллы булырга сәләтле генә. Анысы да — тиешле тәрбия булганда. Урманга ташласаң, адәм баласыннан Маугли килеп чыга. Биш яшькә кадәр җанварлар арасында үскән баланы сөйләшергә дә, үзен кешечә тотарга да өйрәтә алмыйсың. Мохит кешедән чын кеше дә, суперэгоист та, хайван да, теләсә нәрсә ясый ала. Мохит, җәмгыятьтәге культура — төп тәрбияче.

Коллектив рух урынына коллектив рухсызлык, иманны бугазларга алынган тирәлек килгәнен, агониянең көчәюен Көнбатышта да сиземли башладылар бугай. Диннәренең энергетикасы, көче бетеп, таркалып барганын да чамалыйлар. Төре йөртүчеләр, миссионер-конкистадорлар, көчләп чукындыручылар, Лука Конашевичлар заманы узды инде. Ул дин экспанция, төрле мобилизацияләр вакытында гына көчле булды. Шулай булмаса бүген

Европа аристократларына кадәр үзләрен сөннәткә утырттырып намазлык өстенә басмаслар иде.

Ислам тарафдарлары артуга гаҗәпләнәсе юк. Ислам чиста, ул анык, ул тәвәккәл. Ислам техник казанышлар, корал белән түгел, иман белән көчле. Анда гөнаһка, куллану колы булуга, азгынлыкка юл юк. Савап һәм гөнаһ үтә дә төгәл аерылган. «Савап»ка бәрабәр сүз христианнарда, шул ук русларда, гомумән, бармы соң ул?

Тагын энтропияне (тузу, таушалу, тәртипсезлек артуны) искә алыйк. Ислам мохитендә ул түбән. Хаоска урын юк. Һәр нәрсә үзенең киштәсендә. Система ныклы. Адәм затын кысалар эчендә тотучы тормыш уставы – меңьеллык Коръәни Кәрим бар... Көнбатыш үзен-үзе ук бетереп килгәндә алар, мөселман өммәтендәгеләр, калачак, яшәячәк әле.

Ишетәсез, беләсездер, Европага, Америкага, гомумән «Беренче дөнья»га акырын гына шул «Өченче дөнья» үтеп кереп маташа. Акрын, җайга салынган, шуышма, ләкин туктаусыз, тыелгысыз экспанция. Тегеләр кебек тәре походлары оештырып, ут һәм кылыч, миссионерлар белән түгел, ә күбесенчә эш, шөгыль эзләп. Европа белән Америка, бездәге шовинист-фашистлар кайчак моңа каршы шау-шу куптаргалап алалар, тик берни дә кыра алмыйлар. Чөнки андагы аксөяккә әйләнгән гавамга, ак күлмәк киеп, галстук тагып офисларда ыштан туздырырга гадәтләнгәннәргә бар булган кара эшне эшләргә эш атлары кирәк. Шунысы да гаҗәп, ислам тарафдарлары, анда үтеп, төпләнеп, өч буын, биш буын яшәсәләр дә диннәрен дә, гореф-гадәтләрен дә җуймыйча саклыйлар, ассимиляция аларга янамый. Бу да исламның көчен, куәтен күрсәтә бит. Балаларны да мулдан, ишле итеп таба, үстерә киләләр. Сөбханалла дип әйтик, Европада ислам тарафдарлары арта тора. Ә Америкада афроамериканнар арасында Гайсә пәйгамбәрне Мөхәммәд пәйгамбәргә бик теләп алыштыручылар күбәя. Көнбатыш кояшы бу яктан да баюда...

## Упкын сиңа караса

Ә без – ике арада калган, иманга ифрат та акрын барган, күбрәк туктап, таптанып торган, үзебезне татар дип атаган, түбән энергетикалы кавем якын киләчәктәниләр эшләп бетәчәкбез соң? Мәчетләр күпләп калыкты анысы. Тик соңга калмадыкмы? Кайчандыр булган, әмма без сансыз рәвештә җуйган (җуярга мәҗбүр ителгән) инсафка, иманга, мәгънәгә кайту (мөмкин түгел дигән сүзне язасы килми) озак икән бит. Мәчетле, муллалы булу гына «тегеләрдән» аерылу, чын исламга, ислам дөньясына әйләнү, аларча яшәүгә ирешү дигән сүз түгел икән әле. Кайтып җитә алырбызмы, ирешербезме лаеклы яшәешкә?

Шикләр зурдан. Чөнки, ни кызганыч, яшәү рәвешебез, кыйммәтләребез бүген күбрәк «тегеләрчә», ким дигәндә урысча безнең. Читләр арбасына утырып, алар җырын җырлау кимеме, кайчакларда хәтта арта да. Аракы, зина, күсе зәхмәте – әйбер, мал җыю, алласызлык – болар барысы безләрдә дә бик җитәрлек. Татар рухына шактый нык үткән «ирекле» дөнья стандартлары, кирәкмәгән ымсыну-ымсындырулар куйган киртәләр. Бездә аларны кичәргә теләк-ният бармы, исәнме дип сорыйсы бик килә. Ул ният-омтылыш бар да сыман, тик шактый зәгыйфь тә. Татарның бар булган бүгенге фаҗигасе дә шулдыр, бәлки.

Ни генә булмасын, энтропия татарда да кызулый. Без төпкә таба «өлкән абзый» — Көнбатыш белән чагыштырганда кызурак та бармыйбызмы дигән шик тә бар. Милли аң дәрәҗәсен, аның кая таба баруын исәпкә-санга алганда, бу — бәхәссез. Унитар дәүләткә ашкынган урыс цивилизациясе, тырышып-тырмашып, безне үзеннән дә алданрак җәһәннәмгә этә.

Таркау татарны, күпмедер ташлама белән, система дип чутласак, андагы энтропия артуны ничек тоткарларга? Безне авангардка куеп үз-үзләрен үтерергә баручыларга иярмәскә иде дә бит. Билгеле, аерымлануга бару ул күпмедер хыял. «Тегеләр»нең, ягъни Көнбатышның, аларга тагылган урыс культурасының, яшәү рәвешенең имансыз һәм ипсез икәнлегенә, кая

юнәлгәнлегенә төшенү, шул ук, бер үк казанда кайнаган татарга да шактый авыр. Аерымлануны икътисади, техник яктан артта калу дип аңлаучылар күпкә күбрәк. Безгә дә шул югары технологияләр, шул стандартлар, андагы очсызлы «кыйммәтләр» алып килгән һәм киләчәк өстәмә, яңа уенчыклар һәм уңайлыклар, рәхәтлекләр кызыклырак. Бездә дә алардагы сансызлык һәм сабыйлык синдромы. Ялгышмыйбызмы соң дип уйлаучылар, кызганыч ки, юк чутында. Без дүрт күз белән хакимият авызына карап торырга гадәтләнгән кавем. Тик татарның рухи халәте, иманы яки имансызлыгы, милли аңы белән кызыксынучылар күпчелек Мәскәү кушканны башкарырга күнеккән хакимият тирәсендә була алмый. Халык та андый кыйммәтләр белән «чирләми».

Бездә зыялылар да көчсез, аз һәм таркау. Бу хәл бәлки энтропияне көчәйтүче төп фактордыр да әле. Исән каласыбыз килгәндә татарны татар итүче бар булган рухи байлыкны, кыйммәтләрне, шул исәптән, динне дә «эпидемия» итеп бар халкыбызга йоктырырга, сеңдерергә тырышу милләт авангарды — зыялылыр бурычы бит югыйсә. Тик бездә зыялылар һәм зыялы булырга тиешлеләр кайсылары хакимият тирәсенә елышканнар — «придворныйлар», кайсыларында беренче урында тамак кайгысы. Ә дини зыялылык, миңа калса, әле яралып кына маташа. Кайбер «даһи зыялыларыбыз» үзләреннән башканы күрмиләр, белмиләр, танымыйлар. Җыеп әйткәндә, исәпкә алар бар, ә санга, файдага – юк. Ә бит гел башкача булырга тиештер. Интеллигенция бәйсез, булдыра алган чаклы булдырган ярдәм, көчле, һәм, барыннан да бигрәк, фидакарь булганда гына реаль эшләр башкарырга сәләтле. Хакимият тә фәкать шунда гына алар белән исәпләшәчәк. Халык та күрәчәк. Ә болай исәпләшер, күрер кеше юк. Зыялы, чын зыялы икән, ул, хакимияткә оппозициядә торырга тиеш. Чөнки хакимият беркайчан да гөнаһсыз да, кимчелексез дә була алмый. Хакимияткә ышану, ана таяну, аннан проблеманың чишелешен көтү — бүгенге көндә үз-үзеңне алдау, юату гына ул. Дөньяны да, милләтне дә «тәти»гә кызыгучы, бүксә кайгысыннан, күңел ачудан башканы белмәгән гавам түгел, ә кешелек, ил, милләт язмышын кайгыртырга сәләтле, аңлы, акыллы, фидакарь затларга – чын интеллигентларга ияргән актив гражданнар гына коткара аладыр...

Глобальләшкән «кара энергиягә», энтропия артуга, дөнья масштабындагы яман процессларга, анда нинди генә хәлләр булмасын, без, татарлар күләмле йогынты ясый алмыйбыз. Тик шул ук вакытта, җаныбызда калган күпмедер өмет, ышаныч белән, бәлки соңгы тапкырдыр, татар язмышы татарның үз кулында дип тә әйтә алабыздыр. Әлегә. Әмма язмышыбыз безнең кулларыбыздан менә-менә бөтенләйгә ычкынам, башкалар кулына күчәм дип тора. Инде күчмәгән булса.

«Беренче дөнья», бар булган иярченнәрен, шул исәптән түбән энергетикалы урыс цивилизациясен дә ияртеп җәһәннәмгә җыенганда, шулай ук милләтебез тирәсендәге фаразларның, прогнозларның куанычлы түгеллеге эчне пошырганда, иple-иманлы тормышка якына алмый каңгыраганда, безгә алай ерак та булмаган ислам дөньясына карап һәм мәгълүм җырның сүзләрен бераз үзгәртеп: «без бетәбез инде, сез каласыз» диясе генә калмасмы? Ныклап, төбенә төшеп уйланыйк әле бер. Шул исәптән без татарлар да.

**Наил ШӘРИФУЛЛИН**

# «КЫЗ ХИКӘЯТЕ» КЫЙССАСЫ

Урта гасырларда татар телендә иҗат ителгән «Кыз хикәяте» исемендәге шигъри кыйсса булган. Тик аның тексты моңа хәтле өйрәнелмәгән, басылып чыкмаган һәм озак вакытлар онытылып, татар укучыларының киң даирәсенә билгесез калган. «Кыз хикәяте»нә охшаш сюжетка язылган әсәрләрнең бер өлеше «Хан кызы Турандык» исеме белән бөтен дөньяда билгеле. «Кыз хикәяте» Татарстан Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана торган, XVIII гасырга караган кульязма җыентыкларның «1764т» шифры белән билгеләнгәнендә тулы хәлендә килеп ирешкән. Башындагы һәм ахыргы битләре төшкән, барлыгы 85 кәгазьдән гыйбарәт татар кулъязма җыентыгында берничә борынгы әдәби текст язылган. Шулардан җыентыкның 1а–18б кәгазьләрендә Мөхәммәд пәйгамбәрнең мигъраҗы (күккә — Аллаһ катына ашу) вакыйгасын тасвирлаган күләмле шигъри әсәр дә игътибарга лаек. Тик текстының башындагы битләре җуелган. Ахырында әсәрнең исеме һәм аның авторы күрсәтелгән: «Хаҗи Мәхмүд дөзде ошбу «Мигъраҗ»ы / Кем, киясез йәрен андан салават таҗы». Бу юллардан авторы — Хаҗи Мәхмүт, ә әсәрнең исеме — «Мигъраҗ» булуы аңлашыла. Бәлки тулы исеме «Мигъраҗнамә» булгандыр, әсәр ахырында бары тик шигъри төзелешкә һәм ритмикага күрә ул «Мигъраҗ» рәвешендә кыскартып язылгандыр. Кулъязмада «Мигъраҗ» исемле шигъри әсәрнең барлыгы 459 бәйте (918 шигъри юлы) сакланган. Бу әсәрнең теле бик борынгы. Ләкин шигъри куәсе, шул ук җыентыктагы «Кыз хикәяте» белән чагыштырганда, йомшаграк. Палеографиясе үзенчәлекле һәм кызыклы. Хаҗи Мәхмүд «Мигъраҗ»ы белән Мөхәммәтәмин һәм Мөхәммәдьяр әсәрләре арасында тел-стиль уртаклыклары, охшаш рифмаларның күп булуы бу әсәрне XV–XVI гасырларда иҗат ителгән дип билгеләргә бер дәлил булып тора.

Татар әдәбияты тарихын өйрәнгән галимнәрдән Гали Рәхим, Газиз Гобәйдуллин, Әмир Нәҗип, шулай ук Европа тюркологларының хезмәтләрендә XIII–XV гасырларга караган «Мигъраҗнамә» исемендәге шигъри әсәр турында мәгълүматлар бар. Ләкин алар шушы ук текстны күздә тотканнармы яисә бүтәннеме — анысы хәзергә билгесез.

Мөхәммәд пәйгамбәрнең мигъраҗ вакыйгасы Ислам галимнәрен, әдипләрне һәм гади мөселманнарны бик кызыксындырган темалардан булган. Шуңа күрә төрле чорларда һәм төрле илләрдә яшәп иҗат иткән әдипләр бу теманы тасвирларга алынганнар. Бер үк темага һәм бер үк исемдәге, нәзыйрә рәвешендәге, шулай ук мөстәкыйль әсәрләрне төрле телләрдә күп язган Шәрык халыкларында төрле әдипләр тарафыннан «Мигъраҗнамә» исемле әсәрләр дә иҗат ителгән. Мәсәлән, мәшһүр төрки шагыйрьләрдән Әхмәт Ясәвинең «Хикәяте мигъраҗ» исемле поэмасы, Сөләйман Бакырганыйның (1166/67–1186) «Мигъраҗнамә» исеме белән йөргән шигъри әсәре булган. Пәйгамбәрнең мигъраҗ вакыйгасы Мөхәммәд Чәләбинең «Мөхәммәдия» әсәрендә дә киң яктыртылган. Шуңа күрә татар авторларының да бу темага әсәр иҗат иткән булуы бик ихтимал.

Бу әсәр авторының Хаҗи Мәхмүд дигән исеме татар әдәбиятының мәшһүр шагыйре Мөхәммәдьярның әтисе исеменә авазлаш булуы аеруча кызыклы. Билгеле булганча, Мөхәммәдьяр «Төхфәи мәрдан» поэмасының ахырында:

*Атымны кем тиб сорсаң, и шәһрийар,*
*Мәхмуд Хаҗи угылы фәкыйрь Мөхәммәдйар,–*

дип язган юллардан шагыйрь әтисенең исеме мәгълүм иде. Менә бу мисалдан башка төрки-татар әдәбияты тарихында Мәхмүд Хажи (яисә Хажи Мәхмүд) исемле шәхес турында мәгълүмат тапмадык. Мөхәммәдьярнын әтисе Мәхмүд Хажи белән «Мигъраж»нын авторы икесе бер үк зат булуы ихтимал дип фаразларга мөмкин. Болар киләчәктәге фәнни эзләнүләр һәм тикшеренүләр нәтиҗәсендә ачыклануы ихтимал.

Кулъязма җыентыкнын 49а–58б кәгазьләрендә язылган шигъри әсәрнең башында «Кыз хикәяте» дип, исеме күрсәтелгән. Бу текст тулы: башы һәм ахыры бөтен. Әмма авторы кем булганлыгы әйтелмәгән. Хикәят тексты кулъязманың һәр битендә икешәр баганалы 17 (18) юл итеп язылган.

Бу кулъязма җыентык Татарстан Милли китапханәсе фондына 2000 елда Казан шәһәрендә алынган иде.

***

«Кыз хикәяте» турында тәфсилләп язуга керешкәнче, бер мәсьәләгә тукталып үтәргә тиешбез. Әдәбият галиме Нәҗип Исмәгыйлев бу әсәрнең бер вариантын (тулы булмаган күчермәсен) элекке Ленинград (Петербург) шәһәрендәге Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү (хәзерге Көнчыгыш кулъязмалары) институтында тапканлыгын белдереп һәм шул кулъязмага кыскача күзәтүен биреп мәкалә бастырган иде. Н.Исмәгыйлев болай дип яза: «1982 елнын җәендә Ленинград Көнчыгыш институты китапханәсенең кулъязмалар бүлегендә эзләнүләр белән шөгыльләнгәндә «Кыйсса-и Ибраһим егет вә падишаһ кызы» дип исемләнгән кулъязма табылды. Шигъри икеюллыклар белән язылган бу кыйсса «Мәликә китабы»ндагы сюжетка корылган әсәр булып чыкты. Сюжет бик кызыклы, анда башка вариантларда булмаган мотивлар да бар. Кыз белән егет арасында сорау-җавап ярышы беткәч, ахырда егет үзе бер сорау бирә. Кыз аңа җавап бирә алмый. Бик гарьләнеп, җавапны хәйлә белән белү өчен төсен-кыяфәтен үзгәртеп, төнлә егет янына килә. Егет белән мәҗлес корып, аңа шәраб эчертеп, җавапны сорап белә. Соңыннан егеткә йоклата торган дару биреп чыгып китә. Әмма егет янында кызның йөзеге онытылып кала. Шушы йөзек аркасында егет зур хәвефтән котыла һәм патша кызы белән кавыша. Менә бу йөзек мотивы башка вариантларда очрамый.

Безнең өчен шунысы әһәмиятле — әсәр ахырында автор кыйссанын язылган вакытын күрсәтә: ул һиҗри белән 784 ел, милади белән бу 1382 елга туры килә. Димәк, әсәр Алтын Урда чорында, Идел буенда төрки әдәбиятнын чәчәк аткан чорында язылган... Шигырь белән язылган бу әсәрнең башка нөсхаләре, вариантлары бармы, таралуы ничек, — бу аерым тикшеренүне таләп итә. Һәрхәлдә, тулы булмаган нөсхәнең табылуы да безнең XIV йөз әдәбиятына яна бер әсәр өсти, Көнчыгыш әдәбиятлары белән, аерым алганда, фарсы әдәбияты белән бәйләныш традицияләренең бик тирәннән килгәнен һәм беркайчан да өзелеп тормавын күрсәтә». *(Исмәгыйлев Н. Гасырларны кичкән сюжет // Казан утлары. — 1985. — №9. — Б. 181).*

Бу кулъязма истәлек турында бүтән галимнәрнең нәрсә дә булса язганлыгы безгә билгеле түгел. «В 4060» шифрлы ул кулъязма белән без дә таныштык. XVIII гасыр ахыры — XIX гасыр башына нисбәтле бу җыентык Фәннәр академиясе институтына 1936 елда археограф Сабир Алимовтан алынган. Поэма кулъязманың 1а–4б кәгазьләрендә, бит саен ике баганалы итеп язылган. Әсәрнең ахырында мондый юллар бар:

*Бер зәгыйфь кол иде, ады — Ибраһим.*
*Йарлыкасын аны, безне ки Рәхим.*
*Ошбу бәйтләр хасс-у-гамә улур сәбәб,*
*Дога кылучылар кем бездән шәйх-у-шәб.*

*Канкый йылдан бу хәбәр улды тәмам,*
*Әйдәйем бән тарихыны вәс-сәлям.*
*Йиде йөз сиксән дүртендә һәмам,*
*Йарлыкасун Хәллякыль-әнам.*
*Түрт йөз йегерме бәйт бән дидүм,*
*Мөхәррәм айында вә итмам әйләдүм.*
*Шөкре Аллаһ кем, кыйлдук бу дәфтәри,*
*Вир салават — шад кыйл фигамбәри.*



*«1764 т» шифрлы кульязма (Татарстан Милли китапханәсе). 49а кәгазь.*

Менә шушылардан әлеге әсәрне иҗат иткән авторның исеме Ибраһим булганлыгы аңлашыла. Шулай ук поэма 420 бәйтне (икеюллыкны) тәшкил иткәнлеге һәм аның һиҗри 784 елның мөхәррәм аенда язып төгәлләнгәнлеге күрсәтелгән. Бу дата милади ел исәбе буенча 1382 елның февраль-март айларына туры килә.

Кульязма җыентыкта поэманың 154 бәйте сакланган булуын исәпкә алганда, әсәрнең 266 бәйте, кызганыч ки, билгесез кала. Мәгълүм булган өлеше поэманың өчтән береннән аз гына артык. Тик әлеге әсәрнең шушы кульязма нөсхәдә сакланган кадәрле тексты да фәнни кыйммәткә ия һәм кайбер фикер-нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Беренчедән, Н.Исмәгыйлев билгеләвенчә, ул «безнең XIV йөз әдәбиятына яңа бер әсәр өсти». Икенчедән, без тасвирлаячак «Кыз хикәяте»нә әлеге текстның мөнәсәбәте һәм әлеге ике поэманың үзара бәйлелек дәрәҗәсе ачыклана. Кыскача әйткәндә, «Кыз хикәяте» поэмасы — Ибраһим исемле шагыйрь 1382 елда иҗат иткән әсәрнең бүтән бер әдип тарафыннан соңрак эшкәртелгән варианты. (Бу мәсьәләгә алдарак тәфсилләп тагын тукталырбыз).

***

«Кыз хикәяте» әсәренең Татарстан Милли китапханәсендәгедән тыш, бүтән күчермәләре табылмасмы дип эзләнүләребез дә уңай нәтиҗә бирде. Поэма текстының тулы булмаган ике күчермәсен ачыклауга ирештек. Аларның берсе Петербургта, икенчесе Казанда саклана. Шулар турында җентекләбрәк мәгълүмат биреп үтәбез. Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә саклана торган кульязма истәлекләр арасында «Кыз хикәяте» әсәренең тулы булмаган һәм дефектлы бер күчермәсен табып ачыкладык. «Табып ачыкладык» дибез, чөнки бу поэма тексты язылган «5228т» шифрлы, 18 кәгазьдән торган һәм XVIII гасырның ахырына нисбәтле кульязма китапханәнең каталогында «Шигъри әсәр» дигән гомуми исем белән генә теркәлгән. Кульязма төрелгән кәгазьгә зур итеп куелган сорау билгесе дә аның нәрсә икәнлеге моңарчы ачыкланмавына ишарәли. Хакыйкатьтә, әлеге кульязмада бер шигъри әсәр генә булмыйча, ике мөстәкыйль поэманың текстлары өлешчә сакланган. Аларның беренчесе (1а–12б кәгазьләрдә) XVI гасырда яшәп иҗат иткән мәшһүр татар шагыйре Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы, икенчесе (12а–18б кәгазьләрдә; битләр нумерациясендә буталчыклык бар) — «Кыз хикәяте». Монда «Нуры содур» текстының яртысыннан күбрәк өлеше, шул исәптән ахыры бар.

Казан федераль университеты китапханәсендәге кульязмада «Кыз хикәяте» текстының башы бар, ләкин ахыры юк, исеме бүтәнчә язылган. Атамасының беренче сүзләре, хәрефләре унган булуы сәбәпле, аңлашылып бетми. Бу кульязмада әсәрнең барлыгы 218 бәйте язылган. Кульязманың ахырдагы ике кәгазе вертикаль буенча яртылаш диярлек ертылган. Сакланган хәтле текст эчендә кайбер бәйтләр бөтенләй язылмыйча калган.

Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгыш кульязмалары институтында саклана торган җыентыкларның берсендә шулай ук «Кыз хикәяте» әсәренең тулы булмаган бер күчермәсе саклануын ачыкладык. Бу кульязма СССР Фәннәр академиясенең Татарстанда 1934 елда үткәргән археографик экспедициясе вакытында табылган. Күләме 72 кәгазьдән тора. Андагы берничә әсәр арасында — 19б—25б кәгазьләрдә «Кыз хикәяте» теркәлгән. Бу җыентык Мөхәммәтситдыйк Әхмәтҗан улы тарафыннан 1855 елда күчерелгән. «А 1295» шифры белән саклана торган әлеге кульязмадагы «Кыз хикәяте» поэмасының исеме күрсәтелмәгән, аның башланган урынында бары тик «Илаһи бәет» дип кенә куелган. Әлеге кульязмада бу әсәрнең башы һәм ахыры юк. Күчерүче тарафыннан төшереп калдырылган шигъри юллар бик күп. Аерым икеюллыкларның язылмый калуы белән бергә, поэманың урыны-урыны белән тоташ һәм зур-зур өлешләре төшереп калдырылган.

Бу ядкәрләрнең ачыклануы — әлеге әсәрнең татарлар арасында таралып укылганлыгына өстәмә бер дәлил булып тора.

Шулай итеп, «Кыз хикәяте» поэмасының безнең тарафтан хәзергә өч күчермә нөсхәсе ачыкланды. Әйткәнебезчә, аларның тулы нөсхәсе Татарстан Милли китапханәсендә саклана. Поэманың монда тасвирланачак тексты шул тулы күчермәдән алынды. Киләчәктә максатчан эзләгәндә, Ибраһим әсәренең дә, «Кыз хикәяте»нең дә монарчы билгесез күчермәләре табылуы бик ихтимал әле.

## «Кыз хикәяте»нең эчтәлеге

«Кыз хикәяте» унбер-унбер иҗекле гаруз үлчәмендәге, барлыгы 348 бәйттән (ягъни, 696 шигъри юлдан) гыйбарәт.

Ислам мәдәниятенә бәйле бөтен Шәрык һәм шул исәптән төрки-татар язма әдәбиятына хас булганча, әдәби әсәрләр Аллаһка, Мөхәммәд пәйгамбәргә дан һәм мактау сүзләре белән башланган. Әмма, ни сәбәпледер, «Кыз хикәяте»нең башлангыч юлларында әлеге традиция сакланмаган. Дөрес, әсәрнең эчтәлегендә Аллаһы Тәгаләнең исеме 48 мәртәбә искә алынып макталган. Автор үз исеменнән 94 нче бәйттә «Бер салават әйдәлүм Мөхәммәдкә...» дип, пәйгамбәр исемен дә язган.

«Кыз хикәяте» кыйссасының эчтәлеге кыскача тасвирлаганда түбәндәгечә.

Әсәрнең башында:

*Бер хикәят кәлде, әйдәм, дилимә,*
*Ошбу сүздә файда вардур галимә.*
*Һәркем гыйлем илә даим дорыша –*
*Һич гәман юк — соңра гыйлем ирешә,*

— дип, галимлек мәртәбәсе зур булуы искәртелә. Остазын куандырган кешенең дөньяда хур булмаячагы да әйтелә.

Шуннан соң хикәятнең төп өлеше бәян ителә. Элекке заманда мул тормышлы бер хуҗа яшәгән. Аның бик белемле һәм сүзгә оста, яхшы холыклы, күркәм йөзле бер улы була. Бер заман болар, мохтаҗлыкка төшеп, бөләләр. Тамак туйдырырлык хәлләре дә калмый. Улы әтисенә бүтән шәһәргә барырга тәкъдим итә.

Үзара килешеп, бер чит шәһәргә баралар. Анда ачлыкта өч көн, өч төн җан асрыйлар. Аптыраган уллары ата-анасына «Монда ачлык һәлак иткәнче безне, патшага сатыйм икегезне. Ач хуҗа булганчы, тук кол булыгыз. Сез нәрсә диярсез?» — ди. Ата-анасының ризалашмыйча чаралары юк. Уллары шәһәргә барып, «бер колым һәм бер карт хезмәтчем бар — аларны сатам», ди. Солтан, боларны кызганып, сатып ала. Егет әтисе бәясенә ат, әнисе өчен киемнәр ала. Ата-ана тамак туйдыру һәм кием-салым хакына солтанга кол булып калалар.

Егет киенеп, атка менеп сәфәр чыга. Юлда ул бер җайдакны очрата. Сәламләшәләр. Җайдак үзенең калага баруын, андагы бәккә хат илтүен әйтә. Егет исә шул якка юл тотуын әйтеп, «хатынны тапшырырмын» дип, үзенә ала. Аерылышалар. Егет

шикләнеп хатны ачып караса, анда «бу хатны китерүченең башын кисәргә» дигән юлларны укый. Гаҗәпләнеп һәм, хатны укып каравы сәбәпле, башын исән саклап калуына Аллага шөкер кылып, егет юлын дәвам итә.

Бик зур һәм бик төзек, күп халык яши торган бер шәһәргә барып җитә:

*Дүрт яны сулаб агар хуш багчалар,*
*Пул йиренә анда йөрүр акчалар.*

Әмма кирмән манарасына асылган адәм башлары күреп егет бик гаҗәпләнә. Ул бер карчык өенә төн кунарга туктала. Карчык бу шәһәр солтанының гаҗәеп чибәр һәм укымышлы кызы барлыгын, үзен кияүгә алырга теләүчеләргә сораулар-табышмаклар биреп, дөрес җавап бирә алмаганнарны үлем җәзасына тартуларын сөйләп бирә. Бик күп патша һәм солтаннарның уллары йөк-йөк мал китерсә дә, кызның шарты какшамас — сорауларына дөрес җавап бирүчегә генә кияүгә барачак.

Карчыктан рөхсәт алып, бу егет тә кыз катына барып карарга була. Карчык башта каршы килеп, үгетләсә дә, аннары «Аллаһ ярдәм итсен сиңа» дип, фатихасын бирә. Егет солтан сараена барып:

*Гыйлем илә, хәдис илә, тәфсир илә,*
*Сөйләшәлүм икебез анда билә,*

— ди. Солтан егеткә харап буласың дип, фикереннән ваз кичәргә өндәп тә карый:

*Солтан әйдүр: «Каныңа кермә, егет!*
*Белмәз ирсәң, үлдүрүрем, сүзүм ишет!»*

Ниһаять, кыз сараена кертәләр. Егет үзалдына «бу чибәрнең йөзенә баксам, ул күнелемне алып, мәҗнүн итәр дә, мин дөрес җавап бирә алмам» дип фикерли. Кызга «йөзеңне капла, шәригать буенча миңа синең йөзеңне күрү хәрам», — ди. Беренче көрешүдә кыз егеткә дөньяви һәм дини эчтәлектәге җиде сорау бирә. Дини сораулар пәйгамбәрләрнең Коръәндә тасвирланган һәм риваятьләрдә сөйләнгән вакыйгаларына бәйле. Егетнең барлык сорауларга да дөрес җавап тотуыннан кыз пошаманга төшә. Егет үзенә мәрхәмәт кылган рәхимле Аллага шөкерана укып, хушлашалар.

*Ул егет торды йирендән. Сөенә.*
*Кәлде янә ул карыйчук өенә.*
*Карчык аның котыла алуына гаҗәпләнә.*

Икенче көндә иртән егет тагын кыз сараена килә. Бу юлы кыз күпчелеге дини мәсьәләләргә караган, тагын да катлаулырак унике сорау бирә. Егет һәммәсенә җавап биреп котыла.

Бу хәлгә аптыраган кыз ашаудан бизә, йокысыз кала:

*Кыз каты пошукды углан эшенә,*
*Ул кичдә сонмады әлен ашына.*
*Әндишәдән уйку килмәз күзенә,*
*Хәйран улды ул егетүң сүзенә.*
*Өченче көннең иртәсендә егет кыз катына килеп,*
*Сәлям вируб, шадиман утурды хуш.*
*Әйтде: «Дәхи нә сорарсән? Кәлдем уш».*
*Ике көндүр җавабуң вирдүм саңа,*
*Бу көн дәхи нә сорарсән? Ди бәңа!»*
*Кыз исә аеруча кырысланып куркыта:*
*Белмәз исәң, башыңы кисәрәм,*
*Ошбу кальга бөрҗенә хуш асарам.*

Егет ике көн үзенә Аллаһ ярдәм итүен, инде бу юлы да ярдәме булачагына ышануын әйтә. Кыз монысында гөнаһлары өчен Аллаһы Тәгалә тарафыннан кеше сурәтеннән хайван, кош, бөҗәк һәм башка хәшәрәтләргә әверелдерелгәннәрне санап бирергә куша. Егет һәммәсенә җавап бирә. Ул барлыгы унтугыз затны атый. Кыз аларны шул хәлгә төшергән сәбәп-гөнаһларны да әйтергә куша. Егет барысына да җавап бирә һәм үз соравын бирә.

*Ул егет әйдер кызи: «Ий, җарийә!*
*Өч көн улды, сүз дөште арайә.*
*Йиңсәйдүң һәм кисәр идең башыми.*
*Хакга чук шөкер! Үгәрде эшеми.*
*Бугүн өч көндүр, сән мәсьәлә сордың бәңа,*
*Нә сордың ирсә, җавабын вирдем сәңа.*
*Бән дәхи бер мәсьәлә сорам сәңгә*
*Ки, җаваб әйдур улурсаң сән бәңгә,*
*Шөйлә улсун шартымыз — башың кәсам,*
*Илтүб ошбу кальга бөрҗенә асам!»*

Кыз ризалаша. Егет үз башыннан кичкән хәлләрне сорау итеп куя.

*Егет әйдүр: «Кемдүр ул, әй, хуш сурәт,*
*Анасын тун әйләде, атасын — ат?»*

Кыз бик күп уйланса да, җавабын бирә алмый һәм төнлә фикерләп, иртән әйтергә егеттән рөхсәт сорый. Егет ризалашып, карчык өенә кайта. Кыз көчле хәсрәткә-уйга төшә. Ниһаять, яшертен генә егет янына бару карарына килә:

*Хәйлә илә мәсьәләсен сорайын,*
*Иртә кәленчәк җавабын вирәйен.*
*Дәхи нә кылур, башыны кисәйен,*
*Аны дәхи ошбу бөрҗдә асайын.*
*Тора килде, бизәде кәндүзени,*
*Гаклы китәр — һәркем курсә йөзени!*

Төн уртасында кыз карчык өенә килә. Рөхсәт сорап эчкә үтә.

*Бакды, күрде егет каршыдан кызы,*
*Әйтде: «Хуш кәлдең, әй, таң йолдызы!»*

Егет кызның ник килүен сораша. Кыз: «Сиңа гашыйк булдым. Син кем? Солтан кызын җиңгәнсең икән...» дип, хәйлә белән серен ала башлый. Кыз йөзен ачкач, егет аның гүзәллегенә таң кала. Ашап-эчеп көлешәләр. Кыз егеттән: «Шаһ кызына биргән соравың нәрсә иде?» — дип, җавабын белеп ала.

*Хәйлә илә ул кыз аңлады аны,*
*Дунде кыз. Әйде: «Ай, җаным җаны!*
*Кичдән бирү һич эчмәдук шәраб...*

Егет шәрап эчеп, һушын җуйгач кыз китеп бара.
Иртән егет төн кызы белән бәйле хикмәтләрнең серен аңлый. Хафага төшә.

*Әйтде: «Ай-вай, аңламадум эшем,*
*Кәсерсә золым илә ул кыз башым...»*
*Шул вакыт,*
*Бакды — күрде түшәгедә бер йөзук,*
*Әйтде: «Бонуңлә ула сузум төзук!»*

*Кашы йагкут ул йөзук алтун иде,*
*Кашында ул кызың ады йазулу иде.*

Йөзекне алып ул кыз сараена килә. Сәламләшәләр. Кыз егетнең кичәге соравына төгәл җавапны бирә һәм башын кистерергә куша:

*Мәсьәләң бу иде — белдем, әй, егет,*
*Кәстерәрәм башыңы, бел ки, ишет!*

Егетне солтан янына китереп, җиңелгәнлеген хәбәр итәләр. Егет солтанга үзенең сүзе барлыгын белдереп, бер күгәрченнең кыз сараеннан очып чыгып, үз өйләренә керүен әйтә. «Кошны тотып аягыннан бәйләгән идем, тик сизмәгәндә ул кызның сараена очып китте. Шөкер, аның бер каурые калды», — дип, сөйләп бирә һәм солтанга йөзекне тоттыра. Йөзектә кызының исемен укыгач солтан ярсый:

*Әйтде бәр гиз: «Һәй-әй, буйнун өзүң!*
*Бу егет катында нәйләр йөзүгүң?*
*Кыз исә бу йөзекнең үзенеке түгеллеген әйтә, ул егет алдый ди.*
*Солтан әйтде: «Йөзегүң кәтүр, күрәйен!*
*Бу егетә бән җәзасын вирәйен».*
*Куркусындан шаһ кызы дүнде кәрү,*
*Варды сарайына, керде ичәрү.*

Кыз бер останы чакыртып, хакына нәрсә сорасаң да бирәм дип, үзенә тиз генә йөзек ясарга боера. Оста бер сәгать эчендә нәкъ әүвәлгесе кебек үк йөзек ясап, аның якут кашына кызның исемен яза.

*Ул остада вирделәр бең алтунни,*
*Әйдер остад: «Гаебләмәңез бәни?»*
*Алды ул кыз йөзүге, кәлде кәрү,*
*Ата сараена керде ичәрү.*

Кыз менә минем йөзегем дип, атасына бирә. Солтанның вәзирләре, бәкләре һәм башкалар да ике йөзекне чагыштырып карыйлар.

*Бәкләр әйдур: «Иске йөзүкдүр бу йөзук,*
*Яңы йөзүкдүр бу соңрагы йөзүк.*
*Рәнге — бер, калыбы — бер һәм кашы — бер,*
*Бу аның дәгелдүр! — диделәр, — Йа, әмир!»*
*Кол-каравыш, хадим-бәкләр каму,*
*Танык вирделәр солтана, гаму.*

Хәйләләрнең серенә төшенгән ата кызына мөрәҗәгать итә:

*Солтан әйдур: «Сәне вирдем егетә.*
*Бунуң кеби галим улмаз дөньяда!»*

– ди. Шулай итеп, солтан кызын егеткә кияүгә бирә. Жиде көн, жиде төн бәйрәм була. Солтан егетне үз улы кебек күреп, үзенә алмашка хөкемдар булачагын белдерә, бәкләр дә ризалаша.

Егет солтан булганнан соң илгә гадел хөкем ирешә. «Гадел ирде ул каму юксуллара», ягъни ул барлык фәкыйрьләргә дә гадел булган.

*Атасына-анасына хәлне ул,*
*Яздырыб белдүрде әхвальне ул.*

Коллыктагы атасы үзләренен хуҗасы булган шаһка яналыкны житкерә һәм азат итүен сорый. Хаким аларны азат итә. Ата-ана уллары янына килеп, бергәләп озын гомер кичерәләр.

***

Бу хикәяттә кыз егеткә өч тапкыр көрешүдә барлыгы 21 сорау биргән. Аларнын дүртесе дөньяви сораулар булса, 17 сорау дини тәгълимат белән бәйле. Текстта Аллаһы Тәгалә һәм Коръәнгә нисбәт ителгән сорау һәм җавапларда тасвирланган вакыйгаларнын күпчелеге, чынлап та, Коръән текстына бәйле, кайберләре Коръән тәфсирләрендә һәм пәйгамбәрләр тарихына багышланган «Кыйссасел-әнбия» һәм «Тарихе әнбия» әсәрләрендә чагылыш тапкан. Тик әсәрдәге кайбер нәрсәләр Аллаһнын исеме белән бәйләп күрсәтелсә дә, чынлыкта, сорау-җавапларнын бер өлеше Коръәндә язылмаган башка төр риваятьләр, легендалар, халык ышанулары һәм хорафатларга нигезләнгән.

Поэмада кызнын егеткә биргән кайбер сораулары гади, бер яки берничә сүз белән генә җавабын бирерлек булмыйча, катлаулы рәвештә төзелгәннәр. Мәсәлән, түбәндәге сораулар шундыйлардан:

*Ул кыз әйдүр: «Канкый агачдур, вир хәбәр,*
*Ул агачуң унике бодагы вар,*
*Дәкмә бер бодакда вардур утуз ябрак,*
*Һәр беренуң эче — кара, ташы — ак?»*

Бер агачнын унике ботагы, аларда исә утызар яфрак турындагы табышмак, ихтимал, борынгырак заманнардан ук яшәп килә торгандыр. Чөнки бу табышмак әлеге сюжетка язылган текстларнын күбесендә («Мәҗмугыл-хикәят»тә, Карло Гоцци әкиятендә һәм анын Кәрим Тинчурин тәрҗемәсендә, Шиһабетдин Рәхмәтуллиннын «Каләф берлә Турандук хикәяте»ндә һ.б.) очрый. Шулай ук Нәкый Исәнбәт туплап чыгарган табышмаклар арасында

*«Бер өянкедә унике ботак,*
*Ботак саен утыз яфрак:*
*Һәр яфракның бер ягы кара, бер ягы ак»,*

– рәвешендәге һәм шул табышмакнын башка төрдәшләре бирелгән (Татар халык табышмаклары. — Казан, 1970. — Б. 113, 470.).

## Әсәрнең идеясе

«Кыз хикәяте» поэмасынын төп идеясе гыйлем дәрәҗәсен олылаудан гыйбарәт. Автор белем куәтен акыллы һәм гадел хөкемдар мәсьәләсе белән бәйләп карый. Хикәятнен башында ук егеткә Аллаһ хуш гыйлем биргәнлеге, анын холкы-табигате һәм төсе-бите күркәмлеге әйтелә. Гаиләләре бөлгенлеккә төшкәч тә, угылларынын акыл белән эш йөртүе нәтиҗәсендә, ата белән ана ач үлемнән котылып кала. Егетнен ата-анасы бай сәүдәгәрлектән бөлгенлеккә төшүе мисалында автор гыйлемнең мәртәбәсе олуграк булуын күрсәтә. Мөлкәт байлыгына караганда рухи-гыйльми байлык өстенрәк икәнлеген аңлата.

Юлда очраган җайдакның хатын ачып эчтәлеген белгәч, егетнең харап булудан котылуына да төп сәбәпче — белем. Чөнки уку-язуны белмәсә, егет юлчы биргән хатның үз башына җитәрдәй дәрәҗәдә куркынычлы икәнлеген аңламас иде. Ниһаять, солтан кызы белән сорау-җавап бәйгесе дә гыйлемлек ярышын, ягъни ике укымышлы кешенең үзара көч сынашуын тасвирлый. Тирән гыйлемгә ия кыз бу егет белән очрашканчы байтак егетләрне җинеп, башларына җиткән. Ул да иң югары мәртәбә итеп белемне күреп, үзен акыл сынавында җиңгән кешегә генә кияүгә барачагын шарт итеп куйган. Патшалар һәм солтаннарның угыллары хисапсыз мал-мөлкәт тәкъдим итсә дә, байлыкка риза булмыйча, сорауларына дөрес җавап бирүне өстенрәк күргән.

Егет, Аллаһ биргән гыйлемен файдаланганда, әлбәттә, Хак Тәгаләнең ярдәменә ышана һәм даими шөкер кыла. Кыз белән көч сынашканда да «гыйлем илә, хәдис илә, тәфсир илә сөйләшәлүм...» дип, дини гыйлемнәр беренче урында тотылуы искәртелә. Чынлыкта да, егет Коръәнне, Ислам дине тарихын һәм шәригать өйрәтмәләрен тирәнтен белгәнлеген дәлилли. Кыз һәм егет үз сорау-җавапларында чиксез хакыйкать һәм гаделлек чыганагы булган Коръәнгә таяналар, аңа ишарә итәләр.

Әсәр ахырында солтан үз кызын егеткә кияүгә бирүен белдереп, «моның кебек галим булмас дөньяда» дип соклана. Белемнең көченә таянып гамәл кылган егет солтанлык дәрәҗәсенә ирешә һәм дөньядагы иң газиз һәм кадерлеләре — әти-әнисен дә азат итә. Хикәят ахырындагы «каму галим торды анда аңа колга» дигән сүзләрдән мәмләкәттә әлеге егеттән дә гыйлемле кеше булмаганлыгы аңлашыла.

Әсәрнең төп фикерен ил-дәүләт белән зур галим дәрәҗәсендәге кеше идарә итәргә тиеш дип аңларга кирәк. Бу мәсьәлә дөнья тарихы мәйданында һәр чорда да актуаль булган һәм шулай булып калуын дәвам итә.

## Әсәрдә тасвирлау чаралары

«Кыз хикәяте»нең төп геройлары булган егет белән кызны автор гыйлем ияләре итеп чагылдыра. Әсәрдә егет «Галим иде һәм фәсыйх иде дели», «Хуш гыйлем вирмеш иде Аллаһ аңа» һәм «Холкы ләтыйф, күреклү иде сурәте, /Һәм күрке ляик иде сийәрәте, — дип тасвирланса, кыз исә бу рәвешле сурәтләнә: «Күк алында ул кызыйның мисле юк, / Гашыйклар улды шәһәрдә аңа чук». Шулай ук кызны автор «...галимдер — кемсә аны йиңмәз», «Ул кызуң һәрбер сүзе, угул, бали», «Гаклы китәр — һәркем күрсә йөзени», «Кайгулу улан күрүрсә, сәвенә» дип сыйфатлый. Кыз белән егетнең шушы хасиятләре поэмада гамәлләре белән бәйләп күрсәтелә һәм дәлилләнә.

Хикәяттә кыз белән егет бер-берсенә бик зурлап, хөрмәт белән эндәшәләр. Кыз гади генә «әй, егет» дип җиде мәртәбә эндәшсә, «әй, хуш кеше», «сыйлә» (кардәш), «пөрһөнәр» (һөнәр иясе, оста), «әй, паке дин» (изге дин әһеле), «әй, мөһтәди» (иман әһеле), «әй, әһле дил» (акыл иясе), «әй, пишкадәм» (укымышлы кеше), «әй, хуш нәһад» (гүзәл табигатьле) дип ихтирамын да белдерә, шулай ук «әй, җаным җаны», «йара» (сөекле дус), «әй, кандәләб» (татлы ирен) рәвешендәге гыйшык сүзләрен дә әйтә.

Егет тә, кызның белеменә хөрмәт йөзеннән, «пишкадәм», «әй, дәдә» (дәрвиш), «әй, һөмам» (тырыш кеше) кебек мактау сүзләре белән, солтан кызының югары дәрәҗәсенә һәм аксөяк затына күрә, «әй, хатун» һәм «хуш нәһад» дип, гүзәллегенә сокланып «әй, күрекле йөз», «әй, тан йолдызы», «әй, җаным», «әй, нигяр» һәм «йа, нигярин» (чибәр кыз) дигән татлы сүзләр белән эндәшә.

Әсәрдәге башка әңгәмәдәшләрнең мөгамәләсе дә итагатьле. Мәсәлән, егет әтисенә «газизем», солтанга «әй, хуш нәһад» һәм «әй, шаһе җәһан» (җиһан шаһы), карчыкка «и, ана» дигән мөрәҗәгать сүзләре куллана. Солтан егеткә ихтирам белән «әй, хуҗа» дип, ә карчык егеткә «угыл җаный», «җаным» һәм «җаным угыл» дип, якын итеп сөйләшә.

Әсәрнең төп өлеше әңгәмәгә, кара-каршы сорау һәм җавапка корылган. Бигрәк тә кыз белән егетнең диалогы текстның күпчелеген билэп тора. Автор урыны-урыны белән укучыга да мөрәҗәгать итә. Мәсәлән, ул «Гариблекдә мөфлис улманыз, әй, йар!» дип тели. Хикәятнең авторы җанландырып җибәрә торган эндәш сүзләр дә куллана. Мәсәлән, «Торды егет, күр, нә дир атасына», «Морады күр, нәфәка!», «Күргел имди — Хак Тәгалә нәләр идәр!», «Егетә, күр, нә кылур!», «Күр, нәләр деләр».

Автор, үзе дә вакыйгалар эчендә катнашкан кебек, егет белән кыз әңгәмәсе арасында шәхси мөнәсәбәтен белдереп үтә. Мәсәлән,

*Бер салават әйдәлүм Мөхәммәдкә,*
*Хакъ гыйнайәт әйләйә ул егетә.*

Икенче урында автор укучыга мөрәҗәгать итеп болай ди:

*Бу җанварлар, дәхи ишедуң каму,*
*Адәм иде һәрбересе, әй, гаму!*
*...Сакласун сези-безе бу эшдән.*

Кыз егеткә сораулар биргәндә ашыктыра, ягъни уйланырга мөмкинлек тә калдырмый. Мәсәлән, «тиз хәбәр виргел...», «тиз хәбәр вир...», «тиз әйт!». Өстәвенә, ул егетне төрле бәлагә дучар итү белән куркыта, «бүген башың кан булыр» ди, «башынны кисәм һәм асам» дип яный. Кыз, хәтта үз хәле мөшкелләнгәч тә, егеткә «һәр заман асылмыш егетләр солтаны!» дип, һаваланып маташа.

Егет исә җаваплар биргәндә җебеп төшми, Аллаһның ярдәменә һәм үзенең гыйлеменә ышанган хәлдә, «буны белүр каму юксул-бай», «ушак угылы белә», «буны белүр углан ушак, җөмлә белүр бу сүзе», «сорур ирсәң мөшкилендән сор бәнә» дип гайрәтләнеп сөйләшә. Әсәр авторы мондый алымнар кулланып, вакыйгалар агышының һәм тасвирланган хәлләрнең киеренкелеген гәүдәләндерә. Әсәрдәге «Бер күгүрчен кыз сараендан очар, / Канчару варурса, ганбәр сачар./ Кәлде кунды безем әүнүн эченә... — юлларына охшаш манзаралар Рабгузиның «Кыйссасел-әнбия» әсәрендә дә бар. Мәсәлән, Әюп галәйһиссәлам кыйссасында муйнында энҗе, аягында йакут тагылган бер ак күгәрчен килеп керүе, патша кызы аны тотам дигәндә очып китүе турында язылган. Бу күгәрчен исә фәрештә булган икән. Шулай ук Дауд галәйһиссәлам турындагы кыйссада да «Мәүля Тәгалә кодрәте берлә бер кош очуб килде: башы — йенҗүдин, күзләре — кызыл йакутдин, аяклары — яшел зәбәрҗәддин, канатлары — алтундин». Бу кош Дауд галәйһиссәлам алдына кунгач, пәйгамбәр аны тотмакчы була — ләкин кош очып китә. Рабгузи әсәрендәге бу күренешләр белән «Кыз хикәяте»ндәге егет янына күгәрчен очып керүе аваздаш тасвирлардан икәнлеген искәртергә тиешбез.

Хикәятнең «Пул йиренә анда йөрүр акчалар» дигән шигъри юл вак бакыр акча урынына зур бәрәмлектәге көмеш акчалар кулланылуын белдерә. Ягъни шәһәрнең бай һәм мул тормышлы булуы аңлатыла. Нумизматика белгечләреннән галим Әзһәр Мөхәммәдиев язуынча, Алтын Урда дәүләтендә «пул» сүзе язылган татар бакыр тәңкәләре XIV гасырның беренче яртысында Сарай, Болгар, Хаҗитархан кебек шәһәрләрдә сугыла башлаган.

«Кыз хикәяте»нең төп үзенчәлеге һәм шушы сюжетка нигезләнгән бүтән әсәрләрдән аермасы — аның нинди дә булса җирлеккә һәм урынга (патшалык, шәһәр һ.б.) бәйсез тасвирлануында. Автор бу әсәрен аерым географик һәм тарихи хасиятләргә бәйләмичә язып, аның таралыш һәм укылыш офыкларын киңәйткән. Поэманың сәнгати тасвирлау чаралары, әлбәттә, болар белән генә чикләнми. Без монда аларның барысына да тукталмадык.

«Кыз хикәяте»нең теле мәсьәләсенә килгәндә, ул урта гасырлардагы Идел буе төрки-татар язма теленнән аермалы түгел. Хикәятнең теле Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф», Мөхәммәтәминнең «Могҗизнамә» һәм «Кыйссаи Мансур», Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдан» һәм «Нуры содур», шулай ук башка әдәби ядкәрләр теленә бик якын. Хикәятнең лексик составы һәм кулъязма күчермәләренең палеографик үзенчәлекләренә күрә, аның иҗат ителү вакытының гомуми чикләрен XV гасыр башыннан алып XVI гасырның уртасына кадәрге арада язылган дип билгеләп була.

## «Кыз хикәяте» сюжетының төп өлгесе

Бу әсәрнең сюжеты борынгы чорларның Шәрык легендаларына нигезләнгән. Мең еллан әүвәл үк мөселманнарның изге китабы Коръәндә һәм аның тәфсирләрендә, XII гасырда яшәгән мәшһүр шагыйрь Низами иҗатында, Рабгузиның XIV гасыр башында язылган «Кыйссасел-әнбия» әсәрендә, халык авыз иҗатында тасвирланган охшаш һәм уртак тема төрки-татар әдәбиятында да төрле дәрәҗәдә чагылыш тапкан һәм үз урынын алган. Күләмле шигъри әсәрләр язу белән беррәттән, хикәят һәм

әкиятләр рәвешендә телдән сөйләнгән, шулай ук кульязмалары күчерелеп халкыбыз арасында таралып укылган. Шулар тәэсирендә XX гасырга кадәр татар әдипләре (мәсәлән, Фатыйх Халиди һәм Нәкый Исәнбәт) үзләренең яна әсәрләрен иҗат иткәннәр. Гомумән, бу сюжет Ислам мәдәнияте аша бөтен дөнья казанышына әверелгән.

Урта гасырлардагы Шәрык һәм татар әдәбиятында нәзыйрә (өлге, үрнәк, җавап, күчермә) иҗат ысулы, ягъни поэтик калыбы киң таралган булган. Ибраһим исемле авторның 1382 елда иҗат иткән поэмасы турында алдарак язып үткән идек. Аның сакланган өлеше белән «Кыз хикәяте»н чагыштырып чыккач, без мондый нәтиҗәгә килдек: ике әсәрнең дә эчтәлеге бер-берсенә охшаш булса да, аларның авторлары бер үк кеше булмаган. Фикеребезчә, 1382 елгы әсәрне икенче бер әдип нигез итеп алып, аны иҗади эшкәрткән, нәзыйрә рәвешендә үз поэмасын язган.

«Кыз хикәяте» — 1382 елда иҗат ителгән поэманың бер күчермә варианты гына түгел микән дип карау — мәсьәләне гадиләштерү һәм ялгышлык булыр иде. Ике әсәрдәге бәйтләрнең исәп ягыннан тәңгәл килмәвен күчерүче игътибарсызлыгына сылтарга яисә күпмедер өлеше максатчан төшереп калдырылган дип нәтиҗә ясарга, бер карашка, мөмкин кебек тоелса да, мәгънәви төрлелекләрнең күплеге андый ихтималны кире кага. Текстка күчерүчеләр тарафыннан гына бу хәтле үзгәрешләр кертелгән булуы мөмкин хәл түгел. Чөнки әлеге ике поэмадан шактый борынгырак чорда Кол Гали иҗат иткән «Кыйссаи Йосыф» әсәренең өч йөзгә якын күчермәсе булып, мондый дәрәҗәдәге күп аермалар аларда да юк. Шулай ук «Кыз хикәяте»нең хәзергә безнең тарафтан ачыкланган өч кульязма күчермәсендәге текстлар арасында бер-берсеннән бик зур аерымлыклар юклыгын да әйтергә тиешбез. Моны раслар өчен дәлилләргә мөрәҗәгать итик.

Ибраһим әсәренең тулы тексты 420 бәйтне тәшкил иткән (шулардан 154 бәйт безгә мәгълүм). Ә «Кыз хикәяте» барлыгы 348 бәйттән тора. Беренче аерма менә шунда. Чөнки «Кыз хикәяте»нең өч кульязмасын чагыштырып өйрәнү күрсәткәнчә, аларда бәйтләр саны аермалы булганлыкка дәлилләр юк. Бары тик ике кульязманың (Казан университеты һәм Петербург нөсхәләре) тулы түгеллеге һәм дефектлы булулары сәбәпле, текстлары бөтен түгел. Ә аларның сакланган кадәр өлешләрендә Татарстан Милли китапханәсендәге нөсхәдән аермалы яна бәйтләре юк.

Ибраһим әсәре язылган кульязманың һәр битендә «Кыз хикәяте»ндә булмаган, бөтенләй бүтәнчә бәйтләр бар. Ягъни бу текстның барлыгы 46 бәйте «Кыз хикәяте»ндә бөтенләй юк. Шул исәптән, 1382 елгы әсәрнең ахырында аның авторы, иҗат ителү датасы һәм бәйтләр саны күрсәтелгән булса, «Кыз хикәяте»ндә боларның берсе дә язылмаган. Әйтелгәннәргә өстәп, Ибраһим әсәрендәге тагын 12 бәйтнең «Кыз хикәяте»ндәге юллардан бик зур аермалы булуларын да искәртик. Шулай итеп, 1382 елда иҗат ителгән әсәр текстының билгеле өлеше буенча фикер йөрткәндә, аның өчтән бере «Кыз хикәяте» поэмасының текстыннан аермалы. Ә «Кыз хикәяте» текстындагы 25 бәйт Ибраһим әсәренең сакланган өлешендәге бәйтләре арасында бөтенләй юк. Димәк, бу бәйтләр бүтән, ягъни әсәрне яңартып, үз поэмасын тудырган авторныкы дип саналырга тиеш.

1382 елда иҗат ителгән әсәрнең сакланган тексты кызның егет янына килүе белән башланган. Кыз хәйлә белән егетне сөйләтә. Кызның егетне сөйләтү өчен «Буйнундан кочуб сөрде йөзенә-йөзен» кебек юллар «Кыз хикәяте»ндә юк. Егет исә шаһ кызы белән икесе арасында булган сорау һәм җавапларны бәйнә-бәйнә сөйләп бирә. Тик сораулар һәм җаваплар «Кыз хикәяте»тендәгегә тәңгәл килми. Әсәрнең бу өзегендә телгә алынган ун сорау һәм җавапның бишесе генә «Кыз хикәяте»нә туры килә. Тагын шуңа да игътибар итәргә кирәк, әлеге ике әсәрнең охшаш булган бәйтләренең дә сүзе-сүзгә тәңгәл килә торганнары бөтенләй юк. Һәр шигъри икеюллыкта нинди дә булса аерма бар. Бу ике әсәрдә бер-береннән аермалы урыннары бик аз булган бәйтләр санаулы гына диярлек. Ике поэма текстларындагы охшашлык һәм аерымлыклар дәрәҗәсен түбәндәге юллардан да күзалларга мөмкин.

| *«Кыз хикәяте»ндә (Татарстан Милли китапханәсе, «1764 т» шифрлы кульязма)* | *1382 елда язылган кыйссада (С.-Петербург, «В 4060» шифрлы кульязма)* |
|---|---|
| *172 бәйт*<br>Кыз каты пошукды углан эшенә,<br>Ул кичдә сонмады әлен ашына. | *2а кәгазь*<br>Кыз каты госса улубән углан эшенә,<br>Усанмады ул кәчә улган ... (?) |
| *192 бәйт*<br>Дүнде кыз, әйтүр: «Хәбәр вир, әй, егет!<br>Нә сәбәбдән мәнсух улдылар? Әйт!» | *2б кәгазь*<br>Кыз әйдүр: «Анлар дүндеке нәдәндүр,<br>Нә сәбәбдән нәсех улдылар ки? Әйт!» |
| *197 бәйт*<br>Йөз чәверүб Гайсадан, улды гаду,<br>Әйтделәр: Зәһи! Яланчы! Жаду! | *2б кәгазь*<br>Йөз чәверде Гайсадан ул кавемләр, әйде: «Гаду!»<br>Диделәр кем Гайсага һәм: «Яланчы сән кем, жаду!» |
| *199 бәйт*<br>Чөнкем ул инжедмәге кыйллы исә,<br>Сурәтен дүндүрде ул Кадыйр са. | *2б кәгазь*<br>Чөнки эшләсә инжедүмәге эркәк-теши,<br>Сурәтендән тәбдил идәр ул Падишаһи. |
| *200 бәйт*<br>Аю хажилар малын алур иде,<br>Анлары маймүн зәлил кыйлур иде. | *2б кәгазь*<br>Аю улдур — хөжжажларнын малын алур,<br>Анлары мәгъбүн әйләб, мәхрүм кылур. |
| *278 бәйт*<br>Әйтде: «Ай-вай, анламадум эшем,<br>Кәсерсә золым илә ул кыз башым». | *3а кәгазь*<br>Егет әйдүр: «Анламадум эшеми,<br>Кәсдүрәсирдүр ул залим бәнем башыми». |
| *280 бәйт*<br>Кашы йагкут ул йөзүк алтун иде,<br>Кашында ул кызың ады йазулу иде. | *3а кәгазь*<br>Күрде кашында йазу — кызның адын,<br>Кашы йакут ул йөзүк үзе алтун. |
| *301 бәйт*<br>Тору кәлдем шул сәгать, тотдым аный,<br>Бәрк баглады ул кошнуң аягыный. | *3б кәгазь*<br>Дийәр: «Анладум, аулайуб тотдум аный,<br>Бакладум бәк әлени-аягыный». |
| *327 бәйт*<br>Солтан әйдүр: «Сәне вирдем егетә.<br>Бунуң кеби галим улмаз дөньяда!» | *4а кәгазь*<br>«Бән сәне вирәм ошбу егедә,<br>Бончалайын улмайа һич дөньяда!» |
| *337 бәйт*<br>Гакыйбәт, солтан үлде. Калды ул,<br>Солтан әйләмешде аны угул. | *4а кәгазь*<br>Гакыйбәт, ул егет улды солтан,<br>Аны угул өвүтде солтан тәмам. |
| *338 бәйт*<br>Ул бәкләр разый улды хөкеменә,<br>Солтанлыг вирделәр ул угылына. | *4а кәгазь*<br>Каму бәкләр мотыйг улдылар уна,<br>Диделәр: «Солтанлык мөбарәк улсын сәна!» |
| *339 бәйт*<br>Чыкды тәхтә, хөкем эрде элләрә,<br>Гадил ирде ул каму юксуллара. | *4а кәгазь*<br>Тәхтә чыгыб, хөкем идәр анлара,<br>Гадел улур байлара-юхсуллара. |
| *348 бәйт*<br>Сабыр илә ирде егет солтанлыгта,<br>Каму галим торды анда ана колга. | *4б кәгазь*<br>Сабыр белә ирүшделәр солтанлыгта,<br>Каму бәкләр ана дорды коллукга. |

Ике поэмада охшаш һәм аваздаш шигъри юллар булган очракта да рифмалашкан сүзләре бертөрле үк түгеллеге дә күзәтелә.

Мәгънәви аермаларга килгәндә, шушы — югарыда китерелгән — мисалларны

гына күздән кичерү дә шактый нәрсәне төшенергә ярдәм итә. Мәсәлән, 172 бәйттәге «госса улубән» (кайгырып) сүзен «Кыз хикәяте»нең авторы «пошукды» дигән жинелрәк гыйбарәгә алыштырган. Шул ук бәйтнең икенче юлындагы «усанмады» (әһәмият бирмәде) дигән сүз урынына «сонмады» рәвешендә, бүтәнчәрәк мәгънәле сүз кулланган. 192 бәйттә «дүнде» сүзе ике текстта да бар, ләкин ул икесендә төрле кешеләргә карата кулланылган. Ибраһим әсәрендә башка бәйтләрдән үзенең ижек саны күбрәк булуы белән дә аерылып торган 197 бәйт «Кыз хикәяте» авторы тарафыннан жыйнакландырылып, тиешле калыпка кертелгән. 200 бәйттә Ибраһим әсәрендә «хөжжажлар» сүзе «Кыз хикәяте»ндә татар укучысына аңлаешлы гади генә «хажилар» дип алыштырылган. «Хөжжажлар» дигәндәге «хөжжаж» — үзе үк гарәп телендә күплек санны белдерә, ә шуңа күплекне белдерә торган «–лар» кушымчасын өстәү текст өчен грамматик кытыршылык тудырган.

278 бәйттә «Кыз хикәяте» авторы элекке әсәрдәге юлларга «ай-вай» ымлыгын кертеп, эчтәлеккә тагын да җанлылык өстәгән. 301 бәйттә Ибраһим әсәрендәге күгәрченнең кулын (әлен) һәм аягын бәйләү турындагы юлларга «Кыз хикәяте» авторы, кошка карата «кул» сүзе куллануны урынсыз күрептер, «аягын» дигән сүзне генә калдырган. 327 бәйттә Ибраһим әсәрендәге «бончалайын» (мондый, монын кебек) сүзе «Кыз хикәяте»ндә «бунуң кеби галим» дигәнгә үзгәртелеп, егетнең галимлеге игътибар үзәгенә куелган. 339 бәйттә Ибраһим әсәрендәге яшь солтанның бәкләр белән идарә итү мәгънәсендәге юллары «Кыз хикәяте»ндә илләр белән идарә итүе, ягъни киңрәк хакимлеккә ия булуны тасвирлый. Шул ук бәйттә әүвәлге әсәрдә солтанның байларга-юксылларга гадел булуы турындагы сүзләрнең «Кыз хикәяте»ндә «юксыллар» дип кенә калдырылуы да очраклы түгелдер. 348 бәйттә Ибраһим әсәрендә солтанга бөтен бәкләрнең буйсынуы турында әйтелгән булса, «Кыз хикәяте»ндә солтанга барлык галимнәрнең буйсынуы белдерелгән. Ягъни «Кыз хикәяте» авторы максатчан рәвештә ил-дәүләт хакименең галимлеген — тирән белемгә ия зирәк зат булырга тиешлеген ассызыклавы күренеп тора.

Менә бу китерелгән мисаллар Ибраһим әсәренең сакланган 154 бәйтенә генә бәйле булуын искә төшерик. Ул поэманың әле хәзергә билгесез калган 266 бәйтендә дә «Кыз хикәяте» текстыннан аермалары шактый булганлыгын чамаларга мөмкин.

## Авторы кем икән?

Бу әсәрнең авторы мәсьәләсен төгәл ачыклау бик катлаулы, аны фаразлап кына әйтергә мөмкин. «Кыз хикәяте» үзенең шигъри үзенчәлекләре, фикер сөреше ягыннан Мөхәммәдьяр әсәрләренә шактый якын тора. Менә дәлил булырдай берничә мисалга гына тукталабыз.

«Кыз хикәяте»нең «Бер хикәят кәлде, әйдәм, дилимә» дигән иң беренче юлы ук Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдан» поэмасының 247 бәйтендәге «Бер хикәят килде күңлемгә нәзыйр» дигәненә бик охшаш. («Кыз хикәяте»ндәге «дилимә» сүзе «күңелемә» дигәнне белдерә). Мөхәммәдьярның шул ук әсәрендәге 293 бәйттә «Бер хикәят килде йадга дилпәзир» һәм 410 бәйттә «Бер хикайәт килде йадга уш нәзыйр» дигән шигъри юллары да боларга бик охшаш.

Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасындагы аерым шигъри юлларның «Кыз хикәяте»нә охшаш булган берничәсен түбәндә күрсәтеп китәбез.

| *«Кыз хикәяте»ндә (Татарстан Милли китапханәсе, «1764 т» шифрлы кулъязма)* | *Мөхәммәдьяр. Нуры содур: поэмалар, шигырь (Казан: Татар. китап нәшр., 1997) китабында* |
|---|---|
| *35 бәйт*<br>Солтанә хуш кәлде чөн сөйләдеге | *413 бәйт*<br>Шаһга хуш килде аның бу сүзләри |
| *89 бәйт*<br>Кичде йегет, сандал үзрә утырур | *587 бәйт*<br>Үзе алтун сандәлида ултуруб |
| *317 бәйт*<br>Әйдер остад: «Гаебләмәнез бәни?» | *489 бәйт*<br>Гаеб кылмаңыз бу сүздә сез мәни |

Болардан алдагы ике юлны шагыйрь Ибраһим әсәре белән чагыштырып карау мөмкин түгел, чөнки ул әсәр язылган кулъязма текстта аның башлангыч өлеше сакланмаган. Ә таблицадагы өченче мисалга килсәк («Кыз хикәяте»нең 317 бәйт), Ибраһим әсәрендә 316 һәм 318 нче бәйтләргә аваздаш юллар булган хәлдә, 317 нче бәйткә туры килердәе бөтенләй юк.

«Нуры содур» поэмасында шаһның хакимлекне вәзиренә тапшыруын бәйан иткән 414 нче бәйтендәге: «Чөн аның гакыйллыгыны белде ул, / Мәмләкәтне аңа тәслим кылды ул», — дигән юллары «Кыз хикәяте»ндәге солтанның үз тәхетен зирәклеге белән дан казанган егеткә тапшыруына бик охшаш. Сүз уңаеннан искәртик, Мөхәммәдьяр әсәрләрендә бер үк затка карата падишаһ—шаһ—солтан сүзләре параллель кулланылган булса, «Кыз хикәяте»ндә дә шундый ук күренеш белән очрашабыз.

Мәшһүр шагыйрь Мөхәммәдьяр «Төхфәи мәрдан» һәм «Нуры содур» поэмаларында «егет» һәм «ишет» сүзләрен гомумән һәм рифма өчен дә күп кулланган. Шунысы игътибарга лаек, ана кадәр төрки телләрдә иҗат иткән төрле авторларның шигъри әсәрләрендә бу сүзләрнең рифма пары булып килгән очраклар аз. «Егет» һәм «ишет» сүзләренең рифмалашуы Ибраһим әсәрендә ике урында очрый, ә «Кыз хикәяте»ндә аларны өч бәйттә күрәбез. Шулардан 331 нче бәйт Ибраһим әсәрендә бөтенләй юк.

«Уш» һәм «хуш» сүзләренең рифмадаш буларак һәм, гомумән, күп кулланылуы Мөхәммәдьярда һәм «Кыз хикәяте»ндә бер дәрәҗәдә диярлек.

«Кыз хикәяте»нең 53 нче бәйтендәге «Бер могаззам шәһәр иде, йаулак олу, / Хуш абадан, эче — адәм туб-тулу», — дигән юллар Мөхәммәдьярның мәшһүр булган «Бер гаҗиб бу шәһәрнең эче тулуг: / Шагыйрь улмыш барча кечек һәм олуг», — юлларына аваздаш.

«Кыз хикәяте»ндәге солтанлыкка ирешкән егетнең гыйлемлеге, сабырлыгы, гаделлеге кебек сыйфатлар Мөхәммәдьярның монарчы билгеле булган әсәрләрендә макталганын да искә төшерик. Ягъни «Кыз хикәяте»нең идеясе дә Мөхәммәдьяр иҗатына бик якын тора.

«Нуры содур» поэмасында идеал хөкемдарда Мөхәммәдьяр күрергә теләгән ун сыйфат (ягъни гаделлек, рәхим-шәфкать, юмартлык, сабырлык һ.б.) тасвирланган. Тик алар арасында «гыйлемлелек» турында аерым язган бүлекчә юк. Шунлыктан бәлки Мөхәммәдьяр бу сыйфатның әһәмиятен аңлатып аерым әсәр («Кыз хикәяте»н) иҗат иткәнлектән, «Нуры содур»да гыйлемнең дәрәҗәсе турында бүлек итеп зурлап язмагандыр дип тә фаразларга мөмкин.

Казан университетының фәнни китапханәсендә саклана торган бер үк кулъязмада «Кыз хикәяте» белән Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасының булуы, шулай ук Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязма җыентыкта Хаҗи Мәхмүднең «Мигъраҗ» әсәре белән бер үк җыентыкта «Кыз хикәяте» тексты булуы да игътибар уңында тотылырга тиешле. Ягъни бер чор-дәвер әсәрләре кулъязма җыентыкларда бергә язып йөртелгәнлеге авторлык мәсьәләсен ачыклаганда да исәпкә алынырга зарур фактлардан.

«Кыз хикәяте» әсәренең авторы кем булу турында монда язган дәлил һәм фикерләребезне фараз буларак билгеләдек. Бу мәсьәлә махсус рәвештә тагын да җентекләп өйрәнүне һәм киңрәк анализ ясауны таләп итә. Хикәятнең тулы тексты Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязма нөсхәсе нигезендә аерым китап итеп басмага әзерләнә. Ул «Милли китап» нәшриятында чыгып килә торган «Татар археографиясе» сериясенең унынчы китабы буларак дөнья күрәчәк. Анда «Кыз хикәяте» белән уртак сюжетка корылган төрле әсәрләргә күзәтү рәвешендәге күләмле мәкалә дә урын алачак.

**Раиф МӘРДАНОВ**

## Кыйссаның эчтәлеген тасвирлаган өлеше өчен сүзлекчә

ады — исеме
арайә — арага
асайын — асыйм
асарам — асармын
әйдәлүм — әйтәм
әйдүр улурсаң — әйтер булсаң
әл — кул
әндишә — борчылу
багча — бакча
бали — тирән мәгънәле
бәңа — мина
бәр гиз — шунда ук
бәрк — нык
бен — мен
билә — бергә
бодаг — ботак
бонунлә — моның белән
буйнун өзүң — муенын өз
вар — бар
варурса — барса
вирәйен — бирим
гадил ирде — гадел иде
гаду — дошман
гакыйбәт — соң, ахыр
галимә — галимгә
гаму — кардәш, туган
ганбәр — хушбуй, хуш ис
гариб — фәкыйрь
гыйнайәт әйләйә — ярдәм итә
дәгелдүр — түгел
дәкмә — һәр
дәхи — тагын
дел — тел
деләр — теләр
дилимә — күңелемә
дорыша — шөгыльләнсә
дөште — төште
дүнде — борылды
жаду — сихерче, күрәзәче
зәлил кыйлур — мыскыллар, түбәнсетер
зәһи — мактанчык, тәкәббер
илләрә — илләргә
инжедмәге — газаплавы
ирде — ирешә
ишедүң — ишет
ичәрү — эченә
йагкут — йакут
йазулу — язулы
йинсәйдүн — жинсә иден, әгәр жинсәң
йиренә — урынына
Кадыйр са — кодрәт иясе, ягъни Алла
кальга бөрженә — кирмән манарасына
каму — бөтен, һәммәсе
канкый — нинди
канчару — кая
карыйчык — карчык
кәлде — килде
кәленчәк — килгәч
кәндүзени — үзен
кәрү — кире
кәсерсә — киссә
кәстерәрәм — кистерермен
кәтүр — китер
кирү — кире
кисәрәм — кисәрмен
кичдән бәрү — кичтән бирле
күгүрчен — күгәрчен
күк алында — күк йөзендә, дөньяда
күрәйен — күрим
күреклү — күркәм, матур
лятыйф — йомшак, күркәм
мәймүн — маймыл
мәнсух улды — юкка чыгарылды
мисле — тиңе
мөфлис — мохтаж
нә — ни
нәйләр — нишли
пошукды — борчылды
рәнге — төсе
сачар — чәчәр
сәвенә — сөенә
сәңа — сиңа
сези-бези — сезне-безне
сийәрәт — әхлак
солтана — солтанга
солтанлыг — солтанлык
сонмады әлен — сузмады кулын
соңра — шуннан соң
сорайын — сорыйм
сорам — сорыйм
сорур ирсәң — сорасаң
сөйләшәлүм — сөйләшик
ташы — тышы
тәхтә — тәхеткә
тору — торып
ула — була
улмаз — булмас
уш — менә
ушак угылы — бала-чага
үгәрде — уң итте
үлдүрүрем — үтерермен
фәсыйх — матур
Хакъ — Аллаһы Тәгалә
шадиман — шатланып
шөйлә — шулай
чук — күп
чәверүб — чөереп
эүнүң — өйнең
юксуллара — фәкыйрьләргә
ябрак — яфрак
яланчы — ялганчы

## Фирдәвес Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

### Мокшы

Мокшы авылы Әтнә районында, район үзәге Әтнәдән 9 чакрым, жирле үзидарә советы үзәге Күнгәр авылыннан – 5, Казаннан 88 чакрым ераклыкта урнашкан.

Мокшы – борынгы авыл. Ул Казан ханлыгы чорында ук булган.

Авыл исеме тарихи белешмәләрдә шактый телгә алына.

Д.А.Корсаков хезмәтендә Мокшы авылында 12 йомышлы һәм ясак түли торган 17 татар яшәгәнлеге әйтелә. А.Артемьев мәгълүматларына караганда, Мокшыда 44 ир-ат һәм 44 хатын-кыз яшәгән. И.А.Износков җыентыгында да Мокшы авылы искә алына. Уржум сәүдә юлына урнашкан бу авылда 18 хуҗалык булып, анда ислам дине тотучы 62 ир-ат һәм 53 хатын-кыз яшәгән. Авыл Иске Тазлар җәмгыятенә кергән. "Тормыш-көнкүрешләре ярлы, кәсепләре юк", дип яза галим. К.П.Берстель мәгълүматлары буенча, Иске Тазлар белән Мокшы авылында барлыгы 1298 татар кешесе исәпләнгән.

Тарихи белешмәләрдә Мокшы елгасы да искә алына.

Авылда мәчет бинасы сакланып калган.

1908 елның ноябрендә Мокшы халкы җыелып гыйбадәтханә төзү хакында карар чыгара, мәхәллә оештыруга һәм мәчет төзергә рөхсәт бирүне үтенгән мөрәҗәгатькә авылның 104 кешесе кул куя. Анарчы Мокшыда мәчет булмаган, намазны Иске Тазлар авылы мәчетендә укыганнар.

1909 елның июнендә Санкт-Петербургтагы Чит дин эшләре департаментыннан (Департамент духовных дел иностранных исповеданий) мәчет төзүгә рөхсәт бирелү хакында хәбәр килә, Казан губерна идарәсе гыйбадәтханәнең проектын раслый.

1911 елның 28 октябрендә яна мәчетнең имамы булып Мөндеш авылы кешесе Хәбибрахман Дәүләтшин сайланган.

Авылдагы олы буынның сөйләвенә караганда, Мокшы – борынгы авыл. Аны Күшәрдән күчкән дип тә әйтәләр. Күшәр үзе дә Казан ханлыгы чорында ук исәпкә алынган.

Мокшы авылының төп халкы татарлар булуга карамастан, анда күрәсең, чирмешләр дә (марилар) яшәгән һәм хәтта кайберләре исламга да күчкән булса кирәк. Халык хәтерендә бу хатирәләр әлегә кадәр сакланган. Аерым топонимнарның тарихын, килеп чыгышын сорашканда олылар чирмешләрне еш телгә ала.

Авылның күренекле су-инешләреннән түбәндәгеләрне атарга мөмкин: Поварна елгасы, Кимәш елгасы, Әмәтән, Ташлы, Пулат, Кәчти елгалары һ.б.

### Морт

Морт авылы Алабуга районында, район үзәге Алабуга шәһәреннән 24 чакрым ераклыкта, Алабуга пристаненнән 27 чакрым ераклыкта урнашкан.

Морт авылы матур табигать эченә чумып яши. Акай тау башыннан ул бик матур булып күренә. Акай тау итәгендә чишмәләр: Ат чишмәсе, Балавыз чишмәсе, Озын Газиз чишмәсе, Изгеләр чишмәсе һ.б. челтерәп ага.

---

*Дәвамы. Башы 2006 елның бнчы санында.*

Олылар авыллары оешу турында мондый риваять сөйли. Авыл башта Мәмәт суы буена утырган. Бераздан кайбер гаиләләр калкулыкка күчеп нигез кора. Ике урам барлыкка килә. Беренче күчеп утыручы кешеләр Мөхсин һәм Бәкер исемле булган, шуңа нисбәтән урамнар да Бәкер урамы, Мөхсин урамы очы дип йөртелгән. XVIII йөздә Екатерина II (Әби патша) тракты салынган. Бу юлдан каторгага сөрелгәннәр Себергә этап булып барган дип сөйлиләр. Менә шулай Олы урам дип йөртелгән урам барлыкка килгән. Аннан соң Урта урам һәм Зират урамнары оеша. Урта урам авыл уртасында, ә Зират урамында мәрхүм әби-бабалар күмелгән иске зират урнашкан.

Киров өлкәсе архивыннан алынган мәгълүматларга караганда, 1781 елда Морт авылында 46 кеше яшәгән. 1836 елда дәүләт крестьяннары яшәгән Морт авылындагы 95 хуҗалыкта 263 ир-ат һәм 268 хатын-кыз көн күргән. Революциягә кадәр авылда 511 хуҗалык булып, алар 2 мәхәлләгә берләшкәннәр.

Авыл халкының төп чәчү орлыклары арпа, арыш, карабодай, тары һәм житен булган. Крестьяннар тормыш өчен кирәк-яракларның барысын да үз хуҗалыкларында житештергән.

Крестьяннарның йортлары тәбәнәк, 2 тәрәзәле булган. Салам түбә, өй эчендә сәке, озын эскәмия. Салкында мал-туарны өйгә кerткәннәр. Тәрәзәләрдә пыяла урынына карындык булган.

Мортта, югарыда әйтелгәнчә, 2 мәхәллә эшләгән, һәр мәхәлләнең үз мәчете, мәчет каршында мәдрәсә булган. Малайларны мулла укыткан, абыстайлар кызларга дәрес биргән.

Зират урамындагы кибетләрнең берсе Сафа, икенчесе Гобәйдулла байныкы булган. Байлар сап-сары житен мае саткан. Кайберләре үзләренең кибетләрен ачкан. Анда икмәк, прәннек, май, йон һ.б. әйберләр сатканнар.

1941-45 елгы Ватан сугышына авылдан 529 кеше китә. Шуларның 230ы исән-сау туган-үскән якларына кире әйләнеп кайткан.

Авыл тирә-юнендә географик берәмлекләр шактый.

Чишмәләрдән Озын Газиз чишмәсе, Гомәр, Галимулла, Хәлиматтәй, Нур чишмәләре һ.б.ны атарга мөмкин. Балавыз чишмәсенең суы бик тәмле. Аның турында шушындый шигырь юллары да бар:

*Балавыз чишмәләренең*
*тәме телемдә.*
*Кайнар тирем ага минем*
*Изге җиремә.*
*Кил син, иркәм, килми калма*
*Морт якларына.*
*Җибәрмә кайнар сәламнәр,*
*гел хатлар гына...*

Моннан башка тагын Акай тавы, Киленбикә чокыры, Мусакай чокыры һ.б. атамалар алган берәмлекләр очрый.

## Мөрәле

Мөрәле авылы Арча районында, район үзәге Арча эшчеләр бистәсеннән 23 чакрымда, жирле үзидарә үзәге Сеже авылыннан – 1, Мөндеш тимер юл станциясеннән – 7, Казан шәһәреннән 88 чакрым ераклыкта урнашкан.

Авыл шактый борынгы заманнарда оешкан. Арча юлы өстендәге Кече Му авылы белән күршедә урнашкан Мөрәле Казан ханлыгы чорыннан ук билгеле. Казан өязе теркәү кенәгәләрендә (1602-03 еллар) Мөрәле авылы күп урында искә алына. Анда йомышлы һәм ясаклы татарлар яшәгән.

Казан ханлыгы чорларында Казан шәһәрендә Мөрәле капкасы һәм Мөрәле мәчете булган. Бу атамалар белән авыл исеме арасында якын бәйләнеш бар дип әйтсәк, һич ялгыш булмас.

Кесмәс суы янына утырган Мөрәле авылы А.Артемьев китабында (1866) искә алына. Андагы 68 хуҗалыкта 224 ир-ат һәм 232 хатын-кыз көн иткән, авылда бер мәчет эшләгән. 1898 елгы хезмәттә күрсәтелгәнчә, Мөрәле авылында татарлар яшәгән. К.П.Берстель хезмәтендә (1908 ел) Мөрәле авылында барлыгы 630 татар кешесе яшәгәнлеге теркәлгән.

Мөрәле авылы ямьле Кесмәс якасына сырышып утырган. Аксакаллар сөйләвенә караганда, Кесмәс суы яры һәм авыл тирәсе элек кара урман белән капланган булган. Иген чәчү өчен җирне урманнан чистартып ачканнар. Авыл тирәсендәге топонимнар моны бик ачык күрсәтә.

Алан Сырнасы суын Кесмәскә коя. Шулай ук Көек Сырнасы да суларын Кесмәскә юллый. Елга янындагы Бүре текмәсе дигән җирдә бүреләр оялап яткан. Мөрәледә хәзерге көндә 90лап хуҗалык исәпләнә. Аларда 151 ир-ат һәм 161 хатын-кыз гомер кичерә.

***

Арча районындагы Мөрәле авылын хәзерге Тау ягы төбәгенең Кайбыч районы Мөрәле авылыннан килгән Мөрәс бабай нигезләгән дип тә сөйлиләр. Шуңа күрә биредә Тау ягындагы Мөрәле авылы турында да беркадәр мәгълүмат бирүне кирәк санадык.

Кайбыч районындагы Мөрәле авылы район үзәгеннән 17 чакрымда, җирле үзидарә үзәге Федоров авылыннан – 5, Колангы тимер юл станциясеннән 7 чакрым ераклыкта утырган.

Е.И.Чернышев мәгълүматлары буенча, Мөрәле авылы Казан ханлыгы чорында ук булган. 1565-67 елларны эченә алган Зөя өязе теркәү кенәгәсендә Мөрәле авылы да теркәлгән. Д.А.Корсаков җыентыгында Мөрәле авылында 82 йомышлы, 4 керәшен татары яшәгәнлеге күрсәтелә. Мөрәле суы янына утырган Мөрәле авылы турында А.Артемьев түбәндәге мәгълүматны бирә. Авылдагы 114 хуҗалыкта 336 ир-ат һәм 323 хатын-кыз яшәгән, анда гыйбадәт кыла торган бер йорт булган. К.П.Берстель (1908) җыентыгында әйтелгәнчә, Мөрәледә барлыгы 1254 татар кешесе яшәгән.

Мөрәле – борынгы авыл. Авыл урыны һәм аның тирә-юне элек калын урман булган, шуңа күрә халык басу-кырларны урманнан чистартып ясаган. Урманнан чистартылган ышна җире монда икенче төрле Урманга башлаш дип атала.

Мөрәле авылы элек хәзерге урыныннан бераз читтәрәк урнашкан Иске зират янындагы Иске йорт дип аталган җирдә булган. Ни сәбәптәндер халык авылны хәзерге урынына күчергән. Авыл артык зур түгел.

Мөрәле авылы Бәрле суы бассейнына утырган. Авыл яныннан гына Инеш агып уза һәм Бәрлегә кушыла. Аракы елгасы, Гөлминкә чокыры, Ермак, Гөлҗи әби чокыры исеме алган сулар Инешкә коялар (Тау ягында чокыр дип елга-инешләрне әйтәләр). Инеш исә Мунчала күленнән башлана. Колангы чокыры суын Бәрлегә илтә. Авыл янында Авыл күле, Казыган күл, Тирән, Таллы, Якты күлләр бар. Каип, Боламык кизләүләре әле дә исән. Ләкин Мөрәле авылында вак инешләргә, чишмә-кизләүләргә игътибар җитеп бетми. Тирә-юненә агачлар утыртып, чистартып һәм тәрбияләп торсаң, Инеш суы да һәм ул кушыла торган Бәрле суы да, бәлки, бераз гына күбәер иде.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

## О

**ОРЕШИНА** Нонна Николаевна (30.6.1933, Мәскәү), язучы, ТРның атказ. Мәдәният хезмәткәре (2005). 1939 дан Казанда. Казан хим.-техн. ин-тын тәмамлый (1956). 1957-69 елларда ш.у. укыта, 1969-71 елларда Казан авиаотряды авиахимэшләр эскадрильясы инженеры, 1973-88 елларда «Правда» г-тасы хәрби бүлегенең махсус хәбәрчесе. О. очкыч аппаратларның 36 төрендә 800 дән артык очыш ясый, парашют б-н сикерә. Аның иҗаты хәрби, гражданлык һәм спорт авиациясе кешеләренә багышланган. «Сиңа унжиде» («Тебе семнадцать», 1967), «Беренче адым» («Первый шаг», 1971), «Күк белән янәшә...» («А небо рядом...», 1982), «Җирдән атлау» («Шаг по земле», 1983), «Чиксез күк» («Такое огромное небо», М., 1984), «Кошлар кебек!...» («Хочу как птица», 1993) исемле хикәяләр һәм повестьлар, «Биек күкнең бер йотым һавасы» («Высокого неба глоток», М., 1988) исемле очерклар җыентыклары, «Билгеле вакыт узгач шартлый торган мина» («Мина замедленного действия», 2003) исемле кыю сюжетлы психологик роман һ.б. авторы. ТАССРның ЮС Президиумы Мактау грамотасы, Г.Державин исем. әдәби премия б-н (2010), медальләр б-н бүләкләнә.

Әдәб.: Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т.2.

## Ө

**ӨММӘТИ-АЛМАТАВИ** Лотфулла ибне Галиулла (Сабир) Казан өязе Рәс авылы (19 йөзнең 2 нче яртысы), шагыйрь, хаттат. «Сабир» тәхәллүсе б-н дә билгеле. «Кыйссаи Таһир» (1877) поэмасы ахырындагы мәгълүматларга караганда, балачагы Петропавловск шәһәрендә уза, шунда белем ала. Мануфактура б-н сату итә. Шәрекъта киң таралган ике гашыйкның фаҗигале мәхәббәте турындагы сюжетка нигезләнгән «Кыйссаи Таһир» поэма-легенда авторы. Литография ысулы б-н китап бастыру остасы. Шушы ысул б-н татар телендә беренче тапкыр Европа һәм Азия карталарын (1861), ш.у. «Диван-е Ризаи» (1860) исемле шигъри җыентыгын бастыра.

Әдәб.: История татарской литературы нового времени (XIX – начало XX вв.). К., 2003.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ӨММИ КАМАЛ** (чын исеме Исмәгыйль) (14 йөз ахыры – 1475, Кече Азия), төрки-татар шагыйре. Чыгышы б-н Караман шәһәреннән. Гомеренең төп өлешен Крымда, Урта Иделдә яши. Беренче «Өмми Камал китабы» (1884, 4 басмада дөнья күргән) исемле җыентыгына кергән лирик шигырьләр авторы. Татарлар арасында кульязма рәвешендә дә киң таралган була. Ө.К. иҗаты суфичылык мотивлары б-н сугарылган, табигать, кешеләр тормышының һәр күренешен, чагылышын Аллаһ кодрәте б-н аңлата. Шагыйрь фикеренчә, кеше тормышы – вакытлы күренеш, мәңгелеккә күчү юлында бер баскыч кына. Моңа ирешү өчен, суфи карашынча, үзеңне онытып, Алланы сөю утында янарга тиешсең, шунда гына аның б-н кавышырга юл ачыла. Ө.К. иҗаты Дәрдеменд, Г.Тукай иҗатларына йогынты ясый. Аның әсәрләре кульязмалары (чама б-н 13) С.-Петербург, Казан китапханәләрендә саклана.

Әдәб.: Абилов Ш.Ш. Умми Камал // История татарской литературы средневековья (VIII-XVIII вв.). К., 2007; Кадыйрова Э.Х. Өмми Камал әсәрләренең Казан нөсхәләре // Татар әдәбияты текстологиясе мәсьәләләре (Урта гасырлар – XX йөз башы). К., 2006.

*А.М.Ахунов.*

*Дәвамы. 2005 елның 4нче саныннан басылып килә.*

# П

**ПАНАЕВ** Владимир Иванович (17.11.1792, Казан губерниясе Тәтеш ш. – 2.12.1859, Харьков ш., С.-Петербургта жирләнгән), шагыйрь, мемуарлар язучы. Казан ун-тын тәмамлый (1811; 1949 дан шәрәфле әгъзасы). Казанда 1нче ирләр гимназиясендә, ун-та укыган чоры, аерым алганда, укытучысы Н.М.Ибраһимов турында истәлекләр калдырган. Ул: «Күп якларым б-н аңа бурычлымын», - дип яза П. Абыйлары Александр һәм Иван б-н «Аркада көтүчеләре» («Аркадские пастушки», 1804) исемле кульязма ж-л, С.Т.Аксаков б-н «Безнең эшләр журналы» («Журнал наших занятий», 1806-07) чыгара. Аларда Н.М.Карамзинга ияреп язган «идиллик проза», оригиналь һәм тәржемә шигырьләр урын алган. «Рус әдәбиятын сөючеләрнең Казан җәмгыяте» эшчәнлегендә актив катнаша (1847 дән шәрәфле әгъза). 1812 нең декабрендә җәмгыятьне ачу тантанасында «Александр I гә мәдхия» («Похвальное слово Александру I») укый. 1815 тән С.-Петербургта. Рус әдәбияты тарихына ирекле версификация, табигый хикәяләү, төзек шигъри тел б-н язылган рус идиллияләре авторы буларак кереп калды. Идиллиянең жанр буларак төп принципларын «Көтүче яисә авыл поэзиясе турында» («О пастушеской, или сельской поэзии») мәкаләсендә язып калдыра. «Владимир Панаев идиллияләре» («Идиллии Владимира Панаева», СПб., 1820) җыентыгы өчен Петербург ФА нең алтын медале б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Воспоминания // Вест. Европы. 1867. № 3, 4.

Әдәб.: Загоскин Н.П. История Императорского университета за первые сто лет его существования (1804-1904): В 4 т. К., 1902-06; Бушканец Л.Е. Писатель и чиновник // Казань. 1999. №7/8.

*М.М.Сидорова.*

**ПАРОДИЯ** (грек parodia-кабатлау, көлке тудыру өчен бозып күрсәтү), язучының нинди дә булса әсәренә ияреп, аның стиленнән, теленнән, геройларыннан, мәгънәсеннән, композициясеннән көлү ысулы. П.да оригинал гипербола шарж рәвешендә бирелә, әсәргә хас булган әйберләр абсурдка китереп җиткерелә, нәтиҗәдә сатирик-комик эффект тудырыла. П.гә әдәби мода, ялган сәнгати принциплар, стилистик үзенчәлекләр һ.б. дучар була. Шуның б-н бергә искергән шаблоннарга, нормаларга игътибар ителә. П. сатирик һәм юмористик булырга мөмкин. П. аерыча әдәби көрәш барган чорда кин тарала. Әдәби П.нең беренче үрнәкләре татар әдәбиятында 20 йөз башында барлыкка килә. Мәс., Г.Тукайның «Печән базары, Яхут яна Кисекбаш» поэмасы урта гасыр төрки-татар әдәбияты ядкәре - «Кисекбаш китабы»на П. рәвешендә язылган. 20 йөздә сатираның П. формасы үсеш ала. Төрле социаль күренешләрдән көлгән әсәрләр туа: Ф.Әмирханның «Шәфигулла агай» хикәясендә 1920нче елларда соц. идеяләргә артык мөкиббән киткән образ П. тудыруга сәбәп була; Т.Миннуллинның «Минһаҗ мажаралары» романында 20 йөз тарихи һәм сәяси эшлеклеләре комик, карикатура ысуллары ярдәмендә тасвирлана: Николай II, В.И.Ленин, И.В.Сталин, Н.С.Хрущёв, Л.И.Брежнев һ.б.; Хәсән Сарьянның «Нокталы өтер» повесте надан галим эзләнүләрен күрсәтүгә багышланган; Ф.Шәфигуллинның «Суда балык йөзәдер» һәм «Ботка» хикәяләрендә «фәнни» диссертацияләр һәм йомшак тәнкыйди мәкаләләр П. язарга этәргеч була.

Әдәб.: Литературный энциклопедический словарь. М., 1987; Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990; Макарова В.Ф. Татар сатирасының үсеш үзенчәлекләре. К., 2007.

*Ә.М.Шәрипов.*

**ПАРЧА** (фарсыча: кисәк, бүлем, өлеш, бөртек) кыска шигырь яки кечкенә күләмле чәчмә әсәр, авторның теге яки бу унай б-н туган хис-тойгыларын, фәлсәфи фикерләрен, күзәтүләрен эченә алган миниатюр язма. Татар әдәбиятында Г.Тукай, Дәрдемәнд, Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Ш.Галиев һ.б. әсәрләрендә очрый. Лирик П.лар кыйтгага якын.

Әд.: Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

**ПАСТЕРНАК** Борис Леонидович (10.2.1890, Мәскәү – 30.5.1960, Переделкино), шагыйрь. «Тормыш – минем апам» («Сестра моя-жизнь», 1922), «Икенче тууым» («Второе рождение», 1932), «Иртәнге поездларда» («На ранних поездах», 1943) исемле җыентыклар, «Көн аязгач» («Когда разгуляется», 1961) циклы, «Тугыз йөз бишенче ел» («Девятьсот пятый год», 1927), «Доктор Живаго» романы (Милан, 1957, СССРда 1988; Нобель бүләге (1958), дипломы 1990 да улына тапшырыла), повестьлар, автобиографик проза, тәржемәләр авторы. Татарстанга беренче килүе хәрби хезмәт б-н бәйле: 1916 ның сентябреннән 1917 нең мартына кадәр Алабуга ө., Тихие

Горы а. (1967 дән Минделеевск ш. керә) хәрби ведомство канцеляриясендә хәрби-хисап бүлегендә исәпләнә. Бу елларда П. инглиз теленнән сонетлар, А.Суинбергның «Мария Стюарт» драматик трилогиясен, «Киртәләр өстеннән» («Поверх барьеров», 1917) исемле җыентыгын басмага әзерли. 1941 нең октябреннән 1943 июненә кадәр биредә эвакуациядә була (күбесенчә Чистай ш.дә яши). Бу вакытта ул «Шәһәр» («Город»), «Кыш якынлаша» («Зима приближается»), «Киләчәк бар нәрсәгә карашларны үзгәртәчәк...» («Грядущее на всё изменит взгляд...»), «В.Д.Авдеевка» («В.К.Авдееву»), «Марина Цветаева истәлегенә» («Памяти Марины Цветаевой»), «Ашыгулы юллар» («Спешные строки») исемле шигырьләрен яза. Ш.у. вакытта У.Шекспирның «Ромео һәм Джульетта» («Ромео и Джульетта»), «Антоний һәм Клеопатра» («Антоний и Клеопатра») трагедияләре, Ю.Словацкийның шигырьләре тәрҗемәләре өстендә эшли.

Әс.: Собр. соч.: В 5 т. М., 1989-91.

Әд.: Чистопольские зимы Бориса Пастернака. Чистополь, 2005; Быков Д.Л. Борис Пастернак. М., 2006; Пастернак З. Воспоминания. М., 2006.

*А.Э.Скворцов.*

**ПАТИЙ** (Патиев) Кашшаф (Габделкашшаф) (19 йөз ахыры, Сембер губ. Зимничә а. – 20 йөз башы), шагыйрь. 1909 елда туган авылында мулла булып тора. Шигырьләре һәм публицистик мәкаләләре «Идел» г-тасында, «Шура» ж-лында басыла. 1910 да беренче шигъри җыентыгы чыгу унаеннан «Идел» г-тасы: «Гүзәл, милли вә тәэсирле шигырьләр. Кәшшаф Патии җәнабләренә ошбу мәҗмугадагы шигырьләре илә Г.Тукаевтан соң беренче шагыйребез дию лаектыр», - дип язып чыга. «Патии шигырьләре» (1910), «Әшгарь» (1915) исемле җыентыклар авторы. «Габделкашшаф Зимначави» псевдонимы б-н 1906 да басылган «Тугыз чәчәк» исемле китап авторы дип фаразлана.

Әд.: Татар шигърияте. XX гасыр башы. К., 2004.

**ПАУШКИН** Геннадий Александрович (28.2.1921, Казан – 15.10.2007, шунда ук), язучы, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1981). Казан ун-тын тәмамлый (1949). 1950-53 елларда «Комсомолец Татарии» г-та редакциясендә эшли, 1953-55 елларда «Комсомольская правда» г-тасының махсус хәбәрчесе булып тора. 1950 еллар ахырыннан «Әдәби Татарстан» («Литературный Татарстан») альманахының мөхәррире, 1955-65 елларда ТАССР Язучылар берлегенең рус секциясе консультанты булып эшли. Беренче шигырьләре армия һәм фронт г-таларында басыла башлый. «Һәрвакыт юлда» («Всегда в пути», 1954), «Туган яклар» («Родные просторы», 1958), «Кайту» («Возвращение», 2004) исемле җыентыкларга кергән шигырьләр – «фронт юллары җырлары», Ватанга, хатын-кызга, табигатькә лирик мәхәббәтне белдерү. Алар образларның реалистик символикасы б-н аерылып тора. «Еракгагы заставада» («На дальней заставе», 1952), «Кошлар китте» («Птицы улетели», 1962), «Минем позывноемны тыңла» («Слушай мои позывные», 1965), «Йолдызлар сүнми» («Звёзды не гаснут», 1967), «Кайтыгыз, ләкләкләр» («Вернитесь, аисты», 1970) исемле чәчмә әсәрләрендә рядовой гаскәринең хәрби батырлык темасына мөрәҗәгать итә. Автобиографик әсәрләр жанрында язылган «Кар шулай ук яуды» («И так же падал снег», 1981), «Тотылу» («Затмение», 1990) «цикллар, туган җир турындагы повесть һәм хикәяләр, Татарстан төзүче һәм нефтьчеләре турындагы очерклар авторы. Рус теленә Һ.Такташ, А.Расих, Карәхмәт һ.б. әсәрләрен тәрҗемә итә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗәле Ватан сугышы, Кызыл Байрак орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Казанский университет (1804-2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т.2.

*И.И.Андреева.*

**ПАШКУРОВ** Алексей Николаевич (25.6.1972, Казан), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (2006). Казан ун-тын тәмамлый (1994), 1997 дән ш.у. эшли. Фәнни хезмәтләре Г.Р.Державин, А.Н.Муравьёв, Е.А.Боратынский, Г.П.Каменев иҗатларына карый. «Рус сентиментализмы һәм романтизм алды поэзиясендә күтәренкелек категориясе: эволюция һәм типология» («Категория Возвышенного в поэзии русского сентиментализма и предромантизма: Эволюция и типология», 2004) хезмәт авторы.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# ШӘРӘФИНЕ СӨЙЛӘШТЕРҮ

*Берәр шәхес турында язганда кайбер журналистлар аның тәрҗемәи хәленә кереп, балачагын, уку чорын, үсмер елларын, өйләнгәч, яки кияүгә чыккач — тормыш рәвешен, гаилә серләрен, эшендәге уңышларын тасвирлыйлар. Шулай гадәткә кергән, шулай җайлы. Язманың күләме дә зур була, акчасын да күбрәк түлиләр бугай.*



*Мин инде бу уңай юл белән сырлап маташмам. Аннан соң укучыга җиткерәсе фикерләрем халкыбызның иң күренекле артистларыннан берсе, быелның 5 апрелендә 75 яшен тутыручы Равил Шәрәфи белән әңгәмәдә чагылуын да әйтсәм, бизәкләп язуның кирәге дә калмый. Кем белми Шәрәфине?*

*Уйлаган сүзен вакытында, туп-туры, тиешле адреска җиткерә торган кеше ул. Шикләнеп тормый, әйткәненә үкенми. Ике төрле сүз сөйләп, койрык болгап йөрми, шуңа күрә аны аңлавы кыен түгел. Тормыш итү рәвеше — эталон, иҗаты — үрнәк, тел-теш тигезерлек түгел. Күңеле — очар кош, максаты — хыялый, өмете — вактөяк, теләге — һәммәбезгә тазалык.*

Равил абый белән әңгәмәне аның өчен көтелмәгәнчә башладым:

**— Дөрес яшибезме без?**

— Безме?

**— Без.**

— Юк, без дөрес яшәмәдек. Туктале, син әллә ничек башладың сөйләшүне, юньләп аңлап та бетермәдем соравынны.

**— Салкын баш белән уйла әле, Равил абый, без дөрес яшәдекме?**

— Ил күләмендә әйтәсенме аны?

**— Әйе, гомумән, дөнья күләмендә — без дөрес яшәдекме? Бу ил бездән гафу үтенергә җыенмыймы?**

— Ә-ә! Менә ничек куясың син сорауны? Сүз дә юк, без дөрес яшәдек. Ләкин безнең илнең тормышы дөрес үк түгел.

**— Әмма без, хәл кадәри, кешелеккә хас булганның бөтенесен дә эшләдек бит. Әти-әнине сайлап алмыйлар дигәндәй...**

— Менә «бәхетлеме син?» дип сорыйлар бит инде. Бәхетле түгел мин. Бу илдә туу — үзе бәхетсезлек. Чөнки ил дөрес яшәмәде, тормышы дөрес булмады. Совет вакытында да дөрес түгел иде, хәзер дә дөрес түгел. Рәсәйнең инде аның электән шулай. Менә мин ни өчен Герценны яратам, аның язганнары, тормышны тасвирлавы хәзер дә яңгыраш таба. Хәзерге заманда да шул ук «чирләр» — урлаш-талаш, җинаятьчелек, ришвәтчелек... Җәмгыятебезнең бөтен житешсезлекләре — урысның менталитетында. Социализмнан капитализмга күчсәк тә — шул, коммунизм булса да шул булыр, шул ук нәрсәләр яшәр иде. Кыскасы, ил дөрес яшәмәде.

**— Ил — башка, ә менә без үзебез шул илдә дөрес яшәргә тырыштык...**

— Шулай, син дә, мин дә дөрес яшәргә тырыштык, ләкин без бернәрсә дә эшли алмыйбыз. Аны син-мин генә түгел, әйтик, Гамил Афзал да киртәгә, тәртәгә кертергә тырышты, күп кенә башка язучылар, фикер ияләре баш салдылар, күп булды алар, ләкин аңа карап кына...

**— Менә шуннан тагын бер сорау туа. Шушы ил «Рәхәт яшәтә алмадым», — дип бездән гафу үтенергә җыенмый бугай, әйе бит?**

— Нинди гафу үтенергә җыенсын, әле ул һаман да әрсезләнә, комсызлана, вәхшиләнә генә бара.

Менә ни өчен зурлап, моннан җиде-сигез ел элек, бөтен дөньяга Папаны күмүне күрсәттеләр? Күргәнсеңдер, Иоанн Павел IIне бөтен дөнья күмде, чөнки ул чиркәү кылган гөнаһлар өчен гафу үтенә белде.

**— Әйе, әйе, әйе...**

— Менә ни өчен ул изге булып калды! Бөтен дөнья өчен: католикмы, протестантмы, мөселманмы, мәсәлән, миңа мөселман була торып та — ул зур югалту булды. Мин аны иң изге дин әһелләреннән санадым.

**— Син бу мәсьәләне дөрес кузгаттың, Равил абый. Кайбер югары цивилизацияле ил башлыклары кешелек дөньясы алдында үзләренә хәтле кылынган вәхшилек өчен гафу үтенделәр бит, нигә безнекеләр шулай эшләми? Сабак та, савап та булыр иде.**

— Бик шәп булыр иде кана. Элеккеге өчен генә түгел, хәзергесе өчен дә гафу үтенергә тиеш алар! Әйтик, шушы ук Чечня вакыйгасы: Шамиле белән утыз ел интектеләр, безнең чорда — бер сугышып алдылар, икенче мәртәбә...

Икенче мәсьәлә, де-Голь вакытында Алжир Франциянең колониясе иде. Де-Голь шушы колонияне ireккә чыгарды. Аңа каршы Франциянең бик күп сәясәтчеләре, ил эшлеклеләре ризасызлык белдерделәр. Ләкин де-Голь үзенең эшен барыбер эшләде. Алжир китте. Алжир да яши, Аллага шөкер. Франциянең дә бер җире кителмәде һәм де-Голь бөек кеше булып тарихта калды. Ни өчен, мәсәлән, Ельцинның, йә инде менә хәзергесе — Путинның де-Голь буласы килми икән? Аларда «әз генә булса да бер яхшы булыйм әле» дигән, ичмасам, һич югы үз-үзен ярату сыйфатлары юк микәнни?!

**— Юк шул, югыйсә күп тә кирәк түгел бит, ә?!**

— Күп тә кирәк түгел.

**— Шуны да эшләмиләр.**

— Эшли алмыйлар.

**— Без бит әле бу илнең башка илләргә, халыкларга күрсәткән михнәтләрен сөйләмибез...**

— Дөресен әйткәндә, нефть өчен бара кырылыш.

**— Әйе.**

— Ул нефтьнең акчасы инде табылачак нефть өчен дә чыгып беткәндер. Властька киләләр, ләкин яхшы атым калсын тарихта, халык күңелендә дип эшләмиләр. Әгәр андый уй булса, алар менә хәзерге кебек җитәкчелек итәрләр идемени?

**— Башка чара юкмыни инде? Шулай яшәрбез микәнни?**

— Ярый, хәзер җинаятьчелек көчле, үтереш күп, әгәр президент үзенчә эшли башласа, аның үзен дә үтерәләр. Гади халык үзе шушыны аңлап утыра. Әгәр дә үләсең килмәсә, президент булма! Әгәр дә килеп яхшы эш эшлисең икән инде... Әйе, үтерәләр, нишлисең, үлеп изге булып кала кешеләр.

Алар барысы да үз рәхәтләре өчен генә киләләр һәм ил турында уйламыйлар да. Менә шәһәрне кара, мин гадәттә эшкә җәяү йөрим, без эт оясында һәм чүплектә яшибез. Ярый, җитәкчеләр шәһәр читенә чыгалар да китәләр, анда чип-чиста, җыештырып торалар. Аларның шушы шәһәр өчен горурланасылары килми микәнни?

**— Сүз жаеннан чыгып, Равил абый, тагын бер сорау: илдә тәртип урнаштырып буламы?**

— Була! Була тәртип урнаштырып. Ничек урнаштырып булмасын ди тәртипне? Власть булганда, синең армияң бар, полицияң... Әгәр дә тәртип урнаштырырга алынасың икән, тәртипне бик тиз урнаштырып була.

**— Этнең койрыгын кем кисә — шул хуҗа.**

— Әйе.

**— Ярый, монысы шулай, әйдәле, җиргәрәк төшик әле, үз арабызга. Равил абый, менә сине театрда, урамда күрсәләр, син бит инде бер кешене дә дошман күрмисең, кешеләр белән ягымлы аралашасың, «кит әле, туйдырдың» дип кумыйсың.**

— Кайвакытта эштә «Нигә сонга калдың?» дип шелтәлиләр. Аларга бит кешеләр белән сөйләшеп торырга туры килде дип акланып булмый. Еш кына: «Гафу итегез, ашыгам», дип әйтеп китәргә мәҗбүр булам. Өйдән сәгать ярым алдан чыгып китеп тә булмый кешеләр белән сөйләшәсе килә дип.

**— Күп артистлар бик дорфа сөйләшәләр, кешеләрне куып җибәрәләр, бөек булып кыланалар. Синдә бу тискәре сыйфатлар юк икәнен белеп кенә сөйләштерәм, сорау дип кабул итмә! Синең эчке дөньяң шулай корылган, аны инде үзгәртеп булмый. Равил Шәрәфиев шуннан килеп чыккан. Елмаюыңнан сизәм.**

— Әйе шул, мактауларын җенем сөйми.

**— Менә тагын бер нәрсә: театр начар эшлиме, әйбәтме? Анда синең тоткан урының безгә мәгълүм. Ә үзең, шул урыннан торып, үзеңне ничек хис итәсең?**

— Бу авыр сорау, чөнки бу турыда минем уйлаганым юк. Кыргаякка, беренче аягын атлаганда кырыгынчысы нишли, дигән сорау биргән шикелле, монда да шулайрак килеп чыкты. Әйбәт кенә барган кыргаяк буталып бетә, атлый алмый башлый, мин дә шул сорауга җавап бирә башласам, үзем дә кыргаяк хәлендә калмам микән дип куркам.

**— Равил абый, беренчедән, кыргаякның аягы кырык түгел — күпкә азрак, шул күп булган өчен генә «кыргаяк» дип исем кушканнардыр. Икенчедән, без бит әле кыргаяк түгел — кешеләр. Әйдә, яһүд булыйк бу мәсьәләдә. Чыннан да, театр эшли, сукән чакларыбыз да була, мактаган мизгелләр дә. Син үзеңне ничек хис итәсең шушы эшләп торган театр эчендә?**

— Эшли, әлбәттә. Бөтенесе дә минемчә булмый, еш кына фәлән итәр идем, тегеләй итәр идем дисең...

**— Ләкин бит әле аның кайвакытта синеңчә булуы да эталон түгел.**

— Әйе, шулай... Аннан соң үземне шул нәрсәдә тотам, бик яратам кешеләрнең төрле булуларын, төрле фикердә торуларын һәм шул чакта үзем ирек яраткан көе кешеләрне үз фикеремә кертергә тырышам, кара, син хилафлык эшлисең бит, дип битәрлим.

**— Хисләреңне контрольдә тота алу бик яхшы гамәл бит инде ул.**

— Анысын әле булдырам, Аллага шөкер.

**— Равил абый, син — үзеңнеке түгел, син хәзер халыкныкы, сизәсеңме шуны?**

— Беләсеңме, Алмаз, мин эшемне үзем өчен эшләмим. Үзем турында гомумән уйламыйм. Хакыйкать өчен, хаклык өчен, халык өчен сарыф итәм мин үз көчемне. Ул үзеннән-үзе шулай килеп чыга. Һәр нәрсәнең морале, тормышның мәгънәсе бар әле. Шуларны тамашачыга җиткерү осталыгы белән мәш киләбез без — артистлар. Һәрхәлдә, мин үзем шулай. Менә шул сарыф ителгән энергиянең миңа зарплатасы булса, үземдә эчке канәгатьлек тойгысы кабынып калса — шул җиткәндер. Халык шуны сизә — шуңа яратадыр, үзенеке итәдер. Мәҗбүри яраттырып булмый. Мин тумыштан ничек, хәзер

дә шулай — бөек артист булып кыланып йөрү башыма да килми. Нәрсә сорап торасың, үзең беләсең бит инде... Әйдә, икенче темага күчик әле.

**— Мин дә халык яклы. Ләкин мин сиңа үзеңчә дә яшәргә мөмкинчелек «калдырам», чөнки синең яшәү рәвешең мине канатландыра, гаиләңдәге җылы мөнәсәбәт, хатыныңны, улың-кызыңны үлеп яратуың сокландыра. Сезгә телефон аша шалтыратып алу да — бер дәва.**

— Рәхмәт, Алмаз, рәхмәт, үзең дә шундый син.

**— Әйдә, бер-беребезне макташып утырыйк әле. Безне тагын кем мактар. Без бит мәзәк «ашап» яшибез, килешәсеңме? Әллә синең ризык башкамы?**

— Дөрес әйтәсең. Мине шушы яшькә җиткергән дип мин мәзәкне әйтер идем. Чыннан да, файдасы күп бит ул кемнәрдер «чүп» дип санаган жанрның. Стрессларны киметә, күңелне дәвалый, нервларны тынычландыра. Ул аралашу ысулы да, җор теллелек тә, үткен фикерлек тә, кыюлык та... Мин аның бер генә зыянын да күрмим. Кемнәрдер өчен әле ул финанс стабильлеге дә. Ерак китмичә, Шамкайны гына алыйк. Мәзәк сөйләп биш фатир сатып алды бит.

**— Ул фатирларның икесен синең турыдагы анекдотларны сөйләп алды бугай.**

— Алсын. Мин аңа ул анекдотларны үзем дә өстәп торам.

**— Тормышыңа девиз булырлык берәр мәзәгең бармы?**

— Алмаз, ул мәзәкләр барысы да тормыштан алынган бит. Димәк, алар барысы да — девизлы. Мин аерып тормыйм. Кирәксә, менә берсе: «тормышың ничек?» дип сорасаң — «карбыз кебек!» — дим.

**— Ничек инде ул?**

— Корсак үсә, сабак кибә.

Менә шуның белән тормыш фәлсәфәсен аңлатып була.

**— «Мин инде бу дөньяга бер туып киткәнмен», дигән идең. Син анда нишләп йөрдең?**

— Мин бу дөньяга бер генә түгел, ике килдем: берсен Котыпта үткәрдем, икенчесен Санкт-Петербургта.

**— Нишләп Котыпта да Санкт-Петербургта?**

— Котыптагысын ачык итеп тасвирлый алмыйм, ә менә Санкт-Петербургтагысын әйтергә була. Мин бит декабристлар идеясе белән янып яшәгән кеше. Менә алар югары интеллектлы булганнар да инде! Үзләре дворяннар, укымышлылар, прогрессив фикерлеләр. Үзләрен корбан итү бәрабәренә җәмгыятьне үзгәртергә батырчылык итәләр бит. Мин дә шулар арасында булдым. Хәзерге вакытта, югарыда әйтеп үтелгәнчә, андыйлар юк — Пестельләр юк, Рылеевлар юк.

**— Бөеклек − гадилектә диләр. Син бик гади кеше, Равил абый.**

— Нәрсәгә бора дип торам сүзен, карале...

**Алмаз ХӘМЗИН**

# ФИДАКАРЬ ЗАТЛАР ОНЫТЫЛМЫЙ

ИБРАҺИМ НУРУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Татар халкына бөек Тукайны бүләк иткән изге апрель аенда XX йөз башы татар әдәбиятын һәм гыйльми-нәзари фикерен системалы һәм нәтиҗәле өйрәнгән галимнәрнең берсе — Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе, Татарстан Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге әдәби бүләге лауреаты, филология фәннәре докторы, профессор И.Нуруллинның якты дөньяга килүенә 90 ел тула.

***

Әдәбият галиме, тәнкыйтьче һәм әдип Ибраһим Зиннәт улы Нуруллин 1923 елның 18 апрелендә Ульяновск өлкәсе (элеккеге Сембер) Мәләкәс районы Парау авылында мөгаллим гаиләсендә туа. Яна Мылыклы районы Әбдери авылында жидееллык мәктәпне һәм Мәләкәс шәһәрендә сигезенче сыйныфны тәмамлап, 1938 елда Казанга килә һәм мех техникумына укырга керә. 1941 елның октябрь аенда унсигез яшьлек егет үз теләге белән армиягә китеп, 1942 елның жәендә Сталинград фронтына сугышка жибәрелә. Әстерхан өчен барган сугышларның берсендә каты яралана. Дәваланганнан соң, хәрби хезмәттән азат ителә һәм туган авылына кайта. Бер елдан артык авыл мәктәбендә укытучы булып эшләгәч, И.Нуруллин 1945 елның жәендә Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында яна гына ачылган татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Тәүге хикәяләрен «Совет әдәбияты» журналы битләрендә бастырып өлгергән егет студент елларында үзен әдәби тәнкыйтькә һәм гыйльми эшчәнлеккә сәләтле итеп күрсәтә. Университетны тәмамлагач, аны татар әдәбияты кафедрасы каршындагы аспирантурага калдыралар. 1954 елда профессор М.Гайнуллин житәкчелегендә Г.Тукайның идея-эстетик һәм әдәби карашлары үсешен өйрәнүгә багышланган кандидатлык диссертациясен, ә инде 1967 елда «Татар әдәбиятында тәнкыйди реализмның формалашуы һәм үсеше» дигән темага докторлык диссертациясен яклый.



И.Нуруллин Казан университетында 40 елга якын гомерен педагогик эшчәнлеккә багышлый. Татар әдәбияты кафедрасында ассистент вазифасында эшли башлап, профессор дәрәҗәсенә каләр күтәрелә. Татар әдәбияты тарихының төрле чорларыннан, халык авыз иҗаты, әдәбият теориясе һ.б. фәннәрдән лекцияләр укый һәм гамәли дәресләр үткәрә, әдәбият гыйлеменең төрле өлкәләреннән махсус курслар алып бара. Студентларның фәнни эшләренә җитәкчелек итә. Университетта эшләү елларында ул татар әдәбияты фәне өчен гыйльми кадрлар әзерләүгә дә лаеклы өлешен кертә. Аннан тыш милли мәгариф һәм тәрбия-белем бирү учреждениеләре белән тыгыз бәйләнештә булып, татар әдәбиятыннан дәреслекләр язуда, хрестоматияләр төзүдә даими катнаша. Татар халкының рухи-иҗтимагый яңарышында, әдәби-мәдәни тормышын җанландыруда һәм үстерүдә дә И.Нуруллинның лаеклы үз урыны бар. Ул — 1957 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

***

И.Нуруллин әдәбиятчы галим буларак татар әдәбиятының иң бай, кызыклы һәм катлаулы чоры — XX йөз башы татар әдәбияты буенча аеруча яратып һәм нәтиҗәле эшли. Бу өлкәдәге тикшеренүләрен берничә тармак буенча алып бара: әдипләрнең тормыш сукмакларын һәм иҗат биографиясен өйрәнү, чор әдәбиятының үсеш баскычларын һәм закончалыкларын, сыйфади үзгәрешләрен ачыклау, әдәби юнәлешләр, иҗат методлары хәрәкәтен ачу һ.б. Галимнең бу чор турындагы тикшеренү-күзәтүләре иң элек татар әдәбиятының классик шагыйре Г.Тукай белән бәйләнгән. Г.Тукай иҗатының төрле проблемаларын өйрәнүгә багышланган беренче тәнкыйть мәкаләләре матбугат битләрендә 1950 елларда күренә башлый. Беренче адымнарыннан ук яшь тәнкыйтьченең әдәби-тарихи процессны тирән сиземләве, Г.Тукай шәхесе һәм иҗатына мәхәббәте чагыла. И.Нуруллин «Тукай эстетикасы» (1956) дигән хезмәтендә үз игътибарын шагыйрьнең иҗтимагый-сәяси карашларын, аларның үсеш-үзгәреш баскычларын ачыклауга юнәлтә һәм аның формалашуын Россиядәге иҗтимагый-сәяси вәзгыять, дөньякүләм тарихи вакыйгалар һәм марксизм өйрәтүләре белән тыгыз бәйләнештә карый. Әдипнең эстетик карашларын формалаштыруда әдәби факторларның һәм сәнгать кануннарының ролен күрсәтә. Аерым алганда, галим Г.Тукай шигърияте рус-татар әдәби-мәдәни багланышлар яссылыгында күзаллый, шагыйрь иҗатының асыл хасиятләреннән булган халыкчанлыкны В.Белинский, Н.Чернышевский, М.Горькийларның әдәбиятның халыкчанлыгы турындагы эстетик карашларына, һәрбер халыкның олы байлыгы булган «иң кадерле вә иң бәһале бер мирас» — халык авыз иҗаты белән тыгыз бәйләнешкә таянып аңлата. Ул шушы хезмәттә XX гасыр башында әдәбият белеменең башка тармакларыннан аерылып, фән буларак мөстәкыйль үсеш юлына чыккан әдәби тәнкыйтьне формалаштыруда Г.Тукайның ролен югары бәяли.

И.Нуруллинның 1960 еллар гыйльми эшчәнлегендә Г.Тукай темасы тирәсендә эзләнүләре системалы төс алып, үз офыкларын киңәйтә. Галим 1950 елларның икенче яртысында шагыйрьнең тормыш сукмакларын һәм шигъри иҗатын өйрәнергә керешә. Марксистик-ленинчыл эстетика яктылыгында шәрехләнгән мәдәни-тарихи мәктәп кагыйдәләренә таянып, Г.Тукайның Җаек чоры поэзиясенең идея-эстетик үзенчәлекләрен яктырткан «Җаек чоры (Беренче рус революциясе чоры, 1964)» хезмәте дөнья күрә. Галим Г.Тукай яшәгән чорның иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-мәдәни фонын концептуаль тикшерми торып, шагыйрь иҗатының бөеклеген, шагыйрь феноменының серен аңлау һәм бәяләү мөмкин түгеллегенә төшенә. И.Нуруллинның «XX йөз башы татар әдәбияты» (1964, 1982) хезмәтендә, Г.Тукай шигъри дөньясына махсус бүлек багышланып, шагыйрь иҗатын гыйльми күзаллау бөтенлекле төс ала һәм ул чор әдәби-мәдәни хәрәкәте белән тыгыз бәйләнештә тикшерелә. Галим, тарихилык һәм эстетик принципларга нигезләнеп, Г.Тукай шигъриятенең эволюциясен, үсеш баскычларының хронологик чикләрен һәм төп хасиятләрен билгели. XX гасыр башындагы тарихи вакыйгалар, иҗтимагый-сәяси хәл, шәхси тормышындагы үзгәрешләр һәм шагыйрь поэзиясендә халыкчанлык белән реализм җәһәтеннән сыйфади яңарышлар күз унында тотыла.

«Путь к зрелости» (1971) хезмәтендә галим татар әдәбиятында реалистик юнәлеш агымнарының көчәешен, алардагы төп сыйфатларның үзгәрешен башка язучылар белән бергә Г.Тукай иҗатын үзәккә куеп шәрехли һәм ул милли әдәбиятта яңа реалистик агымның нигез ташларын салучы буларак бәяләнә. Яңа заман татар поэзиясенә нигез салучы, татар әдәбиятының классик шагыйре Г.Тукай иҗатын өйрәнүдән И.Нуруллин XX йөз башы милли сүз сәнгатенең иҗтимагый тарихи һәм бай әдәби-мәдәни дөньясын гыйльми күзаллауга күчә. Галим әүвәл күпсанлы мәкаләләрендә XX йөз башы әдәби-эстетик фикере үсешен конкретлаштыра, аның төп тенденцияләрен һәм юнәлешләрен ачу буенча күзәтүләр ясый. Фәнни концепциясенең нигезен тарихи материалда сыный. Ф.Әмирхан, Г.Камал, Г.Коләхмәтов, М.Фәйзи иҗатларына багышланган мәкаләләрендә галим татар әдипләренең иҗат индивидуальлеген тикшерә һәм аларның төп сыйфатлары хакында уйлана. Алга таба XX гасыр башы әдәби хәрәкәтенең идея-эстетик проблемаларын концептуаль тикшерүгә алына. 1960 елларда аның тарафыннан тәнкыйди реализмның барлыкка килүе һәм үсеше яктылыгында XX гасыр башы татар әдәбияты тарихын язуның беренче адымнары ясала.

Янарыш чоры татар әдәбиятын, андагы әдәби күренешләрне даими, эзлекле рәвештә өйрәнү һәм галимнең фәнни фикерләү стиле реализм чылбырындагы агымнарның барлыкка килү һәм үсешенә И.Нуруллинның гыйльми-нәзари карашларын тирәнәйтә. Ул үзенең докторлык диссертациясен татар әдәбиятында тәнкыйди реализмның барлыкка килү һәм үсеш юлын өйрәнүгә багышлый. Х.Миннегулов билгеләп үткәнчә, «Татарстанда гына түгел, бөтен СССР да, бигрәк тә төрки дөньяда зур фәнни казаныш буларак» бәяләнгән тикшеренү татар әдәбиятында реалистик агымнарның (методларның) барлыкка килүен, үсеш закончалыкларын, эчке һәм тышкы сыйфатларын, татар әдәбиятындагы гомуми һәм хосусый үзенчәлекләрен билгели. Моңа ирешү өчен И.Нуруллин тәнкыйди реализм үткән юлны, Рус-Аурупа һәм төрки-татар әдәби багланышлары яссылыгында тикшереп, XX гасыр башында тизләтелгән үсеш юлына чыккан татар әдәбиятында бу методның турыдан-туры мәгърифәтчелек реализмыннан үсеп чыгуын билгели. Аның барлыкка килү факторларын, әдәби һәм иҗтимагый-социаль сәбәпләрен барлый. Тәнкыйди реализм белән янәшә яңа тип Гареб романтизмының формалашуы, казакъ, үзбәк, төрекмән һ.б. тугандаш халыклар әдәбиятында тәнкыйди реализмның әдәби мәйданга килүенә, рухи-иҗтимагый тормышының янарышына татар әдәбиятының, аеруча Г.Тукай шигъриятенең уңай йогынтысы хакында нәтиҗәләр ясала.

***

И.Нуруллин — гыйльми нәзари эшчәнлек белән янәшә әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә актив һәм нәтиҗәле эшләп килгән галимнәрнең берсе. Университетта укыган елларында ук ул әдәби-мәдәни хәрәкәттә актив катнаша. Язучылар берлегенең утырышларында, семинарларда, төрле секцияләрдә татар әдәбиятының күренекле сүз осталары Н.Исәнбәт, Ф.Хөсни, К.Нәҗми, Ә.Еники, А.Расих, Г.Гобәй, Л.Җәләй һ.б. белән аралашып, язучыларның әдәби әсәрләрен тикшерүдә чыгышлар ясап, әдәби осталык мәктәбе уза. Көндәлек матбугат һәм әдәбият белән танышып бару, «Казан утлары», «Вопросы литературы», «Дружба народов», «Литературная газета» газета-журналларын даими уку яшь тәнкыйтьченең каләме чарлануга булыша. Заман сулышын тоеп яшәгән И.Нуруллин, үз сүзләре белән әйткәндә «яңа гына «табадан төшкән» әсәрләргә» рецензияләр яза. Язучылар берлегенең ел йомгакларында ясаган докладларында, әдәбият тарихына кагылышлы аналитик, күзәтү характерындагы язмаларында, көн кадагына сугып язылган теоретик эчтәлекле, проблемалы мәкаләләрендә үз чоры әдәби процессына бәя бирә. Аларда тәнкыйтьче әдип каләменең сәнгатьчә эзләнүләрен һәм табышларын, иҗат кредосын, тормышка һәм кешеләргә мөнәсәбәт-фәлсәфәсен ачарга омтыла, шул ук вакытта әдәби әсәргә тугры сүзен, тәнкыйди карашын белдерүдән курыкмый.

Галимнең бу тармак эшчәнлегендә, әдәби тәнкыйтьнең теоретик мәсьәләләрен яктырткан хезмәтләре дә бар. Аның «Киләчәккә карап» (1981) мәкаләсендә әдәби тәнкыйтьнең үзенчәлеге, максат-бурычлары, өйрәнү һәм бәяләү предметы әдәбият тарихыныкыннан аерып куела. Автор 1970 елларның икенче яртысында әдәби тәнкыйтьнең артта калуына китергән объектив һәм субъектив сәбәпләр һәм тәнкыйтьне активлаштыру, җанландыру юллары, чаралары турында уйлана: мәсәлән, әдәби әсәрне тормышның киң фонында тикшерү, социологик һәм эстетик анализның органик берлеге, тәнкыйтьнең хосусый формаларында белдерелгән фикернең тирәнлеге һәм яңалыгы, тәнкыйтьченең киләчәккә йөз тотып эш итүе һ.б. Аерым драма әсәрләрен, шагыйрьләрнең китапларын бәяләгән тәнкыйди язмалар авторы булса да, И.Нуруллин матур әдәбиятның эпик төрендә тирән күзәтүләр ясауга, әдәби әсәрләрне татар прозасы тарихи фонында шәрехләүгә өстенлек бирә.

Мәгълүм булганча, 1960 елларда социалистик реализм методының нәзари билгеләрен, норматив кануннарын тарсынган матур әдәбият зур эзләнүләр юлына чыга. Шуның нәтиҗәсе буларак үзәк рус һәм татар газета-журналлары битләрендә әдәбиятта уңай герой, «конфликтсызлык теориясе», традицияләр һәм новаторлык, заман әдәби стиле, хәзерге әдәбиятта заманчалык, поэтика мәсьәләләре буенча күтәрелгән бәхәсләрдә И.Нуруллин үз тавышын ишеттерә. Аның «Образлар дөньясында» (1964), «Тормыш һәм сәнгать чынлыгы» (1983) җыентыклары бүген дә кыйммәтен җуймаган хезмәтләр булып тора.

1980 елларның икенче яртысында әдәби мираска, методологик мәсьәләләргә янача карау мөмкинлеге күренә башлагач, 1987 елларда татар рухи-иҗтимагый янарыш һәм милли-азатлык хәрәкәте юлбашчысы Гаяз Исхакый исемен һәм мирасын татар халкына, үз ватанына кайтару мәсьәләсе көн тәртибенә куела. Моңа кадәр үк әдип әсәрләре белән таныш булып, Г.Исхакый иҗатыннан башка XX йөз башы татар әдәбиятын фәнни нигездә өйрәнеп булмавын аңлаган И.Нуруллин язучы иҗатын халкына кайтару өчен фидакарьләрчә көрәшә башлый. Татар дөньясында беренчеләрдән булып, Мәскәү һәм Татарстан газета-журналларында, радиоларда, төрле конференцияләрдә, җыелышларда Г.Исхакыйның шәхесе һәм олы мирасы, милли әдәбияттагы урыны хакында төрле шәкелдәге язмалар, докладлар белән чыгыш ясый. Әдипнең туган авылына, Уфа-Мәскәү-Петербург шәһәрләренә, аның соңгы сыену урыны булган Төркиягә сәяхәт кыла. Шушы изге тартышта галим тарафыннан утызга якын язма дөнья күрә. «Гаяз Исхакый — язучы, драматург, публицист» (1989), «Кайту» (1990), «Үзенә лаеклы булып кайтсын иде (Г.Исхакыйның сигез томлык әсәрләре җыентыгы уңаеннан)» (1991), «Гаяз Исхакый (әдипнең тормыш юлы һәм иҗат эшчәнлегенә кыскача бер күзәтү)» (1991) һ.б.ларда, язучының әдәби-иҗат портреты тудырылып, Гаяз Исхакыйның фәнни биографиясен һәм иҗатын идея-эстетик гыйльми күзаллауда тәүге адымнар ясала. Әдип рухи мирасының асыл хасиятләреннән тормышчанлыкны, миллилекне, халыкчанлыкны һәм тирән психологизмны билгели. Беренче рус инкыйлабы елларында Г.Исхакый тарафыннан «тәнкыйди реализмның беренче җитди үрнәкләре» тудырылуына таянып, әдипнең яңа реалистик татар прозасына нигез салуы хакында зур нәзари гомумиләштерү ясый. Шуңа күрә И.Нуруллин әдип турында фәннең нигез ташларын салган исхакыйчы галим буларак бәяләнергә тулысынча хаклы.

Галим әдәбият теориясен үстерүгә дә үзеннән лаеклы өлеш кертә. Бу өлкәдәге эзләнүләре XX гасыр башы татар әдәбияты, мәдәнияте тарихын яктырткан һәм заман әдәби хәрәкәтен бәяләгән хезмәтләреннән тыш, аның фәнни-теоретик тикшеренүләрендә дә чагыла. «Әдәбият теориясе. Әдәби процесс» (1977) хезмәтендә, нәзари фикернең тарихи үсеш баскычларында ирешелгән казанышларына таянып, матур әдәбиятның тууы, аның үсеш закончалыклары, традицияләр һәм новаторлык, күчемлелек, әдәби стиль һ.б. мәсьәләләрне әдәби бәйләнешләр яссылыгында тикшерә. Хезмәтнең әдәби юнәлешләр һәм иҗат методлары, аларның поэтикасы кебек әдәби күренешләрне өйрәнүгә багышланган бүлеге үзенең фикер киңлеге һәм тирәнлеге, галимнең фәнни һәм диалектик фикерләве белән аерылып тора. И.Нуруллин күренекле рус галимнәре Л.Тимофеев, Ф.Головенченко, Г.Абрамович, Н.Гуляев фикерләренә нигезләнеп, әдәби агым, юнәлеш, әдәби мәктәп, иҗат методы категорияләренең мәгънәләрен, асыл билгеләрен ачыклый һәм аларның татар әдәбиятында барлыкка килүе һәм үсеше хакында үзенең концепциясен тәкъдим итә.

***

Күңелендә иҗат ялкыны пыскып яткан әдәбият белгече һәм тәнкыйтьченең язучылык эше белән шөгыльләнүе бер дә гаҗәп түгел. Әдәби-тәнкыйди һәм гыйльми мохиткә хикәяләре белән килеп кергән И.Нуруллинның бу өлкәдә иҗат активлыгы 1950-1960 елларга туры килә. Шушы вакыт аралыгында төрле газета-журнал битләрендә басылып чыккан әдәби әсәрләре 1976 елда «Аның йолдызы» дигән исем астында китап булып дөнья күрә. Язучы буларак «матурлыкны, нәфисләкне сизә һәм бәяли белгән» И.Нуруллин хикәя һәм драмаларында тормыш материалын үзенә якын, таныш булган авыл кешеләре, югары уку йортларында белем алучы студентлар, галимнәр, зыялылар тормышыннан ала. Аларга тематик киңлек һәм жанр төрлелеге хас. Язучы иҗатында, үз сүзләре белән әйткәндә, «заман сулышы сизелә, ярыйсы гына мөлаем кешеләр җанландырыла», гади, галәти тормыш дулкынында, тормыш матурлыгын, яшәү мәгънәсен, күп санлы йолдызлар арасыннан үз «йолдыз»ын эзләүче геройлар үзәккә куела.

Авторның бер төркем хикәяләрендә («Ана күңеле»,1944; «Рәхмәтулла абзый»,1945) сугыш афәтен, авырлыгын үз җилкәсендә татыган авыл кешеләренең күңел матурлыгы, өмет-ышанычы тасвирлана. «Әтәч фермасы» (1955), «Кара приборы» (1955) юмористик-сатирик әсәрләрендә совет учреждениеләрендә, партия оешмаларында хезмәт итүче

хезмәткәрләрнең, колхоз житәкчеләренең эш-гамәлләрендә житешсезлекләр, кимчелекләр фаш ителә. Мондый эчтәлекле хикәяләрендәге стиль җинеллеге, көлүһөҗү үткенлеге, сюжет корылышы И.Нуруллинны XX гасыр башы хикәячеләре Г.Гобәйдуллин, Ш.Камал иҗатына якынайта.

И.Нуруллин җанын борчыган, уйландырган мәсьәләләрне, үзе тирән инанган кыйммәтләрне драма әсәрендә дә сурәтли. Язучының университет студентлары тормышын гәүдәләндергән «Анын йолдызы» дигән трагикомедиясе 1955-1956 елларда иҗат ителә. Әсәрдә яшәү мәгънәсенә, хезмәткә, гаилә-мәхәббәт мәсьәләсенә караш, бәя-хөкемнәр төрлелеге күрсәтелә, үз күнеленә, җанына хыянәт итмәү, намус, вөҗдан кебек гомумкешелек кыйммәтләре яклана.

И.Нуруллин әдәби эшчәнлегендә XX гасыр башында нәшер ителгән газета-журналлардагы материаллар, хатирә-истәлекләр, архив чыганаклары һәм төрле шәкелдәге язмалардагы әдәби-мәдәни һәм биографик фактларга, вакыйгаларга нигезләнеп, Г.Тукай шәхесен, тормыш юлын һәм татар халкының рухи-мәдәни хәятындагы урынын сәнгатьчә гәүдәләндергән әсәрләр бер шәлкемне хасил итәләр. 1960 елларда И.Нуруллин документаль-биографик жанрдагы әдәби әсәрләр иҗат итә. «Тукай Петербургта» (1965) һәм «Тукай турында хикәяләр» (1971), «Поэт из деревни Кырлай: рассказы о Габдулле Тукае» (1967), «Напевы мятежного саза» әсәрләрендә шагыйрьнең шәхси тормышыннан алынып, авторның иҗади уйланмасы белән баетылган сурәт-картиналарда Тукайның җанлы һәм вакыты белән драматик, фаҗигале образы тудырыла, аның шәхси кичерешләре, бәя-хөкемнәре чагыла. Язучының бу төр эшчәнлегендә иң югары нокта булып «Тукай» (Мәскәү, 1978) һәм «Габдулла Тукай» (Казан, 1979) әдәби-документаль китаплары тора. И.Нуруллин Г.Тукайның тормышына, иҗат лабораториясенә караган фактларны эзләү, аларны тулыландыру юнәлешендә эшне дәвам иттерә. 1980 елларның икенче яртысында ил күләмендә башланып киткән демократик үзгәрешләр китапны яна исемнәр, төгәлрәк әйткәндә, мәсәлән Г.Исхакый шәхесе һәм ике арадагы инсани мөнәсәбәтләр хакында яна сәхифәләр белән баетырга мөмкинлек тудыра. Аның төзәтелгән һәм тулыландырылган икенче басмасы И.Нуруллинның дистә еллар буена «бер җан, бер тән» булып яшәгән хатыны, фикердәше, озак еллар Казан университетының татар журналистикасы кафедрасында эшләгән мөгаллимә һәм галимә Р.Нуруллина тырышлыгы белән 2000 елда «Моңлы саз чыңнары» исемендә басылып чыга. И.Нуруллин татар халык шагыйре Г.Тукай шәхесен, аның кыска, әмма бай тормышын хисси-эмоциональ, образлы чагылдыру юнәлешендә дә милли әдәбият тарихында үзгә сукмагын булдыра.

И.Нуруллинның шушы юнәлештә язылган икенче әдәби-биографик романы татар әдәбиятының классик әдибе, драматургы, оста тәнкыйтьчесе, тирән белемле һәм киң карашлы әдәбият белгече Фатих Әмирханга багышлана һәм «Атаклы кешеләр тормышы» сериясендә 1988 елда дөнья күрә. Г.Тукай хакында әсәр әзерләгәндә үк, И.Нуруллин 1907-1913 еллар аралыгында Г.Тукай белән тыгыз дустанә һәм иҗади бәйләнештә яшәп, уй-фикерләре, теләк-омтылышлары уртак булган, аурупача яшәү үрнәгенә омтылган, чын мәгънәсендә зыялы Ф.Әмирхан тормышы һәм иҗат биографиясенә караган шактый бай материал туплап өлгерә. Романда Ф.Әмирханның зур тормыш сынауларына дучар ителеп, рухи биеклектә кала алуының һәм әсәрләренең заманча яңгырашының серен ача торган, «нәни мулла»ны шәхес һәм язучы буларак формалаштырган гаиләви, әдәби-мәдәни, милли чынбарлык җанландырыла.

Татар әдәбият белеме фәнен үстерүгә рухи-фикри егәрлеген, акыл-гыйлемен, сәләтен багышлаган галим, бөек Г.Тукай гыйльмиятен яна баскычка күтәргән зыялы, яңа заман әдәбиятын нигезләүче Г.Исхакый исемен һәм рухи мирасын туган иленә кайтару юлында бөтен көч-куәтен биргән каһарман көрәшче, милли сүз сәнгатенең үзгәреш закончалыкларын аналитик бәяләгән тәнкыйтьче һәм әдип И.Нуруллинның татар сүз сәнгате, аның фәне тарихында лаеклы һәм кабатланмас урыны бар.

**Таһир ГЫЙЛАҖЕВ,**
*Казан федераль университеты доценты*

# ФӘН ҺӘМ ДИН БЕРЛЕГЕ

Республикабыздагы дини вәзгыять турында вакытлы матбугат битләрендә, радио-телевидение аша да бик күп фикерләр әйтелә, татарларга традицион ислам юлыннан тайпылмаска кирәклеге алга сөрелә. Әмма олы тарихлы, дини мәктәп-мәдрәсәләр тоткан, үзенең дини гыйлем өлкәсендә атаклы галим-остазлары булган татарда ислам дине һаман да үзгәреш кичермичә, гадәттәгечә (традицион) дәвам иткәнме соң? Юк, әлбәттә. Узган гасырның 20-30 нчы елларыннан башлап дини традицияләр жимерелә, имансыз татарлар буыны тәрбияләнә, татарның үзенчәлекле дини йолалары, әдәбияты, тәгълиматы үсүдән тәмам туктый.




Узган гасыр азагында, сәяси үзгәртеп кору чоры башлангач, ислам дине дә әкрен генә булса да җанланып китә: мәчет-мәдрәсәләр ачыла башлый, яшь буында дингә кызыксыну уяна. Әмма Зыя Камали, Шиһабетдин Мәрҗани, Риза Фәхретдиннәребез, алар тәрбияләгән мөгаллимнәр, дин белгечләребез инде булмый. Менә шушы мәлдә татарда үзенең анлаешлы, саллы дини хезмәтләре белән заманча фикерли торган, һәр чыгышы, һәр язмасы белән яшь буынны мөселман рухында тәрбияләүгә, бүгенге дөньяви тормышта югалып калмаска өйрәтүгә төбәлгән башка дин белгечләре белән берлектә Харис хәзрәт Салихҗан да пәйда булды. Аның «Дин вә фән. Дөньякүләм дини һәм мәдәни этика нигезләре»[1] исемле яңа гына басылып чыккан монографик укыту әсбабы — моңа янә дә бер ачык дәлил.

Иң әүвәл, Россия гуманитар фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы, Казан шәһәре «Хәтер» мәчетенең имам-хатыйбы булуы ук аның фән һәм дин арадашчысы икәнлеген билгеләп үтү кирәктер. Автор, диннәр, гуманитар вә төгәл фәннәр бергәлегендә, яшүсмерләргә рухи тәрбия бирүнең әле моңа кадәр гамәлгә куелмаган яңа методикасын тәкъдим итә.

Китап «Фатиха» сүрәсе белән башланып китә һәм беренче бүлеге авторның тәрҗемәи хәленә багышлана. Биредә тасвирланган мәгълүматлар, бер карасаң, дингә һич тә нисбәтле түгел сыман. Әмма тирәнрәк фикер йөрткәндә алар, гади бер шәхес язмышы мисалында, Аллаһның кодрәтен, иманлы булуның гаҗәеп көчен аңларга мөмкинлек бирәләр.

А.Пушкин, Г.Тукай иҗатларында Коръән аһәңнәре чагылышы, Р.Фәхретдин һәм Л.Толстойның толерантлык турындагы фикерләре, аларның бүгенге рухи тәрбия бирү өлкәсендәге иң мөһим мәсьәләләрне хәл иткәндә тоткан урыны, әһәмияте аңлаешлы тел белән укучыларга бәян ителә; намус һәм акыл мәсьәләсе аерымланып карала. Харис хәзрәт Салихҗан, диннәрнең төрлелеген һәм каршылыкларын таныган хәлдә, дин һәм фән берлеге яссылыгында изгелек һәм толерантлык ниятендә диннәр арасындагы бергәлекне эзли. Ул үз алдына: «Бүген барлык диннәргә дә ярый торган кулай, уртак әсбап язып буламы?» — дигән сорау куя һәм бу юлда «дини мәдәниятле кеше шул булыр, кем Аллаһның барлыгына, берлегенә, изге

[1] Салихҗан Х. Дин вә фән. Казан: «Идел-Пресс» нәшр., 2012. – 392 бит.

китапларның, пәйгамбәрләрнең, фәрештәләрнең хаклыгына инанган хәлдә, сүз, куәт, хәрәкәт илән берсе икенчесен юатышса, бер генә дә булса җан иясен рәнҗетмәсә», дигән күзлектән чыгып эш итүне мәслихәт саный (86 бит). Аның фикеренчә, хәзерге Россиядә, динара тигезсезлекнең хөкем сөрүе нәтиҗәсендә, диннәр мәдәниятен мәктәпләрдә укыту мөмкин эш түгел, барлык халыкларга уртак дин ясап булмаган кебек, диннәр әхлагына уртак әсбап язып булмый. Ул бу фикерен бик үтемле итеп, тормыштан мисаллар нигезендә исбатлый.

«Россия конституциясен вә диннәр турындагы гамәлдәге кануннарны күзалласак, — ди остаз- галим. — Федерациядә яшәгән бәндә нинди генә милләттән булып, нинди генә телдә сөйләшмәсен, ул Аллаһу Хак сүбхәнәһү Тәгалә хозурында да, конституция вә дәүләт кануннары алдында да тигез. Бер генә дә дин, бер генә дә милләт вә шәхес алда да, артта да, аста да , өстә дә түгел» (87 бит).

Ләкин дин дәүләттән, мәктәп диннән рәсми аерылган илдә православие мәдәнияте нигезләрен өйрәтүне урыс мәктәпләренә кискен кертү аларда укучы татар-мөселман балаларына ислам мәдәнияте нигезләрен өйрәтү тиешлеген үзеннән-үзе таләп итә. Автор балаларны дини нисбәттән чыгып бүлгәләүгә яисә бар халыкка яраклы уртак дин булдыруны хуплаган Диас Вәлиев, Илдар Ханов кебекләргә каршы.Аның өчен «дин ул — идеология. Идеологиянең нигезе — мәдәният, һәр диннең үзенә генә хас идеологиясе-мәдәнияте бар. Идеологияләрне кушып булмаган кебек, мәдәниятләр дә кушылмый» (88 бит). Әйтик, ислам динендә җир йөзендә яшәгән барлык милләтләр өчен Алла –Бер булса, яһүд дине мәдәниятендә Аллаһ шулай ук Бер, әмма фәкать Яхве — Аллаһ тарафыннан сайланып алынган яһүд милләте өчен генә; Бог- Аллаһ та барлык бәндәләр өчен Бер, ләкин өч рәвештә: «Во имя Отца, Сына и Святого духа». Пәйгамбәрләрнең танылу-танылмау дәрәҗәләре дә төрле диндә төрлечә. Менә шул сәбәпле һәр халыкның — үз дине, аларга уртак дин «ясап» та, диннәр әхлагына багышланган уртак әсбап та язып булмый. Шулай ук мәктәпләрдә дин тарихын гына укытып, рухи өйрәтүләрнең эчтәлегенә төшендермәсән, әхлакый камил балалар үстерүгә ирешү мөмкин түгеллеген дә ассызыклый автор.

Харис хәзрәт Салихҗан фикеренчә, диннәр мәдәниятен бала күнеленә сеңдерү өчен энциклопедик күләмле белемгә ия булырга кирәк. Ләкин мондый укытучылар мәктәпләрдә бик аз. Ни кызганыч, муллаларның күбесе фәнне,галимнәрнең шактые динне белми. «Нәтиҗәдә, әхлаксызлык белән көрәшү өчен дин әһеле бүгенге көн таләпләренә бәрабәр фәнни дәлил китерә алмаган кебек, фән әһеле дә дини исбатлауларга мохтаҗ. Шул сәбәп әхлаксызлыкка каршы глобаль системалы дин вә фән берлегендә аңлату һөҗүме кирәк!» (96 бит).

Автор хаклы рәвештә, дин һәм фән бергәлегендә мәктәптә балалар укытуның төп ышанычлы ысулы итеп дөньяви фән дәресен (физика, математика, химия, рус, татар телләре, әдәбият, тарих, компьютер технологиясе һ.б.) диннәр гыйлеме белән баетуны саный. Бу фикер белән килешми һич мөмкин түгел.

Әлеге методик әсбапта шулай ук дөньякүләм танылган атаклы галимнәрнең, фәлсәфәчеләрнең дингә унай мөнәсәбәттә булулары хакында кызыклы мәгълүматлар бирелә, төрле тискәре күренешләрнең (дини экстремизм, фанатизм һ.б.) асылы аңлатыла, дин һәм фәннең бер-беренә каршы тормавы бәйнә-бәйнә тормыштан мисалларда дәлилләнә.

Монографиянең икенче зур өлешен автор тарафыннан гарәп графикасыннан кириллицага күчерелеп әзерләнгән Харун хәзрәт Яхъяның «Корьән могҗизалары» исемле китабына таянып бирелгән язмалар тәшкил итә.

Гомумән, китапта А.С.Пушкинның күп кенә шигъри әсәрләре авторның үзлегеннән татарчага тәрҗемәдә бирелә, методик әсбапның ике телдә — татар һәм рус телләрендә башкарылуы да аның гамәли яктан әһәмиятен тагын да күтәрә.

Һичшиксез, әлеге хезмәт балаларны, аларның әти-әниләрен дини мәдәният белән таныштыру, әхлакый тәрбия бирү, өлкәсендә татарда яңа, үзенчәлекле методик әсбап, фәнни-гамәли көндәлек кулланма буларак мактауга лаек.

**Фәрит СОЛТАНОВ,**
*фәлсәфә фәннәре докторы*

# УКОЛ

— Зөлфирә, туганым, әйт әле, зинһар: бу кызны үстергәндә нинди ялгышлык җибәрдек соң без? Кайда, кайчан ялгыштык икән? Туган көненнән күреп беләсең ич: нинди матур һәм акыллы бала булып үсте бит ул. Аны иркәләп сөймәгән, яратмаган кеше юк иде тирә-юньдә. Кем уйлаган үскәч шундый кансыз булыр дип? Абыйсы да андый түгел ләса. Аңа ияреп шундый булган дияр идең. Кыз бала бит бу, кыз бала... — дип, яшьләренә буыла-буыла тезде Зөләйха апа.

Соңгы көннәрдә башына төшкән тирән кайгысыннан һич кенә дә айный алмыйча, көннәр һәм төннәр буе чайкала-чайкала өзлексез елап һәм уйлап утыруын күреп торган Зөлфирә Зөләйха сеңлесенең сәламәтлеге өчен борчыла башлады: инсульт булып яисә акылы зәгыйфьләнеп китмәсә ярый инде. Язмышның бу кадәрле зур һәм аяусыз сынавын күтәрү таза ир-егетләр җилкәсен дә җимереп төшереп, изеп атар иде. Инде нишләргә? Тынычландыргыч дару да алмый үзен, ичмасам. Укол ясарга килгән табибны да якын җибәрми. Гомумән, шприц күрү белән күзе акая, бөтен тәне калтырый башлый, үзе туктаусыз елый. Сыек даруларны да эчми. Апасы Зөлфирәнең элегрәк алынган сәдәф даруларын гына эчеп куя кайчакта. Йоклатып хәл кертергә тырышып карыйлар — йокы алмый. Апасы Зөлфирә булмаса, аны күптән сары йортка ябып куйган булырлар иде, мөгаен.

***

Тыныч кына, матур гына яшәп ятканда, Зөләйха апа белән Зариф абзыйның инде укуын тәмамлап шәфкать туташы булып эшли башлаган кызлары Гөлсинә, көтмәгәндә-уйламаганда, өйдәгеләрне шаккатырып:

— Мин бүген кич Италиягә китәм. Җибәрмәссез, гауга чыгар дип алдан әйтмәдем. Кичке поезд белән Мәскәүгә барам да, иртәгә Миланга очам. Бу илдә безнең кебекләргә акча да эшләп булмый. Акчаң булмагач, кешечә яшәп тә булмый, — диде.

Әти-әнисе, абыйсы Ратмир «аһ» итте. Зөләйха апа елап ук җибәрде.

— Бу ни дигән сүз инде, кызым? — диде әтисе Зариф абзый. — Яңа гына эшкә урнаштың. Тора-бара акчаң да булыр. Эшләгәнең — үзеңә. Синнән торган өчен дә, ашаган өчен дә акча сораган кеше юк бит әле. Чит илдә бит барысы өчен дә үзеңә түләргә туры киләчәк. Эштән дә сразы җибәрмәсләр әле? Документларны да бит тиз генә әзерләп булмый. Документсыз-нисез ничек бүген үк чыгып китәсең?

— Документлар күптән әзер инде, әти. Шулай буласын белдем инде мин. Атналар буе әнинең күз яшен, сезнең битәрләүне күрмәс-ишетмәс өчен барысын да алдан эшләп куйдым. Чыгып китәр алдыннан гына әйтергә ниятләдем. Менә шул...

— И, кызым, ничек шундый бәгырьсез була аласың? — диде әнисе, күз яшьләрен тыя алмыйча. — Олыгаеп барабыз бит инде без. Кемгә калдырып китәсең әтиең белән мине?

[1] Бу сәхифәдә тормышта булган хәлләр бәян ителә.

— Абый бар ич, әни. Ул карар. Сезнең янда бит ул, читтә түгел. Бер-бер хәл була калса, чакыртырсыз, мөмкинлегем булса, кайтырмын.

— Соң, абыең ир кеше бит, кызым. Синең кебек табиб та түгел. Авырып китсәк, укол да кадый белми, даруларны да аермый, — диде әнисе. — Без бит инде хәзер гел ярдәмгә мохтаж. Киләчәк көннәр синең кулда иде, балам. Өметләрне өзеп китәсең инде. Аннан бит тиз генә кайта да алмассың.

— Борчылма, әни. Барыгыз да исән-сау, аякта. Кирәк булса, абый да өйрәнер. Укол кадау авыр эш түгел ул. Ярый, озак сөйләшеп торырга вакытым юк. Әйберләрем җыйган. Абый, мине тимер юл вокзалына илтеп куясыңмы? Юк дисәң, такси чакыртам, — дип, әйберләрен алырга үз бүлмәсенә кереп китте. Абыйсы ана иярде.

Күп тә үтмәде, бүлмәдән тәгәрмәчле зур чемодан, бер-ике пакет тоткан Ратмир, аның артыннан ук иңенә кечкенә сумкасын аскан Гөлсинә килеп чыкты. Диванга утырып, юл алдыннан дога кылдылар. Юл кешесенең юлда булуы яхшы дип, кыз чыгып китү ягын карады, әтисе белән әнисе елап калды. Тыныч кына сөйләшә дә алмадылар.

— Менә үстер баланы, — диде Зөләйха апа, күз яшьләрен сөртә-сөртә. — Күпме акча түгеп укыт. Олыгайган көнебездә караучыбыз бар дип ышанып тор. Ә менә дөнья үзенчә борды да куйды.

— Кемгә охшап шундый үзсүзле һәм каты күңелле икән бу бала? Абыйсы ир кеше булса да моннан йомшак. Йә Хода, сәламәтлек, сабырлык бир безгә. Теләге, максаты шул икән, без генә тыеп кала алмыйбыз инде. Ярый, исән-сау, уңышлы гына йөреп кайтсын. Бәлки, әллә ни озак йөрмәс әле. Насыйп булса, бераз эшләр дә әйләнеп кайтыр, — диде Зариф абзый һәм кухняга юнәлде. Тынычландыргыч дару эчеп куйгач, янә залга чыгып, диванга барып ятты. Беренче мәртәбә йөрәгенең чәнчеп-чәнчеп авыртуын, әллә ничек, тигезле-тигезсез тибүен тоеп, борчуга төште. Монысы ни инде тагын? Шул көннән башлап, борчылса да, авыр күтәрсә дә монарчы авыртуның ни икәнен белмәгән йөрәге, мин монда, дип, үзен сиздерә дә тора. Хәлсезләнеп, куллары калтырый башласа, кулындагы әйберләре дә төшеп китә.

Зөләйха апа кызы өчен бер борчылса, ничә ел бергә гомер иткән яраткан ире Зариф өчен дә нык көенде. Үзенең дә башлары әйләнеп, егыла язып калуларын иренә дә, улына да сиздермәде, өстәмә борчу салмады.

Шулай борчылулар, авыр уйлар белән ике-өч ай үтеп китте. Гөлсинәдән һаман бер хәбәр дә юк. Янә хәсрәт: исән-саумы икән? Барып житкәнме? Эш тапканмы? Тапса, нинди эш?.. Ну бу бала дигәнең, әллә бар аңа әти-әни, әллә юк!

Киткәненә дүртенче ай тулып килгәндә, сәер бер шалтырау белән өй телефоны шалтырады. Зөләйха апа үзе генә өйдә булганга, тиз-тиз барып трубканы алды. Башта шылт-шылт итеп торган трубкадан ниһаять хатын-кыз тавышы ишетелде.

— Алло, алло! Кем әле бу? Әни, синме? Кызың Гөлсинә шалтырата. Мин исән-сау. Килүгә, әйбәт эшкә урнаштым: бай гына бер картны карыйм. Үлеп гашыйк булды миңа. Ташлап китмәсен дип үзенә бәйләп куйды: без язылыштык. Болай начар кеше түгел. Үземнең машинам бар хәзер. Йорт-җире әйбәт. Исәнлек-саулыкмы? Яңалыклар юкмы?

Зөләйха апа җавабын да биреп өлгерә алмады, Гөлсинә, ярый хушыгыз, мин үзем шалтыратырмын, дип, трубкасын куйды.

Шулай итеп, ничә ай кызының хәбәрен көткән ана рәхәтләнеп сөйләшә дә алмады. Барыбер иркенләп сөйләшеп булмас иде, мөгаен, чит ил бит. Шулай да өч-дүрт җөмлә әйтергә була иде инде. Зөләйха апаның бите буйлап мөлдерәп агып төшкән күз яшьләре дә аны бу әрнүле халәтеннән арындыра алмады.

Кияүгә чыккач, тиз генә кайтырга уйламый инде бу, дип тә уйлап куйды Зөләйха.

Шул арада Зариф абзый белән уллары Ратмир кайтып керде. Карчыгының күзендә яшь бөртекләре күреп, Зариф абзый куркып калды.

— Ни булды тагын? Бер-бер начар хәбәр бар мәллә? — диде.

— Бик әйбәт тә түгел шул әле, әтисе, — диде Зөләйха апа. — Әле генә Гөлсинә шалтыратты. Баруга, бер картны тапкан, аны тәрбияләп карый-карый, шуңа кияүгә дә чыгып куйган, бай яшибез, ди.

— Начар хәбәр түгел, әнисе. Бай кияү тапкан бит. Әллә ни карт түгелдер, кияүгә чыкмас иде. Тормышы әйбәт булгач, без кирәк түгел инде аңа хәзер. Тиз генә кайтмас, көтмә син аны.

— Тагын кайчан шалтырата? — диде абыйсы Ратмир. — Вакытын әйтмәдеме? Мин дә сөйләшер идем. Телефон номерын әйттеме?

— Әйтмәде шул. Иң кирәкле сүзләремне дә әйтә алмыйча калдым бит, ичмасам. Шалт итеп трубкасын куйды да, ике араны өзде. Кабат шалтыратуын көтәргә генә кала инде.

Ратмирның сеңлесенә ачуы килде: ничек инде, шул гомер шалтыратма, хәбәр җибәрмә, өстәвенә, олыгаеп бара торган әнисе белән дә рәтләп сөйләшмә.

Зөләйха апа йокы бүлмәсенә кереп китте. Караватына ятып, рәхәтләнеп елады.

***

Гөлсинәнең кабат шалтыратуын көтә-көтә тагын берничә ай үтеп китте. Номерын биргән булса, үзләре шалтыратырлар иде дә бит — бирмәде. Чит ил булгач, акчалары күп китәр дип уйлагандыр инде.

Беркөнне, иртәнге чәйгә җыенганнар гына иде, озак итеп телефон шалтырады. Кухняда бәлешләр пешереп мәш килеп йөргән Зөләйха апа ишетми калды, ахры. Бәлеш көтеп утырган Зариф абзый барып алды трубканы.

— Әйе, тыңлыйм. Кем бу? Ә-ә, кызым, синмени? Нигә шулкадәр озак хәбәр бирмисең, кызым. Әниең сине уйлап, сине көтеп саргаеп үлә бит инде. Рәзе шулай ярый, — дип ачуланырга күчте Зариф абзый. Шул арада, тавыш ишетеп, Зөләйха апа да кухнядан йөгереп чыкты. Зариф абзый кулыннан трубканы алды да:

— И-и, кызым, бигрәк озак көттерәсең! Ник моңарчы шалтыратмадың?! — диде.

— Әни, бик мәшәкатьле чагым булды. Ирем үлеп китте бит. Аны күмеп, мал-мөлкәтен үз исемемә яздырганчы шактый вакыт үтте шул. Ни хәлләрегез бар? Исән-саулармы?

— И, кызым, зур кайгы кичергәнсең икән, уртаклашабыз кайгыңны. Бәлки, кайтып китәрсең, бераз ял да итәрсең?

— Кайтып булмый шул әле, әни. Яңа эш урыны табарга кирәк. Кайтып-китеп йөргәндә акча күп бетә бит. Әйбәт эшкә урнашу өчен дә түләргә кирәк. Кайтасы булсам, шалтыратырмын. Ярый, хәзергә сау булып торыгыз. Абыйга да күп сәлам! — диде дә трубкасын куйды.

Зөләйха апа аңгыраеп калды. Бу нинди бала? Нишләп ачылып китеп сөйләшми? Нәрсә дә булса яшерә мәллә? Шатланасы урында борчылып кына калды Зөләйха апа. Зариф абзыйның да кәефе әллә ни түгел иде.

Гөлсинәме соң бу, әллә аның исеменнән сөйләшүче берәр явыз хатынмы? Болар шулай аптырашып торганда, төнге дежурдан Ратмир кайтып керде. Әтисе белән әнисенең кыяфәтеннән эшнең нидә икәнен аңлап алды.

— Нәрсә, Гөлсинә шалтыратты мәллә? Кайтам дидеме? Кайчан? — диде.

— Юк шул, кайтырга бик жыенып тормый әле. Карый торган ире үлеп киткән. Байлыгын үземә яздырдым ди.

— Болай булгач, тиз генә кайтмас. Көтеп тилмермәгез, — диде Ратмир. – Әни, берәр тәмле әйберең бармы, ашат әле мине, ашыйсым килә.

— Әле без дә ашамаган, улым. Әзерләнеп кенә йөри идек. Әйдәгез, әниең пешергән бәлешне бергәләп утырып ашыйк. Шунда сөйләшеп бетерербез сүзебезне дә, — диде Зариф абзый.

Бергәләшеп кухняга кереп киттеләр.

— Өстәлнең ямен, ашның тәмен жибәрде бу мәгънәсез кыз, — диде Зөләйха апа.

Ратмир да түзмәде:

— Якында гына булса, барып, тотып ишәр идем инде үзен. Бәхете, чит илдә. Сагыну түгел, нәфрәт уяна башлады инде мона, — диде.

***

Тагын бер ел үтеп китте. Кинәттән Гөлсинә үзе кайтып төште. Танымадылар башта. Бөтенләй икенче Гөлсинә иде бу: чәче-башы матур итеп ясалган, киеме соңгы модача. Ике зур чемодан тулы әйбер. Аларын, көчкә күтәреп, таксист кертеп куйды.

— Кызым, ниһаять, сине күрер көн дә бар икән, — дип, Зөләйха апа кызын кочып үбәргә кереште. Шатлыгыннан елап та жибәрде. Әниләрнең шул инде: кайгы килсә дә елыйлар, шатлык инсә дә елыйлар.

— Әни, житәр инде. Булды. Нәрсәгә елап торасың? Кайттым бит. Исәнсау. Сез дә, — дип, әнисен салкын гына кочып алды да, шулай ук бик ачылып китмичә генә әтисе һәм абыйсы белән күреште.

Үзгәргән, нык үзгәргән Гөлсинә. Италиягә киткәнче әти-әни, абый дип өзелеп торган кызның тавышында да, йөзендә дә кырыслык, ниндидер салкынлык ярылып ята иде. Аның үзен тотышыннан барысы да өшеп китте. Ничек сөйләшергә дә белми, аптырашып калдылар. Абыйсы авыр чемоданнарын Гөлсинә бүлмәсенә кертеп куйды. Жыйнаулашып, залда зур табын әзерли башладылар. Кызлары кайту хөрмәтенә чәйгә генә булса да туганнарын чакырырга иде ниятләре. Гөлсинә риза булмады. Арыдым, кәефем юк, беркемне дә күрәсем килеп тормый, диде. Табын янына үзләре генә жыелдылар.

— Сөйлә инде, кызым, соңгы вакытта ничек яшәдең? Шалтыратмадың да, — диде Зөләйха апа.

— Шалтыратырлык жай булмады, әни. Беренче ирем үлгәч, тагын бер ир тапкан идем. Бай булса да, беренчесе кебек үк түгел иде. Шулай да, бар да миңа калды. Ул да үлде бит. Үләр алдыннан васыятьнамә язган. Бердәнбер кызы бар иде, нишләптер ана бернәрсә дә калдырмаган. Судлашып йөрде. Барыбер оттырды. Менә шул мәшәкатьләр белән йөреп, шактый вакыт үтте. Инде бераз ял итәрмен дип кайттым менә. Сезне дә күреп калырмын. Шулай да озакка түгел, — диде Гөлсинә.

Аның бу сүзләреннән башкалар имәнеп китте. Бу ни дигән сүз инде: күреп калу. Үләргә жыена мәллә? Ярамаган берәр эш кылганмы? Ни өчен ирләренең икесе дә кинәттән үлгән? Өстәвенә, байлыкларын моңа яздырып үлгән?

— Ник алай тиз үлеп киттеләр соң ирләрең? Бик карт иделәрмени? – дип аптырап сорады Зөләйха апа.

— Юк. Әллә ни карт булмасалар да, йөрәк авырулы иде икесе дә. Шуңа кинәт кенә үлеп киттеләр. Ярый, чәегез тәмле булды, зур рәхмәт. Мин бүлмәмә кереп ял итим әле. Бик арыдым, — диде дә бүлмәсенә кереп китте Гөлсинә. Өчәүләшеп артыннан карап калдылар. Өчәвенең дә күңеленә шик

төште: тегендә усал нияттән бер-бер хәл кылып, качып кайтмады микән? Йөзе кырыс, сөйләшкәндә дә ачылып китми. Элекке Гөлсинә түгел иде бу.

— Кайтмый, хәбәре юк дип бер борчылдык, инде менә исән-сау кайтып күренде, әмма җанда җылылык, күнелдә шатлык юк, — диде Зөләйха апа, кәефе китеп.

— Алай ук борчылма әле, карчык. Иртәгә дә көн бар бит әле. Тагын сөйләшербез. Ирләре үлгәнгә дә йөзе хәсрәтледер, күнеле үсмидер, — дип, карчыгын тынычландырырга тырышты Зариф абзый, әмма үзенең җаны да урынында түгел иде. Кызының бер хәбәрсез кинәт кайтып төшүе, шулай кистереп кенә сөйләшүе аңа да нинди дер шом салды, тынычлыгын алды.

***

Ике-өч көн үтәр-үтмәс, гаиләгә бер-бер артлы тирән кайгы, олы хәсрәт килде.

Гөлсинәнең абыйсы Ратмир, ике бүлмәле үз квартиры булса да, сеңлесе чит илгә китү сәбәпле, әтисе белән әнисе ярдәмчесез тормасыннар дип күбрәк алар белән яшәде. Зөләйха апа да, Зариф абзый да моңа бик теләп риза булдылар, кызларының ташлап китүен дә җиңелрәк кичерделәр. Әлегә үзенең гаиләсе булмаганга, Ратмирга да җайлы: ашарына әзер, киемнәре, урын-җире юылган, үтүкләнгән.

Әтисе белән әнисенең өч бүлмәле квартиры, әллә ни бай җиһазланмаган булса да, чиста, рәхәт; ишектән килеп керүгә яңа гына пешеп чыккан ашларның, бәлешләрнең бөтен өйгә таралган хуш исе тагы да ямьлелек, чиксез рәхәтлек өсти. Инде шактый яшькә җитеп, Ратмирның һаман өйләнмәгән булуының сәбәбе дә шунда: әнисе кебек уңган, тәмле итеп милли ризыклар пешерә торган кыз таба алмый иде. Эчеп, тәмәке тартып йөри торганнарның янына да бармады.

Гөлсинәнең кайтуының өченче көнендә, һич көтмәгәндә, уйламаганда, абыйсы Ратмир авырып китте: бөтен эче янып, әрнеп авыртуга чыдый алмыйча, вакыт-вакыт аңы да китеп бара. Моны күреп, әти-әнисенең коты очты: Ходаем, кайдан килгән, нинди чир бу дип, хәсрәткә төштеләр. Гөлсинә, никтер, ашыгыч ярдәм чакырттырмады. Хәзер, хәзер, үзем терелтәм мин аны, дип, Италиядән алып кайткан нинди дер укол ясады. Биш-ун минуттан хәле яхшырырга тиешле абыйсының хәле тагын да начарайды: буыла башлап, күзләре акаеп, авыз-борыныннан кан китте. Күп тә үтмәде, бер сүз дә әйтә алмыйча, бу дөньядан китеп тә барды. Моны күреп торган, инде Италиягә киткәннән бирле бердәнбер кызы өчен борчылып йөрәге авыртып интеккән Зариф абзый йөрәген тотып егылды. Әнисенең йөгереп кенә алып кергән йөрәк даруын эчертмичә, Гөлсинә әтисенә дә укол кадады. Зариф абзый бераздан тыныч кына бакыйга күчеп китте. Бер-бер артлы ике мәет. Зөләйха апа кызының әлеге гамәлләреннән бер нәрсәне аңлап алды: дөнья малына кызыгып, җанын иблискә саткан Гөлсинәнең ике ире дә шул юл белән китеп барган, үз үлемнәре белән үлмәгән, димәк. «Нинди ерткыч, канечкеч бала үстергәнбез, ничек шуны алданрак сизмәдек икән соң?» — дип уйлады ул, гаҗиз булып. Инде чират миндә дип куркудан хәлсезләнеп кәнәфигә барып утырды да кызының укол тотып үзенә таба килүен көтә башлады. Соңрак бераз тынычланды Зөләйха апа. Инде үлсәм дә исем китми, яшәүнең мәгънәсе калмады, дип уйлап куйды. Кызы әнисен җәлләде булса кирәк, ана тимәде, әнисе ягына борылып та карамады. Үз эше белән мәшгуль иде ул. Зөләйха апа кәнәфидә утырган килеш, вәхшигә әйләнгән кызының, ниһаять, ашыгыч ярдәм машинасын чакыртуын,

тагын нәрсәләрдер эшләвен күз яшьләре аша карап утырды. Ашыгыч ярдәм артыннан ук милиция дә килеп житте. Гөлсинә, табибларга да, милиция хезмәткәрләренә дә кирәк кадәр акча төртеп, мәетләрне ярдырырга җибәрмәде, кирәкле кәгазьләрне шунда ук ясатып алды. Кайгыга баткан Зөләйха апага сорау да биреп тормадылар: башы түнгән, куркудан кызына каршы әйтергә җөрьәт итмәгән ана кәнәфиендә елыйелый утыра бирде. Үзе шәфкать туташы булганга, инде мондый эштә тәҗрибә дә туплаганга, Гөлсинә бу эшләрнең барысын да шома гына, оста итеп башкарып чыкты.

Бер бүлмәдә яткан ике мәеткә Зөләйха апа төне буе дога укып утырды. Янына бер кеше дә чакырырга теләмәсә дә, гомер буе аралашып яшәгән күрше әбиен кертте Гөлсинә. Күрше карчыкның гаҗәпләнеп: «Нидән үлделәр?» — дигән соравына: «Йөрәк», дип кенә куйды. Иртәгесен тиз генә мулла чакыртып, бераз гына булса да йоласына туры китереп, төшке аштан соң икесен дә татар зиратына күмеп куйдылар. Әнисенең зиратка барырлык та хәле булмады — өйдә утырып калды. Бу хәсрәткә «инде мине нишләтер?» дигән уй өстәлде. Кызының зираттан кайтуын куркып көтеп алды.

Әлеге эшләрне гаҗәеп оста һәм бернинди тоткарлыксыз башкарып кайтып кергән кызының мәшәкате күп иде әле. Италиядән кайтуга беркемгә дә сиздермичә, ике квартирны да сатуга куйган Гөлсинә, инде хуҗаларыннан — әтисе белән абыйсыннан котылгач, аларны тизрәк сатып җибәрү хәстәренә керешге. Әнисен пропискадан төшерде. Әле ике чемодан тутырып алып кайткан әйберләрен дә ике-өч бәясенә сатып җибәрәсе бар. Анысы белән дә шөгыльләнде.

Барысын да тиз тотты Гөлсинә. Квартирлар сатылгач, әнисе йортсызжирсез, хәләле Зарифсыз, берданбер улы Ратмирсыз урамда калды. Дөрес, урамда ук түгел, шәһәр читендә үз өе белән берүзе яшәп ятучы әнисенең апасы Зөлфирәгә илтеп куйды аны кызы. «Икәүләшеп, бер-берегезгә терәк булып яшәрсез шунда», — диде. Бераз гына акча калдырды. Бөтен эшен дә җайлап бетергәч, шактый акча туплагач, аны еврога әйләндергәч, артык бер көн дә тормыйча, Италиясенә китеп барды.

Зөләйха апаның бу хәлләрне күтәрә алмыйча туктаусыз елавыннан күзе сукырайды. Үзе урынга калды. Кызының ни өчен мондый вәхшигә әйләнүе сәбәбен апасы Зөлфирә белән күпме генә ачыкларга тырышса да, төбенә төшә алмады.

Шуннан бирле Гөлсинәнең бер хәбәре дә килмәде, үзе дә күренмәде.

Бер-ике елдан хәсрәтеннән саргаеп кипкән, бу дөньядан ваз кичеп, теге дөньяга китеп барган Зөләйха апаны үзеннән дә олы апасы һәм күршекүлән якындагы зиратка, сөекле ире Зариф белән берданбер улы Ратмир янына җирләп куйдылар.

**Флёра ТАРХАНОВА**

## Афоризмнар

• Дөнья белән хис идарә итә. Бу эш акылга гына тапшырылса, кешелек дөньясы мондый түбәнлеккә дә төшмәс, бөеклеккә дә ирешмәс иде.

• Кешенең нәфсе үзе яшәгән галәм киңлекләреннән дә чиксезрәк. Аның гомере, бәлкем, шул сәбәпле Ходай тарафыннан чикләнгәндер дә.

• Күңелеңне байлыкка салудан саклан. Бу читлек-ятьмәдән исән-сау чыга алучылар бик сирәк.

• Ил-нигезеңне төзекләндерергә омтылмасаң, үз йорт-нигезеңне торгызып кына нәселеңне саклап калып булмый ул.

• Күпләрнең якын туганлыклары гомер буе бер-берсенә йомышлары төшүгә кайтып кала.

• Кыйблasыз яшәү авыр. Шул авырлык җиңеллеккә этәрә. Ә аның җимешләре — аракы, наркомания, фәхишәлек...

• Акылга таяну - акыллылык, көчкә таяну — көчсезлек билгесе.

• Кешеләр эреләнгән саен вакчыллана баралар.

## Уйлар уйнавы

• **Яхшы атлы булыйм дисәң...** Бу дөньяда бар кешегә дә охшар өчен кимендә икейөзле, ялганчы һәм имансыз булу мәслихәттер.

• **Гөнаһлы йөк.** Тирә-ягында мохтаҗлар булганда гаиләңнән арткан байлык — артык йөк ул. Күпләрнең шул йөкне тартып җәһәннәмгә барышы...

• **Өметсезлек.** Тәрбиясезләр тәрбиясендә тәрбияләнүчеләрдән нәрсә көтәргә?

• **Татар хыялы.** Хисләр белән тулы, кыерсытылган татар күңелендә һәрчак бер өмет уты — ул бәйсез татар дәүләте төзү. Чөнки аңа чаклы ирексезләп тагылган «ватан» кышлар кебек салкын, көзләр кебек көйсез, ташлар кебек җансыз кала бирә.

**Нурулла ГАРИФ**

# ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУ ДӘВАМ ИТӘ

Хөрмәтле укучыларыбыз!

2013 елның икенче яртыеллыгы өчен вакытлы матбугатка язылу башланды. «Казан утлары»ның индексы физик затлар өчен – **73210**; юридик затлар өчен – **16262**.

Журналга язылуны җиңеләйтү максатыннан абонемент үрнәген тәкъдим итәбез. Әлеге квитанцияне кисеп алып, анда тулы адресыгыз, исем-фамилиягез һәм язылырга теләгән айларны күрсәтеп, элемтә бүлегенә тапшырырга кирәк.

90 еллык бай тарихы булган мәдәниятебез елъязмасы «Казан утлары»на язылырга онытмагыз!

Федеральное государственное унитарное предприятие " ПОЧТА РОССИИ" Ф. СП-1

Ф.СП-1

Бланк заказа периодических изданий

**АБОНЕМЕНТ** на ~~газету~~ журнал **73210** (индекс издания)

*«Казан утлары»* (наименование издания)

количество комплектов

На 2013 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда (почтовый индекс) (адрес)

Кому

Линия отреза

ПВ | место | литер

ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА **73210** (индекс издания)

На ~~газету~~ журнал *«Казан утлары»* (наименование издания)

| Стои-мость | подписки | руб. коп. | Кол-во комп-лектов | |
|---|---|---|---|---|
| | каталожная | руб. коп. | | |
| | переадресовки | руб. коп. | | |

На 2013 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

почтовый индекс

код улицы

дом | корпус | квартира

город

село

область

район

улица

фамилия и. о.

# Мәхмүт Хөсәен

*Мәхмүт Хөсәен (1923 — 1993) – танылган шагыйрь; «Мәхәббәт һәм моң», «Далам таңнары», «Якты моң» һ.б. күпсанлы китаплар, җырлар авторы. Ватан сугышындагы шәхси батырлыклары өчен Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр белән бүләкләнгән сугыш ветераны. Тууына 90 ел тулу уңаеннан берничә шигырен тәкъдим итәбез.*

***

**Җиргә башлап аяк баскач, Адәм**
**Җан сөйгәне иткән Һаваны.**
**Өзелеп бер-берсен яратуның,**
**Кешеләргә күчкән дәвамы.**

**Шул мизгелдән алып мәхәббәт тә**
**Илаһи көч булып танылган,**
**Дөнья аңа ихлас табынган.**
**Мәхәббәтнең утлы, орлыклары**
**Шытып чыккан йөрәк канынннан.**

**Саф мәхәббәт хезмәткә дәрт биргән,**
**Батырлыкка сукмак ярган ул.**
**Кешеләрне үлем газабыннан,**
**Упкыннардан тартып алган ул.**

**Ул тылсымлы, җылы кочагында**
**Кемне телгән, кемне назлаган...**
**Сихри көчен татып мәхәббәтнең,**
**Кемнәр генә һуштан язмаган?!**

**Исерткән ул даһи Хәйямнарны,**
**Такташларның җанын тетрәткән!**
**Актарылып таулар елгасыдай,**
**Ташып аккан кайнар күкрәктән.**

**Мәхәббәтнең махсус мәктәбе юк,**
**Анда йөреп белем алмыйлар.**
**Аның серен укыйлар күз аша,**
**Аның телен сүзсез аңлыйлар.**

**Йөрәк түре — гыйшык кыясы,**
**Йөрәк уты — гыйшык кояшы.**
**Күктә түгел,**
**Янар күкрәкләрдә**
**Гыйшык кояшының кыйбласы.**

Ян, йөрәк, ян, төн карасын телеп,
Күктәге Зур Җиде Шәм кебек!
Җидегәннәр сипкән ямь кебек,
Син, Мәхәббәт, җирдә мәңгелек!

## Исә җилләр

Исә җилләр...
Җәен җилләр — газиз әниләрдәй:
Йомшак куллы, кайнар сулышлы...
Җир өстенә сафлык бөрки алар,
Гөлләр исе, кояш җылысы.

Көзен җилләр — шук малайлар гүя:
Сары чәчле, җирән сипкелле...
Җилә алар, тау-тау икмәк төяп,
Бәйгедәге атлар шикелле.

Кышын җилләр — курайчы карт кебек:
Моңы белән таңны уята...
Аннан алар энҗе сибеп йөри
Көзгедәй ак юллар буйлата.

Язын җилләр — шәфкать кызларыдай:
Ләйсән белән юып кулларын,
Назлый алар яшел хәтфәлектә
Баш калкыткан иген кырларын.
Исә җилләр...

## Тормыш

Сине, тормыш, ихлас ярратканга,
Имин чыктым уттан-судан мин.
Күпме какма, ничек типкәләмә,
Тайпылмадым туры юлдан мин.

Куырса да битне язмыш җиле,
Таласа да җанны комсызлар,
Түшем белән шуып үргә мендем,
Яктырттылар юлны йолдызлар.

Дулкын аша кичтем, упкын аша,
Тигәнәкләр телде теземне...
Йөз чытмадым ләкин!
Дөньяда мин
Бик бәхетле сизәм үземне.

Сине, тормыш, ихлас яратканга,
Исән калдым кырык үлемнән.
Күкрәк көчем белән юл ярганга,
Елар чакта җырлап юанганга —
Урын бирдең миңа түреңнән!

## Мин Шабайның тууына 100 ел

Танылган хикәяче Мин Шабай (Мин Гариф улы Шабаев) 1913 елның 28 апрелендә хәзерге Башкортстанның Кушнаренко районы Каратәкә авылында туа. Сабый чагында ук әтисез калып, алты яшеннән үз көнен үзе күрә башлый, аннары бәхет эзләп ил гизәргә чыгып китә. 1931 елда юлдан язу дәрәҗәсенә җиткән малайны чекистлар тотып Мәскәү янындагы 1 нче номерлы хезмәт колониясенә урнаштыралар. Унҗиде яшьлек егет өчен яңа тормыш башлана. Колониядә ул хезмәт тәрбиясен уза, укып белем ала, шунда матур әдәбият белән якыннан таныша. Бераздан аның үзендә дә иҗат дәрте уяна: еллар буе күнелендә җыелып килгән тәэсирләр нигезендә ул «Таныл» (елга исеме) дигән озын хикәясен яза. 1934 елны әсәр матбугатта басылып та чыга.

Колониядән соң Мин Шабай армиядә хезмәт итә, Казан дәүләт педагогика институтында укый, аннары газета редакциясендә һәм Татарстан радиокомитетында эшли. Бу елларда көндәлек матбугатта аның бер-бер артлы хикәяләре, документаль очерклары басыла, колхоз-совхоз театрларында пьесалары куела. 1941 елны Казанда язучының лирик хикәяләре тупланган «Уйналмаган скрипка» исемле китабы дөнья күрә.

1942 елның 21 ноябрендә М.Шабай янәдән чекистлар кулына эләгә. Монысында инде аны сәяси тоткын сыйфатында, милләтчелектә гаепләп, 1944 елның 8 мартында узган суд утырышы җиде елга ирегеннән мәхрүм итеп хөкем карары чыгара. Ул Колымага шахтада эшләргә җибәрелә.

1941-1954 елларда Мин Шабай Себер якларында һәм Себернең төньяк өлкәләрендә яши. Казанга ул 1955 елда кайта һәм яңадан әдәби иҗат эшенә керешә. 1959-1964 еллар арасында язучының «Бездә ел буе яз» исемле очерклар китабы, «Тормыш баскычлары», «Тормыш чакыра» исемле хикәя җыентыклары һәм «Уяну» (беренче кисәк) исемле тарихи-социаль романы басылып чыга.

Мин Шабайның хикәяләре, нигездә, авыл темасына багышланган. Аларда революциягә кадәрге, революция чоры, колхозлашу еллары һәм Ватан сугышыннан соңгы татар авылы тормышындагы социаль күренешләр һәм үзгәрешләр, шуларның гади хезмәт кешеләре күнелендәге чагылышлары тасвирлана.

Гомеренең соңгы елларында язучы «Уяну» романының дәвамын яза, ләкин аны тәмамлый алмый. 1963 елның 5 сентябрендә ул вафат була.

## Афәтләр кабатлана

**Ике мең дә унбер елда**
**Иделдән килде хәбәр:**
**«Булгария»[1] батты суда,**
**Җитмичә портка кадәр.**

**Ул теплоходны затонда[2]**
**Күрдем быелгы җәйдә,**
**Судан калкып, әмер көтеп**
**Килеп туктаган хәлдә.**

**Искә төште: «Чичерин»[1] да**
**Баткан иде элгәре.**
**Ул замана һәлакәтен**
**Күп кешеләр белмәде:**

**...Караңгы төн. Җәй уртасы.**
**Унике булган вакыт.**
**Үзйөрешле баржа белән**
**Бәрелешкән теплоход.**

**Үлүчеләр аз түгелдер,**
**Кем йөзгән, кем йөзмәгән.**
**Каютада йоклаучылар,**
**Бәлки, берни сизмәгән.**

**Бу дөньяда беркем белми**
**Алда ни күрәчәген.**
**«Чичерин» да шул затонда**
**Көтте үз киләчәген.**

**Ике теплоход хәтердә,**
**Икәве күз алдымда.**
**Күңелемә шомлы уйлар**
**Килә шундый чагында.**

**Комсызлар арткан заманда**
**Афәтләр кабатлана.**
**И, Ходаем, колларыңны**
**Шулардан сакласана?!**

**Нурислам АЙБУЛАТОВ**
*Чиләбе өлкәсе, Чибәркүл шәһәре.*

[1] «Булгария», «Чичерин» - теплоход исемнәре.
[2] Затон - теплоходлар ремонтлый торган урын.

### Өч борынга – бер һәйкәл

Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң татар матбугаты яңа сулыш алып яши башлый. Иң әүвәл татар һәм рус телләрендә яшьләр өчен мөстәкыйль гәзитләр дөнья күрде. Аннары «Чаян», «Азат хатын», «Татарстан коммунисты», «Пионер» журналлары кабат чыгарыла башлады. Яшьләрнең зур активлыгы белән «Үсү юлы» альманахы даими чыгучы «Идел» журналына әйләнде. Инде Бауман урамындагы мәшһүр Матбугат йорты кулмәгенә сыешу кыенлашты. Тагын бер матбугат комбинаты торгызу зарурлыгы туды. Югары житәкчелек тарафыннан төзелеш өчен безгә өч урын тәкъдим ителде! Беренчесе — Дзерженский урамындагы, Тукай телендә «Микитин циркы» дип йөртелгән иске цирк урыны, икенчесе — Кабан күле буендагы бушлык, бүгенге «Татэнерго» бинасы тирәләре күрсәтелде. Өченчесе Кәҗә бистәсенең басу капкасы, дөресрәге, сары чәчәкле болын башы. Сазлыктагы кыйшайган, ярым җимерелгән йортларны күчергәндә, менә дигән тигез урын үзе.

— Гумеров, чакыр Долговны, урын сайларга киттек, — ди Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Ш.Хамматов, идарә сәркатибенә.

Долгов Михаил Филиппович — элеккеге Татарстан радиотапшырулар комитеты рәисе, күптән түгел генә гәзит-журналлар нәшрияты директоры булып эшли башлады. Зәй керәшене. Житәкче урыннарда эшләгән, югары әхлаклы. Сүзен үлчәп кенә сөйли. Бераз куркаграк та. Инде түбәнгә таба тәгәрәү полосасына кергән. Шунадырмы, Хамматов аны еш кына «редакция завхозы» дип атый. Үзенең гел биеклектә каласы килгәндер бәлкем.

Урын мәсьәләсендә Кәҗә бистәсенә тукталдык. Әйткәнемчә — иркенлек.

— Бу йортларны нишләтербез икән? — дип, шикләнә калды Долгов.

— Тунаков бер ай эчендә күчереп бетерә аларны, — ди Шәмси Хәбибуллович, Казан шәһәр башкарма комитетына ишарәләп, һәм сүзен кистереп әйтә:

— Без синең белән, иптәш Гумеров, бу төштә Долговка ундүрт катлы һәйкәл куячакбыз!..

Ирония — ирония дә бит, өч ел эчендә заводтай цехлары белән ундүрт катлы хәзерге «Идел-Пресс» ягъни «Татмедиа» йорты сафка бастырылды.

Ә «һәйкәл» кемгә? Өчебезгә тигез бүленергә тиеш ул! Арадан үземне сызып калдыра алмыйм бит инде. Заман түрәсе булып йөргән чаклары бар иде абзагызның...

### Марҗа чире

Безнең татарда марҗа сөю гадәте элегрәк тә булган. Бигрәк тә Үктәбер түнтәрешеннән соң. Андыйлар «өлкән брат» арасында житәкче урыннарга тизрәк үрмәләгәннәр. Карт гвардия журналистлары командасында шундый «бәхеткә өметләнүчеләр» берничә кеше иде. Әмма алар, ни сәбәптәндер, безгә мөдирлек итүдән ары китә алмадылар. Гаепләмим, заманына күрә укымышлы, зыялы затлар иде үзләре. Тәкъдирләрендәге җепләр бәйләгәндер аларны чит милләт вәкилләре белән.

Югыйсә, Дөбъяз төбәгендәге кечерәк кенә бер татар авылында туып-үскән Барый Корбанов, «бернинди арттан этүчесез», Мәскәүгә тиклем барып чыккан, журналистика мәктәбен тәмамлап, үз тырышлыгы белән һөнәри үсеш юлына баскан. Аңа «этүче» кирәк тә түгел кебек. Урысчасы да хәйран

гына шомарган егетне 1936 елда «Кызыл Татарстан» газите редакциясенә бик теләп эшкә алалар. Аннары бүлек мөдире була. Бөек Ватан сугышы елларында татар телендәге хәрби газитнең редакторы, яу кырының алгы сызыгында йөри. Фронттан исән-имин күкрәк тулы орден-медальләр белән кайта.

Утны-суны кичкән журналистны «Кызыл Татарстан» газитендә төзелеш сәнәгате бүлеге мөдире итеп билгелиләр. Ә инде республикада нефть тармагы үсеш алгач, Барый Шәһивәли улына редакциянең «Кара алтын» бүлеген житәкләү бурычын йөкләделәр. Өлкән журналистның бу чордагы хезмәтләрен үз күзләрем белән күреп тордым. Әлмәттән Балкан илләренә тиклем сузылган «Дуслык» нефть үткәргечен жәяүләп узды, аннан күләмле мәкаләләр, үткен каләм белән язылган очерклар жибәреп торды.

Барый Корбан (редакциядә бер-беребезгә «ов», «ин»нәрсез генә эндәшә идек) кайчан гашыйк булып, ничек өйләнгәндер — анысы мина кадәрге гамәлләре, һәрхәлдә нинди дер «расчет» белән түгелдер, дип беләм. Әмма хатыны чип-чи маржа иде. Нишләп «чип-чи»ме? Инде пенсиягә чыгып, профсоюз кушуы буенча картның хәлен белешергә баргач, тозлы кыяр, кәбестә эштие яратучы карчыгы зарланып: «Нашему Борю (чак кына «бүрегә» әйләнмәгән) лапша да лапша давай», — ди торган иде. Тегесе татар токмачын хуп күргәндер, күрәсең. Минем уйлавымча, Барый ага һич тә «арттан этүгә» өметләнеп өйләнмәгәндер.

Заман чире булырга мөмкин...

## Архангель татары

Вакытлар үтү белән кемнең кемлеген ник онытабыз икән соң без?! Ул да бит кайчандыр мәгълүм татар журналисты иде. Урысча әйтсәк, очеркист һәм үткен телле фельетонист (ни кызганыч, соңгы елларда бу жанр әдәбиятыбыздан бөтенләй диярлек төшеп калды). Мин бу кадәресен бер редакциядә эшләгән хезмәттәше буларак таныйм. Шуның өстенә ул язучы да иде, төгәлрәге — драматург. Шәхсән үзем аның сәхнәләрдә куелган яки аерым китап жыентыкларына кертелгән берничә әсәрен беләм. 1950 елда ук язылган «Вәгъдә» пьесасы озак еллар Татарстан Республика күчмә театры репертуарыннан төшмәде. Әлмәт, Минзәлә халык театрларында «Өермәләр», «Алтын башак», «Күңелсез мәхәббәт» исемле комедияләре уңыш белән барды. Искәргәнсез, сүз драматург Габдулла Вәлиев хакында. «Совет Татарстаны» газитенең Әлмәт зонасында үзхәбәрче булып эшләгән Габдулла агай (1904 елда туган) алагаем гәүдәле, яхшы мәгънәсендә дәһшәтле (ташып торган энергияле, дию ем) кеше иде. Чигә читенә чөелгән калын кара кашлары, кысыграк күзләренең жетелеге аңа олпатлык өсти, үзен-үзе тотышы белән ук гаярь зат ул. Урысчасы да мөкәммәл. Анысының үз сәбәбе бар. Әти-әнисеннән бик иртә ятим калган малай Төньяк боз океанына терәлгән Архангель каласындагы балалар йортында тәрбияләнә. Ютазы районында туган татар баласы үзенең ана телен онытмаган, әдәби әсәрләр язарлык дәрәжәдә саклаган. Вакытлы матбугат битләрендә 350ләп очерк, шуның өстенә берничә дистә фельетон (барысы да әдәби әсәр югарылыгында) язып бастыру өчен, ай-һай, күпме юл йөрергә, кемнәр белән генә очрашырга, никадәр ижади көч сарыф итәргә туры килгәндер аңа! Ә пьесалары — йокысыз төннәр жимеше. Журналист-язучылар икеләтә хөрмәткә лаек, минемчә. Андыйларны онытырга хакыбыз юк.

Яд итик без Архангель татарын!..

## Яза–яза китте

Шигырь язган кеше нишли? Башта гашыйк була. Шуның белән тилереп йөри. Бәгъзеләре дөнья гизә. Ахырдан барыбер газит-журнал ишеген ачып керә.

Төзүче Сафуан Муллагалиев (тәхәллүс алгач, Сафуан Мулла Гали) дигән берәүсе редакция ишеген 52 яше тулып узгач кына шакыды. Шигырь

белән тилергән өлкән яшьтәге абзый шактый сәер тоелды. Әңгәмәдәшенең күзләренә тилмереп карап, гүя, мине бер тыңлап кара әле, ди төсле. Колакка бераз саңгырау булгангамы тәмам иелә төшеп сөйләшә. Култыгында шигырь тулы дәфтәрләре. Мондый кисәк кенә пәйда булган инсан, әлбәттә инде, үзе белән таныштырудан башлый.

Кунагыбыз Ырынбур өлкәсенең Абдуллин районы, Чаганлы авылында 1927 елда туган. Сугыш бетәргә бер ел кала үсмер егетне Армия сафларына алалар, укырга авиация мәктәбенә тәгаенлиләр. Шунда аякларына салкын тидереп, озак вакытлар госпитальдә дәвалана. Әмма күккә күтәрелергә насыйп булмый аңа. Бераз савыккач, Урта Азия якларына китеп, төзүчебизәүче һөнәрен үзләштерә. Теге «тилерү» дигәне аны Казанга Үзбәкстанның Маргилан шәһәреннән китереп ташлый. Дүрт бүлмәле фатирын, вакытлыча дүрт балалы гаиләсен калдырып. Бары тик шагыйрь исемен алу өчен. Ә фатиханы Сафуанга атаклы шагыйрь Сибгат Хәким үзе бирә.

Язды да язды маргиланчы шигырьләрен. Алар әкренләп редакция коридорыннан, дәфтәр битләреннән гәзит-журнал сәхифәләренә күчте. Маргиланнан гаиләсен алып килгәч, Татарстан китап нәшриятында бербер артлы «Сәлам бирәм», «Көзге балкыш» (яшенә карата ишарә кебек), «Мәңгелек йөрәк», «Ераклардан киләм» дигән шигырь җыентыклары, «Биздерсәләр туган җиреңнән» исемле шигырь белән язылган күләмле автобиографик бәяны дөнья күрде.

Чын шагыйрь булып китте Сафуан Мулла Гали фани дөньядан...

## Каберсез мәет

Алай булырга тиеш түгел иде кебек...

Арча төбәгенең Казанбаш авылында, татар гаиләсендә туган кешенең, яше житмештән узгач, рухи-дини адашуы минем башыма сыймый. Фикерләремне үзенә житкерергә омтылып карасам да барып чыкмады. Фәйләсүф-язучының фани дөньядан бакыйлыкка күчкәндә карашлары ныгып урнашкан иде шул инде. Нинди кара көчләр саташтыргандыр аны — белмим.

Язучы Диас Вәлиев белән бер чорда, ул — «Комсомолец Татарии», без фәкыйрегез, «Татарстан яшьләре» гәзитендә, Матбугат йортының бер үк катында эшләдек. Моңа чаклы инде Диас Киров, Пермь якларында, Урал-Себер киңлекләрендә, Хабаровск крае һәм Казакъстанның Тимертау тарафларын, геолог буларак, айкап чыккан була. Үз эшенең тәҗрибәле белгече санала. Башта ул безне ни өчен журналистикага килеп керүе белән гаҗәпләндерде. Аннары шул ук елны (1971) Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театры сәхнәсендә барган «Намус хөкеме» (урысчасы «Суд совести») спектакле белән шаккатырды. Шуннан китте инде язучының иҗади эшчәнлеге. Аның Кама автогигантын төзүчеләргә багышланган пьесасы аеруча яңгыраш тапты — ни әйтсәң дә, көн темасы иде. Д.Вәлиев әсәрләре теге заман сәхнәсенә үзенчәлекле яңалык алып килде. Үзәк матбугат шау килеп алды, автор иҗатына зур бәя бирде. Милли драматургия буенча (тулаем урыс телендә язса да) уздырылган бәйгеләрдә Д.Вәлиев өч мәртәбә лауреат исемен яулады. 1976 елда куелган «Дәвам» пьесасы өчен Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге бүләгенә лаек булды. Аннары аңа Татарстанның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәр бирелде. Язучы данга күмелде.

Шуннан соң нәрсә булды дисезме? Адашты бичаракай. Үз хәлен үзе белеп торгандыр бәлки. Төп йортка күчәр алдыннан васыятен әйтеп калдыра. Диас Вәлиевнең мәетен, индуслар традициясе буенча, крематорийдә яндырып, көлен Казансу елгасы өстенә сиптеләр.

Каберсез мәет тә була икән, әкәмәт!..

### Шымчы

Болай дип әйтү бик үк дөреслеккә туры килми анысы, «разведчик» сүзенең татарча асыл мәгънәсе булмаганга гына искәртүем. Ә чынлыкта шагыйрь кайсыдыр илдә хәрби разведчик-шымчы вазифасын үтәгән. Отставкага, тагын татарчалап жиффәрсәк, хәрби хезмәтеннән лаеклы ялга чыгарылгач, ул бу сүзне бөтенләй «оныта». Шуна күрә, без, язучы халкы, Кави Латыйповның кемлеген белми яшәдек.

Берчак серне миңа гына тиште.

Чыкылдап торган мишәр малае, әлегә тәхәллүссез Кави Латыйпов 1927 елда, Чуашстанның Батыр районы, Кызыл Чишмә (гаҗәп: нигә кызыл?) авылында туган. Җидееллык мәктәптән соң, ул район үзәгендәге педагогия көллиятендә (училище) укый. Татар теле укытучылары сугышка китеп беткәнлектән, дәресләр тулаем чуаш телендә алып барыла. Кави күрше милләтнең әдәби телен бик яхшы үзләштерә. Берара Сеспель, Константин Иванов, гомумән, чуаш әдипләре иҗаты белән мавыга, аларның иң яхшы әсәрләрен татарчага тәржемә итеп бастыра. Безнекеләрне күршеләргә тәкъдим итә. Әйбәт эш башкарды.

Тәржемә кыла торсын әле, без Кави Латыйповның яшьлегенә карап багыйк. Көллияттән соң, ул бер ел Татар Тимәше авылы җидееллык мәктәбендә балалар укыта. Ватан сугышының иң авыр чагында, 1944 елда, яшь укытучыны фронтның алгы сызыгына озаталар. Ачысын-төчесен күп татый. 1946 елда белемле егетне хәрби-сәяси училищега укырга җибәрәләр. Югарыда әйтелгән «шымчылык» тормышы әнә шул чакта башлана инде.

Күнелле кичәдә серне тиште тишүен, кайсы илләрдә йөрүен барыбер әйтмәде. Хәрби хезмәттән лаеклы ялга (отставкага) киткәч, К.Латыйпов, инде мин белгәндә, комсомолның өлкә комитетында инструктор булып эшләде. Берара Казан телестудиясендә әдәби хезмәткәр вазифаларын башкарды. Гәзит-журнал битләрендә шигырьләре күренгәләде. Хәрби кеше бит, ышанычлы, без аны (Татарстан журналистлар берлеге идарәсен күздә тотам) ябык типтагы Дары заводының күптиражлы «Ленинчы» гәзитенә редактор итеп тәкъдим иттек. Әйбәт кенә эшләде, шигырь, кыска күләмле бәяннары шунда басылды.

Теге «серне тишкән» көн узган гасырның алтмышынчы елларында булды. «Ленинчы» гәзитенең зур гына юбилее иде. Татарстан журналистлар берлеге исеменнән (фәкыйрегез идарә сәркатибе) редакция коллективын, шәхсән, җаваплы редактор Кави Латыйповның үзен дә котларга дип, Мактау кәгазьләрен күтәреп, Дары бистәсенә киттем. Тантана Татарстанның X еллыгы исемендәге Мәдәният сараенда (мәһабәт бинаны саклый алмый яндырдылар) үткәрелде. Чөнки, кемнең кем булуына карамастан, чит-ят кешеләргә завод биләмәсенә керү каттый тыелган. Завод үзе «номерлап» кына йөртелә. Продукциягә кагылышлы мәгълүматны ычкындыру юк та юк. Хәтта, күз буяу өчен чыгарыла торган тормыш кирәк-яраклары: алюмин кашык, пычаклар, әйтик, балалар шугалаклары, тимераяклар хакында да телгә алынмады. Ябык булгач, ябык инде!

Тантана гәзит әһелләренең намуслы хезмәте, хәрби серне саклый белүләре хакында гына барды. Табыннары мулдан: сыйланып, яңа чыккан кинофильмнар, театр яңалыклары, гомумән, әдәбият-сәнгать турында гәпләшеп утырдык. Мәдәният сараеның бөтен шәһәребезгә танылган үз сәнгать коллективлары, халык театры (җитәкчесе Касыйм Мөхәммәтҗанов) бар иде. Зур концерт булды. Ахырдан «аяк ялын юарга» дип, тагын редактор бүлмәсенә кердек. Кави Латыйп, миңа антлар эчертеп, үзенең элеккеге разведчик-шымчы икәнлеген тиште. Ант эчкән бит, авызымны бикләдем дә куйдым. Ачып кара!?.

Хәзер ярый инде бикне ачарга да. Бер картның кемгә кирәге бар?!.

**Госман ГОМӘР**

## *«Казан утлары» архивыннан*



*Юрий Гагарин Татарстанда яшьләрнең халыкара «Идел» лагеренда. 1967 ел.*



*Бөек биюче Рудольф Нуриев (1938 — 1993). 1992 елны Казанга килгәч алынган рәсем.*



*Мәскәүдә яшәп иҗат итүче шагыйрь, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Әхмәт Саттар.*



*Әдип Айдар Хәлим һәм җырчы Усман Әлмиев. Мәшһүр артистның соңгы рәсемнәренең берсе. 2009 ел.*



*Шагыйрь Илдар Юзеев Мамадыш районында. Аның белән янәшә Фарис Галиев, Рафаил Газизов. 2003 ел.*



*Композитор Әнвәр Бакиров хатыны Фирдәүсә ханым белән. 1997 ел.*

## ТУКАЙ БҮЛӘГЕНӘ КАНДИДАТЛАР

Г.Тукай исемендәге Дәүләт премияләре буенча Татарстан Президенты карамагындагы комиссия 2013 ел өчен Г.Тукай исемендәге премиягә кандидатлар исемлеген игълан итте. Алар сигез кеше: рәссам Ильяс Айдаров, язучы Нәбирә Гыйматдинова, шагыйрә, язучы Клара Булатова, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты Алсу Гайнуллина, рәссам, декоратив-гамәли сәнгать остасы Софья Кузьминых, Татарстанның халык артисты, җырчы Гөлзадә Сафиуллина, композитор Шамил Тимербулатов, шагыйрә, сәнгать белгече Розалина Шәһиева. Премия ияләре традиция буенча апрель аенда Габдулла Тукайның туган көнендә билгеле булачак.

## УНИВЕРСИАДА АЛДЫННАН

***

Казанда Универсиада музее барлыкка киләчәк

Ул XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиадасы алдыннан төзелгән Халыкара мәгълүмат үзәге бинасында урнашачак. Музейның беренче күргәзмәсе 100 кв м лы мәйданны биләячәк.

Музей спортчыларга Универсиада авылы ишекләре ачылачак көндә — 29 июньдә эшли башлар дип көтелә. Күргәзмәдә студентлар уеннары тарихы, аның җиңүчеләре, Казанда ана әзерлек ничек барганлыгы турындагы мәгълүматлар белән таныштырачаклар. Экспозиция стендларының берсе 1923 елда Парижда узган уеннарга багышланачак.

Хәзерге вакытта музей экспонатлары җыела. Аның кайберләре, әйтик, узган уеннарның медальләре, талисманнары, китаплар башкалага кайтарылган да инде.

Универсиада тәмамланганнан сон, музей ФИСУ Халыкара мәгариф үзәгенең бер өлеше булачак һәм өстәмә белем бирү мәйданчыгы булып торачак. Анда спортчылар белән очрашулар, Универсиадада катнашучыларның мастер-класслары оештырылыр дип уйланыла.

***

6-17 июльдә Казанда узачак Бөтендөнья җәйге Универсиадада 170 илдән 13,5 мең спортчы һәм рәсми делегат катнашачак. Моннан тыш, башкалабызга 100 мең кунак һәм җанатар килүе көздә тотыла. 27 спорт төре буенча ярышлар уздыру планлаштырылган. Уеннар вакытында 2 мең табиб (аларның 550се — Универсиада авылында һәм ярышлар узачак мәйданнарда) «дежур» торачак. Универсиада вакытында кунакларга 8 «су кунакханәсе» (барлык уңайлыклары булган зур теплоходлар) хезмәт күрсәтәчәк.

***

Универсиада вакытында Казанда әлеге ярышларга багышланган махсус газета чыгачак. Әлеге проектны «Казан-2013» Универсиада дирекциясе «Татмедиа» агентлыгы белән берлектә тормышка ашыра. Газета һәр көнне 40 мең тираж белән татар, рус һәм инглиз телләрендә чыгар дип уйланыла. Газета спорт уеннарын гына түгел, ә, гомумән, Универсиада чорындагы Казан тормышын да яктыртачак. Анда спортчылар тормышы, Универсиада яңалыклары, төрле мәдәни чаралар да чагылыш табачак.

***

Казанның яңа футбол стадионын медиаэкран бизәячәк. Стадионның Чистай урамына караган ягына 4,2 мең квадрат метр зурлыгындагы экран куелачак, ул дөньядагы иң зур экраннарның берсе булачак.

## ҖӘЛИЛ БЕЗНЕҢ ГОРУРЛЫГЫБЫЗ

***

Казанда Муса Җәлилнең тууына 107 ел тулуны билгеләп үттеләр. Чарада Татарстанның халык шагыйрьләре Ренат Харис, Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллин, Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбан һ.б. танылган мәдәният һәм фән әһелләре катнашты.

Каһарман-шагыйрьне искә алу Муса Җәлилнең 1 Май мәйданындагы һәйкәленә чәчәкләр салудан башланды. Соңрак Татарстан Милли музеенда шагыйрьнең «Моабит дәфтәрләре» тантаналы рәвештә күргәзмәгә куелды. Быел бу йоланы башкару «Хәтер китабы»ның баш мөхәррире, тарих фәннәре докторы Анатолий Ивановка тәгаенләнгән иде. «Моабит дәфтәрләре» Милли музейга 1966 елда тапшырылган була. Шулай ук Милли музейда «Батырлык елларда калачак» дип исемләнгән шигырь укучылар бәйгесе җиңүчеләрен тәбрикләделәр. Соңыннан шагыйрьнең музей-фатирында «Җырларым» дип аталган әдәби-музыкаль кичә булды.

***

19 февраль көнне Мәскәүдә геройшагыйрь Муса Җәлил һәйкәленә чәчәкләр салу тантанасы булды. Чара Татарстанның РФдәге Вәкаләтле вәкиллеге каршында оештырылган Офицерлар клубының чираттагы утырышы кысаларында уздырылды. Офицерлар очрашуы Ватанны саклаучылар көне алдыннан, Муса Җәлилнең тууына 107 ел тулуына багышлап үткәрелде.

Тантанада ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Мәскәү шәһәр Думасы Рәисе Владимир Платонов, Муса Җәлилнең кызы Чулпан Җәлилова һәм башка рәсми кешеләр булды.

Муса Җәлил һәйкәленә чәчәкләр салу тантанасыннан соң «Милан» кунакханәсенең матбугат залында Офицерлар клубы утырышы булып узды. Аның эшендә Фәрит Мөхәммәтшин катнашты.

## ТЕЛЛӘР БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛ

Татарстанда телләр буенча вәкаләтле вәкил институты булдырырга ниятлиләр. Ул «2014-2023 елларга ТР дәүләт телләрен һәм Татарстандагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча ТР дәүләт программасы» кысаларында оештырылыр дип көтелә. Бу дәүләт программасы ТР Фәннәр академиясе җитәкчелегендәге эш төркеме тарафыннан әзерләнә. Программаның проектын эшләү тәгәлләнеп килә. Ул апрельгә кадәр ТР Министрлар Кабинетына кертелергә тиеш. Әлеге идеяне тәкъдим иткән галимнәребезнең нияте изге, чөнки туган телебез яклауга һәм саклауга бик мохтаҗ.

## ТАТАР КЫЗЫ «ЕВРОВИДЕНИЕ»ГӘ БАРА

Россиянең «Беренче канал»ы оештырган «Голос» проекты җиңүчесе Динә Гарипова «Евровидение» бәйгесендә катнашачак. Май аенда узачак әлеге дөньякүләм җыр бәйгесендә татар кызы Россия музыканты Леонид Гуткин белән бергә швед продюсерлары Габриэль Аларес һәм Йоаким Бьорнберг иҗат иткән «WhatIf» («Әгәр») дип аталган инглизчә җырны башкарачак.

## ЮБИЛЕЙЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

***

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Фәнис Яруллинның тууына 75 ел тулуга багышланган «Мин кайтырмын сезгә янадан» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә булып узды. Бу вакыйга унаеннан беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиев шагыйрьнең иҗатын яратучыларга мөрәҗәгать итеп хат юллаган иде. «Татарстанның халык шагыйре Фәнис Яруллин - көчле шәхес. Аның үзенчәлекле, югары кимәлдәге фәлсәфи иҗаты татар әдәбиятында гына түгел, бөтен татар тарихында күркәм сәхифә. Шагыйрь хәзергәчә барыбыз өчен дә тиңгысыз иҗади хезмәт, рух ныклыгы, көчле ихтыяр үрнәге булып тора».

Юбилей кичәсендә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбан, Татарстанның халык депутаты Разил Вәлиев шагыйрь шәхесе һәм иҗаты турында чыгыш ясадылар, шагыйрьләр Газинур Морат, Ленар Шәех, Рүзәл Мөхәммәтшин Ф.Яруллинга багышланган шигырьләрен укыдылар.

Кичәдә зал тутырып килгән тамашачыны шагыйрьнең якташлары исеменнән Баулы муниципаль районы башлыгы Альберт Хәбибуллин, Казандагы Баулы якташлык җәмгыяте рәисе Нурислам Хәбибов һәм Кызылъяр мәктәбе укытучысы Зилә Фәрәхетдинова сәламләде.

***

Язучылар берлегенең Г.Тукай исемендәге клубында Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗевнең тууына 85 ел тулуга багышлап, искә алу кичәсе уздырылды. Анда әдипнең хатыны Нәкыя ханым белән аларның уллары-киленнәре, Аяз Гыйләҗев әсәрләрен төрекчәгә тәрҗемә иткән Фатих Кутлу һәм Г.Камал исемендәге театр артистлары катнашты. Кичәдә күренекле язучылар Рабит Батулла, Тәлгат Галиуллин, Ризван Хәмид, Мөхәммәт Мирза, шулай ук Наил Дунаев, Ринат Таҗетдинов, Хәлим Җәләлов, Фердинанд Сәлахов кебек танылган сәнгать осталары чыгыш ясады. Кичәне Гүзәл Сәгыйтова алып барды.

***

25 февраль көнне Г.Камал исемендәге Татар Дәүләт академия театрында Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеевның

туыына 80 ел тулуга багышланган кичә булды. «Кыр казлары артыннан» дип исемләнгән әлеге әдәби-музыкаль кичәдә шагыйрьнең әсәрләреннән өзекләр, аның сүзләренә язылган җырлар яңгырады, ТР Мәдәният министры урынбасары Гүзәл Нигъмәтуллина, ТР Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбан, шагыйрьләр Рәдиф Гаташ, Роберт Миннуллин, Башкортстанның Янавыл районы делегациясе вәкилләре, Г.Камал һәм К.Тинчурин исемендәге театр артистлары һәм башка сәнгать әһелләре катнашты.

### ӘДИПНЕ ХӨРМӘТЛӘП

Казанның 12нче кызлар гимназиясендә күренекле драматург һәм җәмәгать эшлеклесе Туфан Миннуллин истәлегенә мемориаль такта һәм истәлек залы ачылды.

Билгеле булганча, кызлар өчен татар гимназиясе 2011 елда, республика парламенты депутаты Туфан Миннуллинның тырышлыгы белән, Декабристлар урамындагы яңа бинага күченгән иде.

Тантанада ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев мемориаль тактаны һәм хәтер залын ачып, Туфан Миннуллинның татар әдәбияты һәм театры, белем бирү системасы үсешенә, милли мәктәпләрне саклауга керткән зур өлешен билгеләп үтте. Ул гимназиянең Туфан Миннуллин истәлегенә һәрвакыт тугры калачагына ышаныч белдерде.

Тантанада шулай ук ТР Дәүләт Советы депутатлары Светлана Захарова, Илсур Сафиуллин, Анастасия Исаева, күренекле җырчыбыз Илһам Шакиров, танылган җәмәгать эшлеклесе Фәндәс Сафиуллин һ.б. катнашты.

### ТУКАЙ КЛУБЫНДА КИТАП БӘЙРӘМЕ

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай исемендәге клубында татар дөньясында мәгълүм шәхес, галим һәм дәүләт эшлеклесе, Россия Дәүләт Думасы депутаты Фатих Сибагатуллинның соңгы елларда дөнья күргән, татар тарихына багышланган китапларын («От Аттилы до президента», «Великие татары») тәкъдим итү кичәсе булды. Анда И.Таһиров, Р.Вәлиев, Д.Исхаков, Р.Хәкимов, Р.Корбан, Т.Галиуллин, Г.Рәхим, З.Зәйнуллин, И.Әхмәтҗанов, М.Галиев, Р.Метшин, Ж.Фазлыев кебек галимнәр, язучылар, җәмәгать эшлеклеләре, дин әһелләре катнашты һәм чыгыш ясады. Кичәне шагыйрь Р.Миннуллин алып барды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Апрель.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрь **Фәрит Габдерәхим**.

# Тукайга куелган һәйкәлләр



*Казан*



*Мәскәү*



*Төркия*



*Санкт-Петербург*



*Кырлай*



*Яр Чаллы*



*Казан*



Фәрит Габдерәхим

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)